С(башк)
Г24

Таңчулпан Гарипова

Асыл ташлы муенса

Татарстан
китап
нәшрияты

ЛИСТОК СРОКА ВОЗВРАТА

КНИГА ДОЛЖНА БЫТЬ
ВОЗВРАЩЕНА НЕ ПОЗЖЕ
УКАЗАННОГО ЗДЕСЬ СРОКА

Колич. пред. выдач. ....

KPO

Каләмнәр туганлыгы

С(Баш
Г24

Таңчулпан Гарипова

Асыл ташлы муенса

Роман, повесть, хикәяләр

Казан
Татарстан китап нәшрияты
2015

УДК 821.512.145-31
ББК 84(2Рос=Баш)-44
Г22

НБ РБ
0000212319

«Каләмнәр туганлыгы» сериясе 1994 елда булдырылды.

Илһам Ногманов тәрҗемәсендә

Гарипова, Т. Х.

Г22 Асыл ташлы муенса : роман, повесть, хикәяләр / Таңчулпан Гарипова ; [башкортчадан И. Ногманов тәрж.]. – Казан : Татар. кит. нәшр., 2015. – 320 б. («Каләмнәр туганлыгы» сериясе.)
ISBN 978-5-298-02903-2

Башкортстанның Салават Юлаев исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Таңчулпан Гарипованың китабына төрле елларда язылган роман, повесть һәм хикәяләре тупланды. Әлеге әсәрләрдә фаҗигале, гыйбрәтле кеше язмышлары, кызыклы һәм үзенчәлекле образ-характерлар психологик тирәнлек белән тасвирлана.

УДК 821.512.145-31
ББК 84(2Рос=Баш)-44

771431

ISBN 978-5-298-02903-2

© Татарстан китап нәшрияты, 2015
© Гарипова Т. Х., 2015
© Ногманов И. Г., тәрж., 2015

ГБУ
Национальная библиотека
имени А.-З. Валиди
Республики Башкортостан

МӨГРИ-МӨГРИ КИЛӘ БӨЙРӘКӘЙ

Роман



БЕРЕНЧЕ КИТАП*

Беренче бүлек

Иртәнчәкләй торып, тышка чыксам,
Мөгри-мөгри килә Бөйрәкәй.
Бөйрәкәйне сауган шул кызны уйлап
Өзелә шул минем үзәккәй...

— Аптыраттың әле син, Мәдинә, — Гөлбану әллә төтеннән, әллә моңнан яшьләнгән күзләрен кызына төбәде, — кемнән отып алдың син бу җырны, ә?!

— Әллә тагын... — Кыска гына күлмәк кигән какча гәүдәле кыз урыныннан сикереп торды, нәзек кенә беләкләрен, беләкләре кебек үк нечкә аякларын тирәякка болгап, күнегүләр ясый башлады: — Бер, ике, өч!

— Ипләп, энеләреңне уятырсың! Ай, ата Габидә!..

«Ата Габидә» димәслек тә түгел иде Мәдинәне шушы минутта: нәкъ малайлар кебек. Менә кызларга гына хас шаянлык белән очкынланган шомырттай күзләре һәм яңа туган айдай сызылып киткән кашлары булмаса, кем ышаныр иде икән аның кыз бала булуына?

Гөлбану мич буена чүгәләгән җиреннән торгач та кызына һаман текәлеп каравында булды: тал чыбыгыдай нечкә үзе, эчендә җаны ничек тора, ә тавышы, моңы... Шушындый моңның гап-гади бер баладан чыгуына ышанырлык та түгел.

Гөлбану үзалдына тирән көрсенде дә чөйдәге кыска тунына үрелде:

— Фермага китәм инде мин, балам. Күмер төшкәч, казандагы суны самавырга салырсың. Кайнап чыкса, басып куй — мин озакламам. — Әнисенең соңгы сүзләре

---

* Пенталогиянең беренче китабы. Әлеге романы өчен автор Башкортстанның Салават Юлаев исемендәге Дәүләт премиясенә лаек була.

инде чоланга чыккач ишетелде: — Абзарны карап тор — сыерның суы киткән бүген! Энеләреңне күзеңнән югалтма — самавырга пешмәсеннәр!

Мәдинә исә, әнисе әйтмәсә дә, сыер янына чыгарга гына тора: бозау дөньяга киләчәк бүген! Мәдинә аңа Бөйрәкәй дип исем кушачак. Әлеге җырын да бит ул шуңа җырлады.

* * *

Иңбашына бишмәт салган, аягына әнисенең тирән галошын кигән Мәдинә абзар ишеге төбенә җиткәч куркыбрак калды. Эчтә өзек-өзек мышнап тын алган тавышны ишеткәч, тагы да ныграк каушады.

— Билдәш! — Үз исемен ишетү белән гадәттә мөгрәп куя торган сыер бу юлы эндәшмәде. — Билдәш, сиңа әйтәм! — Мәдинә, әллә салкыннан, әллә дулкынланудан тыңлаусызга әйләнгән бармакларын көчкә кыймылдатып, ишекнең бавын чиште, сак кына басып, түргә, сыер яткан якка узды. — Билдәшкәй...

Билдәш янә тавыш бирмәде. Мәдинәнең, әлбәттә, сыер бозаулаганын күргәне бар, тик анда, фермада, әнисе, башка өлкән кешеләр була. Өйдән чыкканда бозаулап яткан сыерны күреп, болай каушармын, куркырмын дип уйламаган иде ул. Мәдинә сыер тизәге белән сыланган, хәзер инде төрле-төрле җирдән кубып төшә башлаган читән абзарның ярыгы аша эчкә карады. Аның күзләре туптуры сыер күзләре белән очрашты. Йа Рабби... Хайван күзләренә чыккан өнсез газап менә-менә шартлар да гүя күзе белән бергә атылып чыгар төсле. Йа Ходай, ярдәм итә күр Билдәшкә! Мәдинә йөрәге дерт-дерт типкән килеш эчкә үтте һәм Билдәш янына чүгәләде:

— Тәңрем... Аллам... Ходаем!.. — Билдәшнең хәлен җиңеләйтә торган догалар булса, шушы минутта Мәдинә аларның меңен берьюлы кабатлар иде. — Әни, әнкәем... Әни! — Ул хәзер фермага йөгерер иде, Билдәшне бу хәлдә ничек ташлап китсен?!

Өстенә каплаган бишмәте күптән инде шуып төшеп күлмәкчән калган кызыкай, кинәт бер катгый карарга килгәндәй, гәүдәсен турайтты, аннан ашыкмый гына, әнисенә охшатырга тырышып, әкрен басып, сыер янына килде дә тулгак газабында тартышкан җан иясенең арт санына кулын салды. — Билдәш, җаным, әйдә инде, тырыш!

Печән җитмәүдән күтәрәмгә калган сыер авыр бозаулады. Мәдинә терсәгенә тиклем канга буялып, сыерга бозауларга булышты. Бозауның арткы тояклары карыннан аерылганда, Мәдинә, үзе дә хәлсезләнеп, аркасы белән туң җиргә чалкан төште. Сыер урыныннан торырга маташып карады, ләкин көче җитмәде, кире ятты, аннан, мөгрәп, бозавын күрергә теләп, башын артка борды.

— Хәзер, сабыр ит... — Мәдинә канлы-сүлле юеш җан иясен ничек итсә итте, әнисе алдына салды. — Әниең ул синең, бозаукай, әниең...

Билдәш ач хайван комсызлыгы белән бозавын ялаган арада, бер кочак печән күтәреп, Мәдинә өйгә керде дә сүрелгән учакның җылысы төшкән урынга шул печәнне түшәде.

— Апай... — Уянып, мыгырданырга уйлап яткан энеләренә боерулы тавыш белән:

— Тынычызны чыгармагыз! — диде дә тагы тышка атылды. Хәзер үк өйгә кертмәсә, бозау бит өшер, туңып бетәр. Мәдинә үзенең җилкәсеннән шуып төшеп калган бишмәтен табып бозауны салды да, баласы артыннан кузгалырга маташкан Билдәшнең йөрәкне әрнетеп мөгрәвенә карамый, теше-тырнагы белән көчәнеп, бозау яткан бишмәтне өйгә таба өстерәде...

* * *

Кич булды. Мәдинә, дәреслекләрен алып, учакта янган утка якын килеп утырды. Гөлбану мич алдында, бүкән өстенә тас куеп, көл суында Мәдинәнең, үзенең керләрен юа. Ут аның озынчарак нәфис яңакларын, куе керфекләре арасыннан томрап торган күзләрен яктырта. Матур шул Мәдинәнең әнисе, яшь.

— Әни, хәзер сиңа ничә яшь ул?

Гөлбану авыз чите белән генә көлемсерәде:

— Әниеңнең яше нигә кирәк булды, кызым?

— Болай гына, — Мәдинә, җылыда изрәп йоклаган бозауны уятудан куркып, шыпыртын гына сөйләүгә күчте, — мин туганда сиңа уналты гына яшь булганмы ул, әни?

— Шулай гына иде шул, балам.

— Уй! — Мәдинә кинәт тетрәнеп, күзләрен йомды. — Ә мин, әни, кияүгә бер дә чыкмаячакмын!

— Һы... Кызык икән...

— Әни, әтием... Ул кайтса... — Мәдинә кинәт үз уеннан үзе оялгандай тотлыкты.

— Нәрсә... әтиең?

— Болай гына... Ул кайтса, сиңа кыен булмас иде дигән идем...

— Сиңа түгел, безгә диген...

— Бозаукаебыз матур, әйе бит, әни? — Мәдинә әтисе турындагы сүзне тиз генә икенчегә борырга тырышты. Әнисеннән ул бөтенләй икенче нәрсә: «Нигә син Урыс Һашимга кияүгә чыктың?» — дип сорамакчы иде.

* * *

Читкә какканын хәтерләми Мәдинә әтисенең. Эчүен эчте. Әле ул чакта, сугышка тиклем, авылда салгалаган ирләр булса да, Һашим кебек котырганчы эчеп йөргәннәре юк иде. Базаргамы, он тарттырырга барсынмы — Һашимның аек кайтканы булмады. Шуңа күрә дә авылдашлары ике Һашимның берсенә «Урыс» кушаматы такты. Икенче Һашимга тигән кушамат та шәплеккә шәп түгел: У...к Һашим.

Ләкин Мәдинә дә эти булган кешесенә Урыс Һашим диюләренә гарьләнә. Бу исем аның әтисен ничектер ят итеп күрсәтә сыман. Әтиләренә шундый исем таккач, балаларына ни димәсләр? Мәдинә башта оялды, аннан гарьләнде, соңыннан кирәк-кирәкмәгәнгә кимсетелмәс-хурланмас өчен кыргыйланды, илгәзәк табигатьле, ачык күңелле кыз баладан кырыс, чая үсмергә әверелде. Сугыш та бит әнә күпләрне бөкте. Элек күршесенә сәлам бирмәгән кайберәүләр хәзер кереп шуның чәен бер эчеп чыгар өчен генә дә бит йөз суын түгә.

Мәдинәләр дә артык тук яшәмиләр дә бит. Иншалла, сыер бозаулады. Мәдинә моңа кадәр дә савыт күтәреп күршеләренә йомышка бик йөрмәде, моннан соң инде ул бөтенләй чыкмаячак. Бик кирәк булса, әнә, әнисе Җантимере белән Биктимерен йөртсен. Алар, ике күпкән корсак, ашаудан башка бернигә ярамыйлар. Әнисе шуларны, кич булса иркәләп туймагандай, әле берсен, әле икенчесен тупылдатып сөя, әллә нинди колакка ятышсыз иркә сүзләр әйтә. Ә менә Мәдинә бары тик мал балаларын гына ярата. Идәндә йоклап яткан әнә ул бозаукай булмаса, өйнең ни яме булыр иде? Мәдинә үссә, абзар-курасын тутырып мал асрар, ә инде элегрәк туса, көтү-

көтү атлары Каратау сыртын иңләп йөрер иде. Әйе, әйе, менә шулай бай булыр иде ул! Үзенең силсәвит Ихсанбайныкы кебек кара айгыры, кулында камчысы булыр иде.

Кара айгыр дигәч, Мәдинәнең хәтеренә кылт итеп тагын Ихсанбай килде. Үз гомерендә кешенең җанына тиеп, тынын бугандай яши торган бәндәләр бар бит ул. Шуларның берсе — әтисе, Урыс Һашим. Ярый анысы сугышка китте. Кем белә, бәлки, Алланың рәхмәте төшеп, кайтмас та әле. Икенчесе — Ихсанбай, анысы күз алдында. Сугышка үпкәсе чирле булганга алмаганнар диме шуны... Үзе болай чирлегә дә охшамаган, бурсык маен эчә торгач, бурсыктан болайрак симергән. Аны нигә шултиклем куралмаганын Мәдинә үзе дә төшенми. Бу оятсыз кешенең итләч битенә кысылган зәңгәр күзләренең Мәдинәгә пешерердәй итеп каравымы, корсагын киереп, хатын-кызлар шикелле вак-вак басып йөрүеме — өзеп кенә ни дә булса әйтерлек тә түгел. Хәтта аның ябык озын буйлы, турсык бите өчен үтә бәләкәй уелган авызлы, юка иренле, кечкенә борынлы хатынын да өнәми Мәдинә. Шул борынга — борын рәвешен бирердәй нечкәлекләрне башкарып тормый ябыштырылган орыдай борынга — иренсез генә уймактай авызга көлү бер дә килешми. Ә ул, Сәбилә, шуны һич төшенми, туктаусыз көлә. Көлгәндә йөзе «Куегызчы әле, мине нигә газаплыйсыз инде?» дигәндәге кебек, кызганыч булып тартыша.

Дөресен әйткәндә, Мәдинәне курсә, монысы да кинәт үзгәреп китә. Төссез күзләренең угын кадамыйча үтми...

Әнисе эштән кайткач, җай чыкканда шушы хакта белергә дә тырышып караганы бар аның:

— Әни, Ихсанбай кем ул?

Әнисе, башта каушабрак калган кебек булса да, җавапны кыска тотты:

— Нигә, Ихсанбайның кем икәнен белмисеңмени? Силсәвит бит...

— Беләм...

— Белгәч...

— Әни, ә нигә ул мине куралмый?

— Кем әйтте аны? Ихсанбай үземе?

— Беркем дә әйтмәде, үзем беләм.

— Һы... — Гомергә ашыккан, гомергә бушамаган әнисе бу юлы да тезгенне кыска тотты: — Кирәкмәгәнне төпченгәнче, әнә энеләрең торута тамакларына юнәт.

— Шулар аркасында мин мәктәпкә йөри алмыйм!

— Мәдинә! — Әнисе артыннан ишек ябылды.

Йөрәген кара мәче кебек тырнаган сорауларын күкрәгенә кысып, Мәдинә идән уртасында торып калды. Юк! Әнисеннән сорап берни белерлек түгел! Һичбер сорауга җавап табармын димә! Сәер кыланмышлары бар шул әнисенең. Мәдинә бит энеләре турында соңгы минутына тиклем белмәде. Эскәмиягә чатырдатып тотынган хәлдә:

— Кызым, Фәүзия инәеңне* генә алып кил әле?! — дип ялварды әнисе.

Әйе, әйе! Коеп яңгыр яуган төндә Мәдинә гомергә бер бусагасын атламаган өйнең тәрәзәсен шакырга мәҗбүр булды.

Әнисенең тагы бер кыланышын аңлый алмый ул: этиләреннән хат килсә, агарынып китә, төсе кача. Хатны ашыгып-ашыгып ача да укымый кесәсенә салып куя. Укый башласа, кәгазьне күзе белән тишәрдәй булып, Җантимер белән Биктимергә кагылышлы юлларны эзли. Мәдинә дә бит шунда карап тора, әнисе өчен ул юк кебек.

Берчакны Мәдинә түзмәде. Әнисенең сырмасы кесәсеннән өчпочмаклы хатны алды да тәрәзә янына килде. Башта этисе бөтен күрше-күләнгә сәлам юллаган булып чыкты. Сәламен «күптин-күп, чуктин-чук» дигән сүзләр белән бизәкләп тә җибәргән. Беркемнең дә бу рәвешле сөйләшкәнен ишеткәне юк Мәдинәнең: тикмәгәме аның этисен Урыс Һашим диләр? Бу хәлдән ул шундый нәтиҗә ясады.

Этисе шуннан мал-туарга күчкән, печәннең житү-житмәвен сорашкан. Өшисездер инде, дип кайгырган. Мәдинәнең йөзенә мыскыллы елмаю чыкты: «Бахыр... Үзең монда чакта печән әзерләп, утын кисеп кинәндердең шул». Җаны көеп, алга таба укымыйча хатын кире сырма кесәсенә тыгарга торганда, аның күзенә «малайлар» дигән сүз чалынып калды. «Теге маңкаларны сораша бит бу!» Мәдинә хатка текәлде: *«Малайларны яхшы кара,* — диелгән иде анда, — *кайтмый калсам, токымымны дәвам итәрләр, ускәч, үзеңә таяныч булырлар. Мәдинәбез ул бит инде кыз кеше. Кеше баласы. Их, Гөлбану, сугышка тиклем тормышның кадере нигә беленмәгән икән?!»*

---

* Инәй — ата-анадан олырак хатын-кыз һәм аларга эндәшү сүзе.

Алга таба укып тормады Мәдинә: әтисенең сугышка тиклем нинди булганын ансыз да белә ул, ә менә үзенә кагылган сүзләрдән тәне чемердәде, тыны кысылды: кеше баласы! Дөрес, бер яктан, ул үзенең Урыс Һашим баласы булмавына сөенә дә, икенче яктан, әтисез булырга көчек түгел лә инде ул. Теге чакта ук әнисеннән шуны сорамакчы иде — сөйләштереп буламыни аны?

* * *

— Насыйбуллиннар шушында торамы? — Бәләкәй генә өйне суык болытына тутырып килеп кергән өч ир Мәдинәгә, әкияттәге төсле, җир астыннан калыккандай тоелды. Суык болыты таралгач кына Мәдинә аларның йөзен төсмерләде: бәй, алдан килеп кергәне генә таныш түгел икән. Берсе боларның Ихсанбай да, икенчесе — идарәдә төймә тарткан Ишмәмәт. Чын исеме шуның Ишмөхәммәт шикелле дә. Башкалар Ишмәмәт дигәч, Мәдинә дә шулай ди... Ә теге таныш түгел агай аягына купшы ак пима кигән, кулында папка. Ул, шул ак киез итекләрем пычранмасын дигән кебек, бозау яткан җиргә карап-карап куя.

Мәдинә бу чакырылмый килгән, сәламсез кергән кунакларга ни дә булса эндәшергә өлгермәде, баягы ак киез итекле ир үзе сүз башлады:

— Насыйбуллиннарның син кеме буласың, сеңелкәш?

Сорау Мәдинәгә кызык тоелды:

— Мин, ни, Насыйбуллиннарның бертуган кызы булам.

Ят ир-ат төшенмәде, гәүдәсе-ние белән борылып, юлдашларына карады:

— Как, туйыс, бертуганы, туйыс, кызы?

Ишмәмәт ашыгып моңа ярдәмгә килде:

— Ни бит, Мәдинә, без бик җитди хөкүмәт эше белән йөрибез. Безгә, ни, срочно әниең... Гөлбану кирәк, әйе!

— Әнием ни... эштә. Савым вакыты бит!

Киез итек кигәне, тавышын көрәйтә, гәүдәсен турайта төшеп, янә юлдашларына борылды:

— Кызның әнисе... туйыс, Насыйбуллина, безгә бит постольку поскольку гына кирәк! Әйе. Монда өйнең хәзерге хуҗасының, туйыс, Насыйбуллинаның личносы ни причём! Әйе. Так что, иптәшләр, ялгышмагыз: мәсьәләгә конкретно, по-деловому карагыз! Әйе!

Ихсанбай үз чиратында Мәдинәне көйдергеч карашы аша үткәрде:

— Шулай, шулай! Йортның төп хуҗасы фронтта!

— Ни бит, сеңелкәш, — Ишмәмәт баскан җирендә таптанып алды, — Насыйбуллин Һашим Хаҗиәхмәт улының, — папкасыннан ул бер кәгазь чыгарды, — үзе сугышка киткәндә... түләнмәгән салымы калган булган. — Шуннан ул йокысыннан уянып кыймылдаша башлаган балаларга карады да туктап калды.

Түшәкләренә торып утырган малайлар Ихсанбайның да игътибарыннан читтә калмады, тик нигәдер төсе бозылды:

— Әйе. Әтиеңнең түләп бетермәгән салымы калган. Шуның күләме хәзер... күпме әле, Ишмөхәммәт агай?

Ишмәмәт янә баскан җирендә таптанды.

— Хәзер... тучнысын әйтәм. Тучнысы: бер сыер!

— Сыер?! — Мәдинәнең аңына әле ишеткән сүзнең асылы барып җитми, мәгәр үзенә, менә бу ике җанга, тагын идәндә бер хәсрәтсез йоклап яткан әнә ул бозауга, әнисенә коточкыч куркыныч янаганын шунда ук төшенде. — Сыер...

Каршысында торган ирләрнең кайсысыдыр «Бурыч. Хөкүмәт. Төрмә» дигән сүзләрне әйтте. Ә Мәдинәнең күз алдында шулчак сакал-мыек баскан, эчкәннән шешенгән йөзле әтисе килде. Ул! Киткәндә дә балаларының ризыгын урлап киткән! Өч көнлек бозау янында торган Мәдинә йодрыкларын төйнәде, күкрәген ярып, иреннәрен көйдереп, әтисенә рәнҗүе бәреп чыкты:

— Дөмексәнче шунда, Һашим...

«Егетләр ат алып килгән, чыктык». Бу сүзләрнең мәгънәсе Мәдинәнең миңгерәүләнгән зиһененә барып җитмәде, аны бары тик әче итеп кычкырган әнисенең тавышы гына асылына кайтарды:

— Нишлисез?! Ерткычлар, кансызлар! — дип өзгәләнә иде ул тавыш. — Алыгыз! Җанымны алыгыз! Балаларымны асрый алмагач, ул җанның миңа нигә кирәге бар?!

Ул арада Гөлбану атылып өйгә керде, кычкырыштан куркынган малайларын утын шикелле итеп кочаклады да кире тышка йөгерде:

— Алыгыз, боларын да калдырмагыз! Ачлыктан тилмерешеп ятып үлгәннәрен күрмәм, ичмасам... Бозауны да... Билдәшнең бозавы-ы-ы... — Гөлбану янә өйгә ташланды, бозауны күтәреп алып чыкты да, малайларын болгап аткан кебек, бозауны да боларның алдына ташлады.

Ул арада җыелган күршеләре арасыннан кемдер Гөлбануның үзен тотты, кемдер игезәкләргә ябышты. Кемдер юатты, кемдер әрләде...

Әнә Билдәшнең мөгезенә бау тактылар, чананың тәртәсенә бәйләделәр. Мескен сыер туктаусыз артына каерыла, дүрт аягы белән карышып тарткалаша, мөгрәп акырган бозавын калдыра алмый, җан тетрәткеч тавыш белән кычкыра...

Мәдинә һуштан язар дәрәҗәгә җитте, Билдәш тирәли купкан ыгы-зыгыга карап катты. Сыер китте йорттан. Кот китте. Инде аларның савыт-сабасы беркайчан да сыер сыена сыланмас, иртәнге һаваны зыңгылдатып, сыер җилененнән савытка сөт акмаячак, кичке тынлыкны көтүлектән йөреп кайткан тук сыерның җиңелчә уфылдап куюы тутырмаячак, ә бозаукайның иреннәре иркә бер комсызлык белән әнисенең җилененә төртелмәячәк...

— Туктагыз! — Боерык кебек яңгыраган әче тавыш барысын да сискәндереп, артына әйләнеп карарга мәҗбүр итте. — Туктагыз... — Мәдинә бозауны җилтерәтеп китереп чанага салды. — Сыерны алгач, бозау да китсен, бозау киткәч, мин дә китәм.

— Балам... — Әнисенең үзенә эндәшкәнен ишетте Мәдинә, ләкин артына әйләнеп карамады: аның ихтыярыннан тыш, үзләреннән-үзләре ургылган яшьләрне ул беркемгә дә күрсәтмәячәк...

* * *

Сыер киткәннән соң, мәет чыкканнан да яманрак, тынычсызрак калган өй эчендә чикерткә чырылдый. Игезәкләрне күршесе Маһинур алып кайтты. Кеше кайгысын, кеше гамен җиңеләйтер өчен генә яратылган кебек шул хатын. Кеше яраткангамы, Ходай үзен дә ярата: илдә кытлык, йортлардан бәрәкәт киткән, ә ул гөрләтеп ике сыер сава. Шунысы гына кыен: күп сөйләшми. Ә Гөлбануга бүген соңгы өч елда җыелган хәсрәтләрен сөйләр кеше кирәк. Чарасызлык биләде аның тормышын. Язмышның каты кулы бугазыннан буып тотып алды. Әнисенә таяныр иде — мәрхүмә иртә китте дөньядан. Әтисен ул бөтенләй хәтерләми. Әнисенең, бу авылга читтән килгән кешенең, нәсел-нәсәбе дә юк. Шуннан инде ярдәм, киңәш сорап барырдай кеме булсын Гөлбануның? Әгәр тагы Ихсанбайга барса? Бәлки, ул бүгенге адымын

районнан килгән кешедән уза алмый гына ясагандыр? Ул да бит хөкүмәт кешесе. Алай дисәң, шул Ихсанбай аркасында кичергәннәр аз булдымы? Җелегенә үтмәдеме? Теге чак, кызын ФЗӨгә алып китәргә йөргәндә, ярдәм итте дә бит, ләкин нинди хакка? Гөлбануның кызы өчен куркып аңгы-миңге йөргән чагында теге ике кыз тәрәзә чиертмәгән булса? Хәзер, вакыт үткәч, хөкем чыгаруы ансат та ул, ә ул чакта?

Ул кич, ул төн... Тәрәзә чиерттеләр. Ишекне Гөлбану үзе ачты. Тәрәзәдән төшкән сүрән генә яктыда Гөлбану ике какча гына, ябык кына сынны шәйләде.

— Апай, безне фатирга кертмәссеңме икән?

— Кемнәр буласыз үзегез?

— Без, апай, еракатан, Магниттан киләбез...

Гөлбану хәлне шунда ук аңлады: качкыннар. Кертсә, үзенә кыен, кертмәсә... Юк-юк...

— Әйдәгез...

Түр якка үтә башлаган кызлар артыннан балавыздай сап-сары итеп кырып юылган идәндә пычрак катыш канлы эзләр калды.

— Балакайлар... — Гөлбануның аптырашлы карашы кызлар кигән ботинкаларга төште — аяк киемнәренең табаны юк иде.

Кызларны Гөлбану тагы ике көн яшереп яшәткәч кенә озатты. Аларга иске галошлар табып алып кидерде. Кызларны озатуга бер ай дигәндә, бәла үз башына килде: ФЗӨгә җибәрелергә тиешле исемлекнең иң башында аның Мәдинәсе тора. «Бәләкәй бит әле ул, яше җитмәгән!» — дип, Гөлбану тавышланып, елап йөреп карады — тыңларга да теләмәделәр. Ахырда ул Ихсанбайның, ат эчерергә чыкканын каравыллап торып, каршысына чыкты. Гадәттә, Гөлбану яхшырак киенеп урамга чыкса, Ихсанбай хатыны тәрәзә пәрдәләрен җәһәт кенә тартып куя. Берәр җиргә киткән чагы булды микән Сәбиләнең — бу юлы ул-бу тоелмады.

Ихсанбай, гадәттә, атын кеше су алган коедан байтак югарыда эчерә. Кое янында туктап тормастан, Гөлбану да елга үренәрәк китте.

— Курше су юлын ялгышкан түгелме?

Гөлбану Ихсанбайның тел төбен аңламамышка салышты:

— Миңа бит ни... мунчага елга суы кирәк.

— Кияү керткәнсеңдер дияр идем, кияүгә мунчаны иртән иртүк ягалар.

— Сугыш күп нәрсәне бутады, Ихсанбай. Иртән дигәнең кич була, кич дигәнең иртән була.

— Әгәр бу буталулар синең белән минем файдага булса, хәтта сугыш та начар түгел, Гөлбану.

— Авызыңнан җил алсын, Ихсанбай!

— Алла-а... Шаяртырга да ярамый икән лә...

— Үзең күреп торасың: шаяру кайгысымы миндә?

— Ярдәм итәм мин сиңа, Гөлбану, тик...

Гөлбануның йөзендә аптырау катыш өмет кабынды:

— Чынлапмы, шаярмыйсыңмы?

— Чынлап, шаярмыйм, тик... хакын үзең беләсең...

Ихсанбайның мырылдау дәрәҗәсендә шыпырт кына әйткән сүзеннән Гөлбану колакларына тиклем кызарды. Ихсанбайның игътибарыннан, әлбәттә, бу кызару да, баеп барган кояшның кызгылт нурында аеруча нәфис күренгән Гөлбануның тән сызыклары да читтә калмады. Шәп инде, шәп Гөлбану, әйтеп бетергесез. Нечкә генә кыз чагында да бу тән аны татлы бер сагышка сала иде, хәзер дә, хатын булгач та. Аның Сәбиләсендә шушы хатын матурлыгының, һичьюгы, яртысы гына булсачы... Су үренә бу хатынның нигә килгәнен шунда ук төшенде, әлбәттә, Ихсанбай. Исемлекне дә бит ул үзе төзеде. Белә ул Мәдинәнең яше җитмәгәнен. Бөтенесе дә дөрес бара, Ихсанбай уйлаганча. Һашимның Ихсанбайга һәрчак бүре күзләре белән караган чандыр каракаен кайталмастай җиргә озатканда да начар булмас иде дә, ул чагында Гөлбанудан күңелен биздерәсе була. Ә авызына үзе килеп кергән сары майны кайсы ирнең йотмый кире төкергәне бар? Бер сөйгәнем аркасында алтмыш сөймәгәнне сөярмен, дигәннәре шул, ахры...

Йөзеннән шул елмаюы китмәгән хәлдә, Гөлбану чиләкләренә иелде, Ихсанбай аның куш беләзек кигән йомры беләкләренә, изүеннән күренеп торган шома муенына, күлмәк аша да үзенең тыгызлыгын сиздергән күкрәкләренә дикъкать белән каравын дәвам иткән хәлдә пышылдауга күчте:

— Бүген кич... Шушында көтәм!

* * *

Ул кичне Гөлбану капма-каршылыклы хисләр белән көтеп алды. Урык-сурык искән көчле җил кырдагы учакның сүнеп барган күмерләрен балкыткандай,

Гөлбануның да исенә Ихсанбай белән бәйле төрле вакыйгалар төште. Кичке савым вакытында үзенең нәрсә эшләгәнен, кайсы сыерын сауганын-саумаганын үзе дә төшенмәде. Сәнәк сорап эндәшкән күршесенә — көрәк, көрәк сораганга чиләк тоттырганын үзе дә абайламады.

Хәтер, хәтер... Әнә ул, Ихсанбай, киртә арасыннан башын тыгып, Гөлбануны уйнарга чакыра. Кулында ике конфет. Шуның берсен яңа гына йокыдан тору аркасында чәче-башы тузган Гөлбануга суза.

— Кем билде?

— Әни.

— Миңа дамы?

— Сиңа да.

— Тәмлекәй...

— Ыhы... Бездә ишшү бар!

— Тагын биләсеңме?

— Ыhы. Тик син миңа кәләш буласыңмы?

— Булам.

Менә алар Акъелгада су керәләр. Елганың җәелеп киткән җиренә Ихсанбай җәлпәк ташлар ыргыта.

— Бер кәләш! Ә-ә, юк, икәү. Икәү, Гөлбану, икәү! — Малай шатлыгыннан үрле-кырлы сикерә, кызыкай ашык-пошык киенә башлый.

— Кая барасың?!

— Кайтам.

— Нигә?

— Шәп булгачтын, әнә кәләшләрең белән уйна!

Хәтер, хәтер... Әнә алар, Гөлбану белән Ихсанбай, бер парта артында утыралар. Мәктәпкә йөрткән букчаларында дәфтәр, китап, кара савытыннан башка тагы әллә күпме нәрсә бар. Ихсанбайныкыннан башлыча икмәк чыга һәм нәкъ ике өлеш. Гөлбануның да букчасы бөтенләй буш йөрми: кипкән корт, эремчек, талкан, шомырт, чия, җиләк... Әнисе җыйнак, пөхтә кеше булды. Башкалар ашаганда, балам авызларына карап утырмасын дигәндер инде.

Дәрес башланса, парта астыннан китә алыш-биреш, пыш-пыш килеш: Гөлбану — үз күчтәнәчен, Ихсанбай үзенекен суза. Бу икәүнең чамадан тыш татулыгын укытучы апалары өнәмәде шикелле: беркөнне дәрес вакытында икесен ике партага аерып утыртты. Шушы хәл аларның язмышын билгеләде. Ихсанбай, башын аска

111431
ГБУК
Национальная библиотека
имени Ахмет-Заки Валиди

иеп, иренен канатканчы тешләп, Сәбилә партасына утырды, ә Гөлбану кәтелмәгән хәлдән сүзсез калган килеш — Һашим партасына. Сәбилә шулчак ахирәтләренә тәкәббер, җиңүле караш ташлады, куанычыннан авызы колагына җиткән Һашим үзен-үзе белешми кул чапты. Тик шатлыгы озакка бармады Һашимның. Тәнәфескә чыгу белән, Ихсанбай Һашимның май чәчкәседәй елмайган йөзенә тукмактай йодрыгы белән кундырды. Тиктомалга, эндәшми-нитми китереп сукты...

Шушы көннән башлап ризык та йөртми башлады Ихсанбай.

Хәлле яшәгән Сәбиләнең үзенә тәмле-томлы сузуына да шулай ук карамады. Бишенче классны бетерүгә, Гөлбануның әнисе авырып түшәккә ятты. Гөлбану әнисе урынына фермага бозау карарга китте һәм шул китүдән мәктәпкә кире әйләнеп кайтмады.

Яшь кенә көе нужа баскан, эшкә җигелгән Гөлбану кичләрен соң ятты, таң белән үк торды. Яшьтәшләре белән клубка, утырмаларга да йөри алмады. Бердәнбер тапкыр Сабантуйга җыенган иде ул, анысы да...

Хәтерендә: әнисе сандыктан тасмалы күлмәк, укалы җилән, кызыл итекләр чыгарып алдына куйды.

— Кызым, инде зур үстең, шушыларны киеп бер йөреп кайт әле.

— Абау... Шушындый киемнәрең дә бармыни синең, әни?! Нигә бер дә күрсәтмәдең ул?

— Бәләкәй идең бит...

— Ә нигә үзең бер дә кимәдең?

— Әллә инде... — Үзе турында сөйләргә яратмаган әнисе бу юлы да бер сүз дә әйтмәде.

Гомерендә күрмәгән затлы киемнәр һушын алды Гөлбануның. Үзенең унбиш яшендә яшьтәшләреннән буйчанлыгы белән аерылып торган кызга итекләренә тиклем ятышлы булды. Балтырларының кунычы хәтта кысыбрак торгандай. Ә күлмәге... җиләне... Биле бик нечкә икән шул Гөлбануның. Кызлар тамчыгөл дип көләләр... Әнисе генә менә Гөлбануның чәчләрен үреп бетерә алмый мыштырдый. Юкка үзе тотынмады. Чулпыларына тиклем бар бит әле!

— Тизрәк үрче, әни, чәчемне!

— Кабаланма, халык яңа кузгала гына башлады.

Чәчен икегә аерып үргән, толымнарын калку күкрәге буйлап төшергән, тасмалы күлмәк, укалы җилән, биек үкчәле кызыл итек кигән Гөлбану көзгедән үз шәүләсен

күргәч телсез калды: искитмәле сылу кыз икән лә ул! Әмма шулчак Шәһәрбануга әллә ни булды:

— Кызым, — диде ул шикле бер тавыш белән, — бу киемнәрне сиңа кидереп әллә ялгышам инде?

— Нишләп, әни?

— Әлләче... Йә, ярый. — Кайсы ананың баласының куанганын күрәсе килми. Шәһәрбану да йомшарды. — Хозыр-Ильяс юлдаш булсын инде үзеңә.

Сабантуй булган җиргә Гөлбану турыдан, үзләренең абзар артыннан гына чыкты. Әй шул елгы җәйнең ямьлелеге, байлыгы! Абзар артында үлән билгә житеп үсеп, шау чәчкә атып утыра иде бит! Гөлбану үзе атлый, үзе елмая. Хәситәсендәге, чулпыларындагы, беләзекләрендәге тәңкәләр дә, бер-берсенә сүз кушып, чылтыр-чылтыр көләләр төсле. Их! Гөлбану бүген дөньясын онытып, онытылып бәйрәм итәчәк! Фермага аның урынына әнисе бара. Тик менә әллә нишләп ахирәтләрен көтмәде. Япаялгызы чыгып китте...

Озаграк җыенганмы — ул килгәндә Сабантуй шактый кызган иде. Кызлардан беренче күргән кешесе Сәбилә булды. Бала итәкләр салдырып, яңа күлмәк тектереп кигән киюен, әмма аның коры сеңердән торган тәненә һич кенә дә килешми шул: карачкыга кидергән капчык кебек асылынып тора. Гөлбануны күргәч, төсе бозылып китте бит әле моның. Кәеф шәп чагында нигә әле моны бераз ирештереп алмаска?

— Сәлам кызларның асылына! — Гөлбануның сәламеннән Сәбиләнең тире белән сөяктән торган юка йөзе тартышып, агарып китте, үзе шулай да сер бирмәскә тырыша:

— Сәлам.

— Көрәш кайсы җирдә, ахирәт?

— Мин дә шунда барам бит...

Әйе, әйе... Көтмәгән Сәбилә Гөлбануның бу дәрәҗәдә киенеп килерен, уйламаган. Гөлбану бу тәкәббер килбәтсезнең кикриген бер шиңдергәч, кирәген биргәнче шиңдерергә булды:

— Ихсанбай көрәшә микән?

Сәбилә капыл күтәрелеп Гөлбануга карады, Гөлбану аның күзләренең кызарып шешенгәнен шунда гына абайлады.

— Гөлбану... — Сәбилә аннары сүз таба алмагандай тотлыкты, — мин сиңа әйтермен дигән идем... Без бит Ихсанбай белән...

Гөлбануның да аны тыңлап бетерергә көче житмәгәндәй булды, йөрәгенең нидер сизенеп дөп-дөп тибә башлавын җиңәргә тырышып көлеп җибәрде:

— Нәрсә? Ихсанбай дисеңме? Сиңа гына әллә кем бит ул! — Гөлбану үзе көлә, ә үзенең тавышы бер дә табигый чыкмый. Кешеләрне үзенә әйләнеп карарга мәҗбүр иткәнче көлә-көлә, Сәбиләдән аерылып, мәйданга җыелган халык эченә кереп китте Гөлбану.

Алан гөр килә. Чабышка әзерләнгән малайлар дәрәҗә саклап ат өстендә утырып торалар. Атка менгән ир-атның холык-фигыленең үзгәрүен элек тә күзәткәне бар Гөлбануның, ә инде аларның ярышка әзерләнгәннәре чамасыз үзгәрә. Менә ул үзе ир-ат булып туса, ат өстеннән төшмәс иде, мөгаен.

Башта көрәш була икән — Гөлбану көрәшчеләрне карарга баскан түгәрәккә килде. Ихсанбай да шушында. Ул бик җитди, күрәсең, көч сынашмакчы. Эреләнебрәк тә киткән шикелле ул: җиденчене бетергәч, шәһәргә барып, ниндидер җирдә укып кайтты бит. Тыштан тыныч күренсә дә, кара бөдрә чәчләре астында ялтыраган зәңгәр күзләре аерым бер дәрт белән янгандай. Соңыннан гармун да тартыр инде ул, яныннан кыз-кыркын өзелмәс. Яшьләр генә түгел, өлкәнрәкләр дә яныннан китмәс. Үзенә төбәлеп карауны тойдымы, Ихсанбай да күрде Гөлбануны. Күрде дә шаккатты. Таныган да, танымаган да кебек. Беразга гына күзләре очрашты. Оялмады Гөлбану, керфекләрен элеккедәй аска төшермәде: ул бит бүген авылның бөтен егетләрен дә үзенә гашыйк итәргә килгән!

Ихсанбайга Һашим белән көрәшергә туры килде. Болар — иң соңгылар, кем җиңә, шул җиңүче була. Иң соңгы мәлдә Ихсанбайга әллә нәрсә булды — Гөлбану күз ачып йомган арада Ихсанбай Һашимның астында ята иде. Һашимның уң кулын күтәрделәр. Хатын-кызлар җиңүчегә алып килгән бүләкләрен бирә башладылар. Гөлбану да янчыгын Һашимга сузды...

Ат чабыштыру тәмамлангач, бию башланды. Монда инде урынында түзеп тора алмады Гөлбану. Үзендә шулкадәр дәрт, осталык яшеренеп ятканын, дөресен әйткәндә, ул үзе дә белми иде.

— Шәһәрбануда бар икән бер кыз! — дигән тавышлар ишетелде аның колагына.

— Менә сиңа йомыкый...

— Кыз түгел, су сөлеге!

— Ут!

Ул көнне Гөлбануга Тирәкледән дә матур җир, аннан да бәхетле кеше юк кебек тоелды. Яшьләр белән бергәләп «Наза» уйнарга баскан чагында кемдер аның учына кәгазь тоттырып китте.

Уйныйбыз бергә-бергә,
Эшлибез бергә-бергә.
Косилка, молотилка,
Сортировка, веялка!

Уен да кызды — ташлап китүе җәл, учындагы кәгазь дә тынгы бирми. Һашимнән генә булмаса ярый ла... Җитмәсә, янчык тоттырды бит әле шуңа. Кызыксынуы җиңде Гөлбануны. Читкәрәк китеп, тирләгән учында укмашкан кәгазьне ачты. «Гөлбану, сине су буенда, тирәкләр янында көтәм». Их, Ихсанбай! Үзе! Күпме көтте шушы минутларны Гөлбану, йөрәгенең януын баса алмыйча каеннарны кочты, ай тулса, кавышу сорады, йолдыз атылса, Тәңредән Ихсанбай күңеленә үзенә карата сөю ялварды. Ниһаять, ишетте Илаһ, иреште теләгенә Гөлбану, морадына җитте! Рәхмәтем зур сиңа, Тәңрем!

Гөлбану Ихсанбай көткән тирәкләр янына ашыкты, үзе елый, үзе көлә.

— Гөлбану! Кызым, тукта әле, кызым!..

Инәлгәнгә дә, боерганга да охшаган тавыш Гөлбануны хыял дөньясыннан чынбарлыкка кайтарды, каршында башыннан кара шәле мәңге төшмәгән, ут шикелле янган кара күзләрен үзенә төбәгән Фәүзия карчыкны күргәч, Гөлбану куркып артка чигенде.

— Кая юл тоттың, кызым? — Тавыш һаман да боерулы, буйсындыручан.

— Мин ни... — Ихсанбайның әнисенә ни дип җавап бирергә белми аптырап калды Гөлбану, — мин ни... кайтыйм дигән идем, соң бит инде...

— Әниең дә көтәдер, әйе, соң, кайтырга кирәк, ләкин бит авыл, — карчык ияге белән Гөлбануның килгән ягына ымлады, — артыңда!

Бу үткен, үтәдән-үтә карауч ы караштан болай гына котыла алмасын аңлады Гөлбану. Һәм, гомумән, нигә курка әле ул бу инәйдән?

Шушы кеше көн саен мәктәпкә киткәндә улының букчасына Гөлбану өчен өлеш салмадымы? Ә Гөлбанулар

йортына кытлык килгән чакларда аларның нигезләренә ризыкны аз калдырып киттеме? Әлбәттә, Фәүзия боларны төнлә, кеше күрмәгәндә эшләде, әмма Шәһәрбану да, Гөлбану да бу Хозыр-Ильясның кем икәнен күптән төшенгәннәр иде. Аннан соң, Ихсанбайны дөньяга тудырган кеше кайчан да булса дөресен белергә тиештер бит?

Кызыл итегеннән дә, кызыл күлмәгеннән дә ныграк кызарган Гөлбану сүз башлады:

— Мин, без... Ихсанбай көтә мине!

— Ихсанбай, — Фәүзия кара-кучкыл йөзендә ак сызык булып каткан иренен көчкә аерган кебек, ә куллары Гөлбануга сузыла. Нишли ул? Кочакларгамы, әллә буаргамы җыена?

— Инәй! — Гөлбану маңгаеннан, аркасыннан салкын тир бәреп чыгуын тойды.

— Син... син, кызым, беркайчан да Ихсанбайның кәләше булмаячаксың! Ишетәсеңме, беркайчан да!

— Син, инәй, ни сөйлисең ул? Ни зыяным тиде сиңа?! — Гөлбануның йөрәгеннән чыккан иңрәү Фәүзиянең күңелен чак кына да йомшартмады шикелле.

— Син һаман аңламадыңмы, кызыкай?! Бу киемнәр дә, Ихсанбай да сиңа бәхет китермәячәк! Сал аларны, ташла, утка як...

Куркынган Гөлбану, артка чигенә барып, агачка бәрелде, аннан коты алынып, килгән ягына, авылга таба йөгерде.

* * *

Шушы вакытта Гөлбануларга каршы гына салынган урыс капкалы йортның бердәнбер варисы булган Ихсанбай тармакланып үскән тирәк төбендә Гөлбануны көтте. Бүгенге Сабантуйның үзенә җиңү китермәвенә артык хафаланмый ул, әмма аны калак сөягенә салучысы кем бит әле! Һашим! Теге вакытта мәктәптә шуның муенын борырга өлгермәгәненә үкенә хәзер Ихсанбай. Шәһәргә олагуы шәп булган иде дә, кайткан бит әле. Ихсанбайның җиңелүе Гөлбанудан да булды шикелле. Үзенең киемнәре, төс-сыны белән кинәт килеп чыкты. Башка берәү белән дә көч сынашып карамастан, Ихсанбай Һашим белән көрәшергә булды. Шулай да Гөлбануны күреп каушамаса, бирешмәс иде әле Ихсанбай. Әле дә

ничек каршыларга белми ул Гөлбануны. «Кәләшем бул, гомерлек ярым бул!» дисә, ни дияр икән? Улының бу тәкъдименә әтисе ничек карар тагы? Эчеп алган саен: «Мин — бөек хан токымы!» — дип күкрәк сугарга яраткан нәрсә хәерче кызы кирәкми безгә дияр микән? Бәлки, әнисе күндерер әтисен? Башка күршеләре белән аяк кагып кына исәнләшсә дә, Гөлбануны да, аның чирле әнисе Шәһәрбануны да ифрат якын күрә бит ул. Әйе, бар өмет әнисендә. Тизләтмәсә, Ихсанбай Гөлбанудан тиз арада колак кагачак. Бүгенге Сабантуй Тирәкленең генә түгел, күршедәге Сабаклы егетләренең дә күзен ачты. Ә Һашим?.. Ихсанбай, күзләрен йомып, тешен шыгырдатты: Гөлбану бит шуңа, шул ятимгә янчык бүләк итте!

— Ихсанбай!

— Гөлбану! — Әмма аның куанычы бушка булды: күзен ачканда, йөзенә елмаю галәмәте чыгарып, Сәбилә басып тора иде. — Син?

— Әйе, мин... — Сәбилә, ике кулын алга сузып, аңа омтылды. — Әйе, мин... Читкә тибәрмә мине, ялгыз итмә! Ул... ул бит сиңа беркайчан да килмәячәк...

— Нәрсә сөйлисең син? — Ихсанбай аның изүен йомарлап тотып алганын үзе дә сизми калды. — Артымнан каравыллап йөрүеңне кайчан ташлыйсың син?!

— Теләсәң — колың, теләсәң олтырагың булырмын — кире какма мине, Ихсанбай!!!

Ихсанбайның борып тотуыннан төймәләре коелып, күкрәге ачылып киткән Сәбилә егетнең муенына сарылды, аның муенын, иреннәрен үпте.

— Нишлисең син, Сәбилә?! — Тән якынлыгыннан суына барган Ихсанбай бу сүзләрне ыңгырашу катыш әйтте. — Мин бит сине яратмыйм!

— Яратма... Минем яратуым икебезгә дә җиткән! — Сәбиләнең иреннәре кебек үк комсыз, уттай янган бармаклары һаман да түбәнгәрәк үрмәләде. — Ташлама мине, кызган... Безнең бит... балабыз булачак...

* * *

Гөлбанудан калып, Фәүзия күпме утыргандыр... Менә ул Гөлбану торган җир... Шушында торган җиреннән ярдәм сорап, ялварып, үзенең аккош канатыдай нечкә кулларын сузган иде ул... Өзде баланың өметен Фәүзия,

чәлпәрәмә китерде. Әмма үзенең кысылуы белән аларны Ходай кушмаганны кылудан аралады: канга кан кушылу дан коткарды! Әй бу язмышны! Кайсы уйламаган яктан китереп сукты ул тагы Фәүзиягә... Кемнәрнең каты каһәре төшеп кенә Барсынбикә-Фәүзиягә шушындый каһәрле язмыш җибәрде икән Ходай?! Фәүзия-Барсынбикә. Сибгат-Диңгезхан. Әй язмыш, язмыш, язмыш... Ил анасы, ил агасы булыр Диңгезхан белән Барсынбикәне шушы хәлгә нәрсә, кем төшерде?.. Көтү-көтү өерелеп, басу-кырлар иңләп йөргән малларыбыздан, кымыз-әйрән күпереп утырган турсыкларыбыздан, диңгездәй җәйрәп яткан дала-йортыбыздан нәрсә аерды безне, нәрсә яздырды?.. Әй Ихсанбай, балакаем... Шушы вакытта син кызларның иң сылуын үзеңә каратырлык асыл егет булыр идең дә соң... Гөлбануым... Гөлбану да түгел иде бит исемең: Күксылу син! Күзләреңдә күксел әрем төсе булганга күрә кушкан идем сиңа шул исемне. Ак тирмәмнең коты булып, чырылдап-сайрап уйнап йөргән ике кошчыгым, йөрәк майкайларымны сыздырып, бер-берегезгә гашыйк булдыгыз... Әгәр бүген мин сезне аермасам, үз балам үз бусагама килен булып кына төшә иде бит... Озак уйладым бу хакта, Ихсанбайның Гөлбануга барыр юлына киртә артыннан киртә куйдым... Ай, озак интектем, озак җәфаландым... Хак Тәгалә бутаган язмышны гади бәндә ихтыяры белән ничек сүтим?!

И Раббым!.. Аптырагач, сиңа да тел тидерәм. Ә бит үзем, бары үзем гаепле барысына да!.. Ничек кенә мине җир йотмый да, ничек кенә бу кояш киптереп, көйдереп үтерми?!

Фәүзия кайнарланган учы белән әле генә Гөлбану басып торган җирдәге үләнне сыйпады: ә нинди килешә аңа әнисеннән калган кызыл күн итекләр... җилән... чулпылар...

Әнә кемдер Ихсанбай Гөлбануны көткән тирәкләр ягына йөгерде. Бармый булмый: язмыш куласасына килеп капкач, көчең беткәнче көрәшми, карышмый чараң юк.

«Шушындый чакта әнисе генә җитмәгән иде!» – Тирәкләр төбендә чалкан төшеп яткан Ихсанбай тиз генә итәк-җиңен җыеп өлгермәгән Сәбилә яныннан торды. Фәүзия бик әкрен якынайды, аларга чәч-башларын рәтләргә вакыт калдырды. Шуннан Ихсанбайның колагына әнисенең боерулы, һәр өне һәр күзәнәгенә үтеп керерлек тавышы яңгырады:

— Безгә әйтми-нитми, гомерлек ярыңны шушыннан алырга карар иткәнсең икән, улым, инде мине тыңла: гомереңахырынача шуны иш итәсең, килен кеше алдында башын югары чөеп, ирем — Ихсанбай, мин — аның хатыны дип яшәрлек булсын! Ишетсен колагың, Ихсанбай! Мин ике сөйләмәм.

Әнисе каршысында җир ярылса, шунда кереп югалырдай уңайсыз хәлдә калган Ихсанбайга дәшми буйсынудан башка чара калмады.

* * *

Шәһәрбану кызының кайтканын ашкынып, тыны белән тартып алырдай булып көтте. Фермадан Гөлбану караган бозауларга сөт эчереп кайткач та абзар артына чыкты. Кызы артыннан үзе дә чыгып китәр иде, аяклары сызлый. Әллә тешен кысып чыгарга да китәргәме? Ай, бу бала бер бәлагә генә очрамаса ярый да... Әллә нигә кидерде бит үзе кагылырга да курыккан киемнәрне, шайтанмы тартты аның кулыннан, иблисме котыртты... Адәм күрке — чүпрәк, янәсе. Күптән ташлыйсы иде шул киемнәрне, ташу вакытында елгага гына ташлыйсы иде.

Йа Ходай! Ишеттергән Шәһәрбануның хафасын Гөлбануга! Әнә килә аның күгәрчене! Яшел хәтфә өстеннән йөзеп кенә килә аның алтын чабагы! Түзеп тора алмады Шәһәрбану, сызлаган аяклары белән алпан-тилпән килеп, каршысына атлады. Аһ, ни булган бу балага? Нигә әле аның иртә белән генә май кояшыдай балкыган йөзен кара болыт баскан?

— Әни!.. — Күкрәгенә сыенып үксегән баласы йөрәгенең ауга эләккән кошчыктай тыпырчынуын тойды Шәһәрбану. И бала, бала... Үз йөрәге астында йөртмәсә дә, тулгак газаплары белән үзе тудырмаса да, бар булмышы, бар вөҗүде белән ярата бит шушы баланы Шәһәрбану һәм аның тойгыларының ихласлыгына күктәге кояш та бер Ходай шаһит.

— Ни булды, балам? Кем мыскыл итте? Кем рәнҗетте?!

— Әни!.. — Тыела алмый, сүзен әйтә алмый Гөлбану, аның күзләреннән Шәһәрбануның ялангач муенына аккан күз яшьләре гүя яндырып, пешереп ала иде. Кайдан җыелган бу чаклы ялкын яшь кенә бер балага?

— Сөйлә, балам, әйт... Җиңелрәк булыр. — Шәһәрбану үзе дә елый, аның ябык гәүдәсе кызын рәнҗеткән билгесез кешегә рәнҗеш белән тулыша.

— Әни! Миңа Ихсанбайның әнисе... Фәүзия инәй... киемнәрне... утка ягарга кушты. Ихсанбайга... мине... беркайчан да, — Гөлбану, үкереп елап, җиргә егылды.

— Фәүзия?! Бу киемнәрне?! — Шәһәрбану башта көл кебек агарды, аннан, каты бер карарга килгәндәй булып, кызын ашыктыра башлады: — Алай икән... Тор, балам, чү! Кеше ишетер! Гөлбану Сабантуйдан мәсхәрәләнеп кайткан икән диярләр.

Төнне әни дә, кыз да керфек тә какмый үткәрде. Ә үзләре лампага ут алып та тормадылар. Каршы йортта, Ихсанбайлар өендә дә йокламадылар — анда килен төшерделәр.

Иртән Шәһәрбану идарә ягыннан ат җигеп утырып кайтты. Ашыгып өенә керде дә әле йокысыннан да уянмаган кызы янына килде:

— Тор, балам. Китәбез. Күчәбез.

— Кая?

— Урыс утарына!

— Нигә?

— Чучка карарга кеше таба алмыйлар иде — риза булдым.

— Чучка?! — Чиксез аптыраудан зураеп киткән күз ләрен әнисенә текәп, Гөлбану торып утырды. — Чын әйтәсеңме, әни?!

— Аптырама, балам, тереклекнең барысын да Аллаһы Тәгалә яраткан.

Шул сәгатьтә үк Шәһәрбану ярсу бер кызулык белән тәрәзәләренә аркылы-торкылы такта какты, барлык әйберләрен арбага төяде дә атның кабыргасына чыбык белән сыдырды.

«Урыс утары» аларны котсыз ялгызлыгы, тирә-ягына өелгән чүп-чардан, тирес суыннан таралган укшыткыч исе белән каршы алды. Революциягә тиклем үзенең зурлыгы, басуларының уңдырышлылыгы белән адәмнең күзен кыздырып яткан бу алпавыт җире хәзер Шәһәрбану белән Гөлбану кебек ятимнәрнең борын төртер җиренә — Тирәкле авылының Себеренә әйләнгән.

Әнә чүп-чар өеме арасында пычранып беткән Шәңгәрәй йөри. Шәңгәрәй — аның мулла кушкан, авыл Советында теркәлгән исеме. Аннан тыш бала акыллы җиткән егетне «Шарик» дип тә йөртәләр. Бу кушаматны аңа

кем таккандыр, мәгәр шушы түгәрәк битле, зур башлы, кыска гына аяклы Ходай бәндәсенә исеменә караганда кушаматы ныграк ябышкан. Ишмөхәммәт-Ишмәмәтнең беренче хатыныннан туган бу малай әнисе исән чакта, урамда эт талаштырып, әби-чәбинең тавык кетәгенә кереп, йомыркасын урлап, базына төшеп, каймагын ашап, кеше көлдереп, авылда яшәде. Ишмәмәт мунчада ис тиеп үлгән хатыны урынына балдызын алгач, яшь хатын Шәңгәрәйне утарга алып килеп, Габделәхәт исемле малайның ярдәмчесе итеп бирде.

— Әйдә, апай, урнашыгыз, — Габделәхәт уңайсызланып кына елмайды, — тормыш бездә шәптән түгел инде...

— Кыш бик суыктыр инде. — Шәһәрбану үрмәкүч пәрәвезе сарган түшәмгә, юештән мүк каплаган стеналарга күз салды.

— Яксаң җылына болай... Миче төтен кайтара. Утын җиткереп булмый, җәйдән әзерләргә кеше җитми. Ярдәмгә Шәңгәрәйне җибәргән булдылар да — анысы үзе ун дуңгызга торырлык.

— Ичмасам, стеналарны агартып алырга иде. — Шәһәрбану зур өйнең бер почмагында катып торган кызына карады. — Гөлбануга күңеллерәк булыр иде диюем...

Габделәхәт шунда гына игътибар итте шикелле кызга. Аны күргәч, эченә җан кереп киткәндәй булды. Икенче көнне үк ишегалдына бер йөк ак балчык китереп аударды, утынның да корысын тапты.

Менә шулай дүртәүләп яшәп киттеләр алар утарда. Җәй ничек тә үтте. Әмма кыш... Күз ачкысыз бураннарына да, суыгына да түзәр иден, дуңгызларга азык җитмәү үтте үзәкләренә. Кеше кеше инде: ач булса да түзә, менә дуңгыз ачыкса... Алар шикелле мал актыгын күргәне булмады Шәһәрбануның, чак кына карамыйчарак торсаң, әниләре үз балаларын ашый башлый. Чырылдатып, ерткыч комсызлыгы белән кинәнеп ашыйлар шуларны.

Шушыларны күргән саен, Гөлбану елый, авылга кайтыйк, ди башлый. Җитмәсә, ачтан үлгән дуңгызларны Габделәхәт белән әнисе туныйлар, зур казанга салып пешерәләр дә әштер-өштер генә көрпә кушып, дуңгызлар алдына куялар. Кыш җитеп, суык төшкәч, Шәңгәрәй бөтенләй көйсезләнде, мал астын чистартырга да чыгарып булмый.

— Бар инде, Шәңгәрәй, чык, Габделәхәтнең берүзенә кыен бит, — дип инәлә аңа Шәһәрбану.

— Ы! Тышта буран, мин бураннан куркам!

— Без дә буранда йөрибез. Габделәхәт белән Гөлбану, буран дип тормый, утынга баралар, салам алып кайталар...

— Ы!

— Нигә? Нигә тыңламыйсың, Шәңгәрәй?!

— Кызыңны кәләс итеп бирмисең бит үзең...

— Бирәм, Шәңгәрәй, бирәм.

— Кашан?

— Менә көн генә җылынсын да...

— Кишә дә су-сулай дигән идең...

— Шуннан мин нишләтим? Әйт әнә буранга, дуламый торсын!

— Ярар, шыгам... Тик кызыңны Габделәхәткә биреп куйма!

— Ярар, дидем бит.

— Мин матур, Габделәхәт алама!

— Әйе, Шәңгәрәй, син матурсың.

— Уңганмын!

— Уңгансың, Шәңгәрәй.

— Акыллымын.

— Акыллысың, Шәңгәрәй.

— Кызыңны ыстубы бирәсең!

— Бирәм, Шәңгәрәй, әйттем бит!

— Мин оштым, Сәһәрбану апай! Абзарны виш көрәп шыгарам, шушкаларыңны да көрәп түгәм!

— Ай, шакшы Шәңгәрәй! Тиеп кенә кара чучкаларга! — Шәңгәрәй артыннан ишек ябылырга өлгерми, Шәһәрбану сырмасына ябыша — булыр бу әкәмәт кешедән, карап тормасаң, туңдырып үтереп бетерер хайваннарны.

Төтенгә, буранга, юклыкка, хәсрәткә чәчи-чәчи, көннәр бер-бер артлы үтә торды. Теге хәерсез Сабантуй көненнән соң Гөлбанунын күңеле сулып, сүнеп калды. Ярый әле янында Габделәхәт бар. Кич булса, тальян гармунын алып, сагышлы моңга тулы җырларын суза:

Агач чүлмәк, авызы тар,
Пешә солдат ашлары...
Кошлар очып житмәс җиргә
Китә солдат башлары.

Гөлбану да, Шәһәрбану да, һәркайсысы, үзенчә моңланып, җыр тыңлыйлар. Шәңгәрәйнең генә колагы да, күзе дә идән ярыгында: ул, дөньясын онытып, тычкан аулый.

Их, үзкәем, их, үзкәем,
Их, үзем каен булсам,
Их, үзкәем каен булсам,
Син былбыл булып кунсаң...

— Әни, нигә син бер дә әтием хакында сөйләмисең ул? — Гөлбану йөрәксенеп әнисенә карый.

— Үлгән кешенең туфрагын кузгатырга ярамый бит, кызым. — Шәһәрбану кызының соравыннан инде ничәнче тапкыр шушы рәвешле тайчана.

— Үлгән кешене искә алырга да ярамыймы?!

— Без бит озак яшәмәдек. Ул үлгәндә, син тумаган да идең. Ул... язгы ташуда батып үлде. Агып китте. Хәтта гәүдәсен дә тапмадылар.

— Ул хакта сөйләгән идең...

— Сөйләгәч...

— Юк, ул менә нинди рәк кеше иде? Төсе, холкы...

— Нинди дип, кеше нинди була соң? Гади иде, синең кебек иде, матур иде.

— Ә нигә без авылыбыздан күчеп киттек?

— Ул заманда... күпләр күчте.

— Еракмы ул авыл?

— Төпченмә инде, балам. Ул авылда синең бернинди зат-зәверең юк. Юк белән баш катырганчы, әнә бәйләмеңне ал, үзеңә бирнәлек әзерлә.

— Нигә кирәк ул?

— Бәй, син кыз түгелме? Кияүгә чыкмыйсыңмы?

— Әллә тагы, — «кияү» сүзен әнисеннән беренче тапкыр ишеткәнгәме — колакларына ут капты Гөлбануның, — инде чыгып тормамдыр шул кияүгә.

— Абау, иске авыздан яңа сүз дигәндәй. — Шәһәрбану кызына аптырап карады. — Ул ни дигән сүз?

— Кеше көлдереп... Дуңгыз караучы кызны кем алсын?

— Эшнең ояты юк.

— Ояты булмаганга дуңгыз карарга кеше тапмыйлар икән!

Ә тышта төн. Якында гына бүре улаганы ишетелә. Габделәхәт, гармунын куеп, абзар-кура тирәсен карарга чыккан арада, кемдер тәрәзә чиертте. Шәһәрбану сагайды, утын агачы тотып, ишек янына килде.

— Кем бар анда?

— Яучылар килгән, Шәһәрбану, ачыгыз!

— Абау. — Шәһәрбану ишекнең келәсен ычкындырып җибәрүгә, Һашим һәм аның атасы белән бертуган энесе килеп керделәр. Шәһәрбану каушады, кулындагы утынын кая куярга белми аптырап торды.

— Сез инде, Шәһәрбану карендәш, кияү егете белән бергә кыз сорарга килгәнгә ачуланмагыз. Убыр йөрмәс төндә Һашимсыз кая чыгып китәсең?

— Төннең көне бар, — Шәһәрбану аның исемен исенә төшерә алмый газапланды, — теге ни... кем...

— Бәшәр.

— Әйе, Бәшәр, көн бар, йола бар.

— Шулай да ул, — Бәшәр уңайсызланып тамак кырды. — Һашим бит... Шәһәрдән эңгер төшкәндә генә кайтты...

— Кайтса, шуннан? — Шәһәрбануның нык борчылганда йә дулкынланганда күзе тартыша башлый. — Ут алырга кайтмагандыр бит шәһәрдән?

— Алайга китсә, — Димче диңгез кичерә, дип, Бәшәр бирешмәскә булды микән, тавышын көрәйтә төште, — үзеңнең дә уттан кызу чакларың булмадымы?

— Синең белән миңа, кем, Хәйрелбәшәр, гыйшык хатирәләренә бирелү килешми.

— Анысы шулай да... Яшьләр ни дияр бит әле?

— Яшьләрнең әти-әнисе бар, Хәйрелбәшәр. Төнлә килеп кыз сорау йоласын күргәнем юк иде әле! Бигайбә.

— Бәй, чәй дә эчерми кире борасыңмы?

— Гамәлегезгә күрә әмәле.

Өнсез калган Гөлбану Шаңгәрәй белән Габделәхәт яткан якны бүлеп корылган чаршау артыннан чыкмады; Һашим, баскан җирендә таптана биреп, абыйсының җилкәсенә кулын салды:

— Кайтыйк әйдә, уңмадык.

Шушы хәлдән соң күп тә үтми, Ишмөхәммәт килде, малаена алмаш кием, азык-төлек тапшырганнан соң, Шәһәрбануга эндәште:

— Кызыңны камсамулга алалар. Миңа, ни, утыртып алып кайтырга куштылар. Юлга, ни, көрт салган. Атка, ни, авыр булса була инде. Райком, ни, куша бит.

«Камсамул» дигәнне ишеткәч, Шәһәрбану карышмады: «камсамул»ы да, «партия»се дә хөкүмәт эше бит дип уйлады, ә хөкүмәткә каршы барып буламы?

* * *

Ул көнне комсомолга байтак яшьләрне алдылар. Унбиш-уналты яшьлек үсмерләрдән ФЗӨгә китәргә шул көндә үк гариза яздырдылар. Гаризаны Гөлбану да язды. Аның бу шайтан элмәгенә әйләнгән дөньядан ычкынасы, икенче тормышка очасы килде. Китәргә дә кабат кайтмаска! Һашимы да, Ихсанбае да, Сәбиләсе дә, дуңгызлары да — бөтенесе бергә чукынып кына китсеннәр! Әнисе генә жәл менә...

Шул уйлары белән клубтан чыгып, Гөлбану өйләренә табан атлады. Мөгаен, ул бүген Маһинур күршесенә кереп кенә йоклар, ә иртәгә... Иртәгә ул шәһәргә китәчәк. Авылда инде бер көнгә дә калмаячак Гөлбану. ФЗӨ дигәннәре дуңгыз караудан да җирәнгечрәк түгелдер әле. Әнисенә әлегә хәбәр итми торыр, белеп алса җибәрмәячәк.

— Гөлбану!

Карны шыгыр-шыгыр китереп артыннан йөгергән кеше әллә Һашим инде?

— Ай!..

— Нидән курыктың, Гөлбану? Фызыуга китүдән курыкмаган батыр камсамулка артыннан егет ияргәнгә генә куркамы инде?

— Син үзең кайчаннан бирле шәһәрдә йөрисең — үлмәгәнсең.

— Ул бит мин, Гөлбану, йә, нигә эреләндең? Килгән яучыларны кире бор, артыңнан килгән егетләр белән юньләп сөйләшмә... Хан улын көтәсеңме әллә? Хан малайлары дуңгыз исе килеп торган кызларны вапшы-ты үлеп яраталар, ди!

— Аның каравы дуңгыз исе килгән кызлар аракы исе аңкыган егетләрне үлеп күрә алмыйлар, ди. — Гөлбану бу сүзләрне әйткәндә, үзләренең өй капкалары янына килеп җиткәннәр иде.

— Уһу-у... Шулай ук димени?! Хәзер мин сиңа дуңгыз караган кызларның эчкән егетләрне ничек итеп куралмаганын күрсәтәм икән...

— Нишләтмәкчесең? — Бер класста, бер парта артында утырып укыган кешесеннән курку башына да килмәде Гөлбануның.

— Хәзер, күрерсең... — Һашим күз ачып йомган арада Гөлбануның кулларын артка каерды да, бер кулы белән

борып тотты, икенчесе белән анының башын кысып, аракы исе аңкып торган авызы белән иреннәренә ябышты... Хатын-кыз кулы белән генә ныгытылган өй ишеге бер тибүдә бернинди каршылыксыз ачылды. Һашим типмәсә дә, җилдән генә дә ачылыр иде әле ул.

— Ы! Кит! Кагылма!

— Кычкыр, ела! Урыс утарында уйнаш итеп туймасаң, туй менә!

— Хәшәрәт!.. — Гөлбануның чарасызлыктан калтыранган иреннәрен тагы шул сасык авыз үпте, йөгерек куллар өс киемнәрен өзгәләп-ерткалап атып, үзен сәкенең коры тактасына китереп салды. Шул минутта диярлек имәнеч авырту Гөлбануның күз алдында утлар уйнатты, тактагамы, бүрәнәгәме бәрелгән башы аңыннан яздырды...

— Әни... су... су бир әле, әни! — Тамагы кипкән Гөлбану күзен ачып тирә-ягына карады.

— Аһ!.. Һашим?! Син монда нишлисең?!

— Әни... — Һашим кеткелдәп көлде. — Әниеңнең генә кызы шул син хәзер...

— Ай!!! Нишләдең син, Һашим?! — Үзенең ялангач тәнен күрүдән аңына килгән Гөлбану кычкырып елап җибәрде. — Ерткыч син, Һашим!

— Исеңдә тот, Гөлбану: ирләрнең барысы да ерткыч. — Ул тагы хихылдап көлде. — Әлбәттә, Габделәхәт белән Шариктан башкасы, ике имгәк. Пешеп, авызларына төшәргә торган алманы да йота алмаганнар.

— Инде нишләргә миңа, инде ни хәл итим? Әни!..

— Нишлисең... Менә мин нишлим соң? Күрәсеңдер бит: учакка ут ягып утырам. Өй җылытам. Син дә тор, итәк-җиңеңне рәтләштер. Ертылган ыштаның жәл булса, шәһәрдән ефәген апкилеп бирермен.

Гөлбану кинәт теше тешкә тими калтырана башлады:

— Өшим... Мин өшим!

— Хәзер... Берәр чиләк табып, елгадан булса да су китерсәң кайнатырбыз, эчеңә җылы төшерербез...

— Мин... атлый алмыйм!

— О-о! Син бигрәк: кызлык алу — табанны ярып тоз салу түгел бит ул. Фызыу дип ашкынсаң, анысын да эшләрбез.

— Син нинди... кансыз! — Гөлбану янә сулкылдап елап сәкегә ауды: яшел алан, көрәштә җиңгән Һашим, аңа янчык сузган куллары, Ихсанбайның карашлары, үзенең өметләре, татлы-зәңгәр хыяллар белән бизәлгән

төннәре Гөлбануның күзләреннән ачы яшь булып актылар да актылар...

— Дөрес, Гөлбану, ерткыч мин. — Кинәт уйчанланып киткән Һашим учак яныннан торып сәке кырыена килеп утырды. — Кансызмын. Мәгәр сине яучылар өчен егерме чакрымда яткан утарга төнлә белән юлга чыкканда мин шактый әйбәтрәк идем. Ышан, Гөлбану: бу дөрес. Әгәр дә шунда безне кире бормасаң, ягылмаган өйнең ялангач сәкесендә түгел, каенана йортының түрендә — чыбылдык эчендә күпереп ятар идең. Әйе, Гөлбану, бу да дөрес. Син егетлекнең кадерен белмәсәң дә, матурлыкның бәясен әзрәк белә идең ул.

— Кабахәт син!

— Зөфаф төне өчен катырак әйтелгән сүзләр, әлбәттә. Шулай да... — Һашим ашыкмый гына чалбар төймәләрен ычкындыра башлады. — Сылу кыз авызыннан чыккан сүзләрнең ниндиен дә бүләксез калдыру килешмәс, — учак ялкыны аның җиңүле, масаюлы йөзен яктыртты, — моннан соң да шундый сүзләреңне җәлләмә, яме, кәләш?!

Һашимның авыр гәүдәсе астында калган Гөлбану баягыдан да ныграк авырту тойды... Азактан ул бу җәзалау чарасына әйләнгән хәлнең исәбен-хисабын югалтты.

* * *

Кинәт ачылган ишек сискәндерде Гөлбануны. Мәдинә икән. Кызый көлә-көлә, сөйләнә-сөйләнә чүмеч белән су алып эчте дә тагын чыгып йөгерде. Гөлбануга аның сүзләренең мәгънәсе барып та җитмәде. Атасыннан да, анасыннан да артык наз тәтемәсә дә, ягымлы, матур кыз булып үсеп килә аның Мәдинәсе. Әнисенең бүген кич үзе — Мәдинә хакына адәм ышанмаслык, әйтергә тел әйләнмәслек язык эш кылырга китәргә утырганын белсә әгәр... Аһ, ялгыша бит Гөлбану, ялгыша... Бәлки, Мәдинәне ФЗӨдән алып калуның икенче юлы да бардыр да, тик аны Гөлбану гына белмидер? Ә бәлки, артык куркыныч та түгелдер ул ФЗӨ дигәннәре? Юк, юк... Теге качак кызлар онытырлыкмы соң?! Аллам сакласын!.. Көфер, көфер уй уйлыйм...

Буйга кечерәге чыгып киткәч, Гөлбану оегын ямап утырган икенчесенә сүз кушты:

— Ахирәтеңнең бөтенләй көе юк, көлми дә, сөйләшми дә дигәндәй.

— Авырлы ул, апай, йөкле...

— Шушы кызмы?!

— Әйе, мастер көчләде...

— Аһ...

— Үзенә әйтмә инде, апай. Болай да алдап-йолдап кына апкайтып барам. Үзенә кул салган җирдән алып калдым.

— Берүк кул салмасын үзенә... — Гөлбану китабына текәлгән кызына күз салып алды, — бала ни... үсә дә китә ул.

Кешегә киңәш бирүе җиңел дә ул... Ә үзе, Һашим белән булган коточкыч төннән соң авырга калганын белгәч, ничек елаган иде! Бәкегә төшеп үләргә җыенган иде бит. Төн иде. Башын бәкегә инде тыктым дигәндә, тәнен пеше чыбык яндырып үткәнен тойды.

— Ай!..

— Авыртамы? Тагы кирәкме?!

Каршысында кыш көне яланаяк, яланөс Фәүзия карчык басып торганын күргәч, үзенең монда нигә килгәнен дә онытты Гөлбану. Гөлбануның уен каян белгән ул? Беркемгә дә бер сүз дә әйтмәгән иде бит ул... Хәтта әнисе кызының чыгып киткәнен сизмәгән иде...

— Нишләвең бу, инәй?!

— Сорарга рөхсәт ит: ә синең бу нишләвең?

— Мин дөньядан туйдым... Минем яшисем килми, инәй! Бөтенесенә дә син, син гаепле! Син... син... аердың мине Ихсанбайдан!

— Чү... Ярсыма. Хәзер үк кереп ят. Әгәр тагын бүгенге эшеңне кабатларга уйласаң, үзеңә үпкәлә: өеңә утлы кисәү белән куып кайтарырмын.

— Мин бит... ул... Һашимнан туган баланы яратмаячакмын! Күралмаячакмын!

— Елга күрми итек салма, кызым. — Фәүзиянең инде баштагы усаллыгы басылган иде. — Тугыз ай буе йөрәгең астында йөргән сабый үзеннән-үзе яраттыра ул. Бар, кайт, бар... Шәһәрбану уянса, коты очар...

Нигәдер буйсынды Гөлбану. Хәлсезләнеп, изрәп киткән аякларын өенә табан өстерәде.

Комсомолга керергә дип киткән җиреннән инде өч көн кайтмаган кызын эзләп, күз ачкысыз буранда утардан җәяүләп чыгып китте Шәһәрбану. Буш өйнең коры сәкесендә бөгәрләнеп яткан кызын күргәч, йөрәген тотып, идәнгә утырды. Эш, авыруы белән йончыган Шәһәрбану шул ятудан мантымады, өч айлык кына са-

бые белән Гөлбануны калдырып, якты дөнья белән хушлашты.

Мәет озатырга олылар, күрше-күлән җыелды. Гөлбану нишләргә белмәде: кәфенлеге дә юк бит, ичмасам. Шулчак, йомышы төшкәндәй, ишектән Фәүзия килеп керде. Мәет каршында утырганнар белән ияк кагып кына исәнләште. Мәет озатырга түгел, гомумән, кеше җыелган җиргә беркайчан да йөрмәгән хатынга барысы да гаҗәпләнеп, аптырабрак караганны карчык аңлады шикелле: үзенә төбәлгән күзләргә кургаштай авыр карашын ташлагач, утырып дога кылды, аннан:

— Күрше хакы — Тәңре хакы, — диде. — Менә бу төргәктә мәет өчен кирәк булган бөтен нәрсә бар. Сәдакасы да шунда. Болар минем үз үлемтегем иде, күрше алданрак киткәч, күрәсең, аңа язган. Су җылыттыгызмы? Мәрхүмәнең гәүдәсен үзем юачакмын.

Үзен гомергә бәхетсез ясаган шушы хатынны күпме аңларга тырышса да, булдыра алмас инде Гөлбану. Кем ул? Нинди кеше? Иблисме, фәрештәме? Үзе шикелле изүеннән бөтереп алып, җанын төнлә тышта калган мәчедәй тырнаган сорауларына җавап алганчы селкетсәң иде! Әнә әле дә, берни булмагандай, Гөлбануга эндәшә, дөресрәге, боерык бирә:

— Шаккатып торма, кызыкай! Олы мәеткә — олы тәрбия. Тизрәк селкен: җомгага кадәр җирләп өлгерергә кирәк. Елау белән күз чыгарсаң чыгарырсың, эш чыгара алмассың. Мәрхүмә Ходай бәндәсе булган икән, җомга көнне, изге рамазан аенда үтте. Кылган изгелекләре алдына килеп, Ходай каршысындагы сөальләрен җиңеләйтеп, җанын оҗмах түрләренә әйләсен!..

— Амин, шулай булсын, — диде мәетне юарга дип уратып алган хатыннар. — Читтән килсә дә, халык үзен яратып торды, кешегә авыр сүзле булмады, түрәләр кая җибәрсә, шунда эшләде.

Һашимның бертуган апасы — Гөлбануның каенапасы Зарифага гына мәет өстенә яуган мактау сүзләре ошамады.

— Үлгән кешегә оҗмах юрыйсың инде аны... Ну бит ирсез бала табу — зиначылар хөкемендә. Зина — тәмуг өлеше.

Фәүзия моның авызын тиз япты:

— Кемнең кая эләгере бер Ходайга гына мәгълүм, Зарифа! Килененнең әнисен — кодагыеңны хурлап кына тәмугтан котылырмын, чистарырмын дисеңме? Сүзләрем

нахак булыр да өстемә олы гөнаһ алырмын дип тә уйламыйсыңмы син?

Зарифа башкача гайрәт чәчмәде, шулай да:

— Әллә тагы... — дип, үзен яклап калырга тырышты, — мин үзем ни... әүвәл-әүвәлдән гөнаһтан куркып кына яшәгәч, ни... Кешенең төрлесе була инде, мин ни...

— Җитте, Зарифа! — Хатын-кызларның иң олысы каты итеп тамак кырды. — Мәет янында гайбәт сөйләү үзе олы гөнаһ.

— Әйе, әйе...

— Мин дә шуны әйтә алмый тора идем.

— Аллаһы Тәгалә Шәһәрбануның авыр туфрагын җиңел кылсын, — мәетнең баш очында елап торган Маһинур әйтте моны, — күпме еллар күрше яшәп, бер-беребезгә кырын караган чагыбыз да булмады.

Әнисен югалту кайгысыннан аңын җуярдай булып йөргән Гөлбану хатыннарның сүзен тыңлады да, тыңламады да кебек. Мәдинәсен күтәреп, кешегә анымоны алып биреп, керә-чыга йөргән арада, ул шуңа гына игътибар итте: Фәүзия әллә без уйлаганча карт та түгел микән? Бәлки, ул һәрчак озын күлмәк, башына, күзенә төшереп, кара яулык бәйләп йөргәнгә генә карт күренәдер?..

Шул арада мәетне өйдән чыгара да башладылар. Йөрәк майкаен сыздырып, җаннарын ут-ялкыннарда көйдереп, әнисе чыга өйдән. Башы белән түгел, аягы белән чыга. Барып кына кайтыр җиргә түгел, кайтмастай җиргә китә...

— Аһ, аһ! — Гөлбану кулыннан баласының шуа башлавын тойды. — Аһ!

— Баланы!.. Бир монда баланы... — Маһинур — балага, Фәүзия Гөлбануга ябышты. Фәүзия кинәт кенә капкара күзләрен Гөлбануга томрайтып текәде дә уң кулы белән җиңелчә генә битеннән сыпырды. Гөлбану шул минутта ук, бар дөньясын онытып, сабый тынычлыгы белән йокыга талды...

* * *

Үлгән артыннан үлеп булмый, дигәннәре дөрес икән: Гөлбану Мәдинәсен кайчак күршесе Маһинурга калдырып, кайчак үзе белән алып фермага эшкә йөгерде, Һашимы һаман шулай шәһәрдән килә-китә йөрде. Бала

туды дип, кулына алып сөймәде, килгәндә дә гел эчеп килде. Ирлек нәфсесен канәгатьләндерү белән хырылдап йоклап китте. Төшендә әллә нинди Зоялар, Людмилалар белән саташып, кемгәдер янады, кемнедер назлады. Берничә тапкыр Һашимны кертмәскә теләп караган иде Гөлбану, соңыннан үзе су эчә алмаслык булып ятты: ир көче белән тукмауның ни икәнен шунда татыды ул. Кызгандымы Һашим Гөлбануны, күралмадымы, әллә яратуы шул булдымы? Гөлбану Һашимның холкын һич кенә дә төшенә алмады. Бу хәл күпме дәвам итәр иде һәм ни белән бетәр иде, әгәр дә аны тукмаганнан соң Фәүзия карчык күрмәсә.

Фәүзия белән Гөлбану кое янында суга барган җирләрендә очраштылар.

— Абау, кара янгансың бит! Кем эше бу?

— Кем булсын, ирем бар ич минем.

— Тукта әле, ирлеген кая куярга белмәсә, күрсәтермен әле мин аңа!

Гөлбану аңгы-миңге булып судан кайтып кергәндә, Фәүзия сәкедә кырын яткан Һашимның бугазыннан буып алган иде.

— Үтерәм, Һашим, түземлегем бетте!

— Ы-у-ы-ы...

— Куйчы, инәй, нишлисең син, инәй?! — Гөлбану килеп Фәүзиянең сеңердән дә катырак кулларына ябышты.

— Эткә — эт үлеме! Ул бит синең кискән тырнагыңа да тормый! Нигә тукмый ул сине, нигә мәсхәрә итә?! Нигә ул патшаларга да тәтемәс бер сылудан көлә?!

— Ы-у-ы-ы...

— Шушының белән! — Әллә кайдан кулына уклау эләктергән Фәүзия үзен-үзе белешмәслек хәлдә кызган иде. — Сугып үтерәм, Һашим, билләһи...

— Куйчы, инәй! — Куркынган Гөлбану үкереп елап җибәрде. — Алла хакы өчен, балам хакы өчен тимә!

Гөлбануның елавы гына айнытып җибәргәндәй итте Фәүзияне, анда да бөтенләй түгел. Фәүзия уклауны Һашимның баш очыннан алып, җан җиренә китереп терәде:

— Кычкыр, эттән туган нәрсә, нигә кычкырмыйсың? Атаңны, апаеңны чакыр ярдәмгә! Нигә чакырмыйсың?!

— Судка бирәм, а-а-а... Анаңны...

— Куркытма да, анама да ябышма, Һашим, бел: бәндә хөкеменнән күптән үткәнмен! Ә сине, — ул уклауны тагы

да нытрак батырды, — шушы нәмәстәңне төйгечләп, йолкыш эт итеп йорттан чыгарып җибәрәм! У-у-ух!..

Фәүзия чыгып китте, куркынган Мәдинә сәке астыннан тавыш бирде:

— Әни, үлдеме инде Урыс Һашим?

— Үлмәде, балам. Терелмәде дә...

Шунда ишетте Гөлбану Һашимның елаганын. Исерек дияр идең — иртә әле, эчеп өлгермәгән. Канга буялган сәкедә аунап-тәгәрәп, бала шикелле үксеп-үксеп елый иде.

Гөлбану аны инде бөтенләйгә китәр, бу бусагага аяк басмас дип уйлаган иде — киресенчә килеп чыкты, Һашим аталарыннан шул көндә үк кием-салым, урын-җир китерде, фермага фуражчы булып эшкә төште, гариза язып, колхозга керде. Эчүен генә ташламады ул. Эчәргә акча табу өчен ни генә уйлап чыгармады, хәтта мескен Шәңгәрәйне дә саварга өйрәнеп китте.

— Кәләш аласың киләме? — дияр иде, аны күрү белән.

— Ыжнамы! Үзең алгансың да!

— Сиңа да алып бирәбез.

— Ы!

— Нигә?!

— Миңа Гөлбану кирәк!

— Бирәм Гөлбануны, ал!

— Алдыйсың!

— Ант итәм, чып-чын! Түлке синнән мәгәрич, Шарик!

— Мәгәриш?! Алдашмыйсыңмы?

— Менә инде, ышанмыйсыңмы? Алдашсам, баскан җиремдә җир упсын, аяз көндә яшен атсын!

Бу сүзләрне ишетү белән, Шәңгәрәй, Һашим басып торган җир убылып, мин дә төшеп китмим диптер инде, читкәрәк китә, муенсыз башын күтәргәндәй итеп, күккә карап ала.

— Алайса, оштым! — Табан ялтырата Шәңгәрәй. Инәлеп, тәкатен корытып, атасыннан бер яртылык акча ала да кире Һашимга йөгерә.

— Менә сиңа акша!

— Та-ак... Барып карыйк әле лавкага. Түлке син шушында гына утырып тор, көт.

Көтә моны Шәңгәрәй. Һашим моның янына байтак вакыт үткәч кенә килә.

— Әй, Шәңгәрәй, дус кеше! Акчаң җитмәде бит яртыга!

— Инде нишлим?

— Нәрсә эшлисең... Бичәле буласың килсә, атаңның сакалыннан тотып селкетсәң селкетәсең, ну акчасын чыгартмый туктамыйсың!

— Һы-ы-ы... Күп кирәкме?

— Күп дип, әйттем бит инде: бер яртылык.

Тагын йөгерә Шәңгәрәй мескен. Канәгать Һашим өенең ишеген очырта язып ачып керә.

— Кәлә-әш! Мин сине Шәңгәрәйгә бер яртыга сатып эчтем! Ха-ха-ха!

Гөлбану гына көлми дә, еламый да. Каткан аның күңеле. Корылык елдагы чатнап, яргаланып яткан туфрак кебек, көлсу җиргә әйләнгән аның җанкайлары...

Шушы хәлдә озатты сугышка да ирен Гөлбану.

— Ярый, кәләш, — диде Һашим, ишектән чыккан чагында, — тормыш булгач, — Гөлбануга бу алыптай гәүдәле, уйнаган кебек кенә яшәгән кешенең кинәт оялчанланып, юашланып китүе сәер тоелды, — төрле чаклар булгандыр. Үлмәсәм... кайтырмын... Малай ясый алмый киттем бит, мөгаен, кайтырмын. — Шуннан ул аптыраулы карашын үзенә текәп торган кызына иелде: — Әниеңә булыш, син зур үстең инде!

Озатучылар төркеменең иң азагында барды Гөлбану. Болай гына барды. Ирен озату нияте белән дә түгел, ил өстенә төшкән хәсрәтне ил белән уртаклашу өчен генә барды...

Сугышка ул ирен җәлләми җибәрде дә бит, ә кызын? Бу афәт аның бердәнбер кызын йотмакчымы? Балаларын җибәрмәгән ата-аналарны хөкемгә тарттыралар, хәтта хөкемгә тарттырылучылар арасында унөч яшьлек кызлар бар. Мәдинәсе бигрәк бала гына бит әле, чирләшкә генә. Әнисе булса, мөгаен, бер чарасын күрер иде. Юк бит Гөлбануның таянычы...

Ә эңгер төшеп тә килә. Табага төшеп эрегән сары майдай, кояш инде үзе бая ук югалды, күк йөзенә аннан калган кызгылт нурлар гына таралды. Тау башында үскән әнә ул каеннарны шул нурлар пешерә, өтә төсле. Гөлбану йөрәгендә дә шундый ук ут. Кояшмы пешерә аны, әллә оятмы? Урам уртасында иләс-миләс торган Гөлбану янына шулчак Мәдинәсе йөгереп килде.

— Уф, котымны алдың, нәрсә ул?!

Мәдинәнең кара-кучкыл бите кызарып киткән, ике чигәсе пешкән чиямени!

— Кем бирде?

— Бирмәде, үзем тоттым. Утаудан кайтышлый, су керергә туктаган идек...

— Шуннан ничек итеп тоттың?

— Куып! Әй шәп кача!

— Аһ-аһ, шамбы икән шул... һаман тере...

— Хәзер без аны куырабыз, әйе бит, әни?

— Әйе, әйе... юк ла, сабыр ит... Өйдә генә утыр...

— Син кая барасың ул, әни? Ә безне, бригадир абый әйтте, ни... ике көннән алып китәләр, диде.

— Беләм, беләм... Чак кына сабыр ит...

Ул арада күкне кайдандыр көтмәгәндә килеп чыккан болыт каплап алды, салкынча, дымлы җил исте. Ярсыган Гөлбануның кызын күкрәгенә кысып бер сөясе килде, әмма көче җитмәде, үзен-үзе тыйды. Гөнаһ кылырга ниятләгән бер чагында сафтан-саф баласына кагылырга батырчылык итмәде.

Атлады аяклар, киттеләр. Кинәт кенә караңгылык каплаган күктән эре-эре яңгыр тамчылары атыла. Яусын әйдә, атылсыннар, ичмасам, битем буйлап тәгәрәгән яшьләрем күренмәс... Төн караңгылыгында атлавын атлый да Гөлбану, яктыргач нәрсә эшләр ул? Төнлә пычранган намусын нәрсә белән юар?!

— Имгәнә күрмә, Гөлбану, җайлап бас. — Ихсанбай аны билгеләнгән урыннан күпкә якынрак килеп каршы алды. — Гафу итәрсез инде, ханым, килер юлларыңа келәмнәр түши алмадым.

Гөлбануның гарьлегеннән тыны кысылды: мәсхәрә итә бит Ихсанбай, күрәләтә көлә!

Чыдый алмады Гөлбану, җавап бирмичә түзә алмады:

— Әй, Ихсанбай, — диде ул эчке бер рәнҗү белән, — бала кайгысы бугазымнан алмаса, син паласлар җәйгән хәлдә дә мин анда төнен түгел, көндез дә аяк басмас идем.

— Усал син. — Гөлбану күкрәгенә Исәнбайның кайнар учы ятуын тойды. — Аннан да бигрәк... татлысың, — аның комсызланып, ярсып үбүеннән Гөлбану берникадәр тын ала алмый торды. — Кайнарсың... сылусың... — Ихсанбай, Гөлбануның каршы торырга маташуына карамый, кулларын билдән түбәнгә күчерде, күкрәгенә тешләрен батырды.

— Ыһ! — диде Гөлбану, оялуыннанмы чыкты бу аваз, авыртуыннанмы...

— Хәзер, хәзер... Күпме көттем мин шушы минутларны!

Уңайсыз хәлдә калган Гөлбану оялу катыш татлы бер ләззәт кичерде. Һашим белән күпме яшәде, ә нигә ул мондый тойгыны беркайчан да татымады? Әй Алла! Шултиклем дә гөнаһлы микәнни Гөлбану?!

Үз ирегеннән тыш килде бу очрашуга Гөлбану, ә киткәндә... шушы минутларны каһәрләргә дә, әрләргә дә сүз тапмады.

Туры өенә кермичә, болытлы төндә карага әйләнгән Акъелгага төште Гөлбану. «Шикләремне... гөнаһымны агызып алып китсәң иде, су!» Җирдәге пычракны агыза да бит ул, эчтәге пычракны нәрсә белән юарга? Әгәр дә Ихсанбай аны көчләсә, Гөлбануга, бәлки, бу кадәр дә кыен булмас иде. Ә ул, Гөлбану, шушы каһәрле, урланган очрашудан моңарчы татымаган рәхәт кичерсен әле... Кеше түгелдер ул, хайвандыр... Ә бәлки, болар бөтенесе дә төш кенәдер? Менә ул уянып китәр дә куркыныч төш күргәнлектән берәрсенә сәдака бирер...

Мәдинәсен ул чакта хәтәр эштән алып калды калуын Ихсанбай. Гөлбануның кичергәннәре куркыныч бер төш кенә булмады: Гөлбануга ул игезәк малайлар сыйфатында чынбарлык булып әйләнеп кайтты. Бу хәл Һашимның сугышка китүенә — ун, Ихсанбай белән очрашуына тугыз ай үткәч булды.

* * *

Язмыш, ахры, Гөлбануны гүргә кермичә тынычландырмаска итә. Башка беркемнеке дә түгел, аның сыерын тартып алалар. Сыер, сыер... менә бу чаклы сабыйларны ансыз ничек үстерермен? И Тәңрем, шулай сабыйларымның авызыннан соңгы ризыкны тартып алырсыңмы икән?! Гөнаһлы булсам да, бер мин гөнаһлы бит! Төн чыкканчы бик күп уй үтте Гөлбану башыннан. Һашимга да, Ихсанбайга да уйлары әллә ничә кабат әйләнеп кайтты. Беренчесе берни булмагандай, малайларым дип, хат язып ята, икенчесе башта очрашу таләп итеп йөдәтте. Соңрак, Гөлбануның корсагы беленә башлагач, исәнләшми, урап үтә, эштә юкка-барга бәйләнә торган булып китте.

Хөкүмәткә түләвегез бар дигәнгә дә аптырый Гөлбану. Һашим эчүен эчте, ләкин иң элек хөкүмәткә бурычын түләр иде. Үзләренең май-каймак ашап утырганын хәтерләми дә Гөлбану: булган ризыкларын кырып-себереп тапшырып тордылар. Почмакта мыш-мыш килеп йоклап

яткан әнә ул ике сабый, бәлки, Ходайның аңа җибәргән җәзасыдыр да, тик Гөлбануның аларны бер дә югалтасы килми бит әле. Күзгә күренсә, тавык чебеше дә жәл, болар бит адәм балалары, Гөлбануның үз чәчкәләре. Гөнаһын күтәреп, табуын тапкач, ничек кенә ачтан үтерсен?!

Гөлбану кинәт бер карарга килде: район түрәләренә барачак ул! Сыер таптырып килгән әнә ул упалнамучтан башка да кешеләр бардыр әле. Берсе аңламаса, берсе аңлар, берсе тыңламаса, берсе тыңлар...

Балалары белән хушлашты да таңнан ук торып юлга чыгып китте Гөлбану: бер түгел, кырык биш чакрымны үтәр, ләкин дөреслекне табмыйча кайтып кермәс.

* * *

Ихсанбай йокысыннан бастырылып уянды. Төшен хәтерләргә тырышып, күзен ачмый гына зиһенен тупларга тырышты. Тукта, тукта... Гөлбануның үземе, әллә кызы Мәдинәсе кудымы аны? Әйе, әйе... Ихсанбай әйләнеп, сугыйм гына дигән иде, кызыкай кызыл үгезгә әйләнде дә куйды. Китте шуннан алыш, китте көрәш. Җитмәсә, ябырылып, көчекләр тарткалый башлады чабуыннан, аларын тибеп очырам дигәнче, көчекләр юк булды — алар урынында Гөлбануның игезәкләре, имеш. Икесе дә букча асканнар, хәерче киемендә. Кулларын Ихсанбайга сузганнар да: «Бир», — дип ялварып баралар. «Бирдем бит!» — ди Ихсанбай, качмакчы була, ә алар килеп тагы да чабуына ябыша...

— Ах-ха-ха... — Ихсанбай үзе дә сизмәстән тавышлы итеп көрсенде, «Атаем, ахры, мине сугыштан алып калмады, ә тәмугка салды...» — Йөрәген тырнаган уйлардан качарга тырышып, ул уң ягына борылып ятты. Әйләнгән уңайга тезе белән Сәбиләсенең эченә төртелде. Тегесе, сискәнеп, авыз эченнән нидер мыгырданды да, авыр сулап, иренә арты белән борылды. «Балаларга җыенган әнчек кебек тутырган корсагын». Хатынының авырлы чагын җене сөйми Ихсанбайның. Эче күпкән ябык сыерны хәтерләтә мондый чагында Сәбилә. Болай да сынсыз нәрсә нәкъ албастыга әйләнә: күм-күк иреннәре салынып төшә, күрексез борыны, коры саргылт тиредән торган йөзен җыерылганчы тарттырып, өскә күтәрелә. Берберсеннән гадәти кешенекенә караганда шактый ерак урнашкан күзләре кызарып шешенә, тар гына маңгаеның яртысын каплап үскән кашларының ике очы асылынып

төшә. Әйе... Алды ул хатынның искитәрлеген! Әнисеннән генә булды. Нәфесен канәгатьләндерү өчен генә барып йөргән бу кызны алу уенда да юк иде Ихсанбайның. Авырлы, имеш. Әйтәм балага күмде: ел саен икешәрләп үле бала таба.

Гөлбану... Аны хәтерләсә, Ихсанбайның тәненә татлы бер дулкын йөгерә. Бөтен булмышы ләззәтләнү таләп итеп тулыша. Әмма теге төннән соң алар бер тапкыр да очрашмадылар. Башта Гөлбану Ихсанбайның йөзенә күтәрелеп тә карамады, ишарәләрен күрмәмешкә салышты. Ә инде корсагын күргәч... Ихсанбай, янә ыңгырашып, икенче ягына әйләнде. Корсагын күргәч, тәне эсселе-суыклы булып китте. Шушы минутта ук аңа килерләр дә: «Аһ син, хәшәрәт! Без анда кан коябыз, ә син, дезертир, солдат хатыннарыннан көлеп ятасың икән!» — диярләр кебек. Ихсанбайның кайбер кордашлары яраланып кайта да башлады. Бөтенесе дә ачулы, кара янып йөриләр. Аларның эчендә нәрсә ятканын эт белсенме? Алар янында бигүк әтәчләнеп йөрми Ихсанбай. Тәкәбберлеген артка ташлап, чаманы онытмаска тырыша. Авылда бер кеше генә Гөлбану игезәкләренең кемнән икәнен белеп алса да, көн бетәчәк Ихсанбайга. «Йә, ярый, тынычлан, — дип юатырга тырышты ул үзен. — Сыерын тартып алгач, күпкә бармас ул малайлар, болай да чыкмаган җаннары чак тора».

Күпме генә тырышып карамасын, Ихсанбайны барыбер йокы алмады. Аптырагач, тунын эләктереп тышка чыкты. Мал өендә ут янганга аптырап китте Ихсанбай: шулкадәр иртә торганнармы, әллә һаман ятмаганнармы? Карт тәмам азды шул: көн дә диярлек исереп кайта. Шул йокламый әнисен газаплый микән?

Ихсанбай иплэп кенә тәрәзә янына килде: абау, әтисе, башын учлары белән кысып тотып, мич каршысында утыра. Әллә елый да инде? Әнисе түр башында оекмы, бияләйме бәйли. Ачуы бугазына тыгылды Ихсанбайның, шул ачуының җиле белән килеп ишекләрен ачты:

— Төн буе улап утырмасаң, нәрсә җитми сиңа?

— Ычкын моннан, өтек! Ычкын сугып очырганчы! Әтиең булырга кирәк әле, маңка!

— У, картлач... Эчкече! — Ихсанбай, кызып, аның каршысына басты, әтисе аңа каршы басарга җыенган иде, буыны тотмады — мәтәлеп барып төште.

— Сугыштан... алтын биреп... алып калганда... әтиең, шәт, яхшы булгандыр?

— Кычкырма! — Ихсанбайның бармаклары йодрыкка укмашты. — Мин сорадыммы синнән? Инәлдемме? Ялвардыммы?

— Ә-ә-ә, ту-ты! — Сибгатнең иреннәре чалышаеп бөрешә. — Сорамадыңмыни? Комиссиягә алып барганда, карышып, чанадан төшеп калдыңмы? Әллә мин сине бәйләп, арканлап алып бардыммы?

— Җитте, йокла! — Ихсанбай, чигенеп, ишек яңагына сөялде. — Икенче эчеп кайтып төне буе улап елап утыр әле...

— Үзең йокла, маңка! Миннән йокы гына киткәнме? Өер-өер малларым, көтү-көтү сыерларым, сарыкларым киткән миннән! Китик, дидем әниеңә, Төркиягә качыйк, дидем! Тыңламады... Мине шушында алып килеп, колхозга көн-төн бил бөгәргә кушты! Сиңа... ансат! Син — түрә! Ә мин...

— Күбрәк эчеп, хан заманында югалган малыңны исеңә төшереп улап утырсаң, — Ихсанбай галош кигән аягы белән кабат учак каршысына чүгәләгән әтисенең башына төртте, — менә монысыннан да язарсың.

Фәүзия бәйләмен бәйләвен белде, ата белән ул арасындагы бәхәскә ләм-мим сүз кыстырмады.

Ихсанбай кире тышка чыкты. Тукта, тукта... Гөлбануның капкасы шыгырдады түгелме? Бу вакытта ни... савымчылар да тормый әле. Берәр ир килеп чыксачы шуннан. Ихсанбайга бу җитә калыр иде: ак этнең бәласе кара этка булып куяр иде. Бәй, Гөлбану үзе түгелме соң бу? Ай шундый якты, танымаса аны сукыр гына танымас... Әнә ул урам буйлап китте, әһә, ферма тыкрыгына борылмады, туп-туры олы юлга йөгерде бит әле бу. Анасын эт еккыры... Әллә райкомга жалоба белән китте?

— Нигә син... абзардан чыга алмаган токым үгезедәй котырынасың? — Ихсанбай янында әнисенең тавышын ишетеп сискәнде. Кай арада чыккан да кай арада килеп баскан?

— Һы... кем котырына?

— Бу вакытта юньле ирләр җылы түшәктә... хатыны кочагында ята!

«Хатынның нәкъ кочагыннан чыкмый торганын алып бирдең шул!» — дияргә теле кычытса да, Ихсанбай эндәшмәде. Үкенечкә каршы, әлегә өйдә әнисе хуҗа, карт бары тик аның күләгәсе. Ихсанбай карышмый гына өенә шылды. Ярар, дип фикер йөртте эченнән, китә бирсен әле Гөлбану. Җәяүләп кая бара ул? Урыс авылы Казан-

ка бар юлда, күп булса, шунда барып йоклар. Шунда куып җитәр аны Ихсанбай.

Бер карарга килеп тынычлана төшкән Ихсанбайда шулчак кыргый дәрт уянды. Күп уйлап тормады, җәһәт кенә хатынының йомры корсагына атланды.

— Ай! — Йоклап яткан хатыны, коты алынып, кычкырып җибәрде:

— Харап... харап итәсең баланы!

— Шыпырт! — Иренең теш арасыннан кысып чыгарылган сүзе Сәбиләнең авызын шунда ук япты.

— Иплән соң?! — диде Сәбилә, ыңгырашып. — Ай, ай...

— Чыелдама, кәнтәй... — Ихсанбай куллары белән хатынының тулыша башлаган күкрәкләрен уды, тешләрен батырды. Хатыны авызыннан чыккан саңгырау ыңгырашу Ихсанбайның шашкан дәртен отыры ярсытты.

— Уй! Алла! Аһ! — Сәбилә эчен тотып өзгәләнә башлауга, Ихсанбай тынычланып йокыга талды.

* * *

— Акыртма баланны, елатма! — Ир җикерүе үзенә буйсындыра, әмма Барсынбикә берни кыла алмый: җылы йомгак булып күкрәгенә сыенган баласы, үзеннән әллә ничә тапкырга зуррак тавыш чыгарып, тыныч төнне яңгырата.

— Чү, кызым! — Барсынбикәнең бер кулында ярсып чапкан атның тезгене һәм үзенең киемнәре төйнәлгән төенчеге, икенчесендә — бертуктаусыз елаган Күксылуы — Диңгезхан кулындагы Ихсанбайның игез сыңары. Әллә өермә булып өерелеп чапкан ире белән аның иптәшеннән качып калыргамы? Калыр да иде — баланың бит берсе ирендә — Диңгезханда!

Ай, нишләргә?! Ничек кенә баланы тыярга?! Берәр җире авыртадыр моның, бу кадәр еламас иде... Артта эт өргән тавышлар да аермачык ишетелә башлады. Куып җитеп киләләр. Алда елга. Шуны кичеп чыгып өлгерсәләр генә котылачак алар эзәрлекләүдән. Анда кара урман күренә, урманда юллар һәрчак төрле якка тармаклана. Бала гына еламасын иде.

— Ташла! Ташла, дим, баланы! — Барсынбикәнең баланы кысып тоткан кулын Диңгезханның камчысы көйдереп ярып үтте — акырып елаган Күксылу Барсынбикәнең кулыннан төшеп тә китте. Шул ук минутта Диңгезхан

Барсынбикә белән биянең кабыргасына шпорлы итекләре белән җан ачуына төртте. Барсынбикә күз ачып йомган арада сугамы, яргамы очкан баласы артыннан затлы киемнәре төйнәлгән баягы төргәкне ташлап өлгерде.

— Балам! — Шапырдап суга керә башлаган ат тояклары, елга шавы астында аның кычкыруы ишетелмәде дә шикелле.

Алга таба булган хәлләр дә Барсынбикә күз ачып йомган арада башкарылды: волость түрәләрен үзе белән бергә төнлә суеп чыккан юлдашының аркасына судан чыкмас борын ук хәнҗәр кадады Диңгезхан, шуннан соң Барсынбикәгә әйтте:

— Шушыннан башлап, мин — Сибгат, син — Фәүзия. Малайның исемен үзгәртмәдем. Ә Күксылуны оныт: җаны җәннәттә булсын. Документлар миндә.

— Кая китәбез? — Шул минуттан Барсынбикәдән Фәүзиягә әйләнгән хатын иренә төбәлде. — Кая юл тотабыз?

— Еракка... Фәүзия. Болар озакка килде. Бу якларга, бәлки, беркайчан да әйләнеп кайтмабыз.

Фәүзия тәмам уянып, күргән төшен хәтерләргә тырышты. Төш дисәң... Шул ук күренеш: артларыннан куалар... Күксылу бертуктаусыз елый. Диңгезхан Барсынбикәнең сабый тоткан кулына камчы белән сыдыра...

— Уф! — Ул торып утырды. Сибгате учак каршысында утырган җирендә йоклап киткән. Биреште карт. Күп эчә шул, болай булса, кирәкмәгәнне лыгырдавы белән башына җитәчәк ул Ихсанбайның.

Аталы-уллы тыныша алмыйлар. Берсе олымын дип туктамый, икенчесе кечемен дип тынмый. Нәрсә эшләргә болар белән? Ихсанбай кадерсез шулай да: әтисенең алтыннары булмаса, йөрер иде шушы көнне эчәк шулпасы эчеп...

Фәүзиянең мал өенең кечкенә тәрәзәсеннән тышка каравы булды, аңа үзенең күңеле кебек үк шомлы, шөбһәле кара төн бакты. Шушындый төннәрнең аның сердәшенә әйләнгәненә инде ничәмә ел. Беркемгә дә, хәтта иренә дә әйтә алмаган серләрен ул төн белән уртаклаша. Адәм баласы гомеренең байтак өлешен йоклап үткәрә, ә Барсынбикә-Фәүзия йокламый үткәргән төннәре исәбенә гомерен ике тапкырга озайткан кебек... Күпме уй уйлады икән Фәүзия үз гомерендә, күпме юл үтте икән? Төркиягә чыгып китмичә, елга буйлап шушы якларга кабат килер өчен Сибгатне күндерергә күпме көч сарыф итте икән?

Фәүзиянең бөтен өмете бит үзләре кичеп чыкканда баласы төшеп киткән елгада калды. Ә бәлки, Күксылу тередер? Ә бәлки, ул, елгага төшми, ярда калгандыр? Төн иде бит, караңгы иде, якында гына авыл бар иде шикелле...

Казак далаларында беркадәр яшәгәннән соң, алар шушы якка юл тоттылар. Сибгат-Диңгезхан авыллар буйлап йөреп, киез итек басты, самавыр, савыт-саба ямады. Ихсанбайга җиде яшь тулганда, Фәүзия кайдандыр бала табып алып, авылыннан чыгып киткән Шәһәрбану исемле кыз эзенә төште. Фәүзия-Барсынбикә мең михнәтләр белән табып алган кызын гомере буе яклап яшәрмен дип уйлаган иде — юк, барыбер ул теләгәнчә килеп чыкмый. Фәүзия теләгән беләнмени — Ходай бит үзенчә боера.

Фәүзия йомышын үтәргә тышка чыкса, зур өйнең тәрәзәләре яктырып торганын күрде. Бу ни хикмәт? Тукта, керим әле...

Каенанасы килеп кергәндә, Сәбилә ишек төбендә чүгәләп утыра иде.

— Ни булды, килен?

— Аһ, эчем... Үләм! Эчем!

— Хәзер үк түшәгеңә менеп ят!

— Уй, кайнәм, Ихсанбай... бала...

— Нәрсә «Ихсанбай»? Син бала таба алмаганга да ирең гаепләме? — Ярсыган Фәүзия артыграгын әйтүдән дә тыела алмады, — зиратның яртысы синең үле тудырган балаларың белән тулган болай да!

— Нишлим соң?!

— Тик кенә ят! Хәзер үлән кайнатып бирәм, һичьюгы, авыртуын басар. — Күп тә үтми, Фәүзия буы чыгып торган касәне килененә сузды да түр бүлмәгә, Ихсанбай яткан якка юнәлде.

— Ихсанбай, уян әле, тор! Сүзем бар сиңа.

— Ә...

— Бала түгелсең иркәләнеп ятарга! Әйтәсе сүзем шул. — Фәүзия сүрән ут яктысында улының күзләрен эзләде. — Бала тумыйча киленгә якын киләсе, кагыласы булсаң, зираттагы казылачак чираттагы кабер синеке булачак!

— Соң инде, әни...

— Төшенденме, төшенмәденме? Әй бәндәләр... хайванныкы кадәр дә тотнаклыклары юк...

Фәүзия янә урамга чыкты. Айга карады. Каймаланып тора ул бүген. Болай булгач, көн бозылыр микән?

Көн яманы китәр дә ул... Менә Фәүзиянең күңеле кайчан бер тынычланыр икән? Сибгат беткәнгә кайгырмый ул: Гөлбануы әрнетә аның йөрәген. Менә ул тагын сөткатыксыз калды. Өй тулы бала. Ничек яшәрләр, ничек җан асрарлар? Әнә ул ике сабый... Нишләп кенә ялгышты икән Гөлбану? Барсынбикәләрнең дә, Диңгезханның да нәселләрендә юк иде бит андый хәлләр... Нәрсә булды аның Күксылу-Гөлбануына? Аның ялгызлыгыннан, башына төшкән хәсрәтләреннән файдаландымы берәрсе? Әнә тагы кичә көпә-көндез сыерын талап алып чыктылар. Ихсанбай да йөрде шунда. Кемне талаганыңны белсәң икән, балам?! Ичмасам, Гөлбанугa Фәүзия ачыктан-ачык кереп йөри дә алмый — Ихсанбаен күршесеннән үлеп көнләшкән килене аның һәр адымын каравыллап, Ихсанбайга әләкләргә генә тора. Ихсанбай хәзер үзе дә хатынына бәйле: башта армиядән, соңыннан сугыштан алып кала торган кәгазьләрне Сәбиләнең районда табиб булып эшләгән туган тиешле абыйсы ясап бирде... Аһ шул бармакларны: кайсын тешләсәң, шунысы авырта.

* * *

Гөлбану кич урыс авылы Казанкага барып җитеп туктармын да иртәгесен районга түрәләрнең эш сәгате бетмәс борын барып җитеп, йомышымны йомышлармын дигән уй белән чыкты юлга. Борынгылар: «Ай каймаланганда, каралты-кураңны ныгыт», — дигән дә ул, нишлисең, бармый хәлең юк: тамак тәмугка кертә.

Авыл өйләре артта калды. Аның, кар шыгырдатып, авыл урамыннан үткәнен хәтта этләр дә абайламады кебек, берсе-бер өрмәде дә. Ихсанбайларда гына ут яна иде шикелле. Фәүзия карчыкны: «Ул бит җен нәселеннән, шуңа бөтен эшен төнлә башкара», — диләр. Әллә шул чын микән?

Эш дигәндә Гөлбану да иренеп тормый да бит ул. Корылык елны алар бәрәңгенең һәр төбенә су сибеп үстерделәр, суны елгадан ташыдылар. Ә быел бәрәңгесе дә уңмады: үзе эштән бушамады, авырлы булуы да комачаулады. Сыер белән әле ничек тә ач калмаслар иде — менә ничек килеп чыкты.

Әче җил, кыска сырмасының эченә үтеп, җанын куыргандай итте. Гөлбану адымын тизләткәннән-тизләтә барды. Кайсы тирәгә килеп җитте соң әле ул? Бәй, үзләренең чабынлыгына борыла торган сукмак түгелме

соң бу? Әнә бит күк тирәк кара булып күренә, аннан күп тә бармыйсың — Торна кичүе, аннан Тәңребирде елгасының аръягында аларның чабынлыгы. Кайчандыр ул җирләрдә Шәһәрбану Гөлбануга чалгы тотарга, печән чабарга өйрәткән иде, быел Гөлбану үзе Мәдинәсен өйрәтте. Игезәкләр булмаса, печәннең эшен икәүләп тиз бетерерләр иде алар.

Игезәкләр булмаса... Адәм баласыннан да аңлаешсыз зат юктыр бу дөньяда. Гөлбану менә үзендәге катлаулы тойгыларны үзе дә аңлап бетерми. Балаларны ул ике очракта да Ходайдан теләп-сорап алмады. Мәдинә күзенә күренгәч тә имезде дә кире урынына салды, үчти-үчти китереп иркәләп утыруларның ни икәнен дә белмәде. Мәдинәнең кырысрак холыклы булуын да үзе шуннан күрә: наз җитмәде аңа. Ә нигә әле менә бу игезәкләр өчен үлеп тора икән ул? Эштән шуларны сагынып, йөгереп кайтып керә, йокласалар, уянганнарын көтеп ала алмый йөри. Мәдинә кебек елгыр да түгел бит әле үзләре. Ашау җитмәгәч, капкорсаклы, нәзек кенә аяклы, зур авызлы җан ияләре инде. Мәгәр үзенә караган ике пар зәңгәр нур көлтәләрен күрсә, үзенең дә күңеленнән шундый ук зәңгәр нур агыла башлый. Бөтен дөнья шушы күзләрдән таралган зәңгәр нурга коенган кебек була.

Ә Ихсанбай йөкле йөргән чагында да, сабыйлар тугач та күпме очраганы булды, туктап хәлен дә сорашмады, әйтерсең артыннан кемдер каравыллап килә. Ә инде сыерын алырга килүчеләр арасында Ихсанбайны күргәч укшыды Гөлбану. Шушы кешегә карата кайчандыр йөрткән хисләрен дә, аның белән үткәргән теге төн тәэссоратларын да — бөтенесен берьюлы косып чыгарасы килде...

Юл тауга үрмәләде, аннан төшсәң — Тирән үзәк. Үзәкне үтүгә, таң да яктырыр. Таң атса, бәлки, артыннан берәр атлы кеше килеп чыгып, утыртып та барыр. Үр җиле әче шулай да. Гөлбану ике йомарлам корт, бер икмәк төйнәгән төенчеге белән битен каплады. Шулай итеп, бер алды, бер арты белән бара торгач, үзәккә төште. Монда тау башындагы кебек көчле җил юк, әмма бөтерелеп күтәрелә. Тирән үзәк буйлап байтак барасы бар бит әле, бөтерелгәч, буранга әйләнеп китмәсә ярый да... Гөлбануның аркасыннан ниндидер салкын калтыравык йөгереп үтте. Кызу атлагач өшемәде дә кебек, нигә болай калтыратып җибәрде әле?! Гөлбану белән мондый хәл булганы бар барлыкка, тик ул нигәдер ташкын вакытындагы агымны күргәндәй була. Төшендә дә ул, үзен

йотарга килгән дулкыннарны күреп саташып, бастырылып уянганы бар. Бәләкәй чагында әнисе аны багучыга да алып барып карады. «Судан курыккан бу бала, — диде әби, — бәләкәй чагында батканы йә агып китә язганы булмадымы?» Монда ни... тып-тыныч бит. Тирә-ягында зирек шәүләләре генә чайкала. Бәй, әллә инде юлда ут та күренде? Печәнгә килгән кешеләр дияр идең — бу вакытта урлашырга гына килмәсәләр? Аннан соң, яңа чана юлы да күренмәде шикелле. Әллә күренеп тә Гөлбану үзе абайламадымы? Утлар инде яннан да күренә башлады, артына әйләнде — анда да утлар. Таң алдыннан төшкән куе караңгылык әллә шушы утлардан, әллә көчле җилдән чайкала. Шулчак Гөлбануның йөрәген үткен пәке белән телделәрмени: «Бүреләр!!!» Икмәк салынган төенчеге белән битен каплап, Гөлбану әкрен генә җиргә чүгәләде...

* * *

Ихсанбай эшкә таңнан ук йөри. Бүген исә бигрәк иртәләде. Беренчедән, почмакта шыңшып яткан хатынын күрәсе килми. Икенчедән, әнисенең бөтен нәрсәгә кысылып йөрүе саруын кайната. Ихсанбайның Сәбиләгә өйләнүе дә шул әнисенең тыкшынып, күзәтеп йөрүеннән килеп чыкмадымыни? Шуның аркасында Сәбилә белән яшәгән гомере зирек утыны, арыш икмәге кебек: уты яна — җылысы юк, ашап эчең тула — кәефең күтәрелми.

Әнисе белән әтисенең бетмәс талашлары да туйдырды аны. Әтисе әле булса үзенең совет власте тартып алган малын җәлләп елый, шуңа кайгыра торгач, эчүгә сабышып бетте. Әнисе, кулыннан дәүләте китсә дә, һаман да хан кызы кыланмышларын ташлый алмый. Дөресен әйткәндә, Ихсанбай әтисен хәзер санга сукмый. Ул аның эчкән баш белән тиешсез җирдә юк-бар сүз сөйләп куюыннан гына курка. Ә менә әнисе... һич аңламассың аны, һич төшенмәссең. Кичә булган хәлне генә әйт әле син. Колхоз фронтка оек-бияләй җибәрде. Караса, әнисе дә килгән, кулында олы бер төенчек. Алып килгән оекбияләйләрен һәрберсен санап яздырды. Секретарь чыккач, әнисе белән икәүдән-икәү калды. Ихсанбай сүзне ерактан уратып маташмады:

— Менә кайда яткан ул патриотка! Белмәгәнмен...

— Инде белдең.

— Тик бер атнакысы бар бит әле, — Ихсанбай энисенең күзенә туры карарга тырышты, — патриотның баласы... дезертир булмый.

Әнисенең болай да йомылган иреннәре тагы да ныграк кысылды, иллә мәгәр йөзен үзгәртмәде:

— Ихсанбай, син барыбер әйбәт солдат була алмас идең, чөнки син... әйбәт ул була да белмисең. — Шулай диде дә ишекне каты итеп ябып чыгып та китте.

Сәер хатын аның әнисе, бик сәер. Йә, бүген иртән нәрсә диде? Имештер, зираттагы чокыр синеке булачак... Ә инде Гөлбану игезәкләренең асылына төшенсә, ул чагында... Ул чагында әнисе Ихсанбайны тереләй тунаячак. Кеше чын сөйләсә, заманында ул Алладан да, бәндәдән дә куркуның ни икәнен белмәгән Һашимны кереп кыйнап чыккан хатын... Игезәкләр кеше тел-тешенә кергәләгәнче дөньядан киткәне хәерле инде. Әлбәттә, Гөлбануны ничек тә туктатырга кирәк. Менә сиңа — юаштан юан чыккан. Һич уйламаган иде, ул хатын мондый карарга килә алыр дип, башына да китермәгән иде...

Үз уйларыннан үзе өшегән Ихсанбай кулын мичкә терәде. Мич эссе иде әле. Рауза мичне күптән томалаган, күрәсең.

Ихсанбай кәнсәләрендә байтак уйланып утырганнан соң, Рауза килеп керде. Үзенең колач ярым гәүдәсе белән ишектән көчкә үтте дә эскәмиягә җәелеп утырды. Ихсанбай бүген кәнсәләргә чакыртыласы кешеләрнең исемлеген язып бетергәнче, Рауза авылның соңгы яңалыкларын түкми-чәчми тасвирлап сөйләп бирәчәк. Ихсанбайның кулында каләм, бер колагы телефонда, икенчесе — Рауза авызында. Шулай гадәтләнгән.

— Әй бу адәмне, әй бу халыкны...

Ихсанбай тыңлап утырганын белдермичә, Рауза дәвам итмәячәк — бер-берсен өйрәнеп бетергәннәр.

— Нәрсә булган, Рауза апай?

— Аһ шушы Ихсанбайны... Нәрсә булды дип, миннән көлеп утырасыңмы? Соң, син силсәвитме, минме?

— Соң инде, Рауза апай...

— Рауза апай, Рауза апай... Мин инде, Аллага шөкер, туганнан бирле Рауза...

— Шулаен шулай да...

— Шулай булмый, — аның шомырт бөртегедәй күзләрендә хәйлә галәмәте уйнап үтте, — мин бит әтиең белән әниеңнең сине җитәкләп, кирәк-яракларын ике тәгәрмәчле арбага төяп, Тирәклегә килеп кергәннәренә

тикле хәтерлим. Әйе, әйе! Авылда беренче очраган кешеләре мин булдым. Совет йортын да мин күрсәттем аларга. Җизнәң бүләк иткән теге алтын балдак югалмаган иде әле ул чакта. Әйе, әйе! Башка бармакларыма ярамагач, уң кулымның чәнчә бармагына кигән идем шуны...

«Җизнәң бүләк иткән алтын балдак» Ихсанбайны әллә кайчан туйдырган, туйдыру түгел, гайрәтен чигереп бетергән. Шулай да түзә Ихсанбай, Раузаны туктатмый, чөнки белә: ул моннан утыз ел элек узгынчы бер татарны йортына кертеп, шуның белән бишме-алтымы ай яшәгән дәвереннән бер баласын — Хөсәенен — һәм алтын дип алдап биргән, шуның аркасында урлаткан балдагын сөйләмичә ары китмәячәк. Ярый ла сүзенең башы балдак белән генә бетсә? Әгәр дә шул татар белән Кызыл Мәчет базарына барганын, шунда аерылып, бер-берсен югалтып, ялгыз кайтканын сөйли башласа? Ә балдагын урлату вакыйгасына керешсә, үзе бер кыйсса, үзе бер хикәят. Шәһризадәнең әкиятләре бер читтә торсын. Күрмиме икәнни бу хатын Ихсанбайның бүген кәефе юк икәнен? Туктарга уйламый да бит ичмасам! Әнә аякларын тагы да киеребрәк утырды. Җәелде. Арты эскәмиягә ябышып калыр инде, болай булгач... Ихсанбай, ул сөйләгән арада, буш урын табып, сүз кыстырып калырга, тегенең игътибарын читкә юнәлтергә ашыкты:

— Мичне әйбәт яккансың... — Түрәнең мактавына барометр кебек сизгер Рауза моны шунда ук эләктереп алды. Ихсанбай, ниһаять, иркен тын алды.

— Кызу ягам да ул ягуга, Ихсанбай энем. Ягам, ул ягын... — үзенең үтә дә тугры хезмәт итүен телгә алырга форсат чыгуына куанудан Раузаның иреннәре калтыранды. — Түлке менә утын әзерләве...

— Анысын мин кайгыртам да инде, Рауза апай.

— Кайгырту белән дә... Әнә әле кичә кич утынга киткән Ишмәмәт нәрсә эшләп ята... Бу бит бары шул Зарифаның комсызлыгы аркасында килеп чыккан хәл! Урам тулы бары аларның утыны гынадыр, шәт. Ул кешедән ташыткан, ул үзләре ташыган... Әйтәм бит, бары Зарифа аркасында Шәңгәрәй ябалак — әтисез, Зарифа бичура үзе ирсез кала язды. Әллә, мин әйтәм, Ихсанбай энем, апаеның каргышы төшеп...

— Аңламыйм...

— Аңламаска ни... Ишмәмәтнең беренче хатыны Зарифаның бертуган апасы иде бит.

— Аны әйтмим... Кичә кич Ишмөхәммәт абыйга ни булган?

— Мин дә как рас шуны сөйли генә башладым түгелме? — Раузаның шомырт кара күзләре ризасызлык очкыннары чәчте. — Нибары шуны сөйләмәкчемен. Зарифага тел тидерә дисеңдер инде? Ну бит үзенең дә теле дилбегә буе! Аның теле! Кичә орлык тазарткан җирдә сөйләп тора, ди. Имештер, Гөлбануның игезәкләре энесеннән... теге ни... Урыс Һашимыннан түгел, дип. Ышанмасагыз, дип әйтә, ди, бармакларыгызны бөгеп санап карагыз: Һашимыбыз кайчан китте дә Гөлбану кайчан бәбәйләде, дип.

Аркасыннан тир бәреп чыккан Ихсанбайның башы әйләнеп, тамагы кипкәндәй булды — графиннан җәһәт кенә су салып эчеп җибәрде.

— Рауза апай, ни... — Ихсанбай, кандала тешләгәндәй төрле-төрле җирләрен кашып алды, — синең әйтергә теләгәнең...

— Как рас шуны әйтәм дә инде: Зарифаны һәм Ишмәмәтне. Ишмәмәткә барган бит Гөлбану. Сыерны алырга син кушкансың, район түрәләренә жалу белән барам, үз сыерыңны китереп бирерсең, дип. Зарифа бит инде шуңа да котырына. Элек тә бит алар Гөлбануны ярлы дип яратмадылар. Ишмәмәт Гөлбануга: «Минем гаебем юк, рәспрәжинене күршең, силсәвит бирде!» — дип чыгарган. Вәт менә оятсызлык кайда? Син бит инде кош балалары шикелле авызларын ачып яткан сабыйларны үз белдегең белән шулай итеп ризыктан мәхрүм итәсеңме? Андый фәрманны син, Ихсанбай энем, үлгәндә дә бирмисең! Гөлбану бит франтавик хатыны, районга барып җитүен җитсә, аның сүзе рас булмый, кемнеке рас була?

«Ишмөхәммәт — төлке», — дип уйлады Ихсанбай, моны ишеткәч. Фермадагы үлгән терлекне кешенең шәхси малын җыеп капларга мөмкин булуын алар бит икәүләп уйладылар. Ихсанбай гаепле булса да, исемлеккә Гөлбануны кертүе белән генә гаепле.

— Рауза апай... — һаман тәмләп-тәфсилләп сөйләвен белгән бу хатынга ни әйтмәкче иде әле? Хәтерең бар булгыры... — Ә, әйе... Мине сорасалар, сарык абзарларын карарга китте, диген, яме! Хәзер ат җиктерәм дә...

— Мин бит баядан бирле сиңа шуны тукыйм. Утынга дип барган Ишмәмәтне... — Ихсанбай колагына «бүреләр» дигән сүз чалынып калды, әмма аның бер аягы эчтә, икенчесе тышта иде. Ашыгырга кирәк, туктатыр-

га кирәк Гөлбануны! Яңарак кына сугыштан яраланып кайткан Камалетдиновка әләксә, әллә кайсы җиреңнән асып куяр. Сугышка бармаганнарны, тыл күселәре дип, яман нык яратмый, диләр...

— Гөлбану чабынлыгын кыеклатып, яр астыннан килеп чыкканнар, ди, бүреләр. — Ихсанбай чыгып китсә дә, Рауза туктый алмый сөйләвен белде. — Ярый әле Ишмәмәт теге сары айгырны җиккән булган! Айгыр булмаса, шушы көнне Шәңгәрәй мескен ятим, Зарифа сантый ирсез кала иде. Ирсез калсаң, аңлар идең син дә ирсез хатыннарның хәлләрен. Син, мужет, икәүне түгел, өчәүне шунда ук табар идең. Артым сасык дип тормыйсың, кеше белән булышасың: апаеңның үз үлеме белән үлмәгәнен, нибары синең, җизнәңә гыйшык тотып, мунча ташына тавык тизәге ыргытып, ис тидереп үтергәнеңне бөтен дөнья белә! Ялгызлык... — Үзен жәлләүдән күңеле тәмам йомшарып, борыны җебеп киткән Рауза, итәгенең эчке ягын әйләндереп бер сеңгерде дә, тәмам тынычланып, эскәмиягә сузылып ятты. Гәүдәсенә күрә шактый бәләкәй күренгән башын йомры беләгенә салып йоклап китте...

* * *

Ихсанбай ат сараена барып кергәндә, Раузаның улы Хөсәен лапас астыннан чыгып килә иде. Бу, күрәсең, атларны эчерергә чамалап йөри. Эчерми торып, атны җикми киреләнер микән? Хөсәенне бу эштә ат җанлы булган өчен тоталар да бит, әнә шул сыйфаты өчен сугып җибәрәсе килгән чаклар да аз булмый.

— Сары айгыр мондамы, Хөсәен?

Хөсәен җавап бирергә ашыкмады, күренеп тора: сул ягы белән торган.

— Сиңа әйтәм, Хөсәен, айгыр мондамы?

— Сары айгырмы? — Хөсәен теш арасыннан чырт иттереп төкерде: — Ул пизди!

Менә бер галәмәт: армиягә тиклем гади бер егет шуннан «в» авазы урынына «п» дип, кызып киткән чакларында урысча сүгенергә өйрәнеп кайтты. Берәүләр аны кайтып килгәндә поезддан ташлаганнар, шуннан шулай булып калган диләр. Икенчеләр армиядә хезмәт иткән чагында кыйналганнан шундыйга әйләнгән диләр. Кайсыныкы дөрестер инде, әмма аңа ат җене кагылуы бәхәссез.

— Ничек инде визди, Хөсәен? Сары айгыр колхозда ничәү?

— Йөз, мең — менә ничәү!

Чыгырыннан чыгып кычкырган Хөсәенгә Ихсанбай шикләнеебрәк карады: әллә моңа ат җененнән башка тагын башка зәхмәт кагылганмы?

— Шаяртма, Хөсәен! Атны җик, чана минем өйдә. Районга чыгам.

— Сорыйлар да сорыйлар... Әле генә берегез бүредән ашата язды! Псим нада! Пси просят! Юк сары айгыр, псю! — Әйткән уңаена Хөсәеннең тире туны эченнән кукишы да килеп чыкты.

— Кем белән сөйләшкәнеңне оныттыңмы? Әйтелгән — үтә!

Ихсанбайның кызганын төшенде, ахры, Хөсәен, йөнтәс төлке бүреге астыннан бүре кебек карап, лапас эченә шылды.

Урам буйлап өенә кайтып барганда ук Ихсанбай җилнең буранга әйләнеп котырына башлавын тойды. Толып алмыйча да булмас...

Толыпка дип мал өенә кергәндә, әнисе һаман йон белән булаша иде.

— Буран башланырга торганда юлга чыгарга булгансың икән... — Фәүзия аңа каш астыннан сөзеп-сынап карады. — Ул ниткән ашыгыч йомыш?

— Сугыш вакытында бөтен нәрсә дә ашыгыч, — диде Ихсанбай толыбына үрелгән уңайга. — Үзеңне белсәңче: җомгасына егерме пар оек-бияләй өлгертәсең...

Әйтте дә чыгып та китте. Әле кайчан гына берәр җиргә китәсе булса, әнисеннән фатиха сорар, теләктә торуны үтенер иде. Әнисе исә, җамаяк тутырып, сөт эчереп озатып калыр иде.

* * *

Гөлбануга бәйле ни генә эшләсә дә, ахыры хәерле бетмәгәненә үзе дә аптырый башлады Ихсанбай. Аны очрашуга чакырды — Сәбиләгә өйләнде; янә бер очрашуының әче җимеше булып, игез бала туды; колхозга бер аның гына сыерын тартып алмадылар — райкомга әләкләргә ул китте. Һәм, гомумән, Ихсанбай күңеленең гомере буена ярга чыгарып ташланган балыктай тыпырчынуына шушы Гөлбану гына гаепле түгелме икән? Алай дисәң, гаепне бер Гөлбанудан гына эзләү дә дөрес түгелдер: Ихсанбай

бит, гомере буе елганың ике ярыдай, икегә бүленеп, үзе яшәгән тормышын яратмый, шикләнеп, икеләнеп яшәде. Ихсанбай: «Яшәсен партия, коммунистлар!» — диде, әнисе: «Зилзилә, вәхшиләр», — дип карганды.

Хәтерендә аның пионерга кергән көне. Кызыл галстук тагып, шатланып кайтып кергән улына әнисе:

— Бу нинди галстук булсын?! Күпме адәмнең башына җиткән элмәк бу! — диде.

— Такмыйммы әтү? — Аптыраган малай бер әнисенә, бер әтисенә карады.

— Тагасың инде, такмый кая барасың? Син туганчы ук тагылган иде бит ул...

— Элмәк булгач... мин аңа буылып үлмәмме?

— Үзеңне түгел, хәтереңне буар өчен уйлап табылган нәрсә ул.

— Хәтерем барчы минем, — дип, ничек булса да үзен якларга тырышты Ихсанбай. — Бүген әле арифметикадан биш алдым.

— Хәтерең булгач, син миңа җиде буыныңны, нәселнәсәбеңне, ил саклаган батырларны санап күрсәт!

— Ни... бабабыз... Лилин. Әтиебез...

— Партия...

Ихсанбай бер әтисенә, бер әнисенә карады:

— Минем әтием икәүмени, әни?!

— Хәтерем бар, дисең бит, үзең уйла.

Төштән соң аларның классы мәктәпкә барырга тиеш иде. Кикриге шиңгән Ихсанбай галстугын чишеп кесәсенә тыкты да, гадәтләнгәнчә, Гөлбануга керде. Кызыкайның битләре дә галстугы кебек балкып, нурланып яна, зәңгәр күзләре очкыннар чәчә. Ихсанбайны күрү белән, ул урыныннан сикереп торды:

— Ленин, Сталин эше өчен көрәшкә әзер бул!

Ихсанбайның кулы бик әкрен, ләкин барыбер күтәрелде:

— Һәрвакыт әзер...

Шуннан алар икәүләшеп мәктәпкә чыгып киттеләр. Мәктәп капкасына җиткәч, Ихсанбай галстугын кесәсеннән чыгарды да муенына такты.

Ул чактан бирле күпме гомер үтте. Ихсанбай да күптән инде адәм баласының әти-әнисе бер генә булуын аңлады. Әмма бер нәрсә үзгәрмәде: кесәсендә йөргән галстуктай, уе — бер, эше икенче булды...

Айгыр пошкыра-пошкыра тауга менеп җитүгә, җил каршыга әйләнде.

— Инәңне... — Ихсанбай толыбына ныграк уранды, — эт талагыры нәрсә! Хет кире борыл, авызыңны каерыйм!

Шулвакыт Ихсанбай колагына үзәк өзгеч тавыш ишетелде. Бу йөрәк ярырдай иңрәүгә бихисап улау, канга сусап ырылдашкан тавышлар кушылды. Айгыр колакларын шомрайтып, кинәт үрә торды да артка чигенде. Янтайган чанадан егылып төшә язган Ихсанбай бөтен көченә чанага сеңәрдәй булып тартәгә ябышты. Дилбегә! Дилбегәне кулдан ычкындырмаска! Ул арада баягы тавыш янә кабатланды. Бу рәвешле итеп йә җир, йә җил генә үкерә алыр, гади адәм баласы мондый тавыш чыгарырга сәләтле түгелдер.

— Малкай! Коткар, малкай!

Кыргый ярсу белән чапкан аты авылга якынайгач кына Ихсанбай үзенең нәрсәне кысып тотканын аңлады: мылтык икән. Әйе ләбаса: толыбы белән бергә мылтыгын да эләктереп чыккан иде бит ул! Эченә җылы йөгергән Ихсанбай шунда гына артына әйләнеп карарга тәвәккәлләде — анда бернәрсә күрерлек түгел: таң яктысы иңә барган юл ак буранда кайный. Шулай да, сакланганны сакләрмын, дигән Ходай, Ихсанбай калтырап торган юеш бармакларын көчкә селкетеп, ике көпшәле мылтыгын һавага төбәде...

* * *

Фермадан кайту белән Мәдинә учакка ут якты. Суына башлаган өй казанда кайнаган су пары белән тулды. Самавырга шул кайнаган суны өстәгәч, утлыгына учактан күмер салды. Өй дә җылынган кебек булды, самавыр да җырлап кына утыра. Бәләкәчләрне инде күршесеннән кереп алса да булыр иде, тик алар керү белән ашарга сораячаклар, ә өйдә бернәрсә дә юк. Базга төшеп, тагы бәрәңге эзләп караса әллә? Уйлады да баз эченә төшеп китте Мәдинә. Менә хикмәт: эзли торгач, буралган таш арасыннан өч бәрәңге чокып чыгарды! Инде яшәргә була. Учак астындагы утны тергезеп, Мәдинә шул бәрәңгеләрне кайнар суга салды да күршеләренә йөгерде.

— Әниең кайтканчы, бездә генә булсалар да ярар иде... — Маһинурның изгелеге һәрчак күңелен йомшарта Мәдинәнең. Менә әле дә аның шул сүзеннән күзенә яшьләр килеп тыгылды.

— Уй, апай, болай да инде... — Ул, яшьләнгән күзләрен күрсәтмәс өчен, сабыйларга иелде. — Кич тагын китәм инде фермага. Әнием районга бүген генә барып җитә алмас инде, ни, хәерчегә җил каршы дигәндәй, бураны чыкты.

— Ихсанбай иртүк ат җигеп олы юл белән киткән иде, очрап утыртмады микән?

— Әллә шул... — Мәдинә борчылу тулы кара күзләрен тәрәзәгә әледән-әле килеп сугылган буранга төбәде. — Апай, мин боларны сиңа тагы кертермен инде... тамакларына ашатыйм да...

— Кертмичә нишлисең? Мин сез килгәнче малны карап керәм дә...

Ике баланы күтәреп, буранга ачулана-ачулана килеп керде өенә Мәдинә. Болай булгач, бөтен өмет Ихсанбай агайда. И Раббым-Аллам, утыртып кына барсачы?!

Мәдинә иртә белән калган бер җамаяк бүрткән бодай белән бәрәңгене, кабыгы-ние белән бергә төеп, игезәкләрнең авызына каптыра башлады. Бәләкәй булсалар да, күп ашый алар — Мәдинәнең үзенә тамак ялгарлык каламы, юкмы? Мәһинур күршесе ач та тотмаган бит инде боларны — әнә авыз тирәләрендә катык эзләре бар.

Ул арада кинәт шыгырдап ишек ачылды.

— Абау... — Мәдинә уңайсызланып китте. — Буран булгач, капка ачылганын да ишетеп булмый. Кеше кергәнен аңышмый да утырам. — Мәдинә шулай дисә дә, дөресен әйткәндә, табынының ярлылыгыннан оялды. — Үт, инәй, әйдә, чәйгә утыр... — Үзенә һәрчак кап-кара күзләре белән йотардай итеп карап йөргән карчыктан шүрләсә дә, ул ягымлы сөйләшергә тырышты.

— Әниең кайда?

— Райкомга китте, Таулыга.

— Кайчан?

— Сәхәрдә үк...

— Йомышы... — Фәүзия карчык, тамагына талкан тыгылгандай, кинәт туктады.

— Йомышы шул сыер буенча инде. Салымны түләми калган чагыбыз булмады, ди. Сыерны тартып алу — мондагы түрәләрнең... этлеге, ди.

— Соң бит... — Фәүзия өзгәләнеп тәрәзәгә карады, — буран чыкты бит!

Сыерны алырга килүчеләр арасында шушы карчыкның улы Ихсанбай да булуы Мәдинәнең эчендә яшереп торган ачуын шунда ук тышка чыгарды:

— Болар бит... буран дип тормый, ашарга сорыйлар!

— Әле нәрсә ашатып утырасың? — Мәдинәгә карчыкның соравы урынсызрак бирелгәндәй тоелды. Аның болай да җир тишегенә керердәй булып торганын күрмимени ул?

— Аллага шөкер, болар нәрсә бирсәң дә ашыйлар, — дигән булды Мәдинә.

Карчык, түргә үтеп, игезәкләргә иелде:

— Йа Ходай, бу тиклем дә охшамасалар...

— Бәй, игез булгач. — Мәдинә шунда гына карчыкның төсе үзгәреп китүен күрде. — Ни булды, инәй?

— Су, су бирче әле, балам...

Карчык суны, зур-зур йотымлап, ашык-пошык кына эчте дә, йөрәген тотып, ишеккә юнәлде, аннан, артына борылмыйча гына:

— Чоландагы әйбер сезгә, — дип мыгырданды да чыгып та китте. Аның артыннан чоланга чыккан Мәдинә зур бер төргәккә абына язды. Алып кереп сүтеп карагач, анда байтак он, талкан, кипкән эремчек, сары май, тоз төрелгәнен күрде.

— Абау... рәхмәт тә әйтә алмый калдым. — Мәдинә тәрәзәгә ташланды: юк, берни күренми. Тәрәзә туң, тышта буран.

* * *

Үзләренең ишегалдына килеп кергәч тә Фәүзиянең тыны буылып, сулыш ала алмый торды. Лапас астында кычкырышкан тавышлар ишетелгәч, өенә кереп китми туктап калды. Тавышларына караганда, Ихсанбай белән Хөсәен.

— Айгырны ак күбеккә батыргансың!

— Син хуҗамыни аңа?!

— Ат синеке дә түгел — колхозныкы!

— Менә моны иснисең килмиме?

— Пси хуҗа! Пси командир! Сабантуйларда ал бирмәгән хайванны әрәм иттегез! Хәтта утынга да җигәсез!

— А ну марш моннан!

— Атны шулай суыталармы? Тәрбияли белмәгәч йөрмә!

— Чык диләр сиңа моннан, шыл тизрәк!

— Хәзер! — Хөсәен күз ачып йомганчы ат өстендә иде.

— Төш, төш, диләр сиңа! — Ихсанбай ат янында ар-

лы-бирле угаланганчы, Хөсәен Фәүзия ачкан капкадан чыгып та китте.

— Нәрсәгә дип син аңа капка ачып торасың? — Ярсыган Ихсанбай әнисенә җикеренгәнен үзе дә сизми калды.

— Мин ни... кайтып килә идем...

— Кайтып... — Әнисенең чыгып йөргәнен җене сөймәгән Ихсанбайга бу җитә калды. — Каян? Йә, каян кайтып килә идең?

Үзен кулга алырга өлгергән Фәүзия гәүдәсен турайтты, капканы шартлатып бикләде:

— Нигә син, улым, керпе йоткан аю шикелле тиреңә сыеша алмый йөрисең?

Әнисенең без кебек кадалган карашы астында Ихсанбай оялып, хәтта кечерәя барган кебек тойды үзен:

— Нигә, миңа инде хәзер беркем белән дә сөйләшергә ярамыймы?

— Гөлбану кайда?

— Нинди Гөлбану?

— Таң тишегеннән кем артыннан торып чапкан идең?

— Мин ни... кибәннәрне генә карап килдем...

— Әгәр Күксылуга бер-бер хәл булса... — Шунда гына Фәүзия кызын кеше алдында беренче тапкыр үз исеме белән атавын төшенде.

— Баскан җиреңнән төш күрә башладың шикелле син, әни! — Ихсанбай капкадан чыгып китте, Фәүзия алачыгына юнәлде...

* * *

Алачыкка кергәч, Фәүзиянең янә хәле бетте. Ярый әле улы янында бөтенләй җебеп төшмәде. Дерелдәп торган бармакларын йөрәге турысына куеп, Фәүзия сәке кырыена утырды.

— Нәкъ шулар, үзләре... — Фәүзиянең инде ничәмә еллар яшь түгүнең нәрсә икәнен оныткан күзләреннән борчак-борчак яшьләр атылдылар да саргаеп кипкән бите буйлап актылар. — Малайлар нәкъ Күксылуның игез сыңары — Ихсанбай. Ихсанбайның үзеннән тусалар да бу тиклем охшамаслар... Күксылуның үзен теге төнге ярга ташлаганда ул да кечкенә, алсу гына, күзләре әрем шикелле күк төстә иде бит... Сибгат!.. Синең боерыгыңа буйсынырга мине нәрсә мәҗбүр итте? Камчымы? Әллә балаларның икесен дә югалтудан куркумы? Яшь иде шул

Барсынбикә үзе дә. Дөрес, Диңгезханга чыккач, ул унике ел бала тапмый йөрде. Заман тәмугтай кайнаган бер мәлдә Тәңре сабыйларны аңа ни дип икешәрләп бирде икән?! Ела, Барсынбикә, ела... Соңгы тапкыр кайчан елаган идең әле? Исемдә ул көн, исемдә...

Барсынбикә белән Диңгезханның шушы Тирәкледә ике ай яшәгәч булды бу хәл! Раузаның әнисе исән иде әле ул чакта, шуларда фатирда тордылар. Киез итек тә бастылар, самавыр-комган да ямадылар. Барсынбикә ара-тирә бала табалмаган хатыннарны имләштерде, чыккан буыннарны утыртты, йөрәк тә сылады, кот та койды*.

Тимерлеккә эшкә килүен сорап, Диңгезханга рәис үзе килде. Уйлап карыйм әле, диде, Диңгезхан-Сибгат, сузды. Төпле бер карарга килер иде — Барсынбикәсеннән уза алмый. Ә хатынының ике күзе тәрәзәдә, көн дә китүне генә сөйли. Барсынбикә үзе иренең хәлен төшенә дә кебек: арыды ул илдән илгә йөрүдән, утрак тормышка күчәсе, дөнья көтәсе килә.

— Яхшы өй бирмәкчеләр, — дип сүз башлады ул беркөн, — калабызмы әллә?

Сөйләшү кара таңда башлангач, Барсынбикә иренең йөзен күрми. Тавышына караганда, Диңгезхан бу хакта күптән уйланып йөргәнгә охшый.

— Әллә шул... — Өзеп кенә ни дә булса әйтми Барсынбикә, уйларын тирәнгә яшерергә өйрәнгән инде ул. Уйламый сөйләп, серенең чишелүеннән курка. Илдән илгә, өйдән өйгә йөреп, Барсынбикә баласын эзли дигән уй ике ятып бер төшенә дә керми бит монының. Ярдамы, судамы калган Күксылуны ул, ичмасам, бер исенә дә алып карамады. Диңгезханның бар шүрләгәне — танылып кую. Ә Барсынбикәгә моннан алты ел элек Атҗитәр авылында ишеткән хәбәр тынгы бирми: беркем белән яманаты чыкмаган әүлиядай бер кыз, бала табып, хурлыгыннанмы, әти-әнисеннән куркуданмы, авылны ташлап чыгып киткән. Кая киткәнен сорашса да, беркем бернәрсә әйтә алмады, әмма кызның исеме Барсынбикә йөрәгенә уелып калды: Шәһәрбану. Бу авылдан тизрәк киткәндә, шул кызның эзенә тизрәк төшмәсләр идеме икән?

— Эндәшмисең? — Ире Барсынбикәгә борылды.

— Мин нәрсә әйтим...

---

* Кот кою — куркып авырган кешене имләү ысулы.

— Кайчан да булса бер төпләнергә кирәк лә, хатын!

— Кирәкми димим дә инде...

Дөресен әйткәндә, авыл күңеленә яткан иде Барсынбикәнең: мул гына сулы, ярларында эре-эре тирәкләр үсеп утырган елгасы бар, авылның үзен исә биек-биек таулар уратып алган. Әлбәттә, аларга, ялан башкортларына, бу тиклем биек таулар, урманнар ошап бетми, әмма шул ук таулар, шул ук урманнар яклый да, саклый да кебек.

Барсынбикә түшәгеннән торды, үрелеп пәрдәне күтәрде. Сызылып кына, моңландырып кына атып килгән таң аның йөрәгенең әллә кайсы җиреннән моң ургытты:

Ак куянкайлардан тун тектердем —
Тышкынасын нидән тышлаем?
Җәйгенәсен синдә җәйләгән идем,
Кышкынасын кайда кышлаем?

Барсынбикә җырлап бетереп, бераз утыргач әйләнеп карагаңда, Диңгезхан түшәгендә йөзтүбән ята иде.

— Аһ, ы-ы...

— Маңгайга язылган язмыш бу, Диңгезхан. Ходай әмере.

— Ходай әмере түгел бу, Барсын... Иблис кушуы.

— Ихсанбай хакына...

— Түзәм бит инде болай да! Күрмисеңме: түзәм!

— Түзсәң, бер синме?

— Син... хатын кеше...

— Кимсетмә, Диңгезхан! Токымым ил азатлыгы өчен башын салган узаманнардан килә. Оләсәм — Бәндәбикә! — Горурлыгына тел тиюдән Барсынбикәнең йөрәге ярсып тибәргә тотынды. Бер фетнәдән соң калмыклар киленнәрен, оныкларын куып алып киткәч, хәтерләренә кемнәр икәнлекләрен, кайдан килгәннәрен төшендереп торырмын, җай чыкса, үзе генә белгән юлдан токымымны алып качармын дип ияреп киткән оләсәсе күз алдына килгәч, Барсынбикәнең күзләреннән яшь ургылып чыкты.

— Барсын...

— Тукта! — Ярсыган Барсын бирешергә теләмәде. — Эндәшмә! Син... Хатын-Барсын белән кайчан хушлашканыңны...

— Җитте, Барсын... Аңладым! — Бирешеп, кечерәеп киткән Диңгезхан-Сибгат сәке кырыена шуышты.

— Качма, Диңгезхан...

— Чү, Ихсанбай уяныр...

— Йөрәгең... йөрәгең юк синең!

— Ай әттәгенәсе... — Диңгезхан каушаган, таушалган йөзен хатынына борды. — Йөрәк... Йөрәк бер синдә генәмени әллә, ә?!

Шуннан ике хәтер, һәркайсысы үзенә генә билгеле юл белән шар акырып елаган ак йомгак артыннан киттеләр, күрәсең. Аларның язмышын бер төенгә бәйләгән дә, кайчандыр дөрләп торган сөю кавыштырган бу ике җан арасына гүр салкынын өргән дә шушы йомгак...

— Бүген нәрсә эшлисең? — Барсынбикә моны иренә әйләнеп карамый гына әйтте. — Бер пар киез итегең калган, шуны бас та, сиңа әйтәм...

— Аннан башка да эш бар әле. — Диңгезхан, торып, чөйдә эленеп торган тунының кесәсенә тыгылды. — Шушыны бер хатын, кашларын ныгытып бир әле, дип китергән иде кичә. Син кара әле шуны: беләзек алтынга охшаган, кашлары фирүзә...

— Фирүзә кашлы алтын беләзек?! — Барсынбикә, түземсезләнеп, беләзеккә үрелде. — Шырпыңны сыз әле, Диңгезхан!

Шул, үзе... Баланы биләгән чакта Барсынбикә үзенең затлы киемнәрен, чулпы-беләзекләрен кушып төргән иде. Бохара ягыннан ерак бабасы хаҗга барганда алып кайткан бу беләзекләр икәү булган дип сөйлиләр иде. Аларның берсе калмыклар куып алып киткән әсирләрне яклап киткән әбисе кулында булган, икенчесе менә Барсынбикәгә язган иде дә бит. Ядкяр Барсынбикәгә килеп җиткәнче җиде буын үткән, дип сөйли торган иделәр.

— Кайдан алдың? Кем бирде аны сиңа?

— Әйтәм бит: бер хатын. Исемен ни... сорашмадым. Кызлар кебек чибек* кенә үзе, чырае бик аксыл. Чирле микән бу дип карап та куйдым үзенә...

— Кашларын ныгыт та үземә бир!

Инде шактый яктырган иртә Диңгезханның елмаюын яшерә алмады:

— Барсынбикә яңадан хатынга әйләнә түгелме?

— Уйнап әйтсәң дә, уйлап әйт, әтисе! Биш өер атын, биш тирмәсен, үзем кебек биш хатынны алтынга күмәрлек байлыгын югалткан кеше... бер беләзеккә алданырмы?!

— Ай әттәгенәсе... шаяртырга да ярамый.

---

* Чибек — нечкә.

Беләзек әзер булгач, шәлен гадәтенчә күзенә төшереп ябынып, Барсынбикә урамга чыкты. Чыккач та беренче очраган кешесе Рауза булды. Ул чакта да Рауза, әнисенә ияреп, кәнсәләр карый иде. Әле дә ул, ирләрдән болайрак адымнар белән басып, шунда китеп бара иде.

— Рауза, кил әле монда!

— Мин, апай, килер идем ул, — Рауза, кире борылып, Барсынбикә-Фәүзиягә таба атлады, — төнлә бит силсәвитне наганлы кешеләр килеп алып китте. Хәзер мин ике кеше урынында эшлим: үзем өчен дә, силсәвит өчен дә!

— Мин сине озак тотмыйм, — Фәүзия тирә-ягына каранып алды, — кара әле, Шәһәрбану исемле хатын яшәмиме бу авылда?

— Авылда Шәһәрбану яшәргә ни... өйсез бит ул! Фермада ул, баракта. Мужыт, калхуз язга бер зимнәмкә эшләтер... Түрә авызыннан чыккан сүз булганга әйтәм. Үзенекенә булмаса булмый, читтән килгәнгә шәп тә безнең түрәләр. Әй-йе-е-е... сезгә дә өй эшләп бирмәкчеләр. Сөйләшкәннәрен үзем ишеттем. Сибгатнең кулы алтын, авылда төпләнсә, өй әтмәлләп бирәбез, диделәр.

— Рауза...

— Апай, ике эштә эшләгәч, синең белән көн буе сөйләшеп тора алмыйм шул. Силсәвитне алып киткәчтен... Теге чак, мөгаллимне риставать иткәч, бер интеккән идем. Балаларга хәрефне үзем өйрәтеп йөрдем бит. Хәзер менә икенчегә. Аннан да алда хәзрәт бабайны алып киткәннәрен әйтмәдем бит әле...

— Рауза... сеңлем, карале, Шәһәрбану кем белән яши?

— Абау, абау, кем белән яши дип... Читтән килгән берәүгә монда ир әзерләп куялар дисеңме? Тот капчыгыңны! Монда әле балалы хатыннарга түгел, чиртсәң каны чыгарлык кызларга кияү чыкмый тора.

Раузаны инде туктатырмын димә. Иргә чыгу — аның авырткан җире. Шуңа бастыңмы — беттең. Барсынбикә-Фәүзия, аның сөйләп бетергәнен көтми, ферма ягына атлады. Кемдә нәрсә кайгысы дисәң дә, Раузаны да аңларга була: аның бит әле үзеннән башка өч сеңлесе кияүгә чыкмый утыра.

Фәүзия адымын бер кызулатты, бер әкренәйтте. Гаҗәп: шушыңа тиклем ул күпме юл үтте, күпме су кичте — арымады. Ә хәзер авылга бер чакрым ярым яткан фермага барып җитәр әмәле юк.

Ниһаять, ферманың озын тәбәнәк каралтылары, алардан чак кына читтәрәк утырган ике өй күренде. Фәүзия өйләрнең кайсысында Шәһәрбану яши дип кешедән сорамады. Аяклары үзләреннән-үзләре атлады, ишек тоткасына ничек үрелгәнен дә, бусага аша атлаганын да сизмәде. Караңгы почмакка өелгән түшәк-мендәр арасында селкенгән җан иясен абайлагач, нечкә генә тавыш чалынды аның колагына:

Куксел тауның башында
Кукҗан балам елыйдыр.
Май бирсәм дә тынмыйдыр,
Бал бирсәм дә тынмыйдыр...

Сабый күкрәгеннән чыккан бу сихри моң Фәүзияне чак аяктан екмады: буыннары йомшарып, әкрен генә идәнгә чүгәли башлады:

— Куксылу! Балам!

Мендәр өстенә кара бөтеркәле баш калкып чыкты:

— Куксылу түгел мин... Гөлбану минем исемем. Әнием — Шәһәрбану. Бәбәйләремнең берсе — Кукҗан, икенчесе — Бикҗан. Икәү әлегә шулай. Әнием тагы бер кызыкай эшләп бирәм әле, диде...

— Ә теге... җырны... каян ишеттең?

— Әллә... Бәлкем, әнием җырлагандыр, шунда откан-мындыр. Мин бит елак булганмын, әниемне имми елаганмын...

— Кук... Гөлбану, ә син... — Ул арада ишек ачылды, аннан үсмер кызлар кебек кенә аяклы, аксыл чырайлы кыз килеп керде.

— Уф, күз тышта каламы, әллә өй шулай караңгымы? Балам, ни хәлдә син? — Ул шунда гына чүгәләп утырган җиреннән торып маташкан Фәүзияне шәйләде. — Аһ, кунак бар икән лә! — Шәһәрбану кызы белән тезләнгән килеш сөйләшеп торган хатынга сәерсенеп карады да ашыгыч рәвештә сәкегә, Гөлбану янына утырды.

Фәүзия әкрен генә торайды, шуннан кесәсеннән беләзек чыгарып, Шәһәрбануга сузды:

— Мә, эшләде...

— Рәхмәт... Хакын...

— Кирәкми... — Аягына егылып рәхмәт әйтер бу кыз янынннан эндәшми дә чыгып китте Фәүзия. Нинди вөҗданы җитеп танытсын ул үзен? Нинди намус белән сыенып урынын, йортын, әти-әнисенең җылы кочагын, хәтта кыз

намусын шушы сабыйга алыштырган, этмичә дә егылырга торган ябык бу кызга үзен баланың әнисе мин булам дип таныштырсын?

Барсынбикә, чыккач, үзенең кая барганын, ниләр кылганын үзе дә төшенмәде. Бер исенә килгәндә, бәкегә ятып, йотлыга-йотлыга бозлы су эчә иде, икенче бер юлы зират эчендә чәчләрен йолкый-йолкый елый иде. Нигә килгән ул монда? Тәңресеннән үлем сорапмы, әллә бәндәләрнең кызыксынучан карашларыннан качыпмы? Үләргә дисәң?.. Үлем нигә аңа? Үлем Барсынбикә өчен күптән үзе үлгән. Шул яшь кенә, ябык кына кызга Күксылуның бөтен киләчәген тапшырып үләргәме? Шуның өчен илдән илгә, кырдан кырга йөреп эзләдеме ул баласын?

Барсынбикә яшәп яткан фатирларына шәмгә ут алгач кына кайтып керде. Өс-башын чишенеп тә тормый түшәккә ауган хатынына Диңгезхан-Сибгат сүз кушып карады:

— Берәрсенең хатыны бәбәйләдеме әллә?

Җавап булмады. Уттай янган Барсынбикә-Фәүзиянең авызына Диңгезхан өч көн, өч төн буе су тамызып утырды, ясин чыгартыр иде — курка. Туктаусыз саташкан, өзлексез баласын чакырган хатыны ялгышып ниләр сөйләнмәс?! Ихсанбай гына берни белми. Авыл малайларына өйрәнеп, иялəшеп тә беткән. Өйгә кайтмый уйный шулар белән. Уйнасын әйдә, өйрәнсен дип уйлый Диңгезхан. Иленнән кителеп, читләрдән чителеп яшәргә Ходай кушмасын аңа. Менә Барсынбикәсе үлсә нишләр Диңгезхан? Хатын гына түгел шул аңа Барсын. Диңгезханның кичергәннәре, башыннан үткәргәне, күргән-белгән, кылганы башка берәүнең күкрәгенә сыярлыкмы? Сыйдырса да, шушы Барсынбикә генә. Барсынбикә кулыннан агу эчәргә дә риза Диңгезхан, тик яшәсен генә үзе, Диңгезханны төннән караңгы уйлары, уттан да эссе йөрәге белән бергә-бер калдырып китеп кенә бармасын...

Дүртенче көнне, ниһаять, күзен ачты Барсынбикә. Күзен ачу белән янында тораташ кебек катып торган Диңгезханга эндәште:

— Теге чак сез... волос түрәләренең балаларын да... суеп чыктыгызмы?

— Барсынбикә!

— Сорауга җавап бир!

— Барсынбикә... тубылгыдай синең токымыңнан, кы-

чыткан тамырыдай таралган минем токымымнан... кемнәр калды соң кырылмый?! Канга кан белән җавап бирмәгән дошманны күргәнең бармы синең?!

— Каргыш тора безнең өстә, Диңгезхан! Каргыш! Мин... шуны күрдем...

Шуннан тагын аңын югалтты Барсынбикә. Соңрак җайлап савыга, торып утыра башлады. Беркөнне әзрәк ит шулпасы эчте. Шуны эчкәч, Диңгезханны янына утыртты:

— Мин монда калырга риза, — диде ул. — Өй салырга урынны үзем күрсәтермен. Тик... — Барсынбикә кинәт яулыгын сыпырды, Диңгезхан аның бөртеге дә калмый агарган чәченә шаккатырга да өлгермәде, хатыны уктан очлы карашы белән бәгырен көйдерде. — Моннан соң, — диде Барсынбикә, башыңны минем мендәргә төртәсе булма! — Шуннан ул коры сөяккә калган ияген сәкедә яткан пычакка ымлады. — Пычакны аны, хатын булсак та, без дә күтәрә беләбез.

Диңгезхан, телсез калып, Барсынбикәгә карады: юк, юк! Ул түгел! Кайда аның тирә-як байлар белән ярышып, бер көтү ат биреп, типсә тимер өзәрлек егетләрне бәйгедә, көрәштә җиңә алган, сылулыгы, сөйкемлелеге белән дан тоткан Барсынбикәсе?! Аның каршысында ап-ак чәчле, сап-сары йөзле, алашаныкы төсле чыгынкы яңаклы, сүнгән күмердәй җансыз күзле, уртлары эчкә баткан карчык утыра.

— Барсынбикә! — Коты алынган Диңгезхан, шуып, идәнгә төште, тезләнеп, хатынының аякларын кочаклады. — Барсын?!

— Кагылма. Тор. Шулай яхшы булыр. Икебез өчен дә.

Шушы көннән башлап алар арасында ир белән хатын мөнәсәбәте өзелде. Барсынбикә Фәүзия исемле каты куллы, каты бәгырьле хакимәгә, ә Диңгезхан Сибгат исемле аның шәүләсенә, өнсез колына әверелде.

...Соңгы күз яшьләремне шунда түгеп бетердем микән дип уйлаган иде Фәүзия. Юк, калган икән әле. Саклый алмады ул Гөлбануны. Табып та өлгермәстән югалтты ул Күксылуын.

— Тәңрем? Нигә инде мине бүген таңда сизгерлектән мәхрүм иттең? Гөлбануның капкасы шыгырдаган саен торып карый идем бит. Нигә генә бу юлы ярдәмеңнән мәхрүм кылдың, Ходаем?!

Тирән үзәккә җиткәч, җил басылгандай булды. Һашим, кулындагы солдат капчыгын ераккарак ташлады да кардан әрчелгән калкулыкка чалкан төште. Район үзәгеннән чыкканнан бирле җәяү атлаган аякларының балтырлары тартышып-тартышып куйды шулчак, табаннары да ут кебек яна. Шулай да рәхәт, чак кына ятып хәл җыяр да, үргәрәк күтәрелеп, Тәңребирде чишмәсенең суын эчәр. Шушы чишмәнең башындарак Һашимнарның чабынлыгы иде. Әтисе мәрхүм булды инде, хәзер кем чаба икән? Зарифа белән Ишмәмәт җыеп алгандыр әле. Хәер, болар вак мәсьәлә, иң мөһиме — ул тере, ул исән кайтып килә.

Һашим торып утырды, үтереп тартасы килде, капчыгының төбеннән бер төрерлек тәмәке тапмасмы... Бауны чишкәч, кулы җылы, йомшак тукымага тиде — Гөлбануга дигән ефәк бүләк ул. Көмеш саплы хәнҗәрен алыштырып алды шушы искиткеч шәлне Һашим. Госпитальдән чыккач, Ялта базарына барды, әнә шунда әллә чегән, әллә молдаван ире сатып тора иде аны... Һашимны тере күрәм дип уйлый дисеңме Гөлбануны: яралану, контузия алу, сукыраю, госпитальдән госпитальгә йөрүләр, аннан соң үлүе... яңадан терелүе. Терелү генә түгел — яңадан күзләре ачылу.

Баш очында карга каркылдады, якында гына саескан шыркылдады, артында козгын кычкырды.

— Кычкырма, козгын, ашыкма: Һашим сугыштан түгел, теге дөньяның үзеннән кайтып килә!

Солдат торды. Куак артыннан яшәреп, борынлап килгән бәбкә үләненә карап елмайды: Һашим сугышка кадәр шушындый матурлыкны, шушы җирне, шушы һаваны ташлап нигә читтә йөрде икән? Хәзер ул газиз туфракның бер бөртек яшел үләненә үзе әйләнергә риза булыр, әмма читкә китмәс. «Их, Гөлбану!.. Синең йөрәгеңне яулый алмаганга гына, көчсезлектән, чарасызлыктан чыгып киттем бит мин теге чак...» Гөлбану турындагы уй Һашимның битенә кызыл йөгертте, йөрәген ешрак тибәргә, ашыгырга мәҗбүр итте. Хәзер бит-кулын Тәңребирде чишмәсендә юар, учлап суын эчәр дә авылына атлар, күп калмады...

Менә ул Тәңребирде чишмәсе, язын, әлбәттә, киңәйгән, суы да саргылтрак, тирә-ягы да икенчерәк. Кышын да, җәен дә аның салкынлыгы бер чама була: туңмый да,

җылынмый да. Шушының суына госпитальдә үпкәсенә операция ясаткач сусап яткан иде ул, гел күз алдында булды ул Һашимның, күңеленнән аны эчте, учында тотып торды, коенды. Шушы чишмә тәүлек буе Һашим белән яшәү өчен бергә көрәште.

— Саумы, Тәңребирде?!

Һашим учына аккан күз яше белән әзрәк тозланган суга иреннәрен тидерде. Эчкәч, кинәт буыннары йомшарып, аяклары хәлсезләнеп, чүгә башлавын тойды. Утырыр җир эзләп, ул яфрак арасыннан шактый калкып торган ташка иелде. Кулы шоп-шома каты нәрсәгә тиде. Тукта, ташмы әллә... Кинәт эсселе-суыклы булып кулын тартып алды, бәй, баш бит бу, баш сөяге. Баштагы каушау үткәч, ул сөякне каплап коелган яфрак арасыннан өскәрәк калкытты; шик юк, бу сөяк адәмнеке. Тип-тигез булып тезелгән менә бу тешләренә караганда, бу хатынкыз башына охшый. Күрәсең, бу башның җаны чыкканга күп тә үтмәгәндер: тешләре дә ап-ак, мәрҗән кебек тезелеп торалар. Шулчак Һашим кинәт артка чигенде, зиһене томанланып, башы әйләнеп китте: баш әйтерсең лә кинәт җанланды, ул щул тип-тигез, мәрҗән кебек тезелгән тешләре белән... Гөлбану булып елмайды...

— Тәүбә, тәүбә! Юк, юк! — Һашим, артына әйләнеп карарга да куркып, килгән ягына ташланды. — Мираж, мираж! — дип кабатлады аның агарган иреннәре. — Хәзер менә кайтып җитәр дә Гөлбануын күрер, тере килеш, озатканда күргән моңсу карашы, күңелсез генә елмаюы, кызларныкыдай нәфис сыны белән бөп-бөтен, төп-төгәл килеш күрер!

* * *

Фәүзия үзенең бүген төнлә үлек кебек йоклавына аптырап уянды. Уянгач, күргән төшен исенә төшерергә ашыкты. Күңеле тоя: аның бу төше гади төш түгел иде. Тукта, төш күрдеме ул, әллә оләсәсе Күксу сөйләгәннәрне искә төшердеме аның тынгысыз уйлар билгән күңеле?

— Оләсәй, нигә синең исемең Күксу?

— Булса, аның нәрсәсе бар?

— Тик, болай гына, сәер сымак. Башкаларның оләсәләрендә шундый исем юк.

Фәүзия, ул чакта Барсынбикә, оләсәсеннән курка да, ярата да. Белә ул: ыру-зат тирәсендәге бөтен тормыш аның тирәсендә әйләнә: сыерларының җилене шешсә

дә, сарык-кәҗәгә сырхау төшсә дә, берәрсенең баласына зәхмәт кагылса да киләләр аңа. Кайсыларын бик ихлас кабул итә оләсәсе, бу чакта аның битендәге сырлары язылып, күзләре яшәреп киткәндәй була. Кайсыберләрен тыңлый да, тыңламый да кебек. Сөмсере коела да карашы бер ноктага төбәлә. Әле бүген килделәр аңа, әйттеләр, ерактан, дип. Зур гына малайны әтисе күтәреп китерде; әнисе, күзләрен мөлдерәтеп, Куксу карчыкка бакты:

— Зинһар, ярдәм ит, инәй... Унбер яшь малайга, үзе һаман атламый.

— Күрәм... — Куксу «күрәм» диде, ә үзе күзләрен ачмады. — Үпкәләмә, сеңлем, рәнҗемә миңа: бу баланы дәвалый алмыйм.

— Йа Рабби... Ничәмә зират аша, ничәмә су кичеп килдек.

— Аңлыйм. — Шуннан оләсәсе чаршау белән бүленгән тирмәнең теге ягына эндәште: — Айбагош, мосафирларны кара, бәләкәй киленгә әйт: казан асып, аш салсыннар, үзләренә ял итәргә урын-җир әзерләсеннәр.

— Инәй... — Күз яшьләре мөлдерәп аккан хатын янә Куксуга эндәште. — Бөтен өметем синдә иде, инәй.

— Аңлыйм. — Куксу шунда гына күзләрен ачкандай булды. — Тыңла: әгәр бу зәгыйфь улыңны савыктырсам, өйдә калган өч улыңа, мал-туарыңа зыян килер. Ыруыгызга төшкән каргышны шушы баланың чире тотып тора.

— Йа Рабби!.. — Хатын башын түбән иде, ире тамак кырды. Малай, берни аңламаган күзләрен чылт-чылт йомып, бер әтисенә, бер әнисенә карады.

Куксу тагын күзләрен йомды:

— Малайны рәнҗетмәгез, тамагыннан өзмәгез, яхшы мөгамәләдә булыгыз.

— Хәергә дип... сарык алып килгән идем...

— Сарыгыгызны алып кайтыгыз, юлда бер тоткарлык килеп чыгар, шул сарык белән котылырсыз...

— Йә, хуш, инәй...

— Хушыгыз.

Боларны каралты артында тыңлап утырган Барсынбикә бик җәлләде, оләсәсенең ак йөзле, моңсу күзле малайга ярдәм итмәгәненә җаны көйде. Көйсә дә, турыдан-туры бәреп-ярып әйтергә базмады...

Оләсәсе, әле генә юлаучылар белән сөйләшмәгәндәй, оныгы белән үзенең арасында сүз өзелмәгәндәй, ирен чите белән генә елмайды:

— Исемең сәер дисең инде...

— Сәер димим, кешедә юк исем, дидем. — Барсынбикә кыюлана төште. Белә ул: оләсәсенең җыерчыклары күз очында гына калса, аңа сорауны курыкмый биреп була.

— Тыңласаң, сиңа бернәрсә сөйлим, Барсынбикә.

— Әкиятме?

— Әкиятне көндез сөйләмиләр. Бик борынгы заманда булган хәл бу. Безнең кавемнәр, ыру-ыру булып, бик еракта, зур су буенда яшәгәннәр ул чакта. Маллары ишле булып, даланы иңләп йөргән, хатын-кызлар бик көчле булып, ыруның көч-куәтен җибәрмәс өчен, үзләренең башлыгын мәйдан җыеп, тирә-як батырларын ярыштырып сайлаган. Әмма берчакны, Ходайның рәнҗүе төшеп, далага зур корылык килгән: җир-су көйгән, малларга үләткыргын төшкән, Ходайдан ни тиклем яңгыр сорамасыннар — Тәңре ярдәмгә килмәгән, дала буйлап йомрандай сызгырган коры җилләр яңадан-яңа бөлгенлек китергән.

Ыру күз алдында корый, ачлыктан, сусызлыктан кырыла; зур диңгез янәшәдә генә, иллә мәгәр суы тозлы, эчәргә яраксыз...

Чарасызлык камавында калган зур ыру күзгә күренеп саеккан, бигрәк тә балалар күпләп кырылган. «Бөлдек! — дигән алар. — Бу каргыштан инде котылу юк. Барымта* өчен бу!»

Аптырашта калган ыру. Ыру башлыгы, Тумәрәс хатын, төнге йокыга талган ырудашларының баш очында тирән уйга чумган. Ыруны күп бәлаләрдән саклаган шушы хатын чарасызлыктан бүген шартлар хәлдә икән. Җитмәсә, аның карынында ике җан бар. Шушыларны тапмаса, Тумәрәс ырудан калачак. Хәзер инде аның мәйданнарга чыгып батыр сайлар мәле үтте, ә җенси теләген канәгатьләндерү өчен генә ул ир заты белән якынлык һичбер вакыт кылмады һәм кылмаячак! Шул чакта аның сизгер колагы бүре улаган тавышны ишеткән.

Бүреләр... Күптән ишеткәне юк иде аның бүре тавышын да. Корылык башлангач, алар да ташлаган иде даланы. Күрәсең, болары да узгынчылар гынадыр, ыруның калган малына ияреп килгәннәрдер.

Ыру берни белми йоклый. Көндез сусаудан, көйдергеч кояш нурыннан әлсерәгән адәм үле кебек хәрәкәтсез. Су

---

* Барымта — мал-мөлкәтен, хатын-кызны талап алу өчен чит ыруга ясалган һөҗүм.

эзләп йөргән бу далада бүре аларның беренче очраган тере җан иясе.

Тумәрәснең йөрәге бер ярсып тибә, бер тынып, төнге тынлыкка колак сала: Ходайдан җибәрелгән котылумы, кырылу-бетү чарасымы бу?! Бүре көтүе ишлегә охшаган, әгәр алар актык дөянең башына җиткәннән соң үзләренә ябышса?..

— Аһ, Тәңрем, ярдәм ит, зиһенемне яктырт, акылыма ачыклык бир! Нишләргә миңа, нишләргә?.. Карынымдагы сабыйлар тумаса, ыруым корыячак, сусаудан хәлсезләнгән ырудашларым бала табудан узганнар... Алар... бер-берсенең канын эчеп, сусауларын басар чиккә җиткәннәр. Аһ, Тәңрем...

Тумәрәс кара төндәй күзләрен тагы кара төннең кара төпкеленә төби, ялтыраган ут ноктлары якынайган саен күбәя, улаулары да тынды хәтта, ит-кан исе тоялардыр, ахры. Йа Рабби!.. Әнә дөя торган җиреннән кире гөрселдәп җиргә ауды. Йөрәгеме ярылды урталай?!

Тумәрәснең дә йөрәге, әгәр берәү булса, ярылыр иде, юк шул: анда өч җан. Ә бүреләр һаман якынрак килә, кыршау булып камый ике дистәдән дә аз калган адәм өерен.

— Шулай ук соңгы чарага мөрәҗәгать итәргәме, аһ, Тәңрем?! — Тумәрәс ашыгып җиргә тезләнде, башы белән өч тапкыр җиргә кагылды, авызыннан кайчандыр ишеткән, ләкин беркайчан да әйтеп карамаган татран-арбау яңгырады, шулчак бүреләр дә, түземен җуеп, корбаннарына тәүге һөҗүмгә ыргылды, ләкин адәм дигәннәре зур йомры ташлар булып чыкты, ә бердәнбер дөя үлеге янында үзләренең токымдашы күк яллы ана бүре ята иде...

Күксу, кулын күтәреп, оныгының шомырт кара чәченнән сыпырды, ә Барсынбикә аңа сыенды:

— Оләсәй, Тумәрәснекедәй көчем булса, бу баланы мин ирекле кошка әверелдерер идем!

— И бала...

— Оләсәй, Тумәрәс бүреләр белән киткәндер, әйеме?..

— Бар, уйна, анысы соңрак.

— Уйна дип, мин бит инде... үзем оләсәй!

— Беләм, шуңа да әйтүем: уйна.

— Аңламадым, ничек инде...

— Бар, бар... Ярый әле исемеңне алыштыргансың. Алыштырмасаң, рәнҗеш сине күптән юллап тапкан булыр иде!

— Син... — Нидер сорарга теләгән иде, әтәч кычкырды, Фәүзия-Барсынбикә күзләрен ачты. — Аһ! — Күргән төшенә гаҗәпләнеп, Фәүзия торып утырды. — Нәрсә булды бу?! Төшме, әллә бала чагындагы хатирәме яңарды? Фәүзия сәкенең икенче очына карады: Сибгат юк, кайтмаган. Карт бүре... Раузага иярләнгән дигәннәре чындыр, ахры.

Дулкынланып, куллары калтыранган хәлдә, Фәүзия комганына үрелде: Раузадан ничек биздерергә бу карт алашаны?

Ихатаны чыгып, тәһарәт алырга да өлгермәде, өй ишеге ачылды. Аннан килененең тузган чәчле башы, элеккедән дә ныграк саргайган йөзе күренде:

— Кайнәм, улың бүген дә кайтмады бит...

Фәүзиянең башына килгән беренче уе «яман хатыннан яр пәрие качкан» булса да, үзен тыйды, килене алдында тыныч, гамьсез, дөньясы түгәрәк бер адәм булып күренергә өйрәнгән бит ул.

— Аһ, аһ! — диде ул, комганыннан ашыкмый гына учлап су алып. — Кайтмаса ни, үләргә китмәгәндер бит! Бар, әнә, ирем кайтмады дип, урамга чыгып яу сал, кычкыр, ела...

Сәбилә, борынын җыерып:

— Мин алай димим лә...

— Димәгәч, начар хатыннар кебек тавыш күтәрмә. Бар, әнә сыерыңны сау, җилененә теге майны сөртеп җибәр, кичәге кебек тагы елан имеп кайтармасын... — Фәүзия ашыкмый гына, килененә боера-боера, өйалды баскычына менде. — Самавырны кичтән китергән судан куйма, аны юынырга гына тот...

— Ярый, кайнәм, шулай итәрмен. — Киленен яратмаса да, күндәмлегенә шуның исе китә Фәүзиянең. Ихсанбае ни тиклем кыланса да, бер кайтып китмәде, үз туганнары белән аралашуның ни икәнен белмәде. Авылда халык: «Фәүзия киленен сихерләгән», — дип сөйли. Фәүзиянең исә бу турыда иманы камил: Ихсанбайның күләгәсе кебек йөргән хатынны нидер эшләтергә ничек кулы барсын?!

* * *

Сибгат йокысыннан әллә нинди җиңел тойгы белән уянды. Күптән мондый җиңеллекне тойганы юк аның. Кызык, Ихсанбаен каравыллап кына барган иде кәнсәләргә, соңрак каравылчы булып төште, эчкән баш бе-

лән кызык өчен генә бөеренә төртте шушы Раузаның. Рауза да шаяру белән җавап бирде. Шаярып кына ымшым килделәр — хәзер менә икесе бер түшәктә, башлары бер мендәрдә. Дистә-дистә еллар тоткында зарыккан тойгылары бәйдән ычкынды микән Сибгатнең? Эчмәде түгел, эчте, эчен көйдереп барган сагышын аракы белән юарга исәпләде — булмады. Фәүзиянең, өзелеп яраткан хатынының, аннан баш тартуына, торараташка әйләнүенә дә ни заман... Хәзер ул дәрәҗәсен, малын, данын, хәтта исемен югалтканга да, бердәнбер улының үзенә бүре күзләре белән каравына да, хатынының төн пәриенә әйләнүенә дә, ничәмә еллар кешедән яшеренеп, кара тимерче алачыгында кара рухка әйләнеп яшәвенә дә кайгырмый. Үтте, бөтенесе дә үтте... Сибгатнең бөтен җаны-тәне тынлык-тынычлык сорый, ә аны ул шушы беренче карашка сантый гына күренгән юан хатында тапты. Кара син аны, Сибгат үзе дә әлегә тиклем көч-куәттән мәхрүм калмаган икән... Әнә Рауза, аның култык астына бәләкәч кенә борынын төртеп, бернәрсә белми мышнап йоклый.

— Их, гел шушылай гына булсачы! — Моны Сибгат үзе дә сизмәстән кычкырып әйтте.

Рауза күзен ачты, башын калкытты, симез бармаклары белән маңгаена сырышкан бөдрә-бөдрә чәчләрен артка сыпырды:

— Нәрсә дидең?

— Әйтмәдем. Йокла. — Сибгат Раузаның аркасына юрганны күтәрә төште. — Иртә әле, йокла.

— Таң сызылган... — Раузаның иреннәрендә елмаю уянды. Уңайсызлана нәрсәгәдер. — Кара әле, мин сине... уятмый йоклап киткәнмен...

— Уятсаң да кайтмас идем... — Сибгат битен Раузаның иягенә терәде. — Яныңнан торып китә алмас идем.

Рауза торды, йомры алсу беләгенә таянып, аның йөзенә текәлде, шуннан бармагын төкереклэп, Сибгатнең чигәсендәге миңне ышкып карады.

— Хы, чын миң икән. Элек... юк кебек иде...

— Кырындым бит, сакалны да кырып ташладым...

— Нигә?

— Яшь күреним дип, әтү яратмассың дидем.

Раузага бу кызык тоелды, эче катып көлеп, мендәренә капланды. Сибгаткә дә бу мәзәк күренде, хахылдап көлеп җибәргәч, үз тавышын үзе танымый торды — бу рәвешле көлмәгәненә күпме гомер үткән!

Кинәт ишек шакыдылар. Рауза сикереп торып утырды.

— Уй, әллә карчыгың?

— Юктыр. — Сибгат җәһәт кенә торып чалбарына үрелде. — Ят, ят! Үзем...

Пәрдә ябылган тәрәзәле бүлмәдә сизмәгәннәр икән — ишекне ачып җибәрүгә, биткә яңа туган кояшның ап-ак нуры бәрелде. Таныш түгел ирне күргәч, Сибгат шунда ук тынычланды.

— Кем кирәк?

— Кәнсә җыештыручысы... шушында торамы?

— Шушында.

Килүче Сибгатнең яңа гына йокыдан уянганын шәйләдеме, тавышын төшерә бирде.

— Шушында булса әйтегез: миңа тиз генә председатель белән силсәвитегезне табып китерсен. Камалетдинов үзе эзләтә, дип әйтсен.

— Ярар, хәзер!

Камалетдинов, кинәт аца төбәлеп карагандай, кашын җыера биреп, аптырап калган кыяфәттә капкага атлады.

Рауза чыгып киткәч, Сибгат, кайтыр якка юнәлмичә, Зарифалар тыкрыгына төште. Элек булса, ул монда баш төзәтергә, янган йөрәген хәмер белән басарга барыр иде. Ә бүген — юк. Гаҗәп, нигә аның эчәсе килми икән? Ә менә Ихсанбайны табарга кирәк. Харап бит: Камалетдинов үзе эзләп килгән. Районның башкарма комитеты рәисе күрше Юлдаш авылыннан диләр иде, шуннан кайтып барышлый сугылуы микән, әллә икенче берәр җитди сәбәп беләнме? Табылса ярар иде Ихсанбай, Зарифада төн кунса, шыр исеректер әле ул...

Капка эчтән бикле булып чыкты. Сибгат ярыктан карады. Әһә, эчтә Шәңгәрәй йөри түгелме?

— Шәңгәрәй!

Җавап урынына Шәңгәрәйнең эт булып өргәне ишетелде.

— Шәңгәрәй, исәрләнмә әле, малай! Миңа Ихсанбай кирәк, сездә юкмы ул?

Җавап урынына тагы өрү.

— Шәңгәрәй, тукта, ташла әле! Ач капкаңны!

— Уоф, уоф! Ыу-уаф, ыу-уаф!

— Сездәме Ихсанбай, юкмы?!

— Теслэгәнче, балагыңнан эләктергәнче, сыпырт!

— Йә, җитәр, мин сиңа «эт син» димәдем бит!

— Шарифа сулай ди! Абзар басында йоклата! Йортны яхшы каравылласаң ашатам, каравылламасаң — юк, ди!

— Йә, тукта, икмәкне мин сиңа үзем бирермен.

— Икмәкне ышын бирерсеңме?
— Валлаһи-билләһи!
— Алдасмассыңмы?
— Ант.
— Ике сынык итеп бирерсеңме?
— Ә нигә ике сынык?
— Мин аларны Гөлбануның малайларына асатырмын.
— Бирермен, бирермен.
— Гөлбануның малайлары бит минеке! Гөлбану минем кәләсем иде! Белдеңме?
— Белдем, белдем!
— Малайлар кемнеке?
— Синеке, Шәңгәрәй.
— Чын әйтәсеңме?
— Ант.
— Алайса, ашам капканы. Юкса Шарифа әйтә, каян килсен сиңа малайлар, ди. Малайларны Гөлбану җилдән тапты, ди.
— Һашим кайтса, кирәген бирер әле Зарифаның!
— Шарифа Һасимнан курыкмый!
— Ну, Ишмәмәт этиең кайтса...
— Әтием наган алып кайта, вәт! Шарифаны — тох, тох! Синең Ихшанбаеңны — тох, тох! Белдеңме?
— Авызыңнан җил алсын, Шәңгәрәй!
— Ха-ха-ха! — Эче катып көлә-көлә, Шәңгәрәй Сибгатне эчкә үткәрде. — Кара аны: икмәк бирмәсәң, мин сине дә — тох, тох!
Өйгә кергәч, Сибгат баскан җирендә селкенә алмый торды: Ихсанбае шәрә килеш идәндә ауный. Зарифа күренми. Түп өйгә үтте — Зарифа анда да юк.
— Кәнтәй...
Сибгат, иелеп, Ихсанбайның ялангач ботыннан тартты:
— Әй! Тор...
Ихсанбай янга әйләнде, ләкин тормады, хәтта уянмады да шикелле.
— Ихсанбай, Камалетдинов эзләтә сине!
— Ә?.. — Ихсанбай уянгандай булды, әмма күзен ача алмады.
Сибгат аның өстенә мич буенда торган бер чиләк суны сипте.
— Мә, хаин, эчә белми эчсәң!
— Һәй! Кем ул, ә? Эти?!
— Камалетдинов эзләтә сине, тор, тиз бул штобы.

Сибгат чыгып китте. Әле ярый Шәңгәрәй күренмәде, икмәк сорап өенә тиклем озатыр иде. Их, малайны сугыштан алып калып ялгышты, ахры. Үзе дә эчте шул, үзен онытыр өчен эчте дә бит, күрәсең, үзен түгел, Ихсанбайны онытты...

Өенә җитәрәк, Сибгатнең адымнары ышанычсызрак була барды. Хәзер аны Фәүзиянең дөм кара карашы өтәчәк. Ни уйлаганын сорашырга тырышып, күпме генә аның йөзенә карамасын, нык итеп кысылган юка иреннәрдән, керфек астына, тирәнгә яшеренгән күзләреннән аның берни дә укый алмаячак...

Шушы минутта ул кабаттан үз бусагасы аша атламас өчен генә әллә ниләрен бирер иде...

* * *

— Малайлар! — Өендә күренмәгәч, Мәдинә, энеләрен эзләп, тышка чыкты. — Малайлар, дим! Җантимер, Биктимер, сез кайда? Юклар бит... — Мәдинә, аларны эзләвен дәвам итеп, урамга чыкмакчы иде, үзләренә таба килгән ахирәтен күрде, анысы килеп җитәр-җитмәстән кычкырып сүз башлады:

— Нәрсә анда чебешләрен җыя алмаган тавыктай торасың, ахирәт?

— Малайлар әллә кая чыгып киткән. — Мәдинә Галимәнең өстендәге эре кызыл чәчкәле яшел ситсы күлмәкне шунда ук шәйләде. — Күлмәгең калын икән, — диде ул, ахирәтен чеметергә үрелеп. — Нигә эндәшмисең?

— Һәй! Сине очратып буламы? — Галимә быел яздан бирле колхоз идарәсендә кәгазьләр белән эшли. Әти-әнисе булгач, җидене бетерә алды шул ул, Мәдинә шикелле кара эштә интекми. — Сиңа киләм, ахирәт, кәнсәгә кешеләр килеп тулды, персидәтел мине чыгарып җибәрде...

— Кемнәр икән? — Мәдинәдә әле хаксызга тартып алган сыерын кире кайтару өмете сүрелмәгән.

— Камалетдинов диме шунда, этем белсен! Ихсанбай да шунда кереп калды...

— Камалетдинов районда... баш кеше була түгелме?

Әмма Галимә Мәдинәгә төпченергә ирек бирмәде:

— Әй Мәдинә! Аның Ихсанбае ни дә, Мирхәйдәровы ни. Түрә бит алар! Әллә аларда синең белән минем кайгы дисеңме? Лутчы үзеңә бер нәрсә күрсәтәм.

— Галимә...

— Әйдә әле... Теге чак әйткән идем бит! — Галимә якын-тирәдә кеше-фәлән күренмәсә дә, Мәдинәнең кола гына иелде.

Мәдинә кызыксынуын җиңә алмады:

— Әйдә соң...

Өйгә кергәч, Галимә төенчеген чиште:

— Менә!

— Кемнеке бу?

— Укытучы Сәрбиназ апайныкы.

— Уй... нинди тамаша! — Мәдинә юка ак тукымадан ике бала башлыгын бергә тоташтырган кебек итеп тегелгән әйбергә ис-акылы китеп карады. — Ничек кияргә икән?

— Артында... менә төймәсе бар!

— Уф, әйкәем... Үзең сорап алдыңмы?

— Сорамыйча... Карап тегәбез дә китерәм, дидем!

— Ә нәрсәдән тегәбез?

— Кайгырма! — Галимә икенче төргәкне таратты, аннан метр чамасы ак тукыма килеп чыкты.

— Монысын кайдан алдың?

— Савымчыларга халат тегәргә дип бирделәр, шуннан чәлдердем.

— Уй, Галимә... тотылсаң?!

— Этем белсенме?

— Әй курыкмыйсың да инде, ахирәт!

— Куркып торсаң... — Галимә яңгырап торган тавышы белән янә кычкырып көлде. — Синең белән мин «туес» дигән сүзне өйрәнер идекме? Әйдә, ал кайчыңны, җеп, энә алып килдем.

Ни чыкса, шушы Галимәдән чыга иде элек — әле дә шулай. Мәдинә аңа карулашмый буйсынырга өйрәнгән. Бала чакларында, Мәдинәгә күп булса сигез-тугыз яшь булгандыр, шушы Галимә, Алайгыр базарына барып, урыслардан урысчага өйрәнеп кайтыйк дип котыртты. Әтисе Мөхәррәм агай, бик каты үтенгәч, утыртып алып китте боларны. Караңгыдан ат җигеп чыккач, иртәнге уннарга барып керделәр. Шулкадәр күп халыкны күрүдән Мәдинә дә, Галимә дә башта каушап калдылар, Мөхәррәм агай, атын койма буена туктатып, ыңгырчагын бушатты да:

— Мин әнә теге якка барып әзрәк сату итәм, сез арбадан төшмәгез, атны күздән югалтмагыз! — диде. Үзе, сатуга дигән әйберләрен алып, халык арасына кереп китте.

Мәдинә белән Галимә күпме генә тырышып тыңла-

масыннар, халыкның сөйләшкән сүзе монда килеп ишетелми. Урыс дигәне кайсыларыдыр, әнә ул юан-юан сары йөзле хатыннар шулар микән?

Бераздан үзләреннән ерак түгел бәләкәйрәк бер өй торганын күрделәр. Галимә сикереп төште дә:

— Барып карыйм әле, нәрсә икән! — диде.

— Әтиең күреп калса киткәнеңне...

— Күрсә... — Тиктормас Галимә инде өйгә барып житеп, ишек башындагы язуны укып маташа иде. — Л-а-в-ка — Лавка, Мәдинә, лавка!

Ул арада лавка болдырына бер хатын күтәрелде, Галимәгә елмаеп сүз кушты:

— Кто ты будешь, девочка? То есть, чья будешь?

Галимә, бу тагын берәр нәрсә эндәшкәнче дип, арба ягына йөгерде.

— Нәрсә диде ул сиңа? — Ят апай белән сөйләшкән Галимә үзе дә бик серле булып киткәндәй тоелды Мәдинәгә.

— Ишетмәдеңмени: туес, диде.

— Туес?

Аннары кайтып барганда Мәдинә, Галимәгә карап, авыр көрсенеп куйды:

— Әй... урысча да өйрәнеп булмады...

— Һи... «туес»ны өйрәндек лә инде?

— Аны Рауза да гел әйтә!

Әле менә, ак миткальне кискәли башлагач, шул базарга бару исенә төште Мәдинәнең.

— Моны укытучы хатын кемнән отып алды икән? Әллә марҗалардан күрде микән?

Галимәнең моннан башка да яңалыклары күп иде Мәдинәгә сөйләргә.

— Ахирәт, сезнең күрше, теге карт алаша, нәрсә эшли, беләсеңме?

— Ихсанбаймы?

— Түгел, теге ни... карты!

— Сибгат абыйны әйтәсеңме?

— Шуны!

— Юк, ишетмәдем, — Мәдинә, сүз үзе турында баргандай, нигәдер кызарып китте, — нәрсә булган аңа?

— Раузага барган.

— Шуннан? Барса соң?

— Уф, шушының... Аңламыйсыңмыни?!

Мәдинә тагын кызарды: шуның сыман нәрсәләрне ничек җиңел генә сөйли ала икән шушы Галимә?

— Юктыр, кеше сүзедер...

— Кеше сүзе, — Галимә янә кычкырып көлде, — Рауза үзе исән чакта кешегә сөйләргә сүз калдырамыни? Үзе сөйләгән! «Мин, — дип әйтә, ди, — хәзер, — дип әйтә, ди, — әкияттә яшим, — дип әйтә, ди. — Мин — Зөһрә, Сибгат — Таһир, аебыз — талир, төнне көтеп үткәргән һәр көнебез — үзе бер гомер!» — дип әйтә, ди.

— Адәм ышанмасны!

— Ышанмаска, Сибгат карт бит сакалына тиклем кырган! — Галимә янә шаркылдап көлеп сәкегә тәгәрәде. — Күрсәң, кыргач... уң битендә, колак янындарак, кара миңе килеп чыккан! Урысның теге... тәресе!

Мәдинә янә кызарды, бу юлы хәтта өшеп, калтыранып киткәндәй булды. Тәрегә охшаган кара миң... Җантимернең дә нәкъ шул урында. Шундый ук миң бар Биктимердә дә.

Үз сүзенә үзе исергән Галимә ахирәтенең бер агарып, бер кызарып утыруын сизмәде дә хәтта: аңа бит атна буе җыелган сүзен сөйләп бетерү кирәк.

— Ахирәт, ә безнең персидәтел Мирхәйдәров агай Ихсанбайны эштән кудырам дип кыза.

Мәдинә янә сискәнде. Ихсанбай дигәннән, ул барлык язмышларны бармак очында гына әйләндереп тоткан дәү бер гыйфритне күз алдына китерә.

— Булмас-с!

— Чын, үзем ишетеп калдым! Теге Камалетдинов белән сөйләшкәннәрен ишетеп тордым! Мирхәйдәров агай Ихсанбайны «сөрсегән мәет» диде!

— Кит әле!

— Ишшү, җитмәсә, — Галимә матур иреннәрен бүлтәйтте, — шул килбәтсез Ихсанбай кеше юкта гел минем янга керергә тырыша, әкияттәге хур кызын бер суырып үпсәң иде, ди.

— Уй, ахирәт... сак бул!

— Һи! Үзең беләсең, ахирәт, миңа кем ошаганын. — Галимәнең чем-кара күзләре азга гына сагышка манчылды. — Их, тагын килеп китмәс микән?

— Ә минем кичәдән бирле уң күземнең өсте тарта... — Кайгыдан башка нәрсә күрмәгән Мәдинә моны үтә хафаланып әйтте.

— Ә күз караң борчымыймы?

— Юк шикелле...

— Алайса, әйбәт, уң күзнең асты тартса гына начар була ул.

— Шулай да хәер биреп куйыйм.

Галимә ахирәтенә җәлләп карады: нәрсәсен бирсен инде ул хәергә? Әле дә әнә түр башлары ялтырап ята. Ичмасам, икмәк валчыгы гына булса да табылсачы.

* * *

Әтисе чыгып киткәч, Ихсанбай ах-вах килеп торып утырды. Баш тубал кебек, күзләргә кургаш тутырганнармыни — күз кабакларын күтәрермен димә. Ул, кичә нәрсә булганын исенә төшерергә тырышып, башын чайкады. Хәер, ни булган дисең... Шул Зарифа, шул көмешкә... Тукта, әтисе нәрсә диде әле? Әллә... әллә... Камалетдинов дигәндәй булды түгелме? Әйе, әйе! Бәй, шулай булмаса, әтисе пычагыма эзләсенме ул сакалы биленә җиткән улын?

— Зарифа! — Ихсанбай, угаланып, киемен эзләп, тирәягын капшады. — Зарифа!

Ул арада ишектә Шәңгәрәйнең йомры башы күренде:

— Әй, Ихшанбай, синең мөһерең кайсы җирендә?

— Авызыңны каерыйм. — Ихсанбай шунда аунаган катаны эләктереп, Шәңгәрәйгә җибәрде. — Яп ишекне, инәңнең...

Шәңгәрәй әллә кайсы арада бер-икене «лаф-лаф» өрде дә ишекне шапылдатып ябып куйды. Зарифаның өйдә булуыннан өметен өзеп, Ихсанбай мич янындагы комганнан чөмереп су эчте дә калганын битенә койды. Ах, әзрәк хәл кергәндәй, күзе ачылгандай булды. Ай-яй-яй... Йомышлыйсы хаҗәте дә кыстап тора бит әле, каһәрең!.. Болдырдан торып кына эшен бетерер иде дә бит, теге уйнаштан туган эзләнеп йөри микән? Ай-яй-яй... Ихсанбай түзмәде, атылып болдыр читенә басты, әмма йомышын башлап кына җибәрүгә, болдыр астыннан күшеккән Шәңгәрәйнең башы күренде.

— Әй-әй, нәрсә эшлисең син, Ихшанбай?!

— Анаңның... — Ихсанбай йөгереп диярлек болдырдан төшеп, читән буена шылды. — Җилдән туган! Сукбай! Дивана!

— Үзе башка чаптырды да, үзе әрли... Мин, беләсең килсә, эт! Шарифа энесе! Аф, аф! — Шәңгәрәй дүрт аяклап Ихсанбай тирәсендә бөтерелә башлады: — Аф-а-аф!

— Кит, килбәтсез! Кит, диләр сиңа, дивана!

— Мин сине ашыйм! Син Гөлбануны ашадың, мин хәзер сине ашыйм!

Аптыраган ялангач Ихсанбай арты белән болдырга чигенде. Әллә котырган инде бу Шәңгәрәй?!

— Шәңгәрәй энем, кеше ишетер, нигә юкны кыланасың?

— Мөһереңне күрсәт, Ихшанбай, мөһереңне күрсәт!

— Ай Алла, нинди мөһер? Пичәтне әйтәсеңме? Кил соң кәнсәгә, күрсәтермен...

Шәңгәрәй килеп аңа тырнаклары белән ябыштым дигәндә, капка ачылды, аннан Раузаның тирләп пешкән йөзе күренде:

— Ай, уй! Ихсанбайулла... уф!

— Х-хәзер, Рауза апай. — Ихсанбай яшен тизлеге белән эчкә атылды. — Чёрт, мин... хәзер!

Берни төшенмәгән Рауза бер тузан туздырып тәгәрәп ятып көлгән Шәңгәрәйгә, бер коты алынып өйгә чапкан шәрә Ихсанбайга карап телсез калды.

* * *

Камалетдинов колхозның сөрүлек җирләр планын сорап алды. Кулдан аннан-моннан сызгалаган кәгазьгә карау белән үзе иртән үткән басуларны таныды. Әйе-е... уңдырышлы туфракта утыра Тирәкле. Күрәсең, хәзерге Черекқүл кайчандыр, бөтен шушы колхоз җирен биләгән үзәнне биләп, җәелеп яткан зур су булган. Революциягә тиклем базарга игеннең башлыча шушы Тирәкле ягыннан агылганын сөйли торган иделәр. Тамагы ашка туймаган ятим малайның икмәк шушы якларда үсә икән, үскәч, шул җирләрне үз күзем белән күрермен, икмәген туйганчы ашармын дигән хыялы бар иде. Әлбәттә, аннан соң Азат Камалетдинов күп юллар үтте, илләр күрде, сулар кичте. Икмәккә дә күптән туенган аның күңеле, бу якка эшкә килүе дә үз ихтыяры белән булмады — партия кушты, ул җибәрде.

— Җирләрегез әйбәт сезнең... — Камалетдиновның беренче әйткән сүзе үк Мирхәйдәровны рухландырып җибәрергә җитте.

— Әйбәт булу беләнме?! Авызыңны каерыйм, дөнья Ихсанбайга калгач, эш бармаган! Ярый әле Ишмәмәте китеп котылган, мин паразитны...

— Иптәш Мирхәйдәров, сез һәрчак шулай кызумы?

Мирхәйдәров уңайсызланды. Какча йөзе тартышып, алсуланыбрак китте, торган җиреннән кире утыргычка утырды.

— Гаеплемен, иптәш Камалетдинов...

— Басуларыгызны карадым мин сезнең... Сезнекеннән күпкә мөшкелрәк хуҗалыклар бар...

— Ишмәмәт... тагын шул Ихсанбай. — Мирхәйдәровның янә бите тартышты. — Силсәвитме шул? Өер айгыры, менә кем!

Камалетдинов кабат чыдый алмый урыныннан торды, кабалана-кабалана, тәмәке төрде. Мирхәйдәров аңа тагын нидер әйтте, ә монысының уйлары еракта. Кемне хәтерләтте соң иртән күргән карт? Тукта, картмы соң ул? Кайчан, кайда күрде соң ул бу йөзне, нәрсәсе бик таныш аңа?..

Ишектән бурсык битле, зур зәңгәр күзләренең кабаклары шешенгән кеше керде. Ихсанбай дигәннәре шушы, ахры. Сугыш вакытындагы колхозның күрсәткечләрен карады Камалетдинов. Начар түгелләр. Һәм, гомумән, бу колхозның бөтен төрдән дә планын үтәми калган чагы булмаган. Нәрсәсе ошамый соң бу кешенең Мирхәйдәровка? Шушындый ныклы тыловиклар булмаса, фронтта ничек булыр иде икән? Тыловик дигәннән, карап торышка сау гына күренгән бу кеше сугышта нигә катнашмаган? Күз төпләрендәге «капчыклар»га караганда, йә бөере, йә йөрәге чирле микән? Әллә...

— Утырыгыз, иптәш Моратов.

— Исәнлекме-саулыкмы, иптәш Камалетдинов? Нигә болай әйтми-нитми генә йөрисез?

— Үтеп барышлый мин... — диде Камалетдинов, күрешкәч, тамак кырып. — Шуннан, нинди кыенлыкларың бар, иптәш совет власы?

— Кыенлыклар дип, әлегә зарланган юк. — Ихсанбай ашыгып папкасына ябышты. — Менә монда икенче квартал йомгаклары. Менә халыктан җыелган май, сөт, монысы йомырка, йон... Кирәк дисәгез, тагын тырышырбыз, иптәш Камалетдинов.

— Ә халык... бик йончумы?

— Халык, — Ихсанбай Моратов җилкәсен тырнап алды, — халык, ни... юклыкны ару күтәрә бит ул халык. Халык, иптәш Камалетдинов, барлыкны күтәрә алмый.

— Кызык, һы... — Камалетдинов көлемсерәде, — без нәрсә... шул халык ару яшәсен дип тырышабыз түгелмени?

— Ызнамо шулай... — Ихсанбай тотлыкты. Камалетдиновның бер тешләүдә шартлап ярыла торган чикләвек түгел икәнен башта ук төшенде ул, тик кайсы төшеннән

чатный икән бу? Шулай да, бер мескен кебек, җавапсыз калу килешми. Аңа сугыштан кайтканнан бирле канык-кан Мирхәйдәров алдында һич сер бирергә ярамый. Шуңа күрә ул, бар кыюлыгын җыеп, Камалетдинов-чикләвекнең икенче кабыргасыннан капшап карарга булды. — Халыкны кайгырткач, планны төшерегез инде безгә, иптәш Камалетдинов.

— Үкенечкә каршы, планны киметә алмыйбыз, иптәш Моратов. Башка хуҗалыкларда планны үтәү бик авыр бара. Сезгә район үзәгендә тәҗрибә уртаклашу кирәктер? Мин сездә бүген кичкә тиклем калам әле. Мал торакларының кышка әзерлеген дә карыйсым бар һәм, гомумән, хуҗалык белән төптәнрәк танышырга иде исәп.

— Алайса, атны җигеп китерсеннәр, әйтим. Сезнеке ял итсен. — Ихсанбай урыныннан торып, ишеккә юнәлде.

— Мин чәй куярга кушкан идем. — Мирхәйдәров, борылып, Ихсанбайга карады. — Без чәй эчкәләгәнче, ат китерәләр, әйтелгән.

Идарә йортыннан чыккач, Камалетдинов рәискә кырын күз ташлады:

— Силсәвитең белән артык коры син, агай.

— Һәй... — Мирхәйдәров кул селтәде. — Тыл крысасы! Бабник!..

— Күрсәткечләре ялт итеп тора!

— Җиде кат тирләрен генә түгел, каннарын сыгып алгач...

— Шулай да уртак тел тапсаң яхшы булыр иде. Дөресен әйткәндә... — Камалетдиновның күз алдында янә иртәнчәк күргән кара йөз пәйда булды. — Теге сине чакырып китергән карт кем булды ул?

— Сибгатме? Ул минә Ихсанбайның этисе. Тимерче.

— Тимерче дисең...

— Килеп җиттек, иптәш Камалетдинов. — Мирхәйдәров өенең җил капкасын ачты. — Шушы инде минем дөнья дигәннәре. Хатын! Сәрбиназ, самавырың әзерме?

* * *

Баш сөягеннән коты алынган Һашим, аруын онытып, уттан качкан кеше кебек атлады да атлады. Хәзер инде аңа авылга керергә дә күп калмый. Әнә алда уҗым арышы яшәреп ята. Авыл өйләренең морҗаларыннан чыккан төтеннәр дә күренгәли. Ә тирәкләр кая соң? Бәй, әллә бу аның авылы түгелме? Һашим башына бүтән төрле

уйлар килүдән тынычлангандай булды. Шикләре тарала төшеп, артына әйләнде.

— Бәй, Гөлбану...

Гөлбану елмайды.

— Гөлбану, бу мин... Һашим...

Һашимның бөтен булмышын куанычь ялмады. Гөлбану... Димәк, елга буенда кичергәне, күргәне мираж. Гөлбану һич үзгәрмәгән... Шул күзләр, шул елмаю... Тик нигә ул артыннан эндәшми килгән? Кая барган, нәрсә эшләп йөри?

— Гөлбану... — Һашим үзенә моңсу гына елмаеп торган хатынына кулын сузды. — Мин сине кабат күрер өчен үлемнән качтым. Мин әҗәлне җиңдем!

Әмма хатынына атлыккан Һашим күз ачып йомарга өлгергәнче Гөлбану юк булды. Һашим аптырап тирәягына карады:

— Гөлбану!!!

Юк, беркем җавап бирмәде, үзенең тавышы үзенә кайтаваз булып әйләнеп кире кайтты. Мираж... тагын мираж... Һашим, хәлсезләнеп, юеш җиргә чүгәләде. Башта йөрәген авыр сагыш кысты, әзрәк торгач, зиһене томаланды. Ул үлгән... ул юк. Гөлбану үлгән!!! Һашим, үкереп елап, җиргә йөзтүбән капланды. Ул яткан җирдә дымлы туфраклы каулан актарылды, өсләренә ауган адәм кайгысы астында калган яшь үләннәр бу авырлыкка чыдый алмый иделде...

Юк, тормаячак бу җирдән Һашим. Ул да шушында туфрак булып изеләчәк, таш булып катачак, кар суы булып сеңәчәк. Ул, җимерекләр астында калып үлгәндә, Гөлбануны тагын бер күрер, аны бер кочаклар өчен генә гомер сорады, моңа чаклы кылганнарыннан тәүбәгә килде, кеше булып булмаса, кош булып, кош булып булмаса, бер болыт кына булып кайтып булса да, Гөлбануны бер күрергә хыялланды...

— Гөлбану... Бәхиллек тә алып кала алмадым синнән... Озак, озак кайттым шул мин!..

— Һашим...

Һашим бер онытылып, бер сыктап, бер изрәп яткан чагында колак төбендә генә шушы авазны ишетте. Юк, барыбер күзен ачмаячак ул, ачса... тагын бөтенесе дә буш булачак...

— Һашим...

— Аһ, Гөлбану, көтмәгәнсең мине, бәхиллек тә алмый киткәнсең...

— Һашим, минем бәхиллегем әнә ул ике малайда, игезәкләрдә...

— Хатларыңнан мин барысын да төшендем, Гөлбану.

— Рәхмәт, Һашим...

Һашим кинәт җиңеләйгәндәй булды — өстенә таудай өелгән авырлык, йөрәген җиргә кадаклаган сагыш каядыр очкандай, аны калдыргандай... Ул торып утырды. Ниндидер көч аны яшәргә, дөньяга сабый күзе белән ышанып карарга чакыргандай. Болыт артыннан кинәт килеп чыккан кояш, бөтен булмышына, күңеленә яшәрткеч рух булып тулган менә бу язгы һава, кошлар сайравы — барысы да аның күңелен шифалы тылсым белән тутырды, аны торырга, авылына таба адымнарын ешайтырга мәҗбүр итте.

Үрне төшкәч, юл басу эченә борылды. Басу очындагы куакны үттеме — авыл. Тик тирәкләр күренмәве генә гаҗәп.

Кинәт Һашимның күзенә басу читендә нәрсәләрдер кыймылдаган кебек тоелды. Ул, күзләрен йомып, башын селкеде, әллә тагын миражмы? Күзен ачты, юк, һаман да шул урында нидер кыймылдый. Эт дисәң, бәләкәйләр, бәрәнгә дә охшамаганнар. Йомран дияр идең, шактый зуррак болар. Теге җан ияләре Һашимны шәйләделәрме, тагын юк булдылар, җиргә яттыларамы, әллә чокыр-мазарга төштеләрме? Кызыксыну җиңде — Һашим, эре-эре атлап, басу аша туп-туры шунда юнәлде.

Барып җиткәч, үз күзләренә үзе ышанмый торды: ике малай булып чыкты баягы җан ияләре. Аларның кап-кара сазга буялган йөзләрендә язгы күктәй саф, зәп-зәңгәр ике күзнең янып торуын исәпкә алмасаң, бу ике җан иясен адәм баласы дип атау да кыен иде.

— Нәрсә эшлисез монда?

Малайларның берсе йөзен икенчесенең аркасына яшерде, ә икенчесе үз чиратында кулындагы өзелгән арыш кыякларына карап торды да кычкырып елап җибәрде.

— Чү!.. Мин бит сезгә тимим... Кем балалары сез? Нигә килдегез монда?

Малайлар, бер-берсенә тотынышып, басудан китәргә омтылдылар, Һашим, кардан яңарак әрчелгән ызан буйларындагы эзләргә карап барысын да төшенде.

— Малайлар... малайларым минем...

Һашимның күзләрен яшь әчеттерде, тамагына кургаштай төер тыгылды.

— Каһәр төшсен сугышны уйлап чыгарган бәндәләргә!

Каһәр төшсен сабыйларны үлән ашарга мәҗбүр иткән хаиннарга. – Ул, ашкынып, шушы ике җан иясен кочагына алды, пычрак битләреннән алмаш-тилмәш үпте: юка гына сәләмә киемнәре аша куян йөрәгедәй типкән тамырларын тою аның күңелен бер үк вакытта җәлләү һәм ярату белән тутырды. Ела, Һашим, ела, сугышка тиклем елый белмәгән тәкәббер бер зат булуың өчен түгәсе яшьләреңнең башы гына әле бу...

Елгага төшеп, үзе дә юынып, малайларының да биткулларын чайкап алгач, Һашим юл капчыгын ачты.

Аннан берәр кисәк икмәк, берәр шакмак шикәр чыгарды. Малайлар икмәкне шунда ук каерып тешләп алдылар, ә менә шикәргә икмәк ашалып бетсә дә орынмадылар.

– Ә монысын нигә ашамыйсыз?

– Ә ул нәрсә? – Малайларның икесе дә учларында яткан ак шакмакка төбәлде.

– Шикәр.

– Ә аны ашыйлармы? Әллә ялыйлармы?

– Ялыйлар да, ашыйлар да, сезнең кебек бәләкәч малайларга ул бик кирәк ризык.

Тәмләп-тәмләп шикәр суырган малайларын җитәкләп алгач, Һашимга янә көч кайткандай булды. Әйтерсең лә аның артында сугышта кичергән газаплар да, үлем дә, авырулар да булмаган. Ул менә шушы кечкенә кулларның назын үз учында тоя-тоя бара да бара...

Әниләре турында бер авыз сүз сорашмады ул малайлардан, үзләренең дә кем малайлары икәнен төпченеп тормады. Авылга кергәч, башта кайсы йортка атларга икән дип тә икеләнмәде – туры үзләренә, Гөлбануның җил капкалы бәләкәй генә өенә юнәлде.

Малайлар, учларындагы шикәр валчыкларын ялыйялый, өй артындагы эскәмиядә утырып калды: Һашим, йөрәксенеп, ярсып сагынудан егылыр чиккә җитеп, ишекне ачты.

Сәкедә нәрсәдер тегеп утырган хатын-кыз башын күтәрде, шуннан иплән кенә, шуып дигәндәй идәнгә төште. Һашимга Гөлбануга охшаган бер йөз карады. Әйе, шул ук йөз, шул ук гәүдә, тик моның Гөлбану түгел икәненә кара күзләре генә ишарә ясый...

– Мәдинә...

«Балам» дигән сүз әйтелмәде, Һашим бу сүзне тагын эченә йотты. Элек, сугышка тиклем, үзенең гарьчел, алама холкы аркасында әйтә алмады бу сүзне... Имеш,

Гөлбану Һашимга үз иреге белән бирелмәде, йөрәген ачмады... Ә хәзер аның каршысында Һашим белгән нәзек сыйраклы, чикерткә кебек җиңел сабый урынына хәсрәтләрдән яралган карашлы җиткән кыз басып тора, кулында... әйе, ул ялгышмый, җиткән кыз булган аның Мәдинәсе.

— Мәдинә... — Бу юлы Һашимның тавышы карлыгып чыкты. Бу тавышта Мәдинәнең йөзенә язылган хәсрәтләрнең — Гөлбануны, әнисен югалтудан килгәне дә кушылды. Кайты уртаклашканда кем кочаклашмый да, кем бер-беренә сыенмый?!

— Әти! Әтием!.. — Мәдинә үзенә таныш түгел ят исләр чыккан, нык, бер үк вакытта йомшак гәүдәгә сыенып үксеп җибәрде...

Өченче бүлек

Фәүзия, Һашим кайтканны ишеткәч, янә тынычлыгын җуйды. Ай-һай холыксыз адәмгә тап булды аның Гөлбануы. Хәзер килеп әнә сабыйларны кызгана. Бик рәнҗетер инде аларны Һашим, бик кагар... Алай дисәң, нигә әле Һашим сугыштан туры үз йортына кайтмады? Әти-әнисе дөнья куйса да, мал-туарын Зарифа сеңлесе үзенә күчереп хуҗа булып куйса да, нигезе тора бит, әлмисактагы карагайдан салынган йорт әллә ничә Һашимны картайтып, гүр иясе ясар әле.

Фәүзия икеләнде, уйларының очына чыга алмый азапланды, Гөлбанудан калган ике сабый гына җитмәгән иде аның болай да теткәләнеп беткән йөрәгенә. Шул сабыйлар дөньяга килгәннән бирле Ихсанбай холыксызланды. Үзе генә түгел, Сәбиләсе аша күзәттерә Ихсанбай әнисе артыннан. Өйдән берәр сынык икмәк, берәр җамаяк катык югалып карасын — Ихсанбай күзенә очраган бар нәрсәне вата-кыра. Һай, балалар... Бармаклар тигез түгел дә бит, мәгәр кайсын тешләсәң дә авырта шул... Сәбиләсе дә әнисе өчен өзелеп торган кебек тә бит, ләкин әләкче, шымчы.

Фәүзия, урам аркылы гына торган оныгының хәлен җиңеләйтә алмавына уфтанып, кара янып утыра. Ул уйлаган арада, табадагы сары майда чыжлаган күмәч кара янып көя башлаган әллә? Уф!..

Ул арада алачык ишеге ачылды.

— Нәрсә көйдерәсең анда?

Борылып карамаса да күрә Фәүзия: улының йөзе бу мәлдә көйгән тәбикмәктән дә карарак икәнен. Шулай да Фәүзия элеккечә үзенең бу йортта хуҗа икәнен оныттырмаска тырыша. Ихсанбай әнисе белән исәпләшергә тиеш!

— Савыт-саба тирәсендә чуалу синең эшеңме, Ихсанбай?

— Монда... бу дөньяда бөтенесе дә минем эшем. Төшендеңме? — Ихсанбай бу мәлдә әнисенә якын ук килеп басты. — Кая теге карт алашаң?!

Фәүзия, аркасы белән Ихсанбайдан килгән усал көчне тойса да, җавап бирергә ашыкмады, көйгән күмәч урынына яңасын салгач, кул сырты белән күзенә төшеп барган яулыгын рәтләде, учак каршына куелган утыргычка ботын киереп, уңайлап утырды.

— Нигә эндәшмисең? Карт кая, дим!

— Син сораган картның исеме бар, Ихсанбай улым.

— Төкердем мин аның исеменә. — Ихсанбай лач иттереп алачык идәненә төкереп, өстенә сеңгереп куйды. — Бетмәс сезнең исемнәр!..

— Исемнәрне без уйлап чыгармадык, без каберебезгә дә алып китмәбез!

— Син нигә минем түземлегемне сыныйсың... Үзеңнең карт айгырыңны яклыйсыңмы?!

— Ипләп, Ихсанбай! Әтиең белән безнең түшәк бүлешмәгәнгә ни заман! Син минем... ырысымнан* көләсең!

— Ха-ха-ха! Ырыс... сезнең ырысыгызны, әнкәй, р-революция дигән ач бүре йоткан. Белдеңме? Ә карт шайтаның бүген үк кырган сакалын кире ябыштырып куймаса, миннән яхшылык көтмәсен!

Ихсанбай чыкты. Фәүзия алачык тәрәзәсеннән аның лапас астына кереп киткәнен күрде. Йа Ходай! Тагын ниләр күрер аның башы?! Ах, Ихсанбай, исерек баштан әтиеңә бәйләнсәң, бөлдең бит, беттең!

Ул арада ишектән Сибгат тә килеп керде. Нәрсәсе үзгәргән соң моның? Исерек тә түгел. Ә-ә... сакалы! Чынлап та кырып ташлаган бит бу сакалын!..

— Сакалың... сакалыңны нигә кырдың, карт ишәк?!

— Бетте! Җитте! Сибгат срогын тутырды!

— Әтисе... — Фәүзия буыны тотмый идәнгә тезлән-

---

* Ырыс — абруй.

де. — Соң миңең, яңагыңдагы... тәреңне ни дип уйладың, этисе?!

— Житте, бетте! Срогым чыкты. Туйдым! Куркып яшәүдән, — уң кулының сырты белән бугазын ышкыды, — мин менә болай туйдым!!!

— Чү... Тавышланма, зинһар... Ихсанбай өйдә икәнеңне белмәсен...

— Ха-ха-ха! Минем баш газиз түгел сиңа, Барсынбикә, сиңа... Ихсанбайның... шул чүбек башыңның башы газиз.

— Ул синең каның... Ул безнең токым!

— Токым... Токым! Ха-ха-ха!!! Әнә токымны күк бүре дә үрчетә! Ха-ха-ха!

— Син... акылыңнан язгансың, Диңгезхан!

— Во! Хан мин, хан! Ханмын! Тик хәзер минем кулымнан дан да, шөһрәт тә, мал да, алтын да китқән, әмма мин барыбер ханмын! Үз гомеремнең, үз язмышымның ханы мин! Ә син — кол, Барсынбикә... Ихсанбайның, йолаларыңның, күршеләреңнең, киленнәреңнең, хәтта төшләреңнең колы син...

— Сине сихерләгәннәр, Сибгат... сине...

— Сихерләмәделәр мине, Барсынбикә. Киресенчә, булган сихеремне кайтардылар. Мин кабаттан тудым дөньяга... Яшәргә тудым.

— Чү!.. Тукта...

* * *

Ихсанбай ялан абзардагы атын иярләп, басуларны айкап әйләнергә чыкты. Бу Камалетдинов күбрәк игенчелеккә игътибар юнәлтергә охшый. Шильма. Басуны берүзе генә килеп карап йөргән. Мирхәйдәров — тинтәк. Кешене күп тыңлый. Житәкче булган кеше адәмне жәлләдеме — бетте диган сүз ул. Халыкны кайгыртсаң, югарыдагы түрәләргә ярап булмый. Шуңа бит төшенергә кирәк — түрә өстендә түрә утыра. Кем ныграк буарга, сыгарга ярата, шул югарырак үрмәли. Их, менә Ихсанбай килештерер иде! Күрмәгәннәрен күрсәтер иде! Жәл, белеме житенкерәми. Әтисе белән әнисенең бердәнбер баласын читкә жибәрүдән куркудан гына булды бу. Хәер, Ихсанбай үзе дә әти-әни оясыннан читкә китәргә талпынмады. Талпыну дигәч тә, аның өчен канат кирәк бит, ә Ихсанбайның канаты булмады ул. Үсмәде. Һәр адымын «Кем икәнеңне белеп калмасыннар, чү, ишетерләр, чагар-

лар!» дип искәртеп торгач, канат үсә диме?! Хәзер менә Мирхәйдәров... Шушы яшенә тиклем үзенә җил-яңгыр тидерми яшәгән Ихсанбай ябык Мирхәйдәровка бирешерме? Әә этисе... Күп түздә болай да Ихсанбай әтисенең исерек килеш күрсәткән тамашасына. Ярый, сугыш вакытында элеп алып, селкеп салырлык ирләр булмады, ә хәзер... Хәзер дөнья башкача... Карт азды, үз башына котырына. Хәзер ул, әти булудан бигрәк, җир өстендә яшәгән артык бер шаһит. Шаһитлардан ни тиклем тизрәк котылса, шултиклем озаграк, шултиклем тынычрак яшәячәк...

Ат шапыр-шопыр чит-ярлары кытыршы боз белән капланган елганы кичеп чыкты. Куаклыкны үткәч, Ихсанбайның каршысына ужым арышы чәчелгән җир җәелде. Арыш әйбәт быел. Урыны-урыны белән су җыелып яткан чокырларда черегән ужымны исәпкә алмаганда, башкасы матур күренә. Ул, атыннан төшеп, басу читенә килде. Тукта, басуның өй урыныдай җирен нәрсә шулай таптаган? Мал эзенә дә охшамаган. Әллә эт туе җыелып аунаган? Юк, юк... Бәй, менә яланаяк бала эзләре... Яланаяк... Кар эреп тә бетмәгән килеш кем баласын яланаяк басуга чыгарсын?..

Ихсанбай, чүгәләп утырып, эз караган җиреннән кинәт сикереп торды: «Мәдинә! Мәдинә көчекләре!»

Ул, тиз генә атына атланып, күзенә ак-кара күренми, авыл ягына чапты...

* * *

Мәдинә, фермадан чыккач, силос, тизәк, салам, җир исе аңкыган һаваны сулап, авыл ягына карап торды.

Савымчылар да әнә берәмләп, икешәрләп кайта башлады. Бүген беренче тапкыр аның эштән кайтуын олы җан иясе көтә — әтисе. Әти... Бала чагыннан аңа бүре күзләре белән каш астыннан карап үскәч, Мәдинә әти дип эндәшкәнен дә хәтерләми. Ә әнисен тукмаганын онытырлыкмы? Бала күңеленә бит иң якты күренешләр генә уела. Мәдинә гаеплемени хәтере һашимны яман яктан сыйфатлаган күренешләрне саклаганга?

Кичәге кич тә бик киеренке булды. һашим малайларына агачтан юнып атлар, арбалар ясап бирде; чәй эчкәч, икесен ике ягына салып, йокларга ятты. Мәдинә дә сәкенең бер читенә генә урын җәйде, ләкин йокыга китә алмады. Тартынудан чишенми генә яткач, тәне юньләп ял да итмәде.

Һашим да чөйгә яткан кебек әйләнде дә тулганды. Торып, мич янына килеп, тәмәке пыскытты. Мәдинә аның ах та ух килеп көрсенгәнен таңга тиклем ишетеп ятты...

Алга таба ничек яшәр алар икесе бер түбә астында! Җитмәсә, әүвәлге кебек эчә башласа? Юк, башы җитми Мәдинәнең, очына чыга алмый ул уйларының. Шулай да кайтырга кирәк. Бәрәңге булса да пешереп, тамак ялгарга кирәк, кичә бит аларга күршесе, Һашимны җәлләптер инде, бер чиләк бәрәңге кертте...

Мәдинә өенә килеп җиткәндә, җил капка шар ачык иде. Багана төбендә ак йомычкалар да күренә. Ә-ә... Һашим черегән багананың очын кисеп, яңадан утырткан икән. Хәерлегә булсын, җирнең ипләп эрегәнен дә көтмәгән...

— Мәдинә! — Колак төбендә иләмсез яңгыраган тавыштан, янә таптыр-топтыр иткән ат тоягы тавышыннан Мәдинә чак һуштан язмады. — Мәдинә! — Аттан төшеп, чыбыркысын болгап, күзләрен акайтып, кызыкайга җикеренә башлады Ихсанбай. — Син, кабахәт, көчекләреңне нигә уҗымга җибәрәсең? Нәрсә, әллә шуларны бозау абзарына бикләп куйганны, йә булмаса, песи баласы урынына буып үтергәнне көтәсеңме?

— Аһ... Ихсанбай агай! Мин каян белим?!

— Аһ, син белмисең! Көчекләреңне тыя белмисең! — Ихсанбайның Мәдинәнең муенына үрелгән кулы нәрсәнеңдер шарт итеп бәрелүеннән чабылган үлән кебек салынып төште.

— Кабахәт... — Җир астыннан пәйда булгандай килеп чыккан Һашим икенче бер селтәнүендә Ихсанбайны җиргә чалкан яткырды. — Мин сине, шакшы адәм, сытып түгел, типкәләп үтерәм хәзер!

— Җибәр... Үз башыңа, үз башыңа! — Һашим аяклары астында бөгәрләнеп тәгәрәп йөргән Ихсанбай, кинәт үрелеп, Һашимны ботыннан тартты, тегесе аның өстенә егыла язды, ләкин атланырга өлгереп калды.

— Үтерәм! — Һашимның келәшчәдәй учлары эчендә калган муенын инде хәзер Ихсанбай селкетә дә алмый. Менә аның чигә тамырлары бармак юанлыгы булып бүртенде, иреннәре чалшаеп, зәңгәр күзләре акайды. — Хәрәм җаныңның дөньяда яшәвенә капут килде, Ихсанбай! Газраилең, әҗәлең килде!

Болар янында торган Мәдинә таш сын кебек катты, кычкыра да, селкенә дә алмады.

Шулчак Мәдинәнең күз алдында әллә нәрсә бул-

ды: Һашим башта Ихсанбайны буган кулларына тәү күргәндәге сыман аптырап карады, аннан ипләп-ипләп Ихсанбайны ычкындыра, үзе артка чигенә башлады, менә ул карашын югары күтәрде, әйтерсең лә кемнедер күрде, кемдер аны бу адәмне җанын кыюдан җайлап кына аралады.

Күпмедер яткач, Ихсанбай исенә килде. Янәшәсендә яткан чыбыркысын капшап учына алды да әҗәл белән алышканда юешләнен өлгергән арты белән тышка мүкәләде...

* * *

Фәүзия-Барсынбикә елга буена төшәргә дип чиләкләрен алып чыгуга, каршысына килене басты:

— Аһ, аһ! Иртә белән генә суга барган идем бит!

Фәүзия килененә каш астыннан сөзеп карады:

— Минем сиңа су китермисең дигәнем юк.

— Кая әле, үзем генә барыйм! — Фәүзия киленнең нигә үҗәтләнүен яхшы аңлый. Ихсанбай котырта, карчыкның һәр адымын улы каравыллата. Янәсе, Фәүзия Гөлбану көчекләренә азык ташый. Әле дә Фәүзия куенына ике телем икмәк тыккан, калын гына итеп май да сылаган.

Эт кебек әче тешләргә тора аны килене! Кем аркасында Ихсанбайга барып бәхеттә яшәгәнен онытты бичара. Фәүзия Ихсанбайдан да курыкмый, тик әлегә гаиләдә олы гауга чыгармыйм дип кенә телен тешли. Шуңа күрә ул бу юлы да килененә, эченнән сызылса да:

— Синең болай да эшең күп бит. Мин чиләкләрнең тышын кызыл балчык белән бераз ышкыштырып килим әле, — дию белән чикләнде.

— Аһ, аһ... Улың тагын карт кайнәңне суга җибәрәсең дип орышыр инде. Холкын беләсең лә инде.

— Холык кемдә юк?! — Фәүзия, көянтәсен — бер кулына, чиләкләрен икенче кулына тотып, капкадан чыкты.

Их, ярый да соң Гөлбанунын сабыйлары су буендарак йөрсә. Ничәмә тапкыр алып чыккан ризыгын бирә алмый кайтканы бар. Һашим кайткан, дигән хәбәр дә сөендермәде аны. Үз каны Мәдинәне кагыпмы-каккан бәндә менә бу ике сабыйга ничек түзәр? Гөлбану... Ниләр кичереп яшәгәненңне белә алмый да калдым шул... Нинди генә гөнаһ шомлыгыннан яралды икән бу сабыйлар?!

Елгага килеп җитеп, басмага күз салуы булды, яр астыннан Шәңгәрәйнең башы күренде. Абау! Әллә киемение белән су эчендә йөри...

— Нишлисең син, Шәңгәрәй? — Коты алынган Фәүзия аска иелде. — Бу нишләвең синең, ә, Алла бәндәсе?

Шәңгәрәй, шапыр-шопыр килеп судан чыкты, үзенең теше тешкә тими калтырый.

— Ы! Әйтмим. Әйтсәм, син Ихшанбайга әләклисең!

— Ай әттәгенәсе!.. Кайчан минем әләкләгәнем бар?

— Ы! Син бит аның әнисе!

— Булса ни... Аның үз тормышы, үз җае...

— Икмәк бирсәң, музит, әйтермен...

— Бирәм, бирәм!

— Ә син хәзер үк бир...

Фәүзия култык астына кыстырган телемнәрнең берсен аңа сузды.

— Мә, Шәңгәрәй, синнән ризык җәлләгәнем юк.

— Синең иссу бер телемең бар.

— Каян белдең?

— Беләм. Берсе Җантимергә, иссу берсе Биктимергә...

— Нәрсә, үзләре әйтәме?

— Ы!

— Ә кем әйтә?

— Әйтми.

— Ә каян беләсең?

— Белгәнгә беләм.

— Ә нигә икмәкне ашамый алып куйдың?

— Икеншесен дә бир дә асармын.

— Ай, Шәңгәрәй... Бәлки, син бирерсең малайларга?

— Ыжнамо бирәм. Мин асатмасам, алар күптән, — Шәңгәрәй ияк очы белән зиратка ымлады, — сунда ятарлар иде.

— Әле дә син бар... — Фәүзия шушы минутта бу дәү башлы, пычрак битле адәмнең аркасыннан сөясе килде. Бахыр, ул да адәм баласы бит. Анадан туган. Хәзер Зарифада эт типкесендә йөри.

— Әтиеңнән хәбәр юкмы? — Фәүзиянең соравын Шәңгәрәй колагына да элмәде, үзенекен сөйләвен белде:

— Алар бит минеке! Мин аларның атасы!

— Куй, Һашим ишетсә... Беләсеңдер: кайткан бит!..

— Исетсен, мин Гөлбануны Һасимнан сугыска тиклем үк бер яртыга сатып алдым. Малайлар минеке! Һасимга — сусы! — Шәңгәрәй алар ягына кукиш күрсәтте.

– Ай Алла бәндәсе... Дорфа сөйлисең! Ходайдан куркыр идең!..
– Син үзең бер дә Алла дип тормыйсың!
– Нигә?
– Нигә, нигә... Алладан курыккач, нигә кеселәргә мөһер басасың?
– Авызыңнан җил алсын, Шәңгәрәй! Кемгә нинди мөһер басканым бар?
– Абау... ирең, Җантимергә, Биктимергә. Синең икмәгеңне асамыйм суңа... Асасам, миңа да йогар. Әнә син аларга асатасың гел, шуңа аларның бертөрле мөһере бар, тәре сымак.
– Гөнаһ шомлыгы икәнсең, Шәңгәрәй!
– Ы! Мин... мин алай түгел! Мин алай булсам, Гөлбануны коткарыр идем!
– Син... Гөлбануны... – Фәүзия хәлсезләнеп китте, маңгаена салкын тир бәреп чыкты. – Үлде бит инде ул! Син нәрсә сөйлисең?!
– Ы! Үлмәде. Үлсә... кая аның басы? Сөякләрен күрдеңме?
– Ул ел кар калын булды... Кар суы көчле булды, хәтта бүрәнәләрне агызып алып китте...
– Шушы елгага... Тәңребирде дигән әүлия кылышын ясергән. Тапмаган аны берәү дә. Суны тапсам, Гөлбануны коткарам!
– Ничек... Ул бит зинданга ябылмаган!
– Ябылган! Ул... Ихшанбаеңның эсендә утыра...
– Кит, Шәңгәрәй... кит!..
– Китәм... Йә әтү миңа да мөһер басып куярсың, Шибгатныкы сымак – битемә... – Икмәк телемнәрен ашыга-ашыга алып, киемнәреннән су агызып китеп барган Шәңгәрәй Фәүзиянең өнеме, әллә көпә-көндез күргән төшеме булды?..

Дүртенче бүлек

Тирәклегә язның быел иртә килүе кемнедер сөендерде, кемнедер көендерде. Печәне аз булган крестьян өчен, әлбәттә, бу олы куаныч. Халык малын күптән инде иртүк чыгарып җибәрә. Әйдә, курпы утлап, күшәп алырлык тамак ялгап йөреп кайтсыннар. Хуҗалар өчен табигатьнең вакытыннан алда уянуы шәп түгел: орлык тазартылып бетмәгән, атлар йончу, сыер җигү дә эш түгел.

Ихсанбай шушылардан үзенә ничек тә файда ясарга тиеш. Бөтен район буенча хәл бертөрлерәк инде ул. Кемдә артык көч, кемдә артык орлык бар дисең? Әмма белә ул: Кабан елы кайчан да калҗалы була, әз-мәз тырышлык күрсәтсәң, абруеңны ныгытып калып була...

Ул, мунчадан чыккач, өенә кереп китми, болдырына утырды. Яз кояшының юмарт нурына, тәнгә сихәт биреп искән йомшак җиленә иркәләнеп, аякларын сузып җибәрде. Әнә бит тирә-як ничек ямьләнде: сыерчыгы тургае чыркылдаша, кәрниз буйларында гөрләшеп, берберсен куып, күгәрченнәр тормыш көтә; Күкбүре, кояшка изрәп, ишегалдында җәйрәгән, имчәкләренә ябышкан алты көчеге, әниләренең өнсез буйсынуыннан файдаланып, талаша-талаша тәгам җыя; ә әтәч ничек фырт кылана! Кикрик сытылыр чиккә җитеп кызарган, ә каурыйларына карасаң, күз камаша. Ихсанбай үзенә бу әтәчнең гел кырынрак, яратмый каравын сизә. Әле дә ул, Ихсанбайны күргәч, юкка канат кагып, дөнья ярып кычкырып алды. Янәсе, күр: син кем дә мин кем. Аннан күккә карап, күзен хәйләле кысып, тилгән күренмәсә дә куркыныч янауны искәрткән тавыш белән кыткылдап куйды. Белә ул: мондый тавыш тавыкларны ышыккарак, койма буенарак туплый, әтәчкә нәрсә, шуны гына көтеп тора. Әле дә ул моны Ихсанбайның күз алдында олы бер кинәнеч белән башкарды. Аннан коймага менде, тагын җилпенеп кычкырып алды, ә үзенең ике күзе күрше ишегалдында. Күптәннән сагалый бу дуңгыз шуларны. Күршеләре былтыр, карт әтәчен суеп, яшьне калдырды, шуның көчен чамалый алмый йөри бу. Канга батып сугышыр көннәре алда әле бу икәүнең...

Их, шушы кошлар, хайваннар дөньясы шикелле бер яклы, бер катлы гына булса икән тормыш... Чүп өстенә чүмәлә. Менә Һашимның тере калуын әйт әле. Сугыш беткәч, ике ел дигәндә кайтып төшү ни пычагыма кирәк булды? Кайтып төшү белән Ихсанбайны калак сөягенә салды... Мәдинәне яклыйм дип кенә эшләдеме ул моны, әллә берәрсе игезәкләрнең «тарихын» такылдап өлгердеме? Ихсанбайга калса, ул серне Гөлбану үзе белән теге дөньяга алып киткән булырга тиеш иде дә...

Әтисенең картайган көнендә турсаюы, акылдан язуы нәрсә тагын? Тормыш бит үрелгән чыпта кебек: очын бер табып алсаң, хәзер сүтелергә тора. Әти дип карап торып буламы мондый очракта?

Әйе... төрле яктан китереп кысты аны тормыш. Мирхәйдәров шул кырщауның иң тарына, иң нәзегенә охшаган. Сизә Ихсанбай: аның белән ачыктан-ачык көрәшү куркыныч. Таянганы ышанычлы түгел шул Ихсанбайның, ә менә-менә убам дип чайкалып яткан баткаклык. Шулай булмаса, ике кабып, бер йотар иде ул шул маңка малайны!

Мунча ишегенең шыгырдаганына башын күтәрде Ихсанбай. Күрәсең, Сәбилә чыгып килә. Хатынының ялангач гәүдәсен күз алдына китерүдән үк борынын җыерды. Сәбилә Ихсанбай өчен язмышның бер ормышы. Авырткан җиренә — җан җиренә китереп бәрүе. Шул адәм рәвешлерәк булса, Ихсанбай Зарифаның кубызына биер идеме? Гөлбану юк. Зарифа — җенси дәртне басу чарасы гына. Ә күңел буп-буш.

Шулвакыт ялан абзар башында кот очмалы зилзилә купты. Әһә, әтәчләр сугыша! Күрәсең, күршенең яшь әтәче Ихсанбай әтәченең әдәпсез мин-минлек белән үз тавыкларын күзләвеннән тәмам туеп, үзе сикереп менгән читәнгә. Ихсанбай бу сугышның үз әтәченең җиңелүе йә зәгыйфьләнүе белән бетү ихтималын тойса да, күрше әтәчен кумады, араларына кермәде. Нигә? Сугышсыннар! Кем җиңә, шул ота. Ә кем ота, шул дөньяның кендегеннән тота...

* * *

Һашим Ихсанбай белән булган хәлдән соң хәтсез вакыт зиһенен туплый алмый азапланды. Кинәт ярсып, кызып китүенең сәбәбен төшенә дә, төшенми дә кебек. Элекке исәп-хисап кайтаруымы бу, әллә аңа яңаларының өстәлүеме... Дөресен әйткәндә, Һашим бу ике сабыйның дөньяга килүе хакында берни белми. Тик күңел бер нәрсәгә нык ышана: Гөлбану белән үзенең малайлары булырга тиеш иде. Ходай Һашимның теләген ишеткән — берьюлы икәү итеп биргән. Ә Ходайның бирү юлларын да, чарасын да аңлау мөмкин түгел. Берлинда, җимерекләр арасында калып, фани дөнья белән хушлашкан бер мәлендә, Һашим исәбе буенча, төшендә күргән карт та бит шулай дигән иде. «Кайтуыңны ике игез җан, ике Ходай бәндәсе көтеп торыр, син аларны язмыштан бүләк итеп кабул кыл һәм ярат!»

Күп нәрсәләр әйткән иде кебек ул карт Һашимга, соңыннан, хәрабәләрне актарганда кинәт авырту тою

аны кире фани дөньяга кайтаргач, барысы да онытылган кебек булды. Аннан соң ике ел буе госпитальләрдә яту, исәпсез операцияләр, яңадан бакыйлык белән фанилык арасына өметтән күпер салулар, тетрәнүләр, кире ышанычны югалтулар — берсе дә ул карт алдан әйткәннәрне хәтерендә яңарта алмаган иде. Ихсанбай белән булган көрәштән соң әллә нинди кодрәт белән шул тылсым иясенең әйткәннәре учак төбендәге куздай җемелди башлады. Хәтерендә: Һашим ул төшләрендә үзен озын ак күлмәк кигән малай рәвешендә күрде. Ул карттан: «Авылда бөтен җаным-тәнем белән күралмаган кешем калды. Гаиләмне сыерсыз калдырып, ачлыкка дучар иткән шул мәлгунь, уникесе дә тулмаган кызымны читкә эшкә куарга маташкан. Ризыгым бетми, илгә кайтып, аның белән очрашсам, эчемдә янган утымны ни әмәлләр кылып басармын?» — дип сораган иде. Җавап кыска булды: «Анда сине хатыныңның рухы көтә. Сабыйларны ярат, хатыныңның рухы шуларны саклый!»

Ул рухның нинди көчкә ия булуын кичә аңлады Һашим: Ихсанбайны буган кулларында кинәт хатын-кыз куллары пәйда булды. Мәдинә килеп тоттымы дип башын күтәрүгә, Гөлбануны күрде. Аптыраудан, тетрәнүдән Һашим Ихсанбайның муенын әкренләп бушайта барганын тойды. Шушыңа тиклем һичбер нәрсәгә ышанмый, сугышка тиклем шәһәрдә типтереп яшәгән Һашимның әле дә моңа күңеле ышанып җитми. Бөтенләй ышанып җитми. Бөтенләй ышанмас иде, үзен авыру да тоймый. Янә үзенең айдан артык хәрабәләр арасында ятканнан соң терелүен уйлый да, бу дөньяның серлелек, тылсым белән чолганып алынуын күңеле белән ныграк тоя. Менә әле ул район үзәгенә җыена. Камалетдиновның үзенә кереп, хәл-әхвәлен сөйләмәкче. Һашим таланган малын кире кайтарырга, менә бу сабыйларны, ниһаять, сөт-катыкка тиендерергә тиеш. Мөгаен, тыңларлар аны, аңларлар. Әмма зиһене аның бер нәрсәне төшенмәячәк. Гөлбануның балаларын ачлыктан үләргә дучар итү кем өчен, нәрсә өчен кирәк булды икән?!

Хәер, алда гомере булса, бу соравына да җавап табар. Теге чакта карт әйтте бит: «Бәндәдән сорау алма, җавап үзе килер. Гомерең агышы акылың табышы булыр».

Һашим шул минутта ук юлга әзерләнә башлады: биштәренә кружкасын, калагын, флягасын салды. Бәләкәй генә сапёр көрәген дә алды. Ничәмә госпитальдән госпитальгә күчкәндә дә югалтмаган солдат кирәк-ярагын

үзе белән алмаса, йә юлы уңмас. Аннан соң бит әле Тәңребирде елгасы үрендә күргән баш сөяге тынгы бирми аңа...

* * *

Фәүзиягә су буенда Шәңгәрәйнең әйткәннәре тынгы бирми. Бигрәк тә аның мөһер дигәне. Сабыйларда Сибгатнеке кебек миң булуга аптырамый ул: дәү әтиләреннән бала ни мирас итмәс? Тик менә аның шул турыда сөйләп йөрүе... Ә Ихсанбайның эчен телергә кылыч эзләве ни соң? Бәндә булгач, бәндәлеген итеп, Гөлбануга күңеле төшкән икән, нигә әле ул Һашимга каныкмый?

Уйларының очына чыга алмый җәфаланган Фәүзия үзен эш белән юатырга булды, куырмач кыздырды, талкан майлады; аннан алда тарткан солысыннан буза кайнатырга салды; чормадан кипкән кызыл эремчеген дә алып төште, тартып, майлап куярга ниятләде монысын да. «Һы... туйга әзерләнгәндәй әзерләнәмче», — дип, үз-үзенә сөйләнде ул. Инде онытылдым, эшкә бирелдем дисә, күз алдында Шәңгәрәйнең ялтыр башы хасил була. «Дивана бит ул, аның сүзенә кем колак сала ди?» — дип юатырга тырыша акылын, ә күңеленең кай җиредер моның белән килешми.

Элек, шушы Сибгат-Диңгезханга кияүгә чыгарга йөргәндә, бер дивананың дәү әнисен, кызыңны миңа бир, дип аптыратканы хәтерендә.

— Барсын кырык көнлегеннән ярәшелгән бу егеткә. Вәгъдә — иман! — дип, сабыр гына сөйләшкән дәү әнисенә аптырап карады ул.

— Уф! Нигә шуны ялчылардан кудырып кына җибәрмисең, дәү әни! — дип ярсыды Барсынбикә.

Дәү әнисе иплән кенә аның толымыннан сыйпады:

— Ярамый, кызым...

— Һы... Ярамый! Дивана да булдымы кеше!

Куксу бу чак эремчекме, сөтме кайната иде, чүмечне Барсынга тоттырып, үзе читкәрәк китеп утырды.

— Ходай бәндәгә зиһен белән тоемны тигез бүлми, кызым. Берәүдә зиһен бар — тоем юк; икенчедә тоем көчле — зиһен юк. Еланның юлын бүлгән мантымас, сөюнең юлын кыйган бәхеткә тарымас.

Дәү әнисенең үҗәтләнеп акыл өйрәтүен үгетләү дип аңлаган Барсын аптырауның чигенә житте:

— Дәү әни! Син мине диванага димлисеңме әллә?!

— Исәр... синең бишектән ярәшелгән кешең бар. Ходай үзе иш иткән аны сиңа! Диңгезханны...

— Шулай булгач?

— Әмма синең Сатыбалдыны дивана дип тәккәбберләнеп кире кагуың — язык. Син аннан кичерү, ярлыкау сорарга тиешсең!

— Хәзер барам да Сатыбалдың алдында тезләнәм. Янәсе, кичер мине... Мин, үкенечкә каршы, икенче кешегә ярәшелгәнмен. Мин вәгъдәмне боза алмыйм! — Барсынбикә моны дәү әнисенә тезләнеп, куллары белән ишарәләп сөйләп күрсәтте.

Диңгезхан белән Барсынның туе гөрләп үткән бер мәлдә, дивана кыядан ташланган, дигән хәбәр яңгырады. Фәүзиянең тегермән тоткасына ябышкан кулы тирләде, йөрәге лепердәп типте: «Минем өлешкә төшкән бу бихисап кайгылар дәү әнисенең «сөюнең юлын кыйган бәхеткә тарымас» диюеннән киләме әллә?!»

Сәер кеше булды аның дәү әнисе. Сөйләгән сүзе дә, кылган гамәлләре дә гади адәмнеке төсле булмады. Дәү әтисенең өч хатыны булып, берсе генә ул тапкан, анысы да, Барсынның әтисе, ауга китеп үлде. Аю өненә төтенлек салып маташканда, өстенә селәүсен сикергән. Тирә-якта даны чыккан аучының көтмәгәндә, юктан гына үлүе бөтенесен дә тетрәтте. Дәү әнисе генә моңа аптырамады шикелле, улын җирләгәч, өзгәләнеп елаган килененә, Барсынның әнисенә:

— Елама, килен. Тәкъдирдән үтеп берни эшләп булмый. Карахан туганнан бирле җан кыюга җиңел карады, үзенең дә җаны шуңа күрә көтмәгәндә кыелды. Шунысы яман: безнең токымнан бер Барсын калды, анысы да хатын-кыз заты...

Ул чакта сабыйларына, Ихсанбай белән Күксылуга, йөкле йөргән Барсын оләсәсен юатырга ашыкты:

— Кайгырма, оләсәй, мин берүзем җиде ул табармын!

— Җиде? — Күксу карчык гаҗәпләнеп оныгына карады. — Җиде... каян телеңә килде бу сан?

— Нигә?

— Җиденең серен берәү дә белми... Җиде эчендә бер дә бар, бер башында ниләр бар? Аны да беркем белми...

Оләсәсе әйткән рас килде: җиденең берсе булып Ихсанбай калды. Аның башында ниләр бар?

* * *

Уйлары авыр Фәүзия-Барсынның. Сибгат-Диңгезхан картая белеп картаеп, үз акылында булса, аның башы бу чаклы буталыр идеме? Фәүзиянең җитмеш төрле чирдән шифа да, чамадан чак кына арттырып җибәрсәң, җиде минутта адәмнең тынын буып, йөрәген туктатыр тамыр тоткан куллары бераз хәлсезләнде, бераз сизелер-сизелмәс калтыранды. Нишләргә?.. Ярый, алдына менә бу ризыкларны тезәр. Нигезендә бай яшәгән, борынгы тарханнар тамыры үзе дә. Әйдә, гомеренең калган сәгатьләрен, ичмасам, бәхеттә үткәрсен. Эчәсе килсә эчсен... Барыбер эчте. Эчмәсә, Раузага барып юлыгыр идеме дә картайган көнендә сакалын кыруга тиклем барып җитәр идеме? Әй тиле... әй дивана! Тилеләрне чәчмиләр, алар үзләре үсә дигәннәре шушымы икән? Ахмакның ахмагы Шәңгәрәй аңларлык булгач, нәрсә дип уйлады икән битендәге миңен? Миңе миң ише генәме — тәре бит! Нәкъ урысның тәресе! Әгәр теге төндә, волость түрәләренең җанын кыеп чыккан каһәрле төндә, бер генә адәм качып торып калган булса да, тере шаһит, тере дәлил бит... Әй Диңгезхан, Диңгезхан... Ихсанбае да шәбәйгән. Әтисенә гел киреләнеп тора, киреләнеп сөйләшә. Әллә шул да кирелеге белән картның теңкәсенә тиеп бетсә кирәк. Ни юанырга, күңел басарга Сәбиләсе бәбәй тапмады. Гөлбанукаемның әнә ике малае коеп куйган Диңгезхан да бит... Ә кызы — Мәдинә — ул үзе, Фәүзия-Барсынбикәнең яшь чагы...

Язмышлары шушылай чуалмаган булса, шул балаларны Сибгат тә, мөгаен, сөеп туймас иде дә бит. Болай нәрсә — өй тынычсыз.

Дөресен әйткәндә, өй пәрие төсле, сарайдай йортта бер Сәбилә йөри. Ел да авырлы, ел да, алты ае тулгач, үле бала таба үзе. Шуңа күрә Ихсанбай бер җирдә, әтисе икенче җирдә күңел ача.

Ә Фәүзиянең уйлары бихисап... Чуалчык. Җитмәсә, ул тәүлегенә бары ике, күп булса өч сәгать йоклый. Калган вакыты буш үтә. Эшне дә ул тәмен белеп эшләми хәзер. Кем өчен тырышсын? Ихсанбай, Ихсанбай, диде — анысы да күңелне җылытмый. Күзәткәне — тәрәзә. Шул тәрәзәдән Гөлбануның өе күренеп тормаса, ул, мөгаен, акылдан язар иде. Сабыйларның өстен карарга кирәк. Тик ничек итеп белгертми бирергә? Мәдинәсе дә бит аңа һәрчак сәерсенеп, куркыбрак карый. Әгәр бу карт

фаш булса, аның үзенә дә, Ихсанбайга да тормыш бетә. Фәүзия инде үзен уйламый, ә менә Мәдинәләргә кем ярдәм итәр? Алар бит, дөресен әйткәндә, Фәүзия аркасында гына җан асрап киләләр...

* * *

Абзар арасыннан кергән Сибгат җиз комганнан кулын чайкады. Алачыкка таралган тәмле исләр борынын кытыклады, ахры. Борынын мыш-мыш тарта-тарта түргә узды. Фәүзия эндәшми генә ашъяулык җәйде. Сибгат-Диңгезхан нәрсәдер сизенде. Әллә бу карчык үзе башлап сүз кузгатмакчымы? Алай булса, бигрәк шәп!

Чәй ясалды, Сибгат алдына куелды. Сибгат тә ашыкмады. Тәм-том җитәрлек. Фәүзия пөхтә булды инде ул. Әмма суынган ул карчыгыннан, бизгән, җитмәсә, аның менә бу чем-кара үткер күзләренең һәрчак сынаулы, искәртүчән-боерулы карашы туйдырган. Шушыларны күрмәсә, Сибгат, бәлки, җиңелрәк яшәр иде. Үткәннәре шушы көннән-көн сөйкемсезләнә барган карчыкның күзләренә язылып, уелып-чокылып калган түгелме?! Сибгат-Диңгезхан нигә, ни өчен әле шушылардан элегрәк котылу чарасын күрмәде? Башка шаһитларыннан ул бит шундук, бик вакытлы арына алган иде... Фәүзия-Барсыннан котылырга тырышу түгел, аның күләгәсенә, бер колына әверелде... Әй ахмак, ахмак! Ни пычагыма кирәк булган аңа бу дөньяны төзү, соңгы алтыннарына тиклем биреп, Ихсанбайны сугыштан алып калу?.. Барысына да шушы карчыга борынлы, тилгән карашлы карчык гаепле. Имештер, җирдә үзенең токымын калдыра!.. Калдырды... Ихсанбайның үле туган балалары белән инде зират тулып килә. Әгәр дә Сибгаткә онык сөю бәхете тисә, бу тормыш ул тиклем туйдырмас та иде, кая соң алар? Рауза әнә җиләк кебек әле. Тапсам табам да бирәм бер малай, ди. Менә ничек бит ул, Сибгат-Диңгезханның тәне картайгач кына оҗмахка тиенде. Картайса да, Сибгатнең ирлек комары шиңмәгән дә, сүнмәгән дә — йокыга гына талган булган. Менә хәзер уянды, ерылган буаны туктатып кара, ташкынны кире буып кара! Булмый ул, тик менә карчыкны нишләтергә? Сибгат-Диңгезханга чыгып китәргә дә, уйсыз дөнья көтәргә дә ирек бирмәячәк ул... Сибгатнең башыннан барысы үтте, ә менә бу очракта ул кылган гамәлләрнең берсе дә бармый кебек. Һы... әгәр дә төнлә, йоклаган чагында битенә мендәр капласа?! Бүген

төн караңгы... Фәүзия-Барсынбикә инде йокымсырап, чайкалып утыргандай...

— Ә?! — Барсынбикә-Фәүзиянең кинәт тетрәнеп үзенә эндәшүе Сибгатне сискәндерде, шулай да үзен кулга алырга өлгерде.

— Нәрсә булды?.. Мин ни... бернәрсә дә димәдемче?

Фәүзия Сибгат алдындагы чынаякка чәйнегеннән су агызды.

— Йоклап барамчы... эндәшкәндәй булдың. Эч менә бу үлән чәен. Көн болытлы, сызланмый йокларсың...

Карчыгының утырган җиреннән ойый башлавы Сибгаттә ашкынулы-ярсулы дәрт уятты, йөрәген ещ-еш тибәргә мәҗбүр итте. Йөрәксенүен белдермәскә тырышып, тамагын кырды, калагын әле чияле, әле шомыртлы майга сузды.

— Яман көндә яхшы аш дигәндәй... Менә боларны чыгарып, ничек яхшы эшләгәнсең...

— Күптән тамакны караган юк. — Фәүзия карты алдында, баягыдан да куерак итеп, тагын чәй ясады. — Эч, эч, кушып, тәмләп, капкалап эч... Киленнең бәбәе булса, килгән-киткәнгә дип саклаган идем, булмас, ахры, тагын эчен тотып ята.

Сибгат-Диңгезхан чәй эчкән саен, тәненә изрәткеч рәхәтлек, җылылык таралганын тойды. Тәне авырая, йокысы килә башлады. Әйе, башта ул ятып алыр... Әйе, әйе... Фәүзия-Барсын йоклый да инде, мендәргә башын салды. Ярым караңгылыкта йөзе аграк күренә, маңгаеннан шуган яулыгыннан кыйгач кашлары күренә, керфекләреннән күләгә төшеп, күз төбен карарак күрсәтә. Матур чакларың бар иде синең дә, Барсынбикә! Гайрәтле чакларың бар иде! Шулай булмаса, Диңгезхан сине сайлар идеме?! Әмма һәрнәрсәнең үз вакыты, үз мизгеле! Әллә кайчангы даныңны — матур чагыңны хөрмәтләп, болай да күп яшәде Диңгезхан синең белән, күп түзде. Инде җитте. Тыныч йокла, Барсын... Син инде күптән үзең дә яшәмисең, миңа да яшәргә ирек бирмисең...

Бишенче бүлек

Камалетдинов кыска гына йокысыннан сызланып уянды. Һай бу яралар, инде бетәшмәс тә, төзәлмәс тә. Нигә шулай тормыш аңа гел киреләнеп торды икән? Алты яшьтә чагында ятим калу... Ятим калу гынамы? Әгәр дә

син үзеңне дөньяга бар кылган иң якын кешеләреңнең үлемен үз күзләрең белән күреп торсаң... Әти-әнисе дигәннән, әле төшендә аларны күрде түгелме Әюп? Тик менә әтисенме, әнисенме күрде ул? Кеме белән сөйләште? Нигә әле Әюп соңгы вакытта күргән төшләрен уянгач хәтерли алмый интегә? Хәер, аның ни кирәге... Алай дисәң, ул гомере буена әти-әнисен тик төшендә күрү белән генә юанып яшәде бит! Хәтта сугышта да... Анда да кыска гына ял вакытларында шушы ике кадерле кешесен күрсә, әллә ни тиклем вакыт күңеле булып, тынычланып йөрер иде.

Тышта төн. Иртә язның кара төне тышта. Ул чакта да... теге каһәрле төндә дә шушылай айсыз караңгы иде. Ишек шакыдылар. Әюп иң алда уянды, шуннан әтисен уятты. Әтисе ишек ачар алдыннан кинәт аны мич артына качырды.

— Нишлисең син, әти?

— Тсс... Тавышың чыкмасын.

Әтисенең келәне ычкындыруы булды, эчен тотып бөгелеп тә төште.

— Аһ-аһ!

— Газиз... — Әнисенең тавышы кабат чыкмады. Кулына пычак тоткан кеше шырпы сызды. Караватт артын, почмакларны карады. Икенче сызган шырпысын аяк астына ташлады.

— Шылдык. Беркем дә юк монда!

— Тукта...

— Ашык! Тагын өч өйгә керәсе бар.

Алар киткәч, Әюп байтак вакыттан соң гына исенә килде. Таңны әтисе белән әнисе мәете арасында үзе дә канга баткан килеш каршылады. Авылдагы дәү әнисе Газраил хакында сөйләгән иде. Төнлә килеп кереп, әтисе белән әнисен суеп чыгучыларны әнә шул газраилләрдер дип уйлады. Соңыннан үзеннән револьверлы кешеләр ни булганын сораша башлагач:

— Газраилләр килде, — диде, — абый кеше тавышы белән ишек ачтырдылар.

— Ниндирәк иделәр? Йөзләрен күрдеңме? — дип сорадылар.

— Күрдем. Шырпы сызганда күрдем, — диде Әюп.

— Элек берәр җирдә күргән-очратканың булмадымы берәрсен?

— Юк.

— Хәзер күрсәң таныр идеңме?

— Әйе.

— Ничек итеп?

— Битеннән.

— Бите нинди иде?

Әюп уйлана төште. Берсенең битендәге кара миңе нәрсәгә охшаган иде әле? Кайда күргән иде Әюп шуңа охшаган нәрсәне? Ә-ә, белде: шәһәргә барганда, Әюп әтисеннән: «Бу нинди очлы түбәле өй?» — дип сораган иде, әтисе: «Чиркәү», — диде. «Башындагы нәрсә ул?» — дигәч, «Тәре!» — диде.

— Битендә аның тәре иде.

— Тәре?!

Тәре... Соң, бүген әле яңа күргән төшендә әнисе аны нык итеп җитәкләп алган. Үзләре, ахры, шәһәргә барганнар. Әнисе нәрсәгәдер төртеп күрсәтә, Әюп төшенә алмый... Нәрсәгә, нәрсәгә күрсәтте әнисе? Тукта! Алар бит чиркәү яныннан үтеп баралар иде. Әнисе аңа тәрене күрсәтте!

Камалетдинов шабыр тиргә батып торып утырды. Күрше бүлмәдә Габделәхәтнең тигез тын алганы ишетелә. Уятса җәл инде. Тик берүзенә кара төндә, җитмәсә, менә бу төшне күргәч, бигрәк ямансу...

— Әхәт, Әбделәхәт...

— Ә-ә... Әюп абый? Ни бар? — Габделәхәт шунда ук уянды.

— Берни дә юк... Төш күрдем.

— Төш?.. — Габделәхәт, чыгып, капшана-капшана, аның янына килде. — Нинди төш, абый?

— Ят, ят, юкка торгызДЫМ.

— Ничава... — Габделәхәт шырпы табып сызды: — Тартасыңмы?

— Әйдә. Мин бит үткән атнада Тирәклегә сугылдым.

— Беләм.

— Син үзең шуннан бит. Сорашмадың да...

— Нәрсәсен сорашасың, Әюп Газизович?

— Якыннарыңнан шулай ук беркемең дә юкмы?

— Юк. Хәзер юк.

— Нәрсә, әллә...

— Сугышка тиклем утарда ятып чучка карадым. Шунда бер гаилә белән бер өйдә яшәдем.

— Алар кая соң?

— Шәһәрбану апай дөнья куйган. Кызы... Гөлбану... — Габделәхәт ул фаҗигане үзе дә сугыштан кайткач ишетте. Хәер, сугышка кадәр ашадылар кызыкайның башын...

Ә сугыш вакытында бүреләрдән ашатканнар... — Юк инде ул, Әюп Газизович. Үлгән.

— Үлгән?

— Әйе, бүре ашаган.

— Һы, бер дә сөйләгәнең булмады бит...

— Нәрсәсен сөйлисең? Гаиләле иде инде ул...

— Балалары калганмы?

— Кызы бар иде... Да... Зурдыр инде ул... — Габделәхәтнең күз алдына чем-кара керфекләр белән каймалган зәп-зәңгәр күзле Гөлбану килеп басты. Азап белән яшәп, азап белән үлеп китәр өчен генә шултиклем сылу булып дөньяга килү нигә кирәк булды икән Гөлбануга? Шул сылулыгы булмаса, Габделәхәт тә, бәлки, тартынмый сүз куша алган булыр иде аңа...

Хәер, барыбер эндәшә алмас иде, яшь иде бит әле Габделәхәт, бөтенләй малай гына иде...

— Әбделәхәт, сиңа Тирәклегә барып кайтырга кирәк.

— Нигә?

— Нигә дип, эш бар... — Камалетдинов, торып, яланаякларын идәнгә төшерде. — Разведкага, иптәш өлкән лейтенант.

— Һы... Тыңлыйм, иптәш генерал-полковник. Ни боерасыз?

— Тыңла...

* * *

Ихсанбай җыелыштан кара төннән дә карарак булып кайтты. Мирхәйдәров саруын нык кайнатты. Тамакка кадалган кылчыктай булды шул: ни үзе китми, ни йотарга бирми. Кара, ничек әтәчләнә! Имеш, алар кан койган, ә монда кайсыбер җитәкчеләр трай типкән. Ул гына да түгел, фронтовикларның гаиләсенә килеп, сыерларын тартып алган, үзләрен ач бүреләр көтүенә ташлаган, хәмер эчеп, фронтовикларның хатыннарыннан көлеп яшәгән... Ә бит, әйтелгәннәр үзенә кагылганын сизсә дә, Ихсанбай, торып, каршы сүз әйтә алмады. Үзен якламады. Әйтерсең лә аны утырган утыргычына җан җиреннән кадаклап куйдылар. Үзен якларлык дәлилләре юк идемени аның? Шул ук сыер. Районнан иткә планны арттырганнан-арттыралар, шул ук вакытта сөткә дә планны киметмиләр. Кыз да булсын — буаз да булсын... Ихсанбай нишләсен? Дөрес, халыктан сыерны алдап алдылар, тартып алдылар. Кемгә көчләре җитте, шуларныкын алды-

лар. Башка юл тапмады Ихсанбай... ә бит ул сыкса сыкты, кысса кысты, илгә итен дә, сөтен дә, игенен дә бирде. Монда ничек каты булмыйсың? Каты булды Ихсанбай – анысы да рас. Булды инде, иген урлап ашаганнарның тизәкләрен карап торган чагы да булды. Шунсыз син аның урлашканын ничек исбатлыйсың? Бер-икесен шул юл белән тоттырып төрмәгә җибәргәч, урлашучы да булмады... Хәмер эчте, имеш... Эчсә эчте инде. Солдаткалар белән типтерде, диләр икән, көнләшүдән әйтәләр. Аркылы ятканны аша атламады Ихсанбай. Анысы рас. Мәгәр алар да сугыштан суфига әйләнеп кайтмаганнардыр. Шулай инде ул. Шулай ярагылган. Аларны бит сугышка берсен дә печтереп җибәрмәделәр...

Ә шулай да Мирхәйдәров каныга... Гөлбануның игезәкләре хакында хәбәрне җиткерсәләр?.. Бүген үк ул: «Киләсе җыелышта кайсыбер иптәшләрнең партия сафында калу-калмавын караячакбыз!» – дип торды, алга таба да шушылай барса, бетте баш. Җитмәсә, әтисе. Карт шайтан сакалын кырган. Камалетдинов бик каныкты аңа, бик төпченде. Ихсанбай бер-бер чарасын күрмәсә, ул карт белән әллә нигә таруың бар. Ашарын ашаган, яшисен яшәгән. Анысы да рас.

Ихсанбай, Зарифа яшәгән тыкрыкка җиткәч, бераз таптанып, уйланып торды. Керергәме, юкмы? Ә өенә кайтасы килми, мәгәр әтисе мәсьәләсе хәл итүне көтә. Нишләргә? Юк, бүген кайтсын әле ул. Баш очында болытлар куера... Сәбиләсе, җан көеге, тагын үле бәбәйләр табар микән? Кызык бу дөнья: Сәбилә Ходайдан сорап та бала ала алмый, Гөлбануга исә бер төн, бер мизгел эчендә бер түгел, ике сабый бирде. Хәзер әнә алар, Ихсанбай җинаятенең тере шаһитлары булып, күзгә күренеп үсәләр. Пычрактан арындырып, юындырып, киендереп алсаң – суйган да каплаган Ихсанбай.

Берсеннән-берсе шомлы уйлар белән ир капкасын ачты. Ул кайтуга һәрчак эчтән бикле була торган капка бу юлы ачык булып чыкты. Әнисе капканы ачуга күнеккән Ихсанбай. Мал өендә ут та күренми, боларга нәрсә булган? Карт шайтан, ярый, Раузасындадыр. Ә әнисе? Ихсанбай мал өенең ишегенә барып җитте, колак салды – тавыш-тын юк. Шомлы тынлык аны пошаманга салды. Абзар эчендә әтәч кычкырды. Әтәчме бу... Әллә тавыкмы? Тавык, ахры. Әйе, тавык. Әтәче бит күрше әтәчтән таланып үлде. Ихсанбайның йөрәге кысылып, тыны буылды.

Хәерлегә булса ярый да... Тавыкның әтәч булып кычкыруы охшамый да... Җитмәсә, эңгердә. Иртәгә үк суеп ашарга кирәк. Тик кайсысы икән?..

* * *

Габделәхәт үргә таба атының җаена куйды. Шушы үрне менсә, Тирән үзәк. Аннан күтәрелсә, Тирәкле үзе дә күренәчәк. Габделәхәтнең район үзәгенә кайтып эшли башлавына да елдан артык гомер үтте. Тирәклене кайтып күреп килү теләге көчле булса да, нәрсәдер тыйды. Анда да бит Габделәхәтне күңел әрнетерлек истәлекләрдән башка берни көтми. Ятимлектә үткән балачак. Утыз өченче ел. Әнисе ачлыктан үлгәндә, Габделәхәткә нибары өч яшь иде. Эш, кәсеп эзләп шәһәргә чыгып киткән әтисе артыннан имчәк баласын күтәреп, Габделәхәтне җитәкләп юлга чыккан әнисен ул бәләкәй булса да яхшы хәтерли. Шушы рәвешле авыл саен туктый-туктый бардылар алар. Кайсысы кертеп катык эчереп чыгарды, кайсысы эт шикелле өреп куып та чыгаргалады. Эсседәнме, ачлыктанмы — энесенең эче китә башлады. Әнисе, кайчандыр бик сылу булып, хәзер инде ачлыктан, нужадан ач яңаклы, саргаеп кипкән хатын, елгага төшеп, бәбәйнең чүпрәк-чапрагын юып агачка элә. Үзе дә агач күләгәсенә ятып ял итеп ала. Габделәхәтнең башыннан кытыршы кулы белән сыйпый да:

— Түз инде... Күп калмады. Калага барып җиткәч, әтиеңне табарбыз. Күп итеп икмәк алып бирер әтиең, — ди...

Габделәхәтнең күп икмәкне күргәне юк. Күп булгач, ул әти хәтле була микән, әллә әти үзе икмәк хәтле микән?

— Әни, кала икмәк буламы?

— Юк, балам, кешеләр яши торган җир.

— Авылда да кешеләр яши бит, әни?

— Әйе.

— Ә нигә анда икмәк юк?

Әнисе эндәшми. Бәбәй тагын елый. Әнисе аның зур ачылган авызына имчәген тыга. Сабый бер-ике суыра да, тагын авызын зур ачып елый башлый.

Габделәхәтнең шулчак шушы зур авызлы, күпкән корсаклы, нәзек аяклы җан иясен үтереп ташлыйсы килә.

— Әни, әйдә шуны үтерик!

— Ахмак! Нигә шулай дисең?!

Габделәхәткә кыен. Әнисен җәлләп кенә әйтте, ә әнисе аңламады. Әрләшә. Ә бит белә Габделәхәт: кеше үлсә, ашарга сорамый. Дәү әнисе дә шулай итте. Озак итеп сәкедә сузылып ятты. Габделәхәт әнисенә:

– Дәү әни нигә чәй эчми ул? – дигәч, әнисе:

– Үлгән, – диде.

Шулчак Габделәхәтнең сузылып ятасы да үләсе килде: ичмасам, икмәк турында уйлаудан туктар иде.

Бәбәйнең тагын эче китте. Әнисе, чүпрәкләрен алып, су буена төште.

– Энеңне кара! Әтү тагын пеше чыбык эләгер!

– Әһә... – Әмма әнисенең китүе булды, Габделәхәтнең агачка үрмәләп, кош оясын карарга менүе булды. Бәлки, анда йомырка бардыр? Малайларның саескан оясыннан йомырка алып төшеп, сытып эчкәнен күргәне бар иде бит аның. Тик ничек менеп җитәргә? Габделәхәт ботактан ботакка басты. Әнә ояга да күп калмады. Шулчак кинәт эт ырылдаган тавышлар ишетелде. Аһ, алар монда таба килә. Әнә ләбаса бөтенләй якынайдылар! Тешләрен ыржайтып килгән этләр кинәт сагайды. Берсе, Габделәхәтне күреп, тагын да ныграк ыржайды. Агач тирәсе эт белән тулды, акырып елаган бала кинәт тынды...

– Әни! Әни-и-и!

Күсәк тоткан әнисе яр астыннан килеп чыкканда, бәбәйдән канлы таплар гына калган иде...

Сугышта күпме кан күрде Габделәхәт. Үзе яраланды. Госпитальдә дә ятты. Мәгәр әнә шунда күргән кан исеннән чыкмый, кан күргән саен, шул фаҗига ап-ачык булып күз алдына килеп баса.

Әтисен дә тапмады алар. Шәһәрдә әллә нинди баракта йоклап йөрделәр. Ә беркөнне әнисе йокыдан тормады. Баракка йокларга килгән юлаучылар Габделәхәтне кире авылга утыртып алып кайттылар. Әнисенең сеңлесе, бөкре Ниса карап үстерде аны. Габделәхәт дуңгызчылыкта эшләгән чакта, ул да мәрхүмә булды. ФЗӨ, сугыш. Сугышта командирының якташ булып чыгуы нык шатландырды Габделәхәтне. Камалетдинов та аны якын күрде. Ике ятим уртак телне тиз таптылар. Сугыштан соң мәдәният буенча китәргә дә Әюп Газизович киңәш бирде.

– Гармунны әйбәт тартасың, тавышың да моңлы, укып кайт та мәдәниятне күтәр, – диде ул. – Сугыш җәрәхәтләрен төзәтү өчен хәзер җыр кирәк, сагышны басар өчен моң кирәк.

— Габделәхәт каршы килмәде. Укып бетергәч, кая барыйм дип баш ватмады, туры Әюп Газизовичка туктады. Шуннан бирле икәү яшиләр.

Әле менә Тирәклегә китеп бара. Көтмәгәнчәрәк килеп чыкты. Атының башын кемгә борыр? Туган авылына килеп, кәнсәләргә туктавы да уңайсыз бит әле. Дөрес, күршеләре бар иде. Рауза апа. Телгә оста бер хатын иде. Аңа керсәң, иртәгәсен бөтен авылга күлмәгеңдә ничә сәдәп барлыгы билгеле була инде. Бер яктан карaганда, Камалетдинов кушкан йомышны үтәү өчен нәкъ шул Рауза апа кирәк тә инде: белмәгәне юк. Әлбәттә, озаграк сөйли, аның каравы никадәр хәбәр ишетәсең.

Шулай итеп, Әюп Газизович Ихсанбайның әтисе Сибгат карт белән кызыксына диген... Дөресен әйткәндә, Габделәхәт ул картны бик томанлы хәтерли. Тимерчелеккә ат дагаларга барганда бер күреп калды. Бите-башын сакал-мыек баскан бер бәндә иде. Тагын нишләптер күзләре исендә калган, бәлки, күзләре, коңгырт йөзгә бигүк хас булмаганча, зәп-зәңгәр булгангадыр? Ә менә озын кара күлмәк, кара җилән, башына, кашына төшереп, кара шәл ябынып йөргән карчыгы исендә Габделәхәтнең. Габделәхәт аңа һәрчак курку катыш кызыксыну белән карый торган иде.

Кызык, ләкин шулай да булды: Габделәхәтнең ялангач хатын-кыз тәне белән беренче очрашуы нәкъ шул хатын белән бәйле. Кем иде әле аның исеме? Фәүзия иде, ахры...

Әлеге дә баягы дуңгыз фермасының аты югалды. Бер көн эзләде Габделәхәт, ике көн эзләде. Җәйнең уртасы иде микән, ни булса да, көн бик эссе иде. Бөтен кеше печәндә. Габделәхәт, сусавына чыдый алмый, чытырманлык ерып булса да, озын кичүгә су эчәргә төште. Ботакларны ерып суга барып чыгуы булды, елга уртасында шыр ялангач хатын-кыз гәүдәсе пәйда булды. Ул арты белән тора — Габделәхәтне күрми. Ике кулын югары күтәргән дә:

— Тәңрем, Күксылуыма баладан исән-имин котылырга ярдәм ит! Бигрәк авыр йөри... Туар сабые хакына өзмәче гомерен! — дип ялвара.

Чем-кара озын чәчләре тезеннән аска төшеп, су агышына сибелгән, тар гына җилкәсе, нечкә биле, тулы янбашлары әллә нинди сурәттә күргән илаһи бер сынны хәтерләтә. Хатын кинәт сискәнде, артына әйләнде, ярый әле Габделәхәт ботаклар арасына посып өлгерде.

Посса да күрде: бу Фәүзия иде. «Менә сиңа карчык!» — Габделәхәт хәтта аның тулы күкрәкләрен дә күреп өлгерде. Гаҗәп. Ялангач хатыннар бу тиклем дә матур була икән дигән уй үсмер егетнең башына да килгәне юк иде. Фәүзия карчык бу кадәр матур булгач, башкалары, яшьрәкләре, ничек икән боларның? Габделәхәт иплән кенә артка шуышты...

Утарга кире кайтуына, аты шунда йөри иде. Габделәхәт күргәннәренең төш түгел икәнен аңлады, тик бер нәрсәне зиһене сыйдыра алмады: Күксылу кем ул? Кемгә гомер ялварды Фәүзия? Күксылу... Колак ишетмәгән ят исем бит...

Камалетдинов Сибгат картның битендәге миңенең ни рәвешле булуына кадәр белергә куша. Ул чакта миңфәләне юк иде бит аның, Сибгатнең. Бәй, йөзен сакалмыек баскач күренмәгән генә микән?

Тирән үзәккә төшкәч, елгадан җиләслек бәрелде. Ниса апасы белән шунда печән чабарлар иде. Соңыннан, апасы үлгәч, бу җирләр кемгә күчте икән? Габделәхәт андагы һәр тирәкне, һәр шомыртны белә торган иде. Юк, болай гына үтеп булмастыр, туктамыйча, ятып суын эчмичә түзмәс.

Никадәр гомер үткән, ә җир-су шул ук, хәтта елга читендәге әнә теге тирәк тә... Габделәхәт, атыннан төшеп, елгага атлады. Кичүне караштырды, бер уңайдан атын да эчереп алса, юынып, өс-башын кагыштырып, хәл җыяр.

— Саумы Габделәхәт?!

Кинәт колак төбендә ишетелгән тавыш аны сискәндерде. Бәй, беркем дә юк кебек иде бит. Габделәхәт артына әйләнде.

— Һашим?!

Һашим кулын сузды:

— Саумы әле, Габделәхәт энем...

Габделәхәт аның солдат киемендә булуына игътибар итте. Шулай ук яңарак кына кайтты микән? Һашим аның карашын сүзсез аңлады.

— Шулай килеп чыкты инде, энем. Госпитальдән госпитальгә йөри торгач, вакыт үтте дә китте.

— Хәзер ничек соң?

— Шөкер, титаклыйм, мәгәр үз аягым белән йөрим. Күзгә начарракмын, ләкин күрәм. Колакка катымын — ишетәм.

Габделәхәт бер өшеде, бер янды. Гөлбану шушы кешегә кияүгә чыккач, күпме яшь түкте, күпме рәнжеде... Бөтенләйгә ятим итте бу кеше Габделәхәтне...

— Әле кая юл тотуың?
— Районга... түрәләргә. Йомыш белән.
— Берәр подвода булмадымы?
— Булыр иде дә... Юл уңаеннан эшләп китәр эш бар иде. Әйдә, — Габделәхәт Һашим артыннан иярде. Үргә менгәч, яңа гына казылган, чит-чите таштан салынган туфрак өеме күрде. Кыйбла ягына таш та куелган...
— Кабер?!
— Кабер... — Һашим таш алдына чүгәләде. — Сугыш корбаннарын, Габделәхәт энем, без әле шулай озак, бик озак җирләрбез...
— Ходайголова Гөлбану Тәңребирде кызы... — Габделәхәт әкрен генә җиргә чүгәләде. — Аны шушында...
— Әйе, шушында...
— Матур җиргә җирләгәнсең...
— Хәлемнән килсә, мин аны, Габделәхәт энем, оҗмах бакчасының уртасына җирләр идем. Дөресрәге, хәлемнән килсә, җир куенына бер дә бирмәс идем.
Габделәхәт аптыраулы карашын Һашимга төбәде: бу сүзләрне чынлап Һашим авызыннан ишетәме, әллә ялгышамы?!
— Кызы бар иде Гөлбануның. Ишеткән идем.
— Мәдинә, әйе, бар. Авылда. Аннан башка тагы ике малай бар. Игезәкләр. — Һашимның тавышы кинәт җылынды, ниндидер эчке балку, горурлык белән тулды. — Өч бала атасы мин, Габделәхәт энем. Гөлбануымнан калган өч бөртек әманәт...
Габделәхәт Һашим белән тагы байтак сөйләшеп утырды, элекке зимагурдан шундый тышкы кыяфәт кенә калды микән? Шулайдыр, ахры. Күзләре дә хәтта башкача карый, алардан ниндидер җан эретерлек җылы нур бөркелә.
Аерылышканда алар дусларча кул кысыштылар.
— Йомышыңны Камалетдиновка сөйлә, — диде Габделәхәт. — Туры өенә бар, минем бүлмә буш. Шунда йокла. Әйбәт кеше ул Әюп Газизович, күпне күргән. Тыңлар, ярдәм итәр...
— Син дә авылда кемгә төшәргә белми йөрмә, — диде Һашим. — Туп-туры безгә кер. Мәдинә фермадан кич кайта ул. Әтиеңне күрдем диң, әнисен... Гөлбануны белгәнеңне сөйлә... — Һашимның, соңгы сүзләрен әйткәндә, тавышы карлыгыбрак чыкты... — Сез бит аның белән пашти яшьтәшләр идегез. Йә, ярый, хуш...

Алтынчы бүлек

Рауза гадәттәгедән иртәрәк уянды. Уянгач, йомры беләгенә башын салып, кичтән пәрдәсе тартылырга онытылган тәрәзә аша төшкән иртәнге кояшның якты нурына күзен кыса биребрәк уйланып ятты. Ат җене кагылган улы күптән инде шунда, ат сарае ихатасына терәтеп салынган каравылчы өендә яши. Мунчага да кайтарып булмый. Өйләнергә дә уйламый. Үзенә бертөрле тормыш белән яшәп тик ята. Рауза утынны да бит хәтта кешедән алдырта. Улына әйтсә:

— Не хватало лошадей мучить, так-итак им достаётся! — ди. Урысча әйтә.

Рауза аны барыбер аңлый. Үз баласы бит.

Сибгатнең әнисенә өйләнүенә дә улының исе китмәде.

— Ладно, сама знаешь. Наверно лучше, чем домовой, — диде.

Рауза, дөресен әйткәндә, домовой дигән белән дә яшәргә әзер. Ялгызлык бер Аллага килешсен, димәсләр иде, ансат булса. Теге татар белән күпме генә торды ул? Бары шул: ни урыс, ни башкорт түгел бер ул калдырды. Анысы да Раузага түгел, атларга язган җан иясе булып чыкты...

Кеше ирләренә күз-каш сикертеп тә карамады Рауза. Намус саклады. Берәү булса да, улы бар, үземнән көлдермим, диде. Ә менә Сибгатне, мөгаен, Ходай үзе белеп җибәрде! Шулай булмаса, улы Ихсанбай белән ни гомердән бергә эшләп, аралаша-катнаша йөреп, бер булмаса, бер очраштырыр иде бит. Юк, андый хәл булмады. Ә беркөнне ул үзе килеп керде. Килеп керде һәм кайтмады. Шуннан инде бу хәлне ничек итеп Ходайдан димисең? Тик менә кичә кич килмәде. Карчыкка әйтәм дә сәпсимгә күчеп чыгам сиңа, дигән иде. Теге албастысы җибәрми чат ябышты микән? Ир белән яшәрлек җире дә калмаган да бит бу Фәүзиянең, юк, үҗәтләнә һаман. Уйлап карасаң, Сибгат бит хәзер Раузаның өлеше. Кеше өлешенә нигә дәгъва итәргә кирәк? Рауза үзе ул яктан нык тугры булды. Кеше өлешенә кагылмады. Менә хәзер аның өлешенә кагылгач, Рауза ни кылсын? Бирмәскә, көрәшергә, шунысы дөрес тә булыр. Нәрсә эшләп ул үз өлешен кеше белән бүлешеп яшәргә тиеш?! Татарын тартып алганнары да баштан ашкан. Куенына үзе килеп кергән ирне чыгарып ятмаса...

Рауза торды. Башка вакыттагы кебек, түшәгендә киерелеп-сузылып утырмады, сикереп торып, кешелеккә кия торган, япмалары өстеннән тасмалар салынган күлмәгенә үрелде. Шушыны киеп алсын да китсен Сибгатне алырга. Камзулы таррак, шулай да бата: аның каравы укалары ялт итеп тора.

Урамга чыккач, үрдә, зиратта, кабер казыган кешеләрне күреп, Рауза туктап калды. Сорашырга аның янында кеше күренмәгәч, юлын дәвам итте. Әлбәттә, ул Фәүзия карчыкның карашыннан шүрли. Ну бит бүредән курыккан урманга утынга бармаган. Ә Сибгат — аның бәхете. Шушыңа тиклем ансыз ничек яшәвенә аптырый Рауза. Олыгайган саен гыйшык көчлерәк була, дигәннәре дөрес, ахры. Аһ, әнә Шәңгәрәй килә. Бөтен нәрсәне ул белеп тора.

— Шәңгәрәй, энем, аһ, нигә саулык сорашмыйсың?

— Уаф, уаф!

— Аһ, аһ! Бу ни дигән сүз?!

— Бу хәзер мин эт дигән сүз. Уаф, уаф!

— Кем сине эт ди, шуның теле корысын! Минем сине эт дигәнем юк...

— Уаф! Уаф!

— Аһ, аһ... Шәңгәрәй, зиратка кешеләр китеп бара, әллә берәр хәл бармы?

— Юк, бернәрсә юк.

— Берәү дә үлмәгәнме?

— Берәү дә үлмәгән!

— Алдашмыйсыңмы?

— Антым-синтым! — Шәңгәрәй, алмаш аяклап сикерә-сикерә, зират ягына чапты, үзе көлә. — Алдаттым, песи к...н ялаттым!

— И... сантый! — Рауза юлын дәвам итте. — Син исәрдән сораган мин ахмак!

Сибгатләргә җитәрәк, койма буенда сөйләшеп торган өч карчыкны күрде Рауза. Карчыклар, беренче тапкыр күргәндәге кебек, Раузага, аның кигән киемнәренә текәлделәр. Берсе генә бүленгән сүзен дәвам итәргә онытмады:

— Шул. Ихсанбай мулла чакыртмаска куша, ди. Коммун өендә какуй сезгә җеназа, дип әйтә, ди.

— Ихсанбайның әнисе бар бит әле! — Карчыклар баскан җирендә тораташтай каткан Раузага тагы күз сирпеп алырга онытмадылар.

— Булу беләнмени? Дөньяга бит хәзер балалар хуҗа!

– Шулай, шулай... Улның – әтисен, кызның әнисен тыңлар чакмы?

Рауза, телен көчкә әйләндереп, нидер сорашмакчы булды:

– Сибгат...

Карчыкларның берсенең коры гына җавабы ишетелде:

– Әйе, әйе... Карт киткән, гүр иясе булган.

– Сибгат... – Раузаның колаклары шаулады, башы әйләнеп, күз алды караңгыланды. Аяк астында менә-менә җир убылачак, һәм Рауза шул упкынга очачак. Җир белән бергә убылып, җәһәннәмгә китәчәк. «Ярдәм, ярдәм итегез!» – кычкырыр иде – тавышы чыкмый. Менә бу карчыкларның, һичьюгы, берсе генә кул сузса, җир дә, Рауза да урыннарында калыр иде. «Ярдәм, ярдәм!!!» – Рауза бит сезнең һәрберегезгә ярдәм итте. Һәрберегезнең кайгысын уртаклашты. Ашыгып кына кәнсәгә чакыртырга керсә дә, кайгыгызны бушатышыр өчен, утырмас җиреннән утырды, тыңламас җиреннән тыңлады сезне! «Ай-й-й!» – Рауза эченнән тышка бәреп чыгырга өлгермәгән авазы белән гөрселдәп җиргә ауды...

* * *

Габделәхәт зиратта кабер казыган кешеләрне Тирән үзәкне менгәч тә күрде. «Бүген булган икән... Әйтерсең Габделәхәтнең килүен көтеп торганнар». Шулай уйлады ул, авылның күренешен бер кабат айкагач. Авылы әллә ни үзгәрмәгән, тик авылга якын куаклык, тирәкләр киселгән. Күрәсең, сугыш вакытында атсыз хатын-кыз шушыннан ташыган утынны. Шулай. Менә Габделәхәт тә кайтты. Күңел җылытырлык бер генә морҗа булсачы. Нәкъ шуның булмавы сәбәп түгелмени Габделәхәтнең авылына кайтуын кичектереп йөрүенә. Туган авылында үткәне белән бүгенгесен бәйләр ичмасам бер генә йорт булмавы ничек начар... Әнә баткак юлдан берәү ат белән килеп чыкты. Туктады әле бу. Атның яхшы булуы игътибарын җәлеп итте микән?

– Саумы, энем... кем дип торам... үзебезнең Габделәхәт лә инде син?!

Габделәхәт тә таныды аны. Районда күргәләгәне дә бар:

– Мирхәйдәров абый! Саумысыз?!

— Саумы, энем, саумы?! — Мирхәйдәров, ике куллап күрешеп, Габделәхәтнең аркасыннан какты. — Ир булгансың, үсеп киткәнсең! Әйдә, арттан төш. Туп-туры үземә апкайтам. Җиңгәңә тавык суеп биреп калдырган идем, ничек яхшы булды!

— Зиратта, — Габделәхәт ияге белән шул яка ымлады.

— Ә-ә... Әйе, әйе... сөйләрмен. — Мирхәйдәров тарантаска менеп утырды. — Әйдә, энем. Килеп ничек яхшы иттең!

Мирхәйдәровның аның килүенә бала төсле сөенүен күрү Габделәхәтнең күзенә яшь чыгарды: «Мин кем инде аңа, әйтерсең бертуган энесе...» — дип уйлады ул, Мирхәйдәровның уңган гимнастёрка кигән аркасына карап. Шулай да бирешкән, нык бирешкән ул. Колхоз рәисе хәзер шул дип ишеткән иде Габделәхәт. Сугышка кадәр мәктәп директоры иде ләбаса ул. Күрәсең, көчләп куйганнардыр. Сугыш вакытында хәлсезләнгән хуҗалыкны җитәкләү, ай-һай, җиңел түгелдер...

— Хатын! Ач капкаңны! Кунак апкайттым.

Капка ачарга йөгереп чыккан түгәрәк йөзле хатынны шунда ук таныды Габделәхәт: бу бит теге җырдан укыткан Сәрбиназ апа! Чын исемен әйткәннәрен Габделәхәт хәтта хәтерләми дә. Бөтенесе дә аны, яратып, «Матур апай» дип йөртте.

— Матур апай! Саумысыз, матур апай?!

Үзенең йомышы хакындагы сүзне Габделәхәт ашап алгач, лапас астында, күләгәгә чыгып утыргач кына башлады. Дөресрәге, башламаса да, үзеннән-үзе шулай килеп чыкты.

— Кемнедер җирлиләрме әллә?.. — Габделәхәтнең авылдашларының язмышын тизрәк беләсе килә, ә Мирхәйдәров ул сөйләшүне һаман артка кичектергәндәй.

— Теге нине бит... Сибгат картны.

— Тимерченеме?!

— Әйе, әйе, Ихсанбайның әтисен. Төнлә йөрәге туктап үлеп киткән. — Мирхәйдәров көлемсерәде. — Чак кына яшь хатынга чыгып китми калды.

— Яшь хатынга?

— Ну... әнә кәнсә караган Раузага иярләшеп китте бит ул. Картның табаны астына ут капкан иде кабуын...

— Да-а...

— Нигә? Син аны шулай яхшы хәтерлисеңме? — Мирхәйдәров Габделәхәткә сәерсенебрәк карады. — Алар, ни, бу авылга күчеп кенә килгән кешеләр...

— Кайдан?

— Кайдан икәнен кем белсен... Элек андый халык күп булды бит. Этем белсен... мужет, раскулачиваниедан качып йөргән бәндәләр булгандыр...

— Андый уй... — Габделәхәт әйтеп тә бетермәде, Мирхәйдәров эләктереп тә алды:

— Андый уй килә шул башка. Кинәт килеп шушында төпләнсәләр дә, ярлы яшәмәделәр. Урыс капкалы йорт, шитай, бер аларда.

— Әйе, әйе... хәтерлим. Елга буенда гына.

— Ихсанбаен сугыштан алып калды...

— Авыру булмадымы ул?

— Кайдан авыру булсын? Ул әле дә бурсык сыман. Ә хатыны Фәүзия... Ул бит кеше белән аралашмады. Бикләнеп яшәде.

— Киленнәре бар иде шикелле.

— Әй, әйе... Сәбилә. Анысы инде исем өчен. Ихсанбайның хатын — өй борынча...

Габделәхәтнең башына эссе капкандай бит очлары яныш китте: шулай ук ул соңлады микән? Шулай ук Камалетдиновның йомышын үтәми кайтыр микән? Хәер, үлгән кешедән сорау алып булмый.

— Миңа аны күрергә кирәк иде, Чынтимер агай.

— Кемне, Ихсанбайнымы?

— Юк, әтисен.

— Һы! Аны хәзер күр ни дә, күрмә ни...

Мирхәйдәров белән Габделәхәт зиратка килеп житкәндә, карт төшерелгән чокырга туфрак өеме өелгән иде инде. Килгән кешеләр аны-моны уйламады, түрә бит, хушлашырга килгәндер дигән уйда калдылар. Бер карт Габделәхәт янына басты:

— Мәетне арытмыйк, дидек. Җомгага тиклем җирләү хәерле...

— Анысын үзегез беләсез инде. — Мирхәйдәров тәмәке кабызды.

Карт китәргә ашыкмады:

— Тик менә сөякләр өстенә җирләдек. Мондый хәлнең булганы юк иде, беркайчан да...

— Ничек... «сөякләр өстенә»?

— Шулай. Кабер казып төшкәннәр иде — кеше күмелгән булган. Сөякләрне кузгатып тормадык, өстенә җирләдек.

— Гаҗәп... — Мирхәйдәров белән Габделәхәт китеп бардылар. Габделәхәт Ихсанбайның үзгәрүен күреп ап-

тырады: шешенгәнме, симергәнме шунда. Үзе районда иң шәп авыл Советы рәисеннән санала. Дөресен әйткәндә, клублар Габделәхәт карамагында булгач, Ихсанбайны да күрми булмый. Әш шуны таләп итә. Ә Камалетдиновның йомышын үти алмады Габделәхәт: соңлады. Күрәсең, бәндә теле — Алла боера, дигәннәре шулдыр...

* * *

Әтисен җирләп кайткач, Ихсанбайда уянган иң зур теләк — үтереп эчәсе килү булды. Бер яктан күңеле тынычланды: ни дисәң дә, карт йөгәнсез холкы белән Ихсанбайны киеренкелектә тотты. Соңгы вакыттагы холыгы, гомумән, адәм аңларлык булмады. Теге кәнтәен, Раузасын, иртәгә үк эштән куарга кирәк. Чыксын колхоз эшенә, аз булса да мае кимер, нәфесе басылыр.

Икенче яктан, әтисенең кинәт юк булуы Ихсанбайны нык кына тетрәндерде. Нәрсә өчен яшәде ул? Гомере буе кешедән качып-посып гомер итте, каты бәгырьле хатынының табан астында булды, ә үзе аның бер елмаеп каравына ирешә алмады. Ихсанбайның үзеннән дә бер юньле сүз ишетмәде. Бәлки, аның Раузага бәйләнүе гомерендә бер булса да коллыктан ычкынырга тырышуы, аз булса да үзенчә яшәп калырга омтылуы булгандыр?

Ихсанбай үзе гомере буе бер төрле уйлый, икенче төрле эшли. Ниндидер аңлашылмаган күралмаучанлык яши аның әнисендә тормышка. Шул тойгыны ул үзе дә сизмәстән улында да тәрбияләде. Ихсанбай кычкырып көләр чагында тешен кысты, шашып сөяр, мәхәббәтен яулап утка керер бер чакта сөя алмады, чигенде: кулына килеп кунган аккошны каракошка алмаштырды. Башкалар туфан булып кубып ил сакларга китте, Ихсанбай качты, качкан саен, сазга, баткаклыкка ныграк чумды. Хәзер аңа үз өе дә салкын бер төрмә кебек... Зарифага да аптыраганнан бара ул... Вакытлыча булса да онытылырга дип бара. Охшаш алар икесе дә. Икесенең дә күгелҗем-зәңгәр күзләрендә кеше белмәгән хәтәр упкыннар бар. Үзеңә үзең карау, үзеңне үзең ничек бар шулай күрү кызык түгел... Эчмәгән чагында Зарифаны җене сөйми аның, хәтта, айнып уянып киткәндә янында яткан шул хатынны күреп укшыганы, үзе дә сизмәстән шуны караваттан тибеп төшергәне бар.

Чияләнгән аның тормышы, чуалган. Хәзер җепнең очын үзе дә таба алмый. Мирхәйдәров каныга, бик каныга. Габделәхәт белән зиратка килергә ни калган иде аларга? Сәер, сәер... Сернең төене әнисенең төпсез упкын кебек күзләренә яшеренгән кебек тә бит, тик әйтәме соң ул, ачамыни ул күңелен?..

Ихсанбай капка төбендә таптанып торды да эчкә үтте. Әнисе яшәгән бәләкәй өйнең ишеге ачык. Карчык өйдәдер, мөгаен... Кабер казыган кешеләрне ашатып чыгарган, күрәсең: өстәлдә юылмаган савыт-саба тулып ята.

Әнисенең карашы белән очрашкач, Ихсанбайның йөрәге жу итеп китте, газаптан атылыр, сытылыр чиккә җитеп тулышкан бу күзләргә карап тору мөмкин дә түгел.

— Әни... — Ихсанбай үзенең тавышын үзе танымады. Кайчаннан бирле болай җылы итеп эндәшкәне юк әнисенә!

Әнисе кинәт күзләрен йомды, иреннәре, агарып ярылган, көч белән кысылган иреннәре:

— Чыгып кит... — дип ялварды.

Җиденче бүлек

Әтисенең кайтуы Мәдинәнең рәнҗеш, сагыш, юклык белән каткан күңелен эретеп, йөрәгенең иң тирән бер җирендә киләчәккә өмет очкыннарын уятты. Өмет сүнеп бетмәгән булган икән әле. Әнә ул чак кына һава керү белән кабынып, ялкынланып дөрләр чиккә җитеп тулышты. Моннан соң малайлар, аларның тамыры турында кайгыртыр кеше бар! Әлбәттә, Мәдинә аннан тартына, бала чакта әти дип кочагына сыенмагач, хәзер килеп якыная, кочаклый алмаячактыр инде. Шулай булса да әйбәт. Бәрәңге җирен дә сөрдерде әтисе. Җимерелгән коймаларны да рәтләде. Мичнең торбасы ауган иде, аны яңадан турайтып куйды. Ә теге ике малай, без инде зурлар дип тормыйлар, берсе алдында булса, икенчесе — җилкәсендә. Әтиләре алар нәрсә эшләсә дә түзә, ичмасам, туктагыз инде дип тә әйтми.

Кич йокларга яткач, Мәдинәнең башына төрле уйлар килә: ни өчен әнисе карап торышка сөйкемле, хәтта усал да түгел кеше белән бәхетле була алмаган? Әнисе исән булса, Мәдинә, әлбәттә, тартынмый сорар иде, юк шул һәм булмаячак та.

Ә этисе уфтана. Беркөнне Мәдинә аның әнисенең көлмәгэн тотып елап торган чагын күрде. Хәтта ул шуны аңлады: этисе әнисе тере чакта кигән генә түгел, тоткан нәрсәләрне дә изгеләштерә. Беркөн өй җыештырганда сәке астыннан иске бер пумала тапты Мәдинә. Шуны чүплеккә чыгарып ташларга салып куйган җиреннән этисе кире өйгә алып керде:

— Менә моны, — дигән була, — ташлама әле, Мәдинә.

— Нишләтәсең аны, ашалып, катып беткән.

— Торсын әле, — этисе шуны мич башына алып куйды, — әниең Гөлбану бер Май бәйрәменә шуның белән өй акшарлаган иде. Бавыннан таныдым... Пумаласы таралып китте, — ул көлемсерәде. — Мин әйтәм, кая, Гөлбану, үзем рәтләп бирим. Тимерчыбык белән чорнап бирдем шуннан...

Мондый чакта Мәдинәгә үтә нык кыен. Үзәкләре өзелә. Ә кайчак этисенә «Җитәр, җитәр саташырга! Кайтмый бит инде ул, кайтмый!» дип кычкырасы килә.

Әйе, кайтмаячак әнисе. Ул уй белән Мәдинә инде килеште. Ә яшәргә кирәк. Ходай кушып, этисенә сыерны кире юллап бирешсәләр, ичмасам, менә бу ике малай сөт-катыкка туярлар иде. Ул чагында этисе дә, бәлки, түшәгендә азрак аунар иде.

— Ахирәт!

Утка карап уйланып утырган Мәдинә кинәт артына әйләнде: Галимә икән. Авызы колагына җиткән.

— Шултикле тының беткәнче йөгергәнсең... Аю кудымы әллә?

— Ахирәт, районнан кеше килгән. Габделәхәт диме шунда. Шул бүген клубка яшьләрне җыя. Һөнәре бар кешене укырга алып китә, ди.

— Шуннан?

— Шуннан ни... Мин ишетү белән сиңа йөгердем!

— Миңа... нәрсәгә?!

— Ничек «нәрсәгә»? Җырларга.

— Миңа калган...

— Абау, абау! — Галимәнең аптыраудан күз каралары маңгаена кереп югала язды. — Син дә шулай дигәч! Әтием әйтә: уку әләксә Мәдинәгә, чын әртис булачак, ди!

— Әртис... — Мәдинә тагын моңайды. — Бармакларым сызлаудан төнлә йоклый да алмыйм... Миңа таналар бирделәр, Галимә...

— Әртис булсаң, сыер да саумыйсың, тирес тә чистартмыйсың!

— Мин бит укымаган.

— Әйтәм бит: укырга апкитергә килгән. Талантлы яшьләр кирәк безгә, дип әйткәнен үзем ишеттем.

— Яшь кешеме? — Мәдинә үзе сорады да, үзе кызарды.

— Карт түгел инде. Әйбәт кенә сөйләшә. Культурный.

— Минем анда киеп барыр нәрсәм дә юк...

— Ә теге... әниеңнең, — Галимә алан-йолан каранды, — киемнәре кая?

— Сандыкта...

— Ач әле сандыгыңны!

— Әй, алар бит... әниемнең төсе. Әманәт.

— Булса! Син аларны сатарга алып бармыйсың ла!

— Әллә инде... Кит, Галимә, оялырмын йә...

— Әле кем сиңа өй сата! — Галимә сандыктан укалары ялтырап торган җиләнне, бизәкле итекләрне, тасмалы күлмәк, йөзек, беләзекләрне чыгара да башлады. — Их! Шушылар миндә булсачы! Юк, башта үзем киеп карыйм!..

Мәдинә ахирәтенең бер хәсрәтсез, шаян йөзенә аптырап та, көнләшеп тә карый. Аны да шулай хәсрәтләре азга гына, бик азга гына булса да калдырып торсачы... Әллә Галимә дөрес тә сөйли микән? Әллә Мәдинәгә бәхетен сынап карарга мы? Аһ, ичмасам, әтисе өйдә юк, ул нинди киңәш бирер иде икән?

* * *

Кызның җаны кырык, дип, күрәсең, юкка әйтмәгәннәр. Рауза да аякка басты. Әле дә улы, Хөсәене бар. Әнисен алып кайтып, өшкергән тоз, үлән эчереп, терелтеп, адәм итте. Төн чыкканчы янынннан китмәде. Нindидер бурлы турында сөйләнеп куйса да, атлары янына чыгып китмәде. Шунысына тагын аптырады Рауза: әнисе белән сөйләшкәндә русча сүз кыстырмады.

— Ну курыктым. Миңа бит әниең үлеп ята, дип килеп әйттеләр, — диде ул, әнисенең ак маңгаена сыланган кара бөдрә чәчләрен сыйпап, — борчылма инде кабат. Мин гел янында булырмын, яме?

Их, улы элек тә Рауза белән шулай сөйләшкән булса! Әллә ни булып куйды бит, җен алыштырган диярсең... Ә кайгырмый булмый Раузага. Тик бу юлы кемгә кайгырырга белми. Әгәр Сибгатен гади бер хатын тартып

алса, ул аптырамас иде, кемне каргарга, кемне сүгәргә белер иде. Ә монда бит хәл башкача: Сибгате аяз көнне яшен суккандай юк булды! Аллага рәнҗер иде, аңа сүз тидерергә ярамый, язмышына да зарлана алмый: нәрсә дисә дә, ул Раузага алма кебек ул бүләк иткән...

Ә йөрәк бит яна. Ялкыны бөтен тәненә тарала. Ай, кыен бит түзүләре. Әнә тагын яктыра. Нигә ата ул таң? Кем өчен чыга бу күзне чагылдырган кояш?! Көн яктылыклары куандырмас шул инде хәзер...

Рауза торды, салкын су белән юынып алды. Өйрәнелгән хәрәкәт белән самавырына су салды, сыерын савып, көтүгә куды. Хөсәенгә чәй эчергән арада, үзенә дә чәй ясады, тик тамагына аш үтмәде, хәтта чәйдән дә көл тәме килгән кебек...

Эш калдырып өйрәнмәгәч, аяклары үзеннән-үзе кәнсәләргә атлады. Бүген соңлабрак та китте микән, кояш күтәрелеп үк киткән. Ихсанбай да Сибгатнең ялгыз улы. Ирем кисәге — итем кисәге дигәндәй... Ирем. Ә булдымы соң Раузаның ире?

Кәнсәләр ишегеен ачуга, күзенә чынлап та сөмсере коелган Ихсанбай күренде. Йа Рабби! Аның бу тиклем усал чагын күргәне юк иде әле Раузаның. Кайгымы аны шундый кыяфәткә керткән, йә булмаса, кичтән чамаламый төшергәнме?

— Саумы әле, Ихсанбай улым?!

«Улым» сүзенең теленнән ничек ычкынуын үзе дә сизмәде Рауза.

— Мин сиңа нинди ул булыйм! — Ихсанбай утырган җиреннән сикереп торды, кулы өстәл өстендәге кара савытына ябышты. — Шушыны битеңә алып бәргәнче тай моннан, уйнашчы!

Рауза башта каушады, ләкин үзен тиз үк кулга алды, йөрәгеен өткән сүзләрне чәпәргә кеше табылудан тәненә хәтта рәхәт дерелдәү йөгерде. Кемнеңдер бүлмәгә керүе дә, аның нәрсәдер дип кемгәдер эндәшүе дә туктата алмады аны. Аякларын аерыбрак басып, ике кулы белән биеренә таянды Рауза:

— Кем дидең, Ихсанбай? Кабатла әле? Алай булып, мин нәрсә эшләгән? Гомерем буе ике ир күрдем, эчеп йөрмәдем, азмадым. Ул нишләп мин уйнашчы булыйм, ә?

Ихсанбай да чәчрәп чыгар чиккә җитеп бүртенде:

— Нәрсә, кеше ирен өйдән чыгармый яткыруың уйнашка кермиме?!

— Ул миндә ятса, настәяшнә ятты! Ул, мин яратыштык! Ә син, өер айгыры, ирләр юктан файдаланып, менмәгән хатын калдырмадың!

— Нәрсә сөйләгәнеңне белеп сөйлә!

— Ә мин белеп сөйлим һәм берәүдән дә курыкмыйм! Кеше эндәшмәгәч тә, Гөлбануның игезәкләре күктән төшкәннәр дип беләсеңме?! Син генә, эт, җиттең мескеннең башына...

— Дәлилең юк! Нахак!

— Ә-ә... сиңа дәлил дә кирәкмени? Кирәк булса, пажалыста: ике малайның ике миңе — дәү әтиләренеке! Тагын дәлил кирәкме?!

— Чык, югал күземнән!

— Гомер буе эшләгән кәнсәмнән болай гына чыгара алмассың — пыркарурга барам! Камалетдиновның үзенә керәм! — Рауза, кинәт борылган арада, Габделәхәт белән күзгә-күз очрашты. — А-а-ә, Габделәхәт энем, син икәнсең. Менә күрдеңме Тирәкледә салдаткалардан ничек издеват иткәннәрен! Сез тегендә кан койдыгыз, бу тылда көн-төн эчте, типтерде! Хәзер әнә типтергән хатыннарының кайсысын бүредән ашата, кайсысын эчереп юлдан яздыра!

— Нәрсә, синең белән дә типтердемме?

— У-уй, Алла сакласын! Ходай синең кебек эткә юлыктырмасын!

Рауза әйтеп бетермәгәннәрен урам буйлап кычкыра-кычкыра чыгып китте. Габделәхәт аның: «Барам пыркарурга! Жалу белән барам!» — дип кычкырганын гына аермачык ишетте.

Ихсанбай ярсуыннан калтыранса да, үзен кулга алырга тырышты. Ни дисәң дә, каршысында элекке дуңгыз караучы булса да, хәзер районда хөкүмәт әтәче булып эшләгән кеше басып тора бит. Җитмәсә, теге албасты әллә нәрсәләр кычкырып өлгерде, аның сүзләренә игътибар итте микән бу маңка малай, юкмы? Эченнән шулай уйласа да, тыштан тыныч күренергә тырышып, бөтенләй икенче төрле эндәште Ихсанбай:

— Кичә юньләп синең белән сөйләшеп тә булмады, әйдә, утыр, Габделәхәт энем.

Габделәхәт тә әлеге күргән-ишеткәненә вак-төяк дип карауны хуп күргән кешедәй кыланды:

— Әйе, әйе, кичә минем кайгы идеме? Авыр туфрагы җиңел булсын, дибез инде мондый чакта, ни хәл итәсең...

— Шу-ла-ай... Әти карт кинәт кенә китте дә барды, — шуннан Ихсанбай зәңгәр күзләрен кабат ишеккә төбәде, әйтерсең лә анда Рауза һаман кычкырынып басып тора, — әллә нәрсә дип шушы хатынга иялəште бит... Түзмәдем...

Габделәхәт портсигарын чыгарды:

— Көйрәтеп алмыйкмы?

— Була инде. — Ихсанбай әле Габделәхәтнең ни йомыш белән йөргүен белми. Мирхәйдәровларга туктаган шикелле. Мирхәйдәров моның башын да бутап өлгермәгән дисеңме? — Сине мәдәният тирәсендә эшли дип ишеткән идем...

— Әйе... Әле сиңа килүем дә шул: сәләтле кызлар, егетләр эзлибез. Үзебезнең кешеләрне укытып алырга кирәк.

Ихсанбай җанлана төште:

— Нәрсә теге... җырлаган, биегән кебекләрнеме?

— Әйе, әйе... Бик сәләтлеләре булса, әлбәттә...

— Табабыз, җыябыз. Колыпка килсеннәр, чакыртыйм, алайсаң!

* * *

Тирәкленең дә клубы, башка авылларныкы кебек үк, элеккеге мәчет. Бу мәчетнең манарасын төшергәннәрен Габделәхәт үз күзләре белән күрде. Малай гына булса да, хәтеренә уелып калган. Ул чакта йөзьяшәр мулласы да тере иде әле. Арканнарны мәчетнең манарасына бәйләп, ат белән сөйрәттереп төшереп маташкан ир-егет янына килеп:

— Юк белән булышасыз, оланнар, — диде ул. — Ходай йортларының кайда салынуы җир яратылганга тиклем үк билгеләп куелган. Мин күрә алмам, сез, мөгаен, күрерсез: үзегез булмаса, оланнарыгыз шуларны кире мәчеткә әйләндереп йөриячәк.

— Әй бабай, без нәрсә? Кушалар бит. Боерык югарыдан килә. Син инде безгә берүк бәддога укыма, — диде шунда берсе.

— Каргыш ике очлы, оланнар, — диде мулла, моңа карап, — бер очының ул кешегә барып җиту-җитмәве икеле, ә икенче очы мотлак бәндәнең үзендә кала.

Ихсанбайның «колып» дигәне менә шул мәчет инде. Борынгы осталар тарафыннан зур зәвык белән салынган бу нарат йорт тагын әллә ничә буынны алыштырыр әле.

Үзе тоташ нараттан салынуга карамастан, тыштан да нарат такталар белән тышланган. Тәрәзә капкачлары искитмәле сырлар белән сырланган, карап торсаң, моны эшләгән осталарның түземенә, маһирлыгына исең китә. Бу тиклем камиллеккә ирешү өчен халык бу ырмау сәнгате белән кайсы дәверләрдән алып шөгыльләнергә тиеш булды икән?

Габделәхәт бала чагыннан күреп гадәтләнгән бинаны өр-яңадан күз уңыннан кичереп тора бирде. Хәер, әнә Мирхәйдәров үзе дә килә. Чыдамаган тынгысыз җан.

— Һәй, энем, озаклабрак тордым, эш бетәме... Ишетмәдеңме әле? Мин аларны кайсысын судан, кайсысын фермадан сөйрәп дигәндәй алып килдем.

Алар кергәндә дүрт кыз, өч егет эскәмиядә утыралар, калганнары арттарак, мич буена тезелешкән. Күрәсең, каралырга килгәннәре шул җидәүдер.

Кызлар кыстаталар, чыгып җырларга уңайсызланалар. Габделәхәт аларга моның әле сайлап алу алдыннан карап чыгу гына икәнен, ә укырга алып китәр өчен сайларга ул музыка белгече белән тагын ике атнадан киләсен аңлатты. Шунда бер кыз:

— Без барыбер үтә алмабыз. Әнә Мәдинә генә җырласын, — диде.

— Кайсыгыз Мәдинә?

Борынгы башкорт кызлары киемендә килгән талчыбыктай нечкә, ләкин бик зифа буйлы кыз урыныннан торды.

— Гөлбану?! — Габделәхәтнең башына эссе ут капты, йөрәге өзелер чиккә җитеп җилкенеп тибә башлады.

— Мәдинә мин... Гөлбануның кызы...

Шушы минутта ук үзен кулга алырга тиеш Габделәхәт, югыйсә кыз каушаячак, смотр, шайтан белсен, нәрсәгә әвереләчәк!

— Нинди җыр сайладың, Мәдинә?

— «Бөйрәкәй»...

Шулчак курайчы аягүрә басты. Башта талгын гына курай моңы агылды, аңа әллә кырлардан, әллә төрле чәчкәләрдән, әллә язгы җилдән, әллә сагыштан, әллә шатлыктан яралган искитмәле тавыш кушылды.

Җыр тынды. Габделәхәтнең ничәмә еллар ятимлектән, сугышның кырыслыгыннан, бәхетнең тамчысын да татып карамаудан каткан күңеле гүя эреде, гүя аның күңеленнән килер шатлыкларны буып торган зур бер ташны алып ташладылар.

— Болай булгач, савымчысыз калдырдың безне, Габ-

деләхәт энем, — Мирхәйдәров Мәдинәгә якын ук килде, — җибәрмәсәм нишләрсең, кызыкай?

Мәдинә Мирхәйдәровның тавышында усаллык юклыкны шунда ук аңлады:

— Миңа дигәндә шул инде ул, абый. Мәктәптә укып булмады — сугыш чыкты. Инде сез...

— Шаяртам, шаяртып кына әйтәм. — Мирхәйдәров, күзенә тыгылган яшьне күрсәтмәскә теләп, башын читкә борды.

Габделәхәт тә тыя алмады яшьләрен, аптырагач, клубтан чыгып китте.

Шул китүдән ул байтак җир йөрде. Элек ятып су эчкән чишмәсе дә, малай чагында башларына үрмәләгән тирәкләре дә калмады. Дөньяның матурлыгына, аны тудырган әнисенә, буй җиткергән шушы җиргә рәхмәт.

Мәдинәнең җыры, башкаручысының сафлыгы, сылулыгы башына киткән Габделәхәткә хәзер гармун гына җитми. Җитмәячәк тә аңа гармун. Аның күңеле гармун телләренә басарга гомере буе зарыгып-тилмереп яшәячәк. Габделәхәт кинәт йокысыннан уянгандай, уң кулының бармакларына карады: бәлки, берәр төрле могҗиза белән алар кабат үскәндер? Юк шул, юк: анда бары ике бармак тырпаеп тора, алары да тупас...

— Эх!.. — Габделәхәтнең авызыннан бу иңрәү әллә чыкты, әллә чыкмады. Ни тиклем сусаган аның күңеле шул саф моңга, шул сагышлы, йөрәкнең үзеннән ургылган илаһи моңга. Син, син генә кирәк миңа, Мәдинә! Син генә мине йә күккә күтәрәсең, йә җиргә бәрәсең. Кабат бер дә тормаслык итеп бәрәсең.

Шәһәрбану апа, Гөлбану... Алар белән бергә үткәргән кичләр. Тәүге сөюгә генә хас ярсу белән Гөлбануга гашыйк булу... Һашимның шул бәхетле кичләрне тартып алуы... Юк, бу юлы юаш булмас Габделәхәт. Җирдән түгел, күктән, Ходайның үзеннән сорап алган тансык ярын ятларга калдырмас! Ярын... Тиң итәрме соң Мәдинә Габделәхәтне? Ә яшь аермасы... Зәгыйфьлек... Ә күңел, күңел бит әле дә унҗидедә генә кебек, ә бармаклары... Төшләрендә ул нинди генә көйләр уйнамый да нинди генә көйләр чыгармый. Әйе, әйе... Көйләр чыгара ул! Нигә ул әле үзе дә укырга уйламый? Шуларны ул нотага салса, көй чыгарса, ә Мәдинә башкарса...

Баштанаяк хыялга чумган Габделәхәт басу юлыннан авылга ашыкты, авылга килеп кергәч тә туп-туры Мәдинәләргә атлады...

* * *

Гөлбану киемендә килеп кергән Мәдинәне күргәч, Ихсанбай башта акылдан язып барамдыр, ахры, дип уйлады. Күзен бер ачты, бер йомды. Маңгаеннан салкын тир бәреп чыкты, аяк буыннары хәлсезләнеп, әкрен генә утыргычка чүгәләде. «Ул! — Ихсанбай аңа күтәрелеп карады: — Ул түгел!» — Гөлбануның күзләре Ихсанбайныкы кебек үк күгелҗем-зәңгәр иде. Аларда әрем төсе, әрем йомшаклыгы бар иде. Моның күзләре чем-каралар. Карашы да Гөлбанунықы кебек назлы түгел, сынап карыйлар аның күзләре, каты карыйлар. Ә башка җире, буй-сыны, төс-фигыле нәкъ Гөлбану. Шушыңа тиклем ул Мәдинәне кара яулыгын кашына кадәр төшереп бәйләп, сырмасын билбау белән кысып буып, аягына чабата кигән килеш кенә күрә иде. Ә бу — хур кызы. Хәтта җилдә ярылган, каны саркыбрак торган иреннәре дә үтә дә матур, үтә дә нык үзенә тарта. Елмайганда чокырланган алсу бите, нечкә генә озынчарак ияге, чем-кара сөрмәле күзләре, шул бераз кыярак*, ләкин түп-түгәрәк күзләре өстенә дугаланып сызылып киткән кашлары, ияк очындагы кара миңе — бөтенесе, бөтенесе дә Гөлбануны хәтерләтә. Биле нечкә генә үзенең, җилкәсе тар, җилән кигән күкрәге кабарып-күпереп тора. Шушындый тал чыбыгыдай кызда мондый калку түшләр каян килгәндер ул? Ихсанбайның авызындагы төкереге кипте хәтта. Менә кайда йөргән ул бәхет! Янында гына булган, күршедә генә яшәгән. Мондый хур кызын кочаклап йоклаган бер төнең бер гомергә торырлыктыр ул. Ә аның елан кебек елкылдап биленнән түбән төшкән толымнары... Гөлбануның да чәчләре шушылай иде, үзләре чем-каралар, үзләре кояшта кызгылт ялкын төсенә кереп яналар иде...

Мәдинәнең җырын яхшылап тыңлый да алмады Ихсанбай. Һава җитмәгәндәй булгач, күлмәк изүен ычкындырды, тирләгән учы белән чәчләрен сыпыргалады. Әнә Мәдинәнең ярылып кипкән ирене җырлаганда тартышты, аннан энә күзедәй генә кан саркып чыкты. Юк, җырлаганда ярылмады ул, гүя аны Ихсанбай үбеп канатты. Башкача түзәр әмәле калмады Ихсанбайның: Гөлбануның тәмен татып караганнан бирле ул җаныңтәнең белән тартылган хатынның чын тәмен белә! Белгән өчен дә Мәдинәгә карап утыра алмый ул: әллә кайчан

---

* Кыярак — болан күзле.

сүнгән, әллә кая яшеренгән нәфесен уятты бүген Мәдинә. Теге чак Гөлбану мәсьәләсендә курыкты. Тормышның күзенә туп-туры караудан шүрләде. Ә хәзер — юк. Хәзер, Мәдинәгә карап, үз югалтуының, ул хатасының хакын яхшы аңлады Ихсанбай.

* * *

Мәдинә, өенә кайткач, байтак вакыт өстен салмыйча, сәкедә миңгерәгән сыман утырды. Әллә нинди көн булды бу. Әллә ничек кыюлыгы җитеп, менә бу киемнәрне киде, әллә каян йөрәге җитеп, клубка барды, районнан килгән абый алдында җөрьәт итеп, авыз күтәреп җырлап җибәрде. Аптырамаслык та түгел шул. Җитмәсә, шул кеше Мәдинәнең күзләренә шундый итеп карады. Әле аңа беркемнең дә шул рәвешле караганы юк иде. Ә нигә ул Мәдинәгә кинәт «Гөлбану!» дип эндәште икән? Димәк, ул агай Мәдинәнең әнисен белгән булып чыга. Исләрең дә китәр! Әгәр дә Мәдинәнең җыры ошап, укырга алып китеп барсалар... Уй! Була торган хәлмени? Җитмәсә, игезәкләр... Абау, алар күренмиләр ич... Әллә нишләп соңгы вакытта еракка китеп уйнарга гадәтләнделәр.

Мәдинә, киемнәрен җәһәт-җәһәт чишеп, кире сандыкка тутыра башлады. Өстенә шулай да элеккеге сәләмәләрен киясе килмәде, әтисе алып кайткан батисттан күршесе тегеп биргән күлмәген киде, аягына яңа каталарын эләктерде. Аңа теге клубта күргән агай тагын очрар, тагын йә Гөлбану, йә Мәдинә дип сүз кушар сыман...

Сигезенче бүлек

Күкбүре көчекләре белән мәш килеп абзар артында ята. Төнлә сөйрәп китергән үләксәне алар кинәнеп ашый. Бөтенесе дә беришләр. Кешеләр аларны шултиклем әнисенә охшаталар. Ә Күкбүре белә: алар үзләренең урмандагы әтиләренә күбрәк тартканнар. Менә бу баш очындагы күкнең үзе кебек аларның әтисе. Күзләре дә шулай. Күкбүре хәзер ни өчен авыл этләрен өнәмәгәнен, ни өчен гел үле көчекләр табуын төшенде. Быел гына төшенде. Күңеле үртәлеп, әрнеп, сызлану катыш рәнҗешкә чыдый алмыйча, абзар башында утырган килеш улап җибәрде ул бер төнне. Аның улавына авыл этләре кушылмады,

киресенчә, тынып, шым калдылар. Ә урман ягыннан аны тиз ишеттеләр һәм шундый ук улау белән җавап кайтардылар. Белә хәзер Күкбүре: тансыктырып тапкан көчекләре үсә төшкәч, ул әнә шул урманга ияртеп китәчәк аларны. Урмандагы әтиләре болар янына инде әллә ничә тапкыр килеп китте. Чакыра ул Күкбүрене. Ә теге чак, Күкбүренең улавын ишетеп, көтүләре белән абзар башына тулгач, шатлыктан күзләре атылып чыга язды аның. Берничә төн рәттән Күкбүре булачак балаларының әтиләре белән туй ясады. Туй, әлбәттә, абзар башына гына сыймады, ул башта бәрәңге бакчасына, аннан урманның үзенә күчте. Узаманның Күкбүрене кайтарасы килмәде, әмма Күкбүре көчекләрен урманда табудан курыкты...

Инде хәзер китәр. Каны яңа яшәү комарын, тансык, көчле узаманның сәм-дәртенең үзенә агылуын көтә. Авыл этләренең әрсезлеген, котыруын күреп, күпме гомере заяга үткән... Нигә шуларның муеннарын чәйнәп кенә ташламады икән?! Их, әгәр дә аны кайчандыр, кемдер әнисенең җылы куеныннан аерып, башын томалап, каядыр алып китмәгән булса! Алып китүләре җитмәгән, чылбырга бәйләделәр, тыңларга, боерыкларын үтәргә өйрәттеләр.

Күкбүре, су ягында шыпырт кына сөйләшкән тавышлар ишетеп, колакларын шомрайтты. «Тегеләр! — дигән уй йөгерде аның башыннан. — Гел шул җиргә киләләр!» Элек ярыктан гына аның көчекләренә сокланып карап торалар иде. Хуҗа, бер тактаны каерып алып, юл ясагач, башларын да тыга башладылар. Күкбүре сизә: болар аның балаларына көннән-көн ныграк кызыга. Әгәр яннарында әниләре ятмаса, көчекләрне күптән берәмләп ташып бетерерләр иде. «Ягез, йә, килеп карагыз!» — Күкбүре юри, башын алгы тәпиләренә салып, йоклаганга салышты. Малайлар, шуны гына көткәндәй, теге ярыктан кысыла-кысыла керделәр һәм, әзрәк тирә-якларына карангалап торгач, «Маһ-маһ!» дип әкрен генә пышылдап, көчекләргә якыная башладылар. Күкбүренең мондый әрсезлеккә ачуы чыкты, шулай да, түземлеген җыеп, нәрсә булырын көтәргә булды: бу адәм маймычлары аның өчен үтә дә вак мәшәкать бит. Аларның зурысыннан гына курка Күкбүре: мәсәлән, Ихсанбайдан. Бу икәүнең Ихсанбай белән бер оядан икәнен дә яхшы төшенә ул, тик Хуҗаның шушыларны нигә үзе белән ияртеп алып йөрмәвенә аптырый.

Малайларның берсе аксыл нечкә генә бармаклары белән Күкбүренең бер көчеген тотып алды, теге бахыр, эче бүселә язганчы туенган сабые, аның кысып тотуыннан хәтта ыңгырашып куйды. Икенчесе дә үрелде көчегенә. О! Ул болай да ябык. Төпчек. Берәр җирен имгәтсә, у ләгънәт! Күкбүре бер сикерүдә малайның муенын бугазлады, тагын бер ташланып, икенчесен дә тешләде. Малайлар, кычкырырга түгел, ыһ итәргә дә өлгерми, яшел үләнгә сузылып яттылар. Көчекләр, чыелдашып, кире ояларына йөгерде. Күкбүре оясы тирәли арлы-бирле йөрештерде дә кире кереп ятты.

* * *

— Ихсанбай абый, безнең малайларны күрмәдеңме? — Абзар артыннан кайтып килгән Ихсанбайны Мәдинәнең кинәт очравы каушата төште.

— Юк... Мин ни, бая киткәннән яңа кайтып киләм...

— Кешеләр шушы якка киткәннәрен күргән.

— Әллә тагын... саз эчендә йөрмәсәләр. — Ихсанбай тирә-ягын караштырган арада, Мәдинә йөгереп китеп тә барды. Ихсанбайның йөрәге тагын да ашкынып тибә башлады: нәрсәдер сизенә бит күңеле. Малайлар бик күптән инде Күкбүренең көчекләренә күз сала. Ихсанбай да моны әллә кайчаннан сизеп йөри. Шуңа да ул теге тактаны алып ташлады. Бала бит алар, ымсынмый булмаслар. Ә Күкбүре, көчекләренә якын бара башласаң, нәкъ аждаһа. Әгәр дә инде хәл-вакыйгалар Ихсанбай уйлаганча шома барып чыкса... Югыйсә бит каныгалар. Әнә бит Рауза нәрсә дип чыгып китте. Җитмәсә, Габделәхәт алдында! Әтисе үлеп, аны олы мәшәкатьтән коткарган иде, болары да шулай тавыш-тынсыз гына китеп барсалар... Ә бит Ихсанбай үз гөнаһының тере шаһитлары белән гомере буе күрше булып яши алмаячак. Һашим әнә ничек итеп теш кайрый. Мирхәйдәровы? Аларга Раузасы килеп кушылды. Ничек кенә булмасын, Ихсанбай муенындагы элмәк көннән-көн кысыла. Әгәр дә ул кылганнарның барысы да өскә чыкса, Мәдинәне, үзенең колагын мәңге күрә алмаган кебек, беркайчан да күрә алмаячак.

Ихсанбай, келәгә эленгән арткы капканы тавышсыз гына ачып, бакча эченә үтте. Күкбүре оясыннан башын чыгарган да тәпиләренә салган. Хуҗасын күрүгә, ул башын күтәрде, ләкин урыныннан кузгалмады. Озын үлән арасыннан күренеп яткан, балчыкка буялып беткән

аякларны күреп, Ихсанбай баскан җирендә катып калды: бер-берсеннән ерак түгел йөзтүбән яткан ике бала Җантимер белән Биктимер иде...

«Нишләргә?!» — Башыннан яшен тизлегендә үткән уйдан Ихсанбайның тезләрс калтырады, тамагы кипте: «Нишләргә?!» Миеннән тагын бер дулкын уй йөгерде: «Юк-юк! Монда аның гаебе юк... Әлбәттә, Ихсанбай аларның тууын да, яшәүләрен дә теләмәдс, ләкин... Ул сәбәпче түгел боларның үлемендә! Түгел!!!»

Башына ут капкан Ихсанбай бәрәңге сабаклары аша лапас астына йөгерде, күзе абзар почмагында торган көрәккә төште, шуны тиз генә эләктереп, кире теге урынга килде. Кая, кая яшерергә?! Әгәр боларга әҗәлнең Ихсанбайның кәнтәеннән килгәнен белсәләр... Болай да сүз күбәйде...

Болай да аның өстендә болытлар кабара... Чокыр казыса эзләрләр, белерләр. Ә менә... Ихсанбай әле чәчкә атарга өлгермәгән, ике-өч яфракта утырган кыяр түтәленә карады. Тиресе калын, чокыры да ярыйсы тирән. Казып мәшәкатьләнү дә кирәкми. Иң мөһиме, кыяр үсеп утыра.

Ихсанбай тиз-тиз генә яшелчә түтәленең астын казый башлады. Әлегә монда беркем дә килмәс, ә соңыннан... Аннан соң әллә кайчаннан кыяр үсеп утырган түтәлне шик астына кую кемнең башына килсен?!

Капчыкка салынган ике бала мәетен чокырга өстерәгәндә йөгенең җиңеллегенә аптырады Ихсанбай: малайлар үзләре шултиклем ябыкмы, әллә үз йөгең авыр булмый дигәннәре шулмы?..

* * *

Габделәхәт Мәдинәнең капкасына үрелгәч, куркып, каушап калды: менә шулай, көпә-көндез кыз кешенең өенә килү килешерме? Алай дисәң, Габделәхәт Тирәклегә мөһим эш белән килгән: милли сәнгатьнең киләчәге өчен кадрлар эзли, сәләтле яшьләрне күреп сөйләшергә килгәнен бөтен авыл белә. Клубта җайлап сөйләшә алмады, килгәч-килгәч, ул бит Мәдинә белән яхшылап сөйләшеп, көнкүреше белән дә яхшылап танышып китәргә тиеш.

— Саумысыз...

Сәкедә нидер эшләп утырган кыз аптырап, каушап калды, йөзенә бәреп чыккан кызыллыкны хәтта каракучкыл йөзе дә яшерә алмады.

— Саубыз әле, Габделәхәт абый, үтегез.

— Килгәч, үтми ярамастыр, ни... сеңелкәш... Мәдинә... Шәһәрбану апайның өе, димәк, шушы инде?

— Шушы... сез, абый, минем әниемне дә белә идегезмени?

«Тавышына тиклем Гөлбанунықы!» — Хатирәләре яңарудан күңеле тулган Габделәхәт стенадагы фотодан күзен алмый гына җавап бирде:

— Белә идем, утарда бергә эшләдек. Оләсәең дә, әниең дә, — ул көлемсерәде, — янә Шаңгәрәй...

«Шаңгәрәй» дигәнне ишеткәч, Мәдинә елмайды.

— Шаңгәрәй абый, ни, ул әле һаман әниемне, ни, яратам дип сөйләп тик йөри ул...

— Шаңгәрәй дөресен сөйли, Мәдинә. Әниеңне без... бөтенебез дә яраттык. — Шуннан Габделәхәт кинәт Мәдинәгә борылды: — Яраттык, ләкин саклый алмадык! — Шушы минутта каршысында торган Мәдинә Габделәхәткә үтә дә кадерле, үтә дә якын тоелды, менә бит ул — гомере буе эзләгән бәхете, җан чишмәсе... Ул янында гына! Төшләренә кереп кенә дә үзеннән башканы сөйдерә дә, якын китерергә дә ирек бирмәде бит ул! Гөлбануга шултиклем дә охшар икәнсең! Килеп җиткәч, инде тапкач, үзенеке итмәсенме? Сусаган иреннәре суга ябырылмасынмы? Алҗытыр чиккә җитеп талчыккан хисләренә баш була алмыйча, Габделәхәт кинәт кызны ике куллап тартып алды да күкрәгенә кысты, күзләреннән алмаш-тилмәш үбеп, янып барган иреннәрен Мәдинәнең көйдергеч иреннәренә терәде. Кызның үзеннән тартынганын, тартылганын аңлап, Габделәхәт аны кире ике куллап, иплән кенә артка этәрде. — Гафу ит! Бер сөйләрмен, аңлатырмын! Мәдинә... Сиңа укырга кирәк! Синең тавышың... Халыкка хезмәт итәргә тиеш! Ә мин... җыр язармын... Синең хакта... әниең... үзем, җир... яшәү... тормыш, мәхәббәт хакында! Көт мине... Зинһар, көт! Атнадан да калмый килермен. Ә хәзер... хуш!

* * *

Биктимер белән Җантимер югалган дигән сүз Тирәкледә икенче көнне бөтен авылга таралды. Беренче көнне кичкә таба Мәдинә үзе генә эзләде. Су буйларын карап чыкты башта, якындагы куаклыкка кереп кычкырып чакырды — һичберәү тавыш бирмәде. Төнгә каршы,

хәлсезләнеп, йончып беткән Мәдинә, ут алып та тормый, сәкесенә ауды.

Фәүзиянең алачыгында бу көнне, киресенчә, ут сүнмәде, аның кара төннең үзе кебек чем-кара күзләре күптән инде бер ноктага төбәлгән дә каткан. Төрлечә кичерә адәм кайгыны, акылдан да төрлечә яза.

Шул ике сабый өшемәсен, ачтан үлмәсен дип, Фәүзия аз тырышмады. Шулар аркасында килене аны һәрчак боздай салкын карашы белән коендырды, Ихсанбаена да дошмандай күренде, ә инде үзенең изгелеген ачыктан-ачык күрсәтә алмый, киресенчә, күрсәткән ярдәмнәренең эзен яшерергә тырышкач, Мәдинә дә, малайлар да аңа сәерсенеп, ятсынып караудан узмады. Ихсанбаеның шул игезәкләрне ни өчен җене сөймәгәнен дә аңламады ул. Күңелендә төрле шикләр туып куйды куюын, тик Фәүзия ул уйларны башына кертүдән курыкты. Әгәр алар табылмаса, Мәдинә бахыр ничекләр итәр дә, Һашим мескен ничек күтәрер бу кайгыны? Әйе, әйе, Һашим. Фәүзия шул Һашимның фронттан икенче кешегә әйләнеп кайтуына исе китә. Ул кайтканнан соң, малайлар буйга җитеп, үсеп киттеләр; Мәдинәнең дә йөзеннән ятимлек чырае китте. Ә инде кызның клубта җырлап, районнан килгән түрәне елатканын ишеткәч, Фәүзиянең түбәсе күккә тиде: үз каны! Фәүзия-Барсынбикә үзе дә бит җыеннарда кыз-кыркынның гына түгел, ил картларының да күзенә яшь чыгарып моңсулата иде. «Моңлы кеше бәхетсез була», — дип әйтә иде әнисе, бу юрау бары Мәдинәгә кагыла күрмәсен, аларның затына төшкән каргыш берүк Мәдинәне урап үтсен. Тапмасын аны, юлыннан язсын... Фәүзия-Барсынбикәнең өлешенә төшкән ләгънәтне дустына түгел, дошманына бирмәсен...

Ә тышта төн. Мәдинә тәрәзәсендә дә ут кабынмады. Әй бала... Әтисе кайтмаса, куркадыр да, энеләрен уйлап кайгырадыр да. Ичмасам, капка төбенә чыгып утырыйм. Кыз бала яшәгән шушы өйне таң атканчы яман күзләрдән, усал телләрдән саклап карап утырыйм...

* * *

Һашим, районда эшләре беткәч, Тирәкле ягына атмазар чыкканын көтеп тормады, төш узган булса да, җәяүләп юлга чыкты. Ашыгасы да бар: Мәдинәгә сөенечле хәбәрен тизрәк җиткерәсе килә. Әле дә ул Камалетдинов

белән булган әңгәмәсен кайта-кайта күңеленнән уткәрә, исенә төшергән саен, күңеленә рәхәт, җылы дулкын йөгерә.

— Көяләнмә, Һашим. Кәгазьләрең тулы тәртиптә, бернинди бурычың юк хөкүмәткә. Тартып алган сыерыңны өч еллык түле белән кайтарсыннар. Ә Ихсанбайга «дело» ачылган...

Һашимга сыерның өчесе түгел, берсе дә җиткән. Башыннан ашкан! Малайларның тамагы сөт-катыкка туенса, тагын нәрсә кирәк? Әлбәттә, бирсәләр, Һашим аның икесен алыр. Берсен сатып, Мәдинәнең, малайларының өс-башын юнәтер. Аннан соң үзенең өен сипләтеп, шунда күченерләр. Гомере буе нәрсә дип Ихсанбайга күрше яшәсен ул? «Дело» ачылган, ди дә ул Камалетдинов, еланның бит агуы барыбер үлми...

Камалетдинов янә Ихсанбай урынына кеше кирәк, урысча да яхшы беләсең, әйдә, сине куйыйк, ди бит әле. Хәер, кеше эшләмәгән эш түгел. Эш башында тормышның әчесен-төчесен татыган кеше утырса яхшы инде.

* * *

Габделәхәт Һашим алдында үзенең, малайлар шикелле, Һашимны очратуына, уратып булса да, Мәдинәгә булган мөнәсәбәтен җиткерә алуына шатланды. Сүз ничектер үзеннән-үзе килеп чыкты.

— Укырга китүенә мин каршы түгел дә, — диде Һашим, — тик кыз бала бит: куркыта.

— Ни бит, Һашим абый, мин үзем дә укырга уйлыйм... Ну менә бергәләп укысак димәкче идем...

— Яшьләрне белмәссең... Әле кайчан гына, Тирәкледә кемдә туктарга белмим, ди идең...

Габделәхәт Һашим алдында үзенең малайлар шикелле кызарып басып торганын төшенә, ләкин ни хәл итсен?

— Һашим абый, — Габделәхәт үз тавышын үзе танымады, — Мәдинәне бәхетле итәр өчен мин барысын да эшләргә әзер.

Җылы хушлашты Һашим Габделәхәт белән. Әлбәттә, Габделәхәт Мәдинәдән өлкәнрәк иде. Бер уйласаң, шулай булуы да яхшы: хатынның кадерен дә бит ирләр өлкәнәя төшкәч кенә белә. Гөлбануның кадерен белмәве дә, бәлки, Һашимның яшьлегеннән килгәндер? Аннан тыш Ихсанбай арага керде. Һашим Гөлбануның Ихсан-

байны якын күрүен кичерә алмады. Әле менә Гөлбану да юк, ул барыбер хатынын шул ук Ихсанбайдан көнләшә. Гөлбануның хәтта рухын көнләшә ул башкалардан.

* * *

Әюп Камалетдиновны Габделәхәт Тирәкледән алып кайткан хәбәр сөендермәде: карт үлгән. Әлбәттә, аның карчыгы исән, аны чакыртырга, сорау алырга мөмкин. Әмма ләкин хатыннар белән көрәшеп гадәтләнмәгән Әюп. Аннан соң хатын кешенең иренең кемнәр белән бәйле булганын әйтә алуы да икеле.

Камалетдинов бу вакытта үзе дә тик ятмады: республика архивыннан Моратов Сибгат Ярлыкап улы һәм Моратова Фәүзия Тайсын кызының бөтенләй гражданлык актына теркәлмәвен исбатлаган кәгазь алды. Димәк, бу исем-ат астында йөргән кешеләрнең бүтән фамилиясе бар? Утызынчы елларда сөргенгә җибәрелгән кулак гаиләләренең тулы исемлеген тикшерү һәм аларның хәзерге яшәү урынын ачыклау үтә дә озакка сузылган, мәшәкатьле эш... Аннан соң... таныды бит Әюп ул кешене, Сибгат исеме астында яшәгән тимерчене. Бәхете — үлеп котылды. Ихсанбайга да документлар әзер: сугыштан ул туберкулёз чире белән калган итеп теркәлгән, хәзерге көндә аның чирле булмавын раслау кыен түгел. Аннан соң сугыш вакытындагы кылган этлекләре теркәлгән шикаятьләре ята аның өстәлендә. Шикаятьләрнең берсе Рауза исемле хатын тарафыннан язылган. Ул хатын Һашимның хатыны үлү вакыйгасын да, игезәк малайларның дөньяга килү тарихын да Ихсанбайга бәйләгән. Хөкем алдына басу өчен моннан тыш Ихсанбайның үзенең кылганнары да башыннан ашкан...

* * *

Башын учлары белән кысып тоткан Ихсанбай һаман кәнсәләреннән чыга алмый. Алдында райком бюросына чакырып язылган кәгазь. Бетте, барысы да өзелде. Әле кайчан гына бөтен «козырной»лар аның кулында кебек иде — бүген килеп учы тулы «шестёрка». Кая ялгышты ул? Кем бутады, кем ялгыштырды аны? Заманында дәрте ташып торган үткер күзле, ачык зиһенле егет түгел идеме

ул? Ни өчен, ни өчен?.. Сораулар күп, җавап юк. Ни өчен ул бала чагыннан үз иткән, егет булып җиткәч, үлеп гашыйк булган кызына өйләнмәде? Әнисе, әйе, теше-тырнагы белән бу никахка каршы торды. Ә ни өчен Ихсанбай көрәшмәде? Көрәшмәде, чөнки ул үз-үзен аңлаганнан бирле ике тормыш белән яшәде. Берсе аны алга әйдәде, икенчесе артка җибәрде. Һәрвакыт икеләнергә, посарга, качарга мәҗбүр итте... Мәхәббәте өчен көрәшү түгел, аны үзенең нәфрәтенә әйләндерде. Әйе, Гөлбану аңа бары тик нәфрәт белән карады. Бу нәфрәт Ихсанбайда дошманлашу, үчләшү теләген көчәйтте... Азактан инде... Азактан нәрсә: ялгышкан ике язмышның ачы җимешләре Ихсанбайның кыяр түтәле астында ята.

Кайчак Ихсанбайның шул мәетләрне чыгарып, бөтен дөньяга сөрән саласы, тамагы ярылганчы кычкырасы килә. Бигрәк тә әнисе күрсен иде: ул бит, ул бозды улының тормышын! Әйе, әйе, ул, әнисе... Ихсанбайның яшьтәшләре, туфандай кубып, ил сакларга китте. Ихсанбай кулына корал алмаслык егет идеме?! Юк, әнисе каршы төште. «Баламны сугыштан алып кала алмасаң, өемнең бусагасына басма, — диде ул иренә, — күземә кайтып күренмә!» Ихсанбай үзе дә үҗәтләнмәде, аска карап, иренен тешләде.

Хәзер инде Мәдинә... Күңеле төбендәге соңгы чаткыдан яралган бу сөю үтә кыйммәткә төшмәкче Ихсанбайга. Барысыннан язарга риза ул. Әйдә, партиядән дә чыгарсыннар, иленнән дә кусыннар, ләкин ул Мәдинәсез китмәячәк. Алтыны бар, атлары әзер — Мәдинәне генә күндерү кирәк. Кыз бала, әлбәттә, аның белән качарга үзе теләп риза булмас, Ихсанбай да ләкин бирешмәс: Һашим булып Һашим үз заманында Гөлбануны үзенеке итү чарасын тапты, Ихсанбай аннан киммени?! Ихсанбай шуннан соң лампаны өреп сүндерде. Кичтән иртә хәерлерәк. Башкасын ул иртәгә уйлар...

* * *

Зарифа үзен кая куярга белми бүлмә буйлап арлыбирле йөрде. Өенең урам ягына караган тәрәзәсен ачып, тыштагы тавышларга колак салды. Анда-монда эт өреп куйды, көтүдә әнисеннән адашып калган бәрән кычкыруын исәпкә алмаганда, авыл тып-тын. Ә көндез ул бөтенләй икенче иде. Гөлбануның игезәкләрен эзләргә

бөтен авыл белән чыктылар. Зарифа чыкмады. Суга барганда, бөтенесе дә гаҗәпләнеп аңа карады. Һәрберсенең карашында «абыеңның балалары югалган, син ничек түзеп өеңдә утырасың? дигән сорау ярылып ятканын күрде Зарифа. Кайсылары карап кына куймады, турыдан-туры сорау алу оештырды:

— Абау-у-у... Син өйдәмени?!

— Күреп торасың — өйдә, — дип җавап кайтарды андыйларга Зарифа һәм, алар оялмагач, үзе дә шул алымны сайлады, — ә нәрсә? Югалган һәрбер зинадан туган бала өчен мин чабарга тиешме?

— Ходайдан куркыр идең!

— Ходайдан курыккан өчен дә мин уйнаштан бала тапмыйм! — Зарифаның җавабы шул булды.

Әйе, ул хәзер шуны төшенде: кешенең үзеннән дә әрсезрәк, әчерәк телле булмасаң, хәзер өстеңә менәргә торалар. Ә Зарифага болай да җиңел түгел: Ишмөхәммәте сугыштан кайтмады. Сугыш бетеп барганда диярлек китеп, үләргә дә өлгерде микән? Ни бер хәбәр юк... Дөрес, ул өйдә чакта иренең китүен теләде Зарифа. Ихсанбай белән очрашуга комачаулый кебек күренде. Ишмөхәммәт китсә, Ихсанбайны бөтенләй үзенеке итәрмен дигән уй да булмады түгел. Хәтта Ихсанбай белән бергәләп Ишмөхәммәттән ничек тизрәк котылу юлын эзли торган иделәр. Һәм котылды: Ишмөхәммәт тә юк, Ихсанбай да онытканда бер, анысында да эчәргә генә кереп чыга. Ягарга утынсыз утырган чаклары күп хәзер Зарифаның: Шәңгәрәйнең каенлыктан ташыган утыны белән генә нишләп була? Хәсрәткә тару килешми Зарифага: сыр әсәре кунмаган йөзендә, күз төпләрендә җыерчыклар күрүдән сискәнде ул бүген. Һәрвакыт буялган кебек кызарып-тулышып торган иреннәре дә төссезләнгән... Болай булса, ул тиздән карчыкка әвереләчәк, ә шуннан аңа кем карасын? Ишмөхәммәт барында ул иртән торып учакка ут ягуның, көянтәләп суга баруның ни икәнен белмәде. Торуына өе җылынган, чәе кайнаган булыр иде, мунча керсә, өенә күтәреп алып кайтыр иде бахыр... Эх, терсәк якын да, тешләп булмый икән шул. Ишмөхәммәт китүен китсә, бергә тора башларбыз дигән вәгъдәсен тиз онытты Ихсанбай... Алай гына түгел, эчкән килеш ничәмә тапкыр сукты ул Зарифага. Әйе, эчә хәзер Зарифа. Ихсанбай өйрәтте эчәргә дә! Шуңа ярыйм дип, бергәләп эчте. Эчә торгач өйрәнде, даны чыкты...

Зарифа, черки тулудан куркып, тәрәзәне япса да, һава житмәгәндәй булгач, кире ачты, тагын төнге тынлыкка колак салды: күңелендә ярагаган шик тынгы бирми аңа — Ихсанбай берәрсенә иялəшмәгәнме икән? Әнә кәнсәләрендә дә ут юк, шушы вакыттан кайтып өендә ямь табып утыра торган кешемени ул? Зарифаны шушы көнгә төшергәннән соң, берәрсенә иялəшсә, гафу итә алмас Зарифа, булдыра алмас!

Калтыранып торган куллары белән Зарифа шырпы табып, җиделе лампаны кабызгач, мич башындагы мичкәдән бер җамаяк ачы бал алып эчкәч, кулының калтыравы басылды, үзенә ышаныч, дәрт өстәлде. Җиделе лампаны кулына тоткан килеш, стенадагы көзге алдына килеп басты. Көзгедән караган хатын Зарифа уйлаганнан күпкә кайтышрак булып чыкты: күз төпләрендә тирән чокырлар, кабаклары шешенгән, иреннәре дә күгәргән, тупасланган... Әйе-е, Зарифа, элекке сылулыгыңның әсәре дә калмаган шул синең... Шушылай күрсә, хәтта Ишмөхәммәт тә танымас иде. Ә бит ярата иде Ишмөхәммәт аны! «Бала чагыңнан, сиңа җизни булып барган көнемнән яраттым мин сине!» — дияр иде. Бала шикелле кулында тирбәтеп йоклатты, маңгаеннан сыйпап, үбеп уятты... Башта Зарифа аны яраткан кебек иде. Яратмаса, апасын, бертуган апасын үтерү хәленә барып житәр идеме?! Тәүбә, тәүбә... моны беркем белми, моны хәтта Ишмөхәммәт тә белми! Тик әнә котсыз кара карчык Фәүзия генә Зарифаны үтәдән-үтә күрә, әллә нәрсәләр сизенә кебек...

Юк! Шушы чаклы исеме чыкканнан соң, Зарифа Ихсанбайны беркемгә дә бирмәячәк! Кем белән каралган, шуның белән агарырга тиеш ул! Хәзер чыгар Зарифа... Шикләнгән хатыннарның һәрберсенең өен йөреп чыгар, ләкин Ихсанбаен табар. Кәнсәләреннән кайтмагач, кайдадыр күңел ача торгандыр, ниндидер тол хатынның күңелен күрәдер...

Зарифа өеннән инде чыктым дигәндә кире борылды, савыт-саба янында яткан икмәк пычагын алып җиң эченә тыкты: Зарифаның сутын суырып ташлар җимеш түгел икәнен күрсәтер ул!

Болдырга чыккач, тагын тын төнгә колак салды: бер тавыш юк. Ихсанбай, мөгаен, мунчасында йоклый торгандыр, иртә ята бит ул. Ишек ачылганны ишетеп, мөгрәп җибәргән сыеры гына сискәндерде аны — саварга оныткан икән бичараны. Ярый, анысы соңыннан...

Зарифа юлның үзләренә борыла торган җирендә туктап уйлана башлады: шушында көтәргәме, әллә... Юк, моннан үтмәс Ихсанбай. Соңлап кайткан чакларында, кеше күзенә чалынмас өчен, елга аша салынган асылмалы күпердән йөрүчән ул. Асылмалы күперне үткәч, өенә абзар артындагы капкасыннан барып керә.

Йөрәге ярсып типкән Зарифа пычагының сабын кысыбрак тотты: «Бүген йә беркайчан да!»

* * *

Һашим Мәдинәнең ут янган маңгаена салкын суга юешләп әледән-әле чүпрәк куя. Әгәр дә Мәдинә дә ташлап китсә, ул ничек яшәр бу дөньяда? Малайлар табылмады. Гөлбануның сөякләренә Һашим искәрмәстән барып юлыккандай, кемдер берәү шул гөнаһсыз сабыйларның да скелетына юлыгыр. Әгәр дә инде Мәдинә уйлаганча сазлыкка баткан булсалар, беркайчан беркем таба алмас сөякләрен дә. «Җир генә упты инде үзләрен, җир!» — дип елый Фәүзия карчык. «Җир уба торган булса, аның Ихсанбаен йотар иде ул. Бу сабыйларны нинди гөнаһлары өчен җир упсын?!» — Шулай уйлый Һашим.

Күршесе Фәүзиянең бу аралардагы кыланышы үтә дә сәер тоела Һашимга. Аларның Һашим сугыштан кайтканнан бирле күзгә-күз очрашканнары юк иде. Күзгә-күз алар чытырманлыкта очрашты. Монда аларның икесен дә бер хәсрәт китергәнен сүзсез аңладылар.

— Тәңребирде буйлап Олы тауга тиклем бардым, — диде Һашим, маңгай тирен сыпырып.

— Ул тиклем ерак китәргә бәләкәй бит әле алар. — Фәүзия, ботакка тотынып, каенга сөялде. — Абзар-кура артыннан ары китми торган иделәр.

— Аптыраганнан, — балаларның югалуын тагы кемнеңдер авыр кичерүеннән Һашимның күзләренә яшь бәреп чыкты. — Инде каян эзләргә, нәрсә эшләп карарга...

— Һашим...

Үзенә атап эндәшкән тавышка ул башын күтәрде һәм карчыкның кап-кара күзләрендә әйтелмәгән, ләкин үзенә төбәлгән сорауны укыды. Барысын да төшенде Һашим, тик ул сорауны бирергә карчыкның ни хакы бар? Бик тирәнгә киткән сорау бу. Әмма шунысы да мәгълүм: бу теге урам гайбәтчеләренең чираттагы гайбәт итеп чәйнәр кызыксынуы түгел. Каушабрак калды Һашим. Хәләл хатынының рухын Һашимны рәнҗетә торган кеше? Бән-

дәләрнең дөньялыктагы эшләре дә, яхшы исеме дә үзе үлгәннән соң да яклауга мохтаҗ икәнен төшенгән шул инде Һашим. Әмма... дөрес булмаган җавабы белән карчыкны да рәнҗетәсе килми.

— Фәүзия инәй, — диде ул, шуннан икесе арасындагы киеренке тынлыкны бозып, — Гөлбануга кагылышлы бөтен нәрсә изге миңа. Бу ике сабыйны мин аннан калган әманәт рәвешендә кабул кылдым. Шул.

— Син... изге кеше, Һашим, — карчык бите буйлап аккан яшьләрен әллә тоймый, әллә оныткан, — Мәдинә өчен инде күңелем тыныч, рәхмәт сиңа...

Шуннан алар тагын икесе ике якка китте. Төбетамыры белән ауган агач янында, муеныннан сазга баткан Мәдинәне Ихсанбай тартып чыгарып маташкан урында янә килеп очраштылар. Дөресрәге, карчык аваз салды:

— Һе-ей! Кем бар анда, килегез ярдәмгә!

Йөрәге күкрәк читлеген ярып чыгардай типкән Һашим килеп җиткәндә, карчык Мәдинәне ана каз шикелле саклап, Ихсанбай белән ярыйсы гына ярсып сөйләшә иде:

— Тимә! Беркайчан кагыласы булма! Алып кайтырга аның үз әтисе, яшәргә үз өе бар!

— Мин килеп җитмәсәм, батып үлә иде бит ул! Мин коткардым, мин җавап бирәм аның өчен!

Һашим аңлап алды: Ихсанбай кызны үзләренә алып кайтмакчы.

— Кит әле, Ихсанбай, яхшы чакта кит! Күрәсеңме, ул һаман аңына килмәгән!

Һашим килеп башын күтәрүгә, Мәдинә күзләрен ачты:

— Әти...

— Кызым! Син исән, син тере! Әтиеңне гомерлек кайгыларга сала язгансың бит, кызым...

— Малайлар... шушында... — Мәдинәнең күзләреннән яшь тәгәрәде, — шушында кебекләр.

Кызын күтәреп өенә юнәлгән Һашим артыннан Фәүзия белән Ихсанбай карап калды. Фәүзиянең шатлык яшьләрен күрде Һашим, ә Ихсанбай авызыннан ризыгы тартып алынган җенле бер җанварга охшаш иде.

Һашим үзенең салкын иреннәрен кызының янган маңгаена тидерде: кызы савыксын, кызы бәхетле булсын өчен ул үз җанын да уйлап та тормый бирер иде. Әйе, әйе, җаны хәзер шушы Мәдинәдә, ул яшәсә яшәячәк, ул яшәмәсә яшәмәячәк. Мәдинәсез аның үз-үзенә кирәге калмаячак.

* * *

Ихсанбай, урам чатында туктап, уйлануын дәвам итте. Тыкрыкка борылса, Зарифаның сагалап торуы бар — ничәмә тапкыр ул Ихсанбайны шунда көтеп торып өенә алып керде. Күрәсе килми аның Зарифаны. Бизде. Тегесе шуны аңламый, карышуын белә. Карышу гына түгел, ээәрлекләүгә күчте. Сабый булып сабый да, сөте булмаса, коры имчәкне суырмый. Бу бит шуны да аңламый. Күрде исә: «Китик моннан, качыйк!» — дип, теңкәне корыта. Үзенең дә, әтисенең дә өен, мал-туарын сатып китәргә риза. Ихсанбайның бөтен тупаслыкларына түзә. Бу хатыннарны аңламассың: үзе өчен үләргә әзер ирне сугышка җибәреп, үзен чүпкә дә санамаган берәү белән җәһәннәмгә олагырга риза.

Асылмалы күпергә җиткәч, Ихсанбай тәмәке кабызды, папиросын ашыгып-ашыгып, комсызланып суырды да күпергә басты. Уртасына җиткәч, алда бер карачкы шәйләде. Кем?..

— Ихсанбай!

— Зарифа?! Син... — Ихсанбай сорап та өлгермәде, ай яктысында пычакның йөзе ялтырап китте.

— Миңа булмасаң...

— Зарифа! — Ихсанбай артка тайпылган-янтайган уңайга Зарифаның тезенә тибеп өлгерде, тростан кулы ычкынып киткән хатын күз ачып йомганчы елгага очты.

— Кот-ка-ар! — Зарифаның тавышы бер-ике генә ишетелде дә тынды. Төнге елга элеккечә көнчыгышка, билгесез киңлеккә ничек аккан, шулай агуын белде.

Әле генә күз ачып йомган арада булган вакыйгадан коты алынган Ихсанбай, артына да әйләнеп карамастан, өенә ашыкты. Ничек тә Мәдинәне урларга, урларга да качарга! Ычкынырга. Тирәкледә аның инде бер көн яшәрлек тә әмәле калмады. Әлбәттә, Зарифаның юклыгын бер-ике көн берәү дә сизенмәс — эчкән хатынны кем эзләп йөрсен? Ә соңыннан... Ул турыда уйлап торуның ни хаҗәте — качарга дигәч качарга! Ихсанбайның кесәсендә ике кешегә паспорт та әзер: анда алар икесе дә завод эшчеләре. Иң кыены әнисеннән алтынын таптыру булачак. Әнисенең холкын яхшы белә Ихсанбай: үлсә үләр, сүзендә торыр.

Ихсанбай аягы астында яткан нәрсәгәдер сөрлегеп егылды: нәрсә дигәне әтәч үләксәсе икән. Теге күрше

этэчтэн таланып үлгэн үз этэче. Фу... Ихсанбай этэчне ботыннан алып читкэ атты. Ә күнеленең төбендә этэч үләксәсе үкенечкә охшаш тойгы уятты: бу кошның да бар иде бит шәп чаклары! Күршенең этәче түгел, эте керэ алмый койрыгын бот арасына кыстырып торыр иде.

Арт капкага якынлашканда, Ихсанбай янында гына ырылдау ишетте. Йөрәге эсселе-суыклы булып, тәне чемердәп китте:

— Күкбүре!

Юк, Күкбүре тавыш бирмәде: капка артыннан тагын да җитди искәртүгә охшаган ырылдау ишетелде. Шуннан соң ырылдаучы үзе дә күренде: караңгы булганга күзенә шулай күрендеме икән — бу бозау зурлыгындагы бүре иде. Аның артыннан Күкбүре үзе чыкты, аңа, чыелдап, көчекләре ияргән иде.

— Күкбүре... — Туктату өчен түгел, ярлыкау, яклау сорап пышылдады этенә Ихсанбай. Көчекләрен иярткэн бүреләр тар сукмак буйлап саз арасына кереп күздән югалса да, Ихсанбай урыныннан кузгала алмады — аяклары йөрмәс булды. «Бүреләр!» Шәһәрдәге Михаил кордашы биргән кәнтәйнең эт затыннан булуына шикләнгән чаклары булса да, бу кадәрен көтмәгән иде Ихсанбай. Күрәсең, урман кунагы үзенең токымы артыннан килгән, канмы, җанмы тартып китергән.

Кулының бармакларына тиклем җан тиргә баткан Ихсанбай, көчкә кузгалып, эчкә үтте. Эт оясы янына гына бәйләгән атларын күрмәгәч, йөрәге янә жу итеп китте: әллә бүреләр?! Ә, юк... юктыр. Булмастыр! Аптырауның һәм куркуның чигенә чыккан Ихсанбай әле һаман калтыраудан туктамаган бармаклары белән өй ишегенең тоткасына ябышты.

* * *

Йокысы кебек, төше дә кыска гына булды Фәүзия-Барсынбикәнең. Имештер, дала күз ачкысыз буранга чолганган. Шул җир белән күк арасын тоташтырып дулаган зилзиләдә ат көтүе чаба. Буранга чәчи-чәчи, бер-берсен таптый-таптый, каядыр еракка, билгесезлеккә атыла атлар. Фәүзия үзе дә җайдак, яхшы атка менгән, кулында камчы. Өерне өереп, кире җыймак, абзарга кертү аның уе, әмма булдыра алмый: меңәрләгән ат тоякларыннан чыккан тавыштан колагы тона, буран күзләренә, борын

тишекләренә өшәнгеч карын бәрә. Күп тә үтми, ул үзе дә, хәле бетеп, атыннан егылып төшә...

— Аһ! — Фәүзия күзләрен ачты. — Нинди рас төш булды. «Төшеңне кешегә сөйләмә, кеше сихерче кебек, гел яманга юрар», — ди торган иде оләсәсе. Фәүзия күргән төшләренең берсен дә кешегә сөйләмәде дә бит, әмма бөтенесе дә, сихерче юрагандай, дөрескә чыкты.

Әнә ишек шыгырдады. Күрәсең, Ихсанбай кайтты. Аекмы, исерекме инде? Бүген аның һичкайчан булмаганча аек булуын тели Фәүзия. Ул арада түр якның ишеге ачылды. Аек Ихсанбай, аек. Тик йөзе нигә шул-тиклем агарган? Атлары өчен генә түгелдер бит? Ләкин Ихсанбайның беренче соравы да ат турында булмады:

— Киленең кая?

— Әтисенең бертуган энесе... Ансар кайнагаң үлгән. Шунда китте.

— Атларны җигеп киттеме әллә?!

— Әлбәттә, җәяү чыгып китмәде, ир хатыны бит. — Әнисенең соңгы сүзләрендә әче киная ятканын тойды Ихсанбай, ләкин аның кайгысымы?

— Син нәрсә сөйләгәнеңне беләсеңме?

— Белмәскә... Үзебездә балыктай елкылдап торган атлар барында, килен, синеңчә, кемнән чыгып ат сорарга тиеш?

— Син! — Ихсанбайның тешләре шыгырдады. — Минем бөтен теләгемә, эшемә, хыялларыма каршы төштең! Мине бәхетсез ясадың! Инде килеп, соңгы... У-у-ух... буып кына үтерәм, билләһи!!!

— Ихсанбай... — Акылдан шашкан кеше кебек, үз башын үзе стенага бәргәләгән улына карап каушый төшсә дә, курыкканын белдермәде Фәүзия: андый хәлләрне күрмәгәнме ул? — Ихсанбай, — дип тыныч кына эндәште ул янә, — сине мин түгел, безнең өлешкә төшкән язмыш, шул язмыш аша килгән каргыш бәхетсез ясады, балам.

— Нинди язмыш? Нинди каргыш? Ул ниткән бетмәгән саташу?!

— Минем саташканым булмады, Ихсанбай.

— Син... Синме саташмадың?! Улыңны җан сөйгәненнән аерып, май сөртеп ташласаң, эт тә яламас Сәбиләгә өйләндергәндә дә үз акылыңда идеңме?!

— Үз акылымда идем.

— Соңрак, Гөлбануның авыры беленә башлагач, Сәбиләне аерам дигәндә каршы төшкәндә дә үз акылыңда идеңме?!

— Үз акылымда идем, Ихсанбай.

— Әле дә, Мәдинә белән качарга дип әзерләгән атларны чыгарып җибәргәндә дә үз акылыңда идеңме?!

— Үз акылымда... — Фәүзия-Барсынбикә, чак кына күтәрелеп, җайлап утырды. — Син Мәдинәгә беркайчан да... Ишетәсеңме? Беркайчан да!

— Бу юлы инде синнән сорамам! — Күзләре атылып чыгарга җитешкән Ихсанбай әнисенә якын ук килде. — Алтын кая?!

— Алтын?!

— Белмәмешкә салынма: барып чыкмас! Үземә тияр өлешне генә сорыйм. Бир и вәссәлам — мин юк булам!

— Мәдинәгә кагылмыйсың икән — әнә барыр юлың!

— Мәдинәсез мин китмим! Кирәк икән — һашимны, кирәк икән — кем юлыма аркылы төшә шуны, — ул муеның ышкыды, — ләкин морадыма җитәрмен!

— Ихсанбай, — хәле бетеп барган Фәүзия улының күзенә беренче тапкыр ялварып карады. — Улым... Ташла ул уеңны! Башыңнан чыгар, ул бит синең сеңлең! Туганың!

— Мәдинәнең яшь икәнен синнән башка да беләм! Акылдан язмаганмын.

— Аңламадың... Ул... Гөлбану белән син... бертуганнар! Игезәкләр сез!

Учлары белән башын кысып тынып калган әнисенә Ихсанбай шактый якын килде:

— Ух, елан... Юлыма аркылы төшәр өчен ниләр генә уйлап чыгармый, иблис!

Бугазына ябышкан куллар да, улының шашкан карашы да куркытмады Барсынбикәне:

— Бу чын! Гөлбану белән сиңа никахка керү ярамый иде!

— Әкиятеңне тыңларга вакытым юк: алтын кая, шуны әйт! Балаңның иминлеге хакына гомереңдә бер тапкыр бер адым эшли аласыңмы, юкмы?

— Синең бәхетең... иминлегең хакына мин бөтенесен дә эшләдем, Ихсанбай!

— Син?! Бөтенесен дә?! — Шашып, сәкегә ятып, тәгәрәп көлде Ихсанбай. — Күләгә син! Менә кем! Үзең дә яшәмәдең, мине дә яшәтмәдең!

— Уйлап сөйлә, Ихсанбай... Синең иминлегең хакына мин әтиеңнең гомерен кыйдым!

— Син?.. Әтине?! Син...

— Әйе, мин! — Сәкедән төшеп, чыгып китәргә җыенган

Фәүзияне улының күзләрендә ялтыраган сәер яктылык туктатты. — Мин! Мин! Илне интектерми, ыруны таркатмый тотып торган тарханнар токымы корымасын өчен, мин бөтенесен дә эшләдем! Бер нәрсәдә хаклы син: үзем күләгәдә, кара кисәүгә торып калдым! Сине сакладым... Тик бары үзеңне, тәнеңне, гәүдәңне саклаганмын. Мин синең рухыңны саклый алмадым! Хәзер үкенәм: нигә мин ил белән бергә күрер казалардан сине саклыдым икән?! Син бит саклаган саен котырдың, яклаган саен тилердең!..

— Сезнең качып-посып, икенче исем астында яшәвегезгә дә, үзегез яшәгән тормышны үзегез куралмаганга да мин гаепле ме?

— Акылыңа кил, Ихсанбай: илнең астын өскә китерер зилзиләне мин ясамадым!

— Ә хәзер минем үлемемне телисеңме? Хәлем кыл өстендә! Аңла!

— Мин сине тотмыйм!

— Алтынсыз һәм Мәдинәсез мин беркая да китмим!

— Мәдинәне мин сиңа... — ярсыган Фәүзия тыны буылып туктап калды.

— Алтынсыз да югалмам, — Ихсанбайның ирене бер якка чалшайды. — Ә Мәдинәне... туганым булмый чёрт булсын, Һашимга, язмышыма, сиңа үч итеп алып китәм! Бәлки, мин аны ташлап та, башын комырыкка тыгып та китәрмен, әмма аннан алда ул минеке булырга тиеш! Ә синең кебек аңгыра карчыкларга, — ул кесәсеннән наган чыгарды, — шушы да...

— Ихсанбай! — Фәүзия кинәт турайды, йөзенә чая җитдилек чыкты. — Мин бит әле синең әниең!

— Юк минем әнием! Юешләнгән судан курыкмый, — ул наганы белән күкрәгенә төртте. — Үз балаларымны үз бакчамның тутәленә тыккан кеше мин...

— Ихсанбай, акылыңа кил, балам?! Миңа үз гомерем күптән җәл түгел... Мәдинә, Мәдинәгә генә кагылма! Пычранмаган, гөнаһ кылмаган, ирекле бер кеше калсын безнең токымнан!

— Юк синең токымың! Юк синең улың! Ул булудан да, кол булудан да арыдым мин! Соңгы чарага мөрәҗәгать итәргә син мине үзең этәрдең... — Ихсанбай наганын чирттерергә өлгермәде, җиделе лампа белән дерелдәп кенә яктырган өйдә шартлау тавышы яңгырады. Кулыннан коралы төшеп киткән Ихсанбай, почмакта кап-кара күзләрен чекерәйтеп басып торган әнисенә таба бер адым ясады да гөрселдәп идәнгә ауды.

* * *

...Үлек кебек йоклаган халык төнне янгын булганын да сизмәде. Башка өйләрдән читтә, ялгыз-ярым утырганлыктан, Ихсанбайлар өендә чыккан янгын башка йортларга күчмәгән. Төне дә җилсез иде бит. Иртән көтү куарга торган хатыннар, бу урыс капкалы зур йорттан бер өем көл дә күмер калуын күреп, үз күзләренә үзләре ышанмады. Янган йорт янында Ихсанбай да, Фәүзия дә күренмәде, Сәбилә дә күзгә чалынмады. Тик бер сыер гына Фәүзиянең яратып, гел үзе сауган Бөйрәкәе генә, үкси-үкси бакырып, бөтен авыл өчен ят, тик үзенә генә якын булган кара күзле боек хатынны эзләде.

— Җилене сызлыйдыр, әллә савып җибәрәсеңме шуны? — дип эндәште Һашим кызына.

— Һәү, һәү... Кил, Бөйрәкәй, әйдә, мә!

Бөйрәкәй үзен әйдәгән Мәдинә артыннан күндәм генә иярде, күп тә үтми, чиләккә зың-зың, чыж-чыж килеп ак агынты агыла башлады. Шушыларга кушылып, Мәдинә күзеннән дә яшьләр ага чиләккә.

«Бөйрәкәйне сауган шул кызны уйлап, өзелә шул минем үзәккәй», — дип үкси бүген Мәдинәнең күңеле. Бөйрәкәйнең хуҗасын гомере буе уйлап, гомере буе сагыныр Мәдинә, тик моны беркем белмәс, беркем уйламас. Эченнән генә сызар ул, эченнән генә көяр. Шушы сагыш күңеленнән җырлар җырларына күчәр, тыңлаучыларның йөрәген сихерләп, мәхәббәтен яулар. Ә хәзергә бары ак моңнар, ак юллар сузыла — чиләккә җырлый-җырлый җылы сөт агыла...

1997

ИЛЕКӘЙ

Повесть



Бөек Ватан сугышы башланганның икенче көнендә үк үз теләге белән фронтка китеп, атлы Башкорт дивизиясе составында яу юллары үтеп, Берлинга җитеп, сугышны 1945 елның август ахырында Ерак Көнчыгышта тәмамлаган җырчы һәм чичән атам Хизбулла Гыйбадулла улы Мөхәммәтколовның; дәһшәтле елларның җанны куырырдай суык җилләренә бирешмичә, балаларын ачлыктан үтермичә, өстәвенә укучыларының язар каралары гына түгел, йөрәкләре туңардай салкыннарда якты көнгә өметләрен өздерми, мәктәптә эшне бер көнгә дә туктатмый, учактан утын өзми ирен фронттан көтеп алган нечкә хисле, киң күңелле әнием Әсма Рәхмәтулла кызы Баймурзина рухларына багышлыйм бу әсәремне. Яткан туфраклары мамыктай йомшак, гүрләре кояштай якты булсын. Амин.

«Нурулла!» Тавыш янә кабатланды. Өй эчендә таң алдыннан гына була торган тынлык.

Карт, сөякләрен юкка гына кузгатып, тәненең тынычлыгын югалтудан курыккандай, сарык йонынннан сырылган юрганын өскәрәк күтәрде, башын эчкәрәк чумдырды. Кем йөри диген әрле-бирле таң сызыла гына башлаган мәлдә? Бәндәнең йомышы төнгә-көнгә карамый да бит, төшәм дисә төшә дә куя. Мәгәр, төшкән мәлдә дә, ул йомыш аның онытгы силсәвит Гәрәйгә төшәр иде. Ә Нурулланың... теге, кем әйтмешли, буласы булган, буявы уңган. Аның башкаларда эше булмаган кебек, башкаларның да анда эше юк. Бөтен Яңавылда ашын ашаган, яшен яшәгәннәрдән нибары өч кеше калды. Ул үзе — Нурулла, авыл мулласы Әхмәтҗан, янә поп Гапун, әттәгенәсе... Гыйндулла. Бер уйласаң, күп авылда фронтовиклардан бер кеше калмаган, ә монда өчәү берьюлы... Калу беләнме? Нурулланың Әхмәтҗан белән Гыйндулланың бусагасын атламаганына ни гомер? Тегеләр дә шулай. Нурулла гына түгел, теге икәү дә берберсенә йөрешми. Ә бит Илекледә бер класста укыды-

лар, унҗиде яшьләре тулар-тулмас малайлар кырык өчтә бергә фронтка киттеләр.

Авылдан аларны кырык бердә, сугыш башланганның икенче көнендә, фронтка киткәннәрне озаткандагы кебек шаулы озату булмады. Өчесен ялгыз ат җигелгән бер арбага утыртып, бер аягын немец снаряды ярчыгыннан өздереп кайткан Лотфулла алып китте район үзәгенә. Нурулланың да, Әхмәтҗанның да, Гыйндулланың да аталары фронтта. Һәркайсысын, яулык очларына күзләрен сөртә-сөртә, кычкырып елап җибәрмәс өчен иреннәрен авыртканчы кысып, әниләре озатты. «Сакла, балам, үзеңне! Атаңны күрсәң...» — Һәрберсе шушы сүзләрне кабатлады. Гыйндулланың әнисе, Маһикамал апай, бөтенесеннән дә олырак та, чирле дә иде. Ул чакта улын озату кайгысыннан бөтенләй күгәреп каткан иде. Ниндидер көч кенә аны атлата, шагыр-шогыр тәгәрәгән тәгәрмәчләр артыннан хәлсез кулын болгый-болгый барырга мәҗбүр итә. Көзге юл аның «Ба-ла-ам!» дип кычкырганын өзәерта сары яфрак өермәсенә ыргыта.

Район үзәгендә аларны машинага төяделәр. Бөтенесе дә бала-чага. Ирләрнең типсә тимер өзәрлекләре күптән сугышта. Аннан кайтканнары Лотфулла ише: йә аяксыз, йә кулсыз. «Ни... бик очынып бармагыз, — диде Лотфулла, хушлашканда, — сак, уяу йөрегез».

«Алкино» дигән җирдә алар тәүге хәрби хезмәт күнекмәләрен үзләштерделәр. Бер ай булды дигәндә, «теплушка»ларга төйи башладылар. Моңа тиклем үз эшенә, үз уена чумып йөргән солдатлар, фронтка озатылыр мәл җиткәч, кинәт җанланды, гармун шыңгырдата, түгәрәк ясап әүмәкләшә, көлешә, кычкырып сөйләшә башладылар. Гармунга кушылып берәү җыр башлады:

Безне сугышка алдылар...
Юкә яфрак койганда,

Аны башкалар эләктереп алды:

Кайтырбыз чәчкә атканда
Юл буенда багана.

Аннан бию китте.

Эх, яблочко,
Кайда катишься?
Нимесләргә плен төшсәң,
Хрен воротишься!

— Кем шулай җырлады?! — Күзе аларган офицер киемендәге кеше, рәтләрне ерып, уртага чыгып басты. — Мин сездән сорыйм: кем башлады?

Күзләр җиргә төбәлде, шып-шым булдылар. Кемдер яңа алган солдат киемен төзәткәләп маташкан була, кайсыдыр фуражкасының эчен-тышын әйләндергәләп карый.

— Трибунал хотите?! — Зур күзле, кызыл йөзле офицер (командир бугай) гармунчының кулыннан хромканы йолкып алып җиргә ташлады, өстенә сикереп изгәләде. — Строиться! Направо — равняйсь. Смир-но! Шагом марш!

Ул арада атка атланган командирлар чабып килеп җитте, солдатлар, чыбыркы эләгүдән куркып, тагы сөрлегеште.

Тиздән Алкино станциясе артта калды. Нурулланың колагында гармунчының: «Безне сугышка алдылар, юкә яфрак койганда», — дип, карлыкканрак тавыш белән үз уңаена уфтанып, ыңгырашкан гармунына кушылып җырлаганы озата барган кебек булды.

Тагы бар станциядә аларны аердылар. Хушлашканда һәрберсенең авызында «Алдарак кайтсаң, минекеләргә...» дип өзек-төтек әйтелгән сүз булды.

Нурулланы поезд билгесезлеге белән күңелен сихерләгән дә, шул ук вакытта куркыныч та булган көнбатышка ашыктырды...

«Нурулла кордаш!» — Тавыш янә кабатланды. «Кордаш» сүзенең ишетелеп калуы йокысын тәмам качырды. Тавыш иясе йә Әхмәтҗан, йә поп, теге ни, Гыйндулла. Чыкмый булмый. Нурулла аякларын, караваттан төшереп, йомшак башмагына тыкты, кармаланып, таягын тапты. Күрше йортта яшәгән улы белән килене уянмасын дип, шыгырдавыннан куркыбрак кына ишекне ачты, хәленчә йомшаграк басарга тырышып, капкадан урамга чыкты.

* * *

Нурулла өйалды бакчасына терәтеп эшләнгән эскәмиядә утырган Әхмәтҗанны төсмерләде.

— Бәй...

— Йокыңны бүлсәм, гафу ит, Нурулла.

— Йокыны ни... сатып алмыйбыз... Нишләп, иртә

дисәң, иртә, төн дисәң, төн түгел... — Нурулла, Әхмәтҗанның янына утырмакчы булып, эскәмияне кармалады.

– Таң атканны көтәргә тәкать калмады.

– Йә, шуннан... Ни булды? – Җайлап утырган Нурулла Әхмәтҗанның таң яктысыннан күгелҗемләнә төшкән күзлегенә текәлде: чир китсә дә, гадәт китми, дигәннәре дөрестер — хәтта шушындый мәлдә дә төрттерми түзә алмады: — Бисмилланы әйтеп, иртәнге намазыңны укып, түреңдә, абыстай кочагында изрәп ятасы урында...

— Һәй, кордаш... Әйткәнең дөрес тә бит... Бисмилла дигәнче вакыт үтә бит.

— Нәрсә булды?

— Илекәйдә булганың бармы?

— Бәй... булмаска әллә... Поп Гапун чукынудан бушамый, син — сәҗдәгә китүдән. Ә тегеләрнең, — Нурулла таягын Илекәй ягына төбәде, — хәлен миннән башка белгән адәм юк. — Нурулла зиратка бармак йә таяк белән төртеп күрсәтергә ярамаганны яхшы белә, бала чактан аңына сеңдергәннәр, ияк белән генә ым-ишарә итәргә кирәк. Бу юлы кызып китте, таяк төбәвен үзе дә сизми калды. Әхмәтҗанга үгет-нәсыйхәт укуга бер сәбәп булды. Хәзер башлый инде: «Сине, Нурулла кордаш, мин аңламыйм...»

— Әйткәнең хак. Дөрес сүзгә җавап юк. — Ике учы белән таягына таянган Әхмәтҗан кинәт тынды.

Байтакка сузылган тынлыкны, тамак кырып, Нурулла бозды:

— Мин авырсынмыйм, тик менә аяклар...

— Илекәй зиратында әрвахлар рухына Коръән укырмын дип барган идем мин дә... — Әхмәтҗан бөтен гәүдәсе белән Нурулла ягына борыла бирде. — Оныгыңа, кем, Гәрәйгә рәхмәт, зиратны матур киртә белән әйләндереп алган. Нык. Шунда бер әкәмәт күренешкә дә тап булдым: әле таң тишегеннән үк сиңа килүемнең сәбәбе дә шул.

— Йә?! — Инде Нурулла Әхмәтҗан янына шуышты. Яхшырак ишеткән сул колагын кордашына якынайтты. — Шуннан?

— Авыл булса, как рас олы урамга туры килер иде — рәт-рәт флажоклар кадап чыгылган. Шунысы кызык: алар зират эченнән дә үтә...

— Ә үрдә... Илекле кырда?

— Тын кысылып, үргәрәк күтәрелә алмадым. Күрше малаен бер сәгатькә генә дип алып киткән идем. Ул да кабаландырды...

— Ул нәрсә диде?
— Һы. — Әхмәтҗан кулын селтәде. — Карап та тормады. Туктау белән машинасында казынды. Ул нинди хәл булырга мужыт икән, ә, кордаш?
— Гыйндулла беләме?
— Башлап сиңа килдем. Оныгың... силсәвит бит. Әллә, мәйтәм, берәр эше ачылып, изге урынга өйләр төзергә уйлыйлармы икән дим. Урыны бит нинди!
— Аптыраттың, кордаш... Минем дә әллә бар гомер, әллә юк гомер, быел исән чакта Җиңү көнендә Илекәйгә барып кайтмабыз микән дигән уй бар иде барын.
— Бер дә начар булмас иде, — Әхмәтҗан җанланды, таягының кәкре башына ябык учы белән суккалап алды. — Шәп булыр иде! Теге... ике сәбәпне бер итеп... Гыйндулланы, дим, уятыйкмы әллә?

* * *

Хәзерге автобус юлы белән барсаң, Илекәй Яңавылга унике чакрымнар чамасы. Нурулланың исә үз юлы бар: Сарытау аша чыгып, Ялтыркүлдән астарак күлдән чыккан елганы үтәсең. Аннан инде Илекле кыр, тауның астында Илекәй авылы. Авыл хәзер үзе юк. Хрущёв патша нишләптер вак авылларны яратмады. Үзәккә якынрак дип, халкын көч белән Яңавылга күчерделәр. Халык күчми этләшкәч, медпунктны, башлангыч мәктәпне, кибетне яптылар, чыбыкларны өзеп, баганаларын кисеп, ут бирүне туктаттылар. Шул хәлдә дә ике-өч өй калгач, штраф салабыз, печәнлек бирмибез, дип куркыттылар. Шулай корыды авыл, бетте. Хәзер анда борынгы авылдан калган зират бар да, Бөек Ватан сугышында катнашканнарга һәм башын салганнарга һәйкәл-обелиск тора. Янә... Нурулланың өе. Әйе, Нурулланың атасы Хәйруллага олатасы Шәйдулладан калган, карагач бүрәнәләрдән салынган өй.

Нурулла өен Яңавылга күчермәде: башта совхоз өендә тордылар, соңыннан үзенекен салып чыкты, оныгы Гәрәй, Әфганда алган яраларыннан вафат булган улы Закирдан туып калган ир бала, хәзер олатасы өе белән ярышып, бер ихатада үзенең тормышын корып җибәрде.

Атасы мәрхүм Хәйрулланың: «Илекәйне ташлама, улым, бу урын котлы, — дип сөйләгәне хәтерендә. — Безнең олатай сөйли торган иде. Элек бу тирәдә кеше

яшәмәгән. Корылык вакытында, үлән үскән сулы урын эзләп, халык шушы якларга агылган. Үзләре таң атканда берничә тапкыр ара-тирә күренеп калган илеккә — кыр кәҗәсенә ияргән. Кыр кәҗәсе кайда күренсә, алар шунда таба киткән. Тора-бара шушы урынга килеп чыкканнар. Дөресрәге, монда килеп җиткәч, кыр кәҗәсе югалган. Бер көн көткәннәр, ике, өч... Кыр кәҗәсе башкача күренмәгән. Халыклар, күрәсең, Тәңренең безгә атап калдырган төбәге шушыдыр дип туктап, тирә-юньдәге карагачларны аударып, тормыш кора башлыйлар. Монда туган тәүге ир баланы Илекәй дип атаганнар. Авылга аның исемен биргәннәр.

— Кыр кәҗәсе бүтәнчә бер дә күренмәгәнме?

— Күренгән. Күренгәләгән. Кем дә кем Илекәйдә яңа йортка нигез сала башласа, теге кыр кәҗәсе күренеп киткән. Шәйдулла бабагызга да күренгән ул, дип сөйли торган иде минем әти.

Кыр кәҗәләре әнә анда, Илекле кыр тавының иң башында күренә, ди ул. Ул күренгәндә, тирә-як беркавымга яктырып, нурланып тора, имеш...»

* * *

— Антретен! — Гыйндулла караңгылыкка чумган төрмә камерасы сәндерәсендә яткан җиреннән кинәт торып утырды. Итеген капшады, тапмады. Йөгереп барып сафка басарга тырышты, ләкин саф юк. Бөтен тоткыннар караңгылык дөньясында идәндә мүкәли. Кемгә төртелсә дә ялангач. Бер хикмәт инде менә! Алар нәрсәләрендер югалткан. Кичтән бер кружка чәй генә булды. Гыйндулланың да төшкә бирелгән паёгы — 50 грамм икмәге калган иде. Гыйндулла аны башта салам тутырылган мендәре астына салды, исе тынгы бирмәгәч, ашап куюдан куркып, мендәре кебек үк салам матрасының астына тыкты. Матрас аша да исе борынны ярып кергәч, киемнәрен бикләп тоткан шкафының уртадагы киштәсенә салды. Салып бикләр алдыннан читләрен тешләштерде, икмәк — шырпы кабыннан чак кына зуррак кисәк — түгәрәкләнә, югары төште. Гыйндулла аны башта өстәге киштәгә салырга булган иде — кире уйлады. Онытылып, куллары белән кисәкнең барлыгын, урланмаганын белгеләгәнче йөрәгенең түзмәве бар. Ә болай... шкаф ишеген ачуың була, ул шундук күзгә ташлана!

— Дизе?
— Хир?

Болар кемнедер эзли. «Этот?» «Здесь?» дигән сүзләрнең мәгънәсен күптән төшенде Гыйндулла. Күрәсең, кемдер качкан. Гыйндулла хәтта караңгыда да алар — полицайлар белән күзгә-күз очрашудан курка. Гыйндулла бар көченә икмәге яткан шкафка таба шуышты, ләкин тоткыннар, корт кебек кайнашып, аңа алга омтылырга ирек бирми. Тыны кысыла, йөрәге дөп-дөп тибә, башына ут капканмыни — кызу.

— Файрашт!

«Отбой» командасын ишеткәч, Гыйндулла кире артка чүкте. Инде ул сәндерәсен таба алмый җәфалана. Һаман да шул тоткыннар. Алга да, артка да барыр әмәл юк. Ул арада ишекне дөбердәтә башладылар:

— Ауфштийн! Ауфштийн!

— Хәзер! Хәзер! — Гыйндулла күзләрен ачты. Бүлмә таңгы кызылсу яктылыкка чумган. Шторалар селкенә. Монда беркайчан да саф һава үтеп кергәне юк. Шторалар... һава... бу яктылык... Гыйндулла күзләре белән түшәмдәге «подъём» командасы белән бергә яктыра торган зәңгәр лампочканы эзләде. Юк. Лампочка күренми. Бәй, ул һәрчак шушында, баш очында иде...

Дөбердәү кабатланды. Бәй... Гыйндулла үз өендә ята бит! Әй, хәтерең! Кичтән башы әйләнеп йончыган иде шул. Капканы соң нигә шакыйлар? Гыйндулланың элегрәк капка бикләп ята торган гадәте юк иде. Соңгы вакытта телевизордан сугыш ветераннарының орден-медальләрен урлау, үзләрен үтереп, бүләкләрен алып качуны еш күрсәтәләр. Белмәссең. Сугышка керүнең тәүге көненнән әсирлеккә эләккән Гыйндуллада ул бүләкләрнең барлыгы-юклыгын замана яшьләре тикшереп торамы?

Ул арада тәбәнәк тәрәзәнең пыяласы аша мыдыр-мыдыр сөйләшкән тавышлар ишетелде. Кемнәрдер йөри. Гыйндулла тыңлаусыз аякларын түшәктән көчкә аерып алып, торып, ачылмалы тәрәзәсен тышка кадәр этәрде.

— Кем бар анда?
— Кордаш... Гыйндулла кордаш, без әле, без...
— Сез?! Нурулла, синме бу?
— Мин, мин. Әхмәтҗан кордаш белән...

* * *

Гыйндулладан чыкканда, кояш төшлеккә үк житеп бара иде. Яры бүселгән буа кебек, агылды гына бу өчәүнең сүзе. Шулай булмый, өчәү бергә үстеләр, бергә пионер сафына керделәр, соңыннан — комсомолга. Борын аслары кибеп бетәр-бетмәстән фронтка киттеләр. Хәтта (Ходайның кушуы!) өчесе бер кызга гыйшык тоттылар. Авылда гына түгел, тирә-якта чибәрлеге, ипле холкы белән даны чыккан кызга — Хәтирәгә.

Дүртесе гел бергә уйнады. Яз житкәч, апрель мәлендә үк Илекле кырга юага чыгалар иде. Өчесе җыелалар да Хәтирәне көтәләр. Әнисе белән генә яшәгән кызыкай кул арасына иртә керде. Әнисе колхоз эшендә, савымчы. Дөньяларын Хәтирә көтә.

— Уф! — дияр иде Хәтирә, малайларны көттерүеннән уңайсызланып. — Китә торсагыз да булыр иде, куып житәр идем әле...

— Ни... Вакытны акчага сатып алмыйбыз ла... — дияр иде Нурулла.

— Өчәүдән дүртәү яхшы, — дип ныгытып куя Әхмәтҗан.

— Теге ни бит, — ди Гыйндулла, сипкелле түгәрәк йөзен читкәрәк борып. — Теге ни...

Менә шулай кара яздан кара көзгә чаклы Илекле кырдан дүртәүләп ризык ташыдылар. Яз — юа, кузгалак, сарана*. Җәй — җиләк, чия, шомырт, бөрлегән, гөлҗимеш. Көз — балан. Сыйдан мәхрүм итмәде аларны бу игелекле тау.

Ир-егетләр яуга китәме, армиягәме — кыз-кыркын бүләк бирә. Бүләкләр башлыча йә көмеш тәңкә, йә йөзек, йә кульяулык, йә янчык. Бу өчәүне станциягә алып киткән ат арбасына тотынып, Хәтирә бераз бара бирде. Аннан туктадылар. Төз буйлы сылу Хәтирә моңсу иде бу чакта. Кесәсеннән өч кульяулык чыгарды. Читләре төрле төстәге җепләр белән каелган. Ак ефәк тукымага хат тешләп очкан күк күгәрчен чигелгән.

— Истәлеккә! — Кызның күгелҗем соргылт күзләренә яшь тулды. — Онытмагыз!

— Рәхмәт. — Нурулла белән Әхмәтҗан хушлашыр өчен кулларын бергә сузды. — Онытмабыз. Без кайтырбыз.

---

* **Сарана** — суганчалы үсемлекнең бер төре.

— Хәтирә! — Гыйндулла көтмәгәндә кесәсеннән йөзек чыгарды. — Бу сиңа, Хәтирә! Онытма, Хәтирә!

Хәтирә янында моңа тиклем «теге ни»дән башканы әйтә алмаган сипкелле Гыйндулланың бу батырлыгыннан оялып, аптырап калган егетләр кире арбага сикерде, кучер Лотфулла атның сыртына мул гына итеп чыбыркы тамызды. Йөзеген учына йомып, тораташтай каткан Хәтирә урыныннан ат борылышка җиткәнче кузгалмады.

Ахырда, Алкинога җиткәч, төнен Нурулла күз яшьләренә ирек куйды. «Җебегән! Пешмәгән! Гыйндулланың хәленнән килгәнне син эшли алмый идеңме? Син үзеңне хур кызыдай сылу Хәтирәгә тиң булмам дидең... Ә ул... Гыйндулла...»

Шунда ул үзенең колак төбендә Әхмәтҗанның пышылдавын ишетте:

— Минем кульяулыкта чәчкә сурәте дә чигелгән. Роза гөл...

Гыйндулла да саңгырау түгел бит:

— Минекендә... теге ни... йөрәк...

Нурулла белән Әхмәтҗан икесе берьюлы кульяулыкка текәлде:

— Йөрәк?!

— Йөрәк. — Сипкелле Гыйндулланың түгәрәк йөзе ямьсез көзге төндә дә кояшның үзе кебек балкый иде. Әйтерсең ул җәһәннәмнең үзе кебек сугышка түгел, Хәтирәне Илекле кырга җиләккә чакырырга китеп бара...

Нурулла өенә җитәрәк капка тышында машиналар торганын, кемнәрнеңдер шулар янында таптанганын шәйләде. Кунаклар бар, ахры. «Әттәгенәсе, — дип куйды эченнән. — Гәрәйнең үзен генә күреп, теге флажоклар хакында сорашырга иде бит әле. Алай дисәң, ярый, янмый. Тугызынчы майны быел өч кордаш бергәләп Илекледә бәйрәм итәргә сүз куештылар бит. Баргач күренер».

* * *

Әхмәтҗан, Гыйндулладан чыгып, Нурулла кордашыннан аерылгач, туры авылдан читкәрәк салынган мәчеткә карап атлады. Азан әйтер вакыт якынлаша, намазга соңламаса ярый ла. Озаграк та утырдылар шул. Әй гомер! Үзләрен белә-белгәннән бер сынык икмәкне дә

бүлешми ашамаган җан дуслары белән күпме гомер бер авылда торып та аралашмый яшәлгән!

Башта бөтенесе дә әйбәт барды баруын. Әхмәтҗан сугыштан кырык бишнең май азагында кайтканда, әти-әнисе исән, дөньялары имин иде. Бер кулын Польша җирендә калдырып, кырык дүрттә кайткан иде атасы. Чулак булса да, ир кеше ир кеше инде — дөнья бөтен генә, абзарда мал, кош-корт та юк түгел. Кытлык үзен сиздерсә дә, авыр сугышта җиңеп, үз илен генә түгел, бөтен Европаны фашист изүеннән коткарган җиңүче рухы белән яши авыл. Хәтта аталарын сугышта югалтканнар да үзләрен ятим итеп тоймады: алар — җиңүче балалары. Җиңүче бәхетсез булмый. Әхмәтҗанга да өзелгән яшьлеге кире кайткандай, дөнья аны колачын киң җәеп каршы алгандай тоелды.

— Колхоз нык бетерешкән, ай-һай терелтүләре, — диде атасы, тәмәке тартып утырганда. — Ир-ат... син дә мин, Мөхәммәтәмин дигәндәй.

— Терелтербез! — Әхмәтҗан моны һич икеләнүсез әйтте. — Үзең белмәгән ни эш бар, әти? Бер төн эчендә шарлап аккан елга аша күпер салып, иртән танкларны үткәрә торган идек.

— Анысы шулай. Фронт фронт инде ул. Монда, улым, хатын-кыз, карт-коры. Курпы юк хәлендә. Считай, биш ел буе бер бала тумаган...

— Бик мескенләнеп китмик әле, атай... — Әхмәтҗан, атасы белән бертигез әңгәмә корып утыруыннан уңайсызлана биреп, тамак кырды. — Өйләнермен... Балалар туар... Гыйндулла белән Йомры Нурулла кайтса...

Әтисе кыенсынып, бөрешеп китте:

— Әле бит, улым, Гыйндулладан хат-хәбәр бер дә булмаган. Бәлкем, исәндер дә, бәлкем... Кем белә...

— Ә Хәтирә?!

— Хәтирә авылда. Почта ташый. Сезне озату белән почтага эшкә төшкән. Гыйндулланың әнисе, көз обозда йөреп, салкын тидереп, үпкә белән яткан. Менә апрельдә генә җирләделәр. Хәтирә аны өенә алып кайтып карады.

— Ә әнисе? Минҗамал апай?..

— Ә ул юк... Кышын фермага печәнне дә савымчылар ташыган бит. Шунда карда, буранда... адашканмы, өшегәнме. Мәетен яз гына тапканнар...

Әхмәтҗанның күз алдында Хәтирәнең ягымлы йөзле, сылу әнисе теп-тере булып гәүдәләнде. Юк, шулчаклы

шат күңелле, чибәр, яшь хатынны җир ничек... Соңгы сүзләрен үзе дә абайламастан, кычкырып әйткән, ахры, моны ул атасының: «Җиргә дә яхшы кирәк», — диюеннән аңлады.

Тынлыкны Әхмәтҗан бозды:

— Хәтирәгә кереп чыгыйм әле, әти, — «бүләгем дә бар» диярга укталды да, килештермәде. Артыгын ычкындырмыйм, диде.

— Кер, кер... Бергә үстегез. Каралтысы да тузган, колхоз эшенә керешкәнче, мужыт, ярдәм итәрсең. Нурулланың әнисе, Хәдичә җиңги, туже авыр хәлдә, диләр...

— Алайса, мин киттем, әти.

Атасы эндәшмәде. Әхмәтҗан, өенә кереп, чемодан төбенә кәгазьгә төреп салган ефәк яулыгын куенына тыгып, Хәтирәләр тыкрыгына борылды.

Әхмәтҗанның күзенә сәгать чалынды. Өйләне үткәреп җибәрә язган. Кабаланып кына тәһарәт алып, намазлыгын түшәде. «Фатиха» сүрәсен укый башлагач, күңеле тынычлангандай булды. Әмма моңарчы оеп яткан зиһене таркалды, «Колһуалла»ның уртасына җиткәч, кире «Фатиха»га кайтты. Буталды, ахыр чиктә тәмамлап, дога кылды.

Намаздан торгач, кулы киштәдәге китапка үрелде. «Тарихе әнбия» китабын ачты. Аннан читләре төрле ефәк җепләр белән чигелгән ал кулъяулык килеп төште. Саргайган китап битләре арасында ятса да, сафлыгын, пакьлеген җуймый шушы кулъяулык. Үзеннән Илекле кырның җиләкле аланы исе килгәндәй. Теге чак, Хәтирә янына баргач, кызга күрсәтеп, шушы кулъяулыкны кесәсеннән алды. Сугышка киткәндә озатып калган какча кыз урынына дөнья бәгырен өзәрдәй сылу басып торганын күрүдән кинәт оялып, башы әйләнеп китте Әхмәтҗанның. Маңгаена хәтта салкын тир бәреп чыкты. Кулын кечкә күтәреп, өнсез калып, оялчан йөзен шушы кулъяулык белән сөртте. Беренче һәм соңгы тапкыр шунда кулланды бу бүләкне. Башкача кагылмады.

Башлап Хәтирә эндәште:

— Саумы, Әхмәтҗан! Менә... — Кыз йөзен тугарып торган атының муены артына яшерде — әллә инде күз яшьләреннән оялды, әллә ни...

— Менә... кайттым... — диде Әхмәтҗан, үзе җитез хәрәкәтләнеп атны тугарыша башлады. — Почта ташыйсың икән...

— Почта...

Шуннан болдырга утырдылар.

— Бөтенләйгәме?
— Бөтенләйгә.
— Нурулла... юк әле.
Әхмәтҗан җанлана төште:
— Йомры баш белән бер очраштык без!
— Ничек?
— Станциядә. Су алырга колонкага йөгереп барсам, берәү котелогына су тутыра. Мәйтәм: «Поторопись, поезд уходит!» Бу миңа әйләнде, карасам, Йомры. Кочаклаштык та аерылыштык. Безнең поезд көнбатышка, анықы — төньякка.
— Ә Гыйндулла... Аны...
— Аны — юк.
— Хәтта әсирләр дә кайта башлады... — Хәтирәнең күгелҗем күзләренә соры болыт шәүләләре җыелды. Болай аның озын кара керфекләр каймалаган күзләре караррак күренә. Бит очлары алсуланды да, иренен тешләүдән читәләрендә йомры уемнар ап-ачык беленде.
— Әсирләр кайталар да ул... — Әхмәтҗан, сылу кызның йөзеннән карашын көчкә аерып, бәбкә үләннәре яшәрткән туфракка текәде. — Кем коткара бит аларны: американнармы, әллә инглизләрме, әллә юкса французлармы...
— Алай дисең...
Сүзсез утырдылар. Әхмәтҗан уңайсызлана, йөрәгенең ярсып тибүен Хәтирә дә ишетәдер кебек. Җитмәсә, кызның ачык муеныннан, тыгыз беләкләреннән кайнарлык, зиһенне томаларлык хуш ис бөркелгәндәй. Илекле кырның җиләкле аланы исе. Ә бу кичерешләргә дучар итүче зат үзе шундый чибәр, шундый якын. Тик... Гадәти бер кеше, солдат (сержант булса да) башың белән аңа ничек үреләсең? Куеныңдагы ефәк яулык та тәнен пешергәндәй. Аны ничек итеп бирергә? Ә менә аның бармагындагы фирүзә кашлы йөзек? Бу теге чак Гыйндулла биргән бүләктер әле.
— Нигә болай утырабыз әле? Әйдә, өйгә керик, самавыр куям. — Хәтирә торып басты.
Әхмәтҗан да торды:
— Йә, ярый, Хәтирә, башка вакытта. Үзең дә юлдан, талчыккансыңдыр...
— Ә башка вакыт булмаса? — Хәтирә, күзләрен кыса төшеп, озын керфекләренең угын егеткә төбәде.
— Нигә булмасын? Нурулла әйтмешли, вакытны акчага сатып алмыйбыз әле. Абзар-кураң ирләр кулы сорый...

— Син, Әхмәтҗан, колхозга кирәк. Председатель юк. Вазифа инәй картайды, аңа ни үпкә?!

«Хәзер йә беркайчан да!» — Әхмәтҗанның зиһенен шушы уй телеп үтте һәм куенынннан теге ялкын ялмаган яулыкны тартып чыгарганын үзе дә сизми калды:

— Бу сиңа, Хәтирә!

— Ой! — Хәтирә кулында нәфис ефәк тукыма таралып җәелде, кояшлы көндәге дулкындай ялтырады. — Матур икә-ән! Тик... — Хәтирә яулык тоткан кулларын кинәт түбән төшерде. — Әхмәтҗан, син бу матур яулыкны үзеңдә тот. Өйләнеп җибәрерсең, кәләшеңә бүләк итәрсең...

— Мин аны сиңа дип алдым, Хәтирә! — Әхмәтҗан, кинәт борылып, урамга ашыкты — шул соңгы сүзләре белән Хәтирә аның аралар, бәлки, якынаер дигән өметенә нокта куйгандай булды.

— Без дуслар бит, Әхмәт... җан... — дигән сүзләр өзек-төтек чалынды колагына.

Гади дуслык тойгысы Әхмәтҗан күңелендә алтыны бетереп, җиденче класска күчкән җәй үк мәхәббәткә бөреләнгән иде. Хәтирә генә моны сизмәде.

Әхмәтҗан китап эченнән алган кульяулыкны бөкләнгән килеш түш кесәсенә салды. «Онытылып калмасын, — дип уйлады ул. — Илекәйгә Җиңү көнен билгеләргә барганда алып барам үзем белән. Кызык, тегеләр ул бүләкне саклый алдымы?»

* * *

— Кайда йөрисең син, олатай? Туруннарың отпускага кайтып төште бит!

— Абау, шулаймыни? — Нурулла тирә-ягын айкады.

Зур кара машинаның багажнигыннан сарык чыгардылар.

— Олатай! — Машина артыннан ялт итеп килеп чыккан солдат Нурулланы кочаклап кына калмады, күтәреп үк алды.

— Ай, шайтан малай, карт сөякләр таралып китсә, җыеп ала алмассың бит!

— Менә бит, күрештек, олатай. Озатканда, башка күрә алмам, дип, котны алган идең.

— Иншалла. — Бу сүзнең теленә ничек килеп кергәнен карт үзе дә сизмәде. — Шөкер, шөкер... Әй, Илекәй улым,

Илекәй... — Карт учы белән турунының аркасыннан сыпырды. — Алдан хәбәр итсәң... мин ни...

— Аптыратмыйм дидем, аннан... отпуск та көтелмәгәндә килеп чыкты...

— Йә, ярый, ярый... — Нурулла белән Илекәй капка эченә үтте. — Ә бу хәтәр машина кемнеке?

— Нимесләр эшли аны...

— Нимесләр... дисең? Нимес машиналарын Нурулла олатаң күрде инде. Син әллә шуның белән... — Нурулла нуры кайткан күзләрен турунына төбәде. — Генерал төяп кайттыңмы әллә кунакка?

— Әти, үземнеке, ди дә...

— Шаяртадыр... Станциядән сине барып алырга алып торгандыр берсеннән йә яллагандыр... И-и, заман. — Нурулла бакча алдындагы эскәмиягә җайлап утырды. — Безнең заман генераллары да, түрәләре дә нимес машинасына утырып йөрергә гарьләнер иде. Сталин карт исән булса, нимеснекеннән ун тапкыр шәбрәк машиналарны инде күптән үзе эшләтер иде...

— Ә син, олатай, утырып кара! — Турунының күзләрендә кара карлыгандай җемелдәгән чаткылар күренде. — Әйдә, үзеңне очыртып кына йөртеп китерәм. Әйдә, олатай, кая алып барыйм?!

Яраткан турунын исән-имин күрүдән хәле бетеп шатланган Нурулла урыныннан калкынды:

— Атаң орышмасмы?

— Бүген аның бездә кайгысы юк. Урыс дусты килә...

— Урыс дусты?..

— Әй... Семён, диме...

— Симун! Симун... теге Ыстапан ызнакумның оныгы. Аның ни йомышы төшкән атаңа?

— Сорамадым... Әнә бит сарык суялар...

— Синең кайту хөрмәтенә дип торам мин.

— Әйдә, олатай, ыгы-зыгыдан файдаланып калыйк. — Илекәй, машинаның ишеген ачып, олатасын күтәреп утыртты.

— Уңай икән каһәрең... Болай булгач, син, улым, мине туган төбәккә — Илекәйгә алып барып кил, — диде Нурулла, турунына канәгать күзләре белән яратып карап. Ә үзе эченнән: «Тугызына күп калмады, күмәкләп барып төшкәнгә чаклы өйне караштырыйм, юлын карыйм. Янә... теге флажоклар. Чынлап күргәнме аларны Әхмәтҗан, әллә күзенә күренгәнме?» — дип уйлады.

Ул арада Гәрәйнең тавышы ишетелде:

— Илекәй! Син кайда?
— Мин... олатамны йөртеп апкайтам.
— Ипләп йөре!
— Ярый.

* * *

Немец, каһәрең, уңай яшәргә ярата. Сугышта да җәяү изаланмадылар, ат карап та җәфаланмадылар — өч тәгәрмәчле мотоцикл белән выжлатып йөриләр. Ә тиз йөрешле бронетранспортёрлары? Һәй, нык әзерләнгәннәр иде сугышка. Рәсәйнең аяусыз суыклары булмаса, белмим, ни булып бетәр иде. Болай да инде аларның югалтулары белән безнекен чагыштырырлыкмы? Нуруллалар частен Җиңүдән соң тагы бер ел тоттылар Германиядә. Шунда ныклап күрде аларның көнкүрешен Нурулла. Әй-й-й... Уйласаң, уелып китәрлек. Колхозлашу чоры Нурулланың йөрәген телеп кенә түгел, изеп үтте. Атасы йортыннан сыерны, тананы алып чыгып киттеләр. Имеп йөргән бәләкәй кенә бер бозау торып калды үзләренә. Сыер йөрәкне ярып колхоз абзарында бакыра, бозау — монда. Абзар дигәнең киртә белән уратып, түбәсен аннан-моннан япкан лапастан гыйбарәт иде. Халыктан кан елатып җыйган мал март айлары җитүгә ачлыктан күтәрәмгә калды, йөткерә башлады. Нуруллаларның сыеры да күпкә бармады. Кич җитсә, кеше күрмәгәндә, әнисе танага вак-төяк ризык җибәрә иде. Анысы язга бозаулады. Җәй җитүгә, кешедән җыелган малның күбесен югалтып, калганнарын көтүгә кудылар. Нурулланың әнисе, танасын жәлләп, фермага савымчы булып эшкә керде.

Германиядә сыер, ат, дуңгыз абзарларын күреп исе китте Нурулланың. Колхозлашуны уйлап чыгарган җитәкчеләргә җаны көйде: малны җыяр булгач, башта син ныклы абзар төзе. Иген чәчәсең — саклар җир юк, бәрәңге утыртасың — баз казылмаган. Немец базларындагы азык запасын хәтта сугыш та киметә алмаган! Боларны карап йөргән Нурулланың саруы кайнады: кайту белән тотыначак ул колхозны бөтәйтү эшенә. Тылдан, әнисеннән килгән сирәк-мирәк хатлардан белүенчә, кайткан ирләр бармак белән генә санарлык. Кем белән төзер икән ул абзар, баз, келәтләрне? Әлегә тиклем ирләр йөген иңнәрендә күтәргән кыз-кыркын беләнме? Эх! Ярый, Әхмәтҗан кордашы исән-сау кайтып төшкән. Аның өчен

бик нык сөенсә, Хәтирә өчен көенде. Бала чакта узыша-узыша буага су керергә барулары исенә төште. Янәсе, кем алдан төшә, сунын ямен шул ала, йә булмаса, кем элек — шул алтын балык. Шундый чакта алдынгылык күбрәк Әхмәтҗан өлешенә төшәр иде. Озынторык малай булгангамы, Гыйндулла белән Нурулланы әллә кайда калдыра иде ул. Менә әле дә фронттан иң элек ул кайткан. Аның Хәтирәгә ничек караганын хәтерли бит Нурулла. Хәтирәнең әнисе Минҗамал апайга да утынын кисеп, коймасын төзәтеп, карын көрәп яраган иде ул. Нурулла да ярдәм итәргә гел әзер булды, тик ул чакырганнарын, әйткәннәрен көткәләде, ә бу Әхмәтҗан... «Әрсезҗан» дигән кушаматы юкка бирелмәгәндер дә. Әрсезҗан медальләрен ялтыратып, болай да нәзек билен өзелгәнче ялтыр каеш белән буып, сылу кызның каршысына бөгелеп-сыгылып барып басты инде... Эх!.. Гармунына күз төшерде Нурулла. Бердәнбер сердәше шушы.

Йөргән җирләр калды инде —
Сары чәчкә алды инде...

Әнисенең дә хәле мөшкел. Атасы Чехословакия җирендә калды. Колхоз эшеннән, ирен югалту кайгысыннан йончыган әнисен күрше кызы Зәкия карый. Хатны да әнисе шул Зәкиядән яздыра. Нурулла киткәндә аңа күп булса 11—12 яшь булгандыр. Кыр кәҗәседәй какча, нәзек сыйраклы, җиңел сөякле, кара бөдрә чәчле кызыкай иде. Үзеннән бер сүз кушмаса да, уйчан, акыллы сүзләр белән әнисенең, авылның хәлләрен бәян кыла.

Сары чәчкә — сагыш төсе,
Йөрәккәем...

* * *

— Син... Башкортстаннанмы?

Гармунын караватына утыртты Нурулла.

— Мин, әйе, башкорт. Башкортстаннан.

— Әйдә әле, иптәш, чыгыйк.

Кавказ кешесенә тартым солдат белән Нурулла казарма буйлап атлады.

— Миндә бер нәрсә бар, — диде солдат. — Әманәт. Тик... кайчан, кем биргәнен сорама. Тапшырырсыңмы?

— Әлбәттә, тапшырам. — Иленә кайтуын кайтып житсә, Башкортстан бер учына гына сыярлык кебек иде Нуруллага.

Солдат китте. Ниндидер билгесез шомлы салкынлык белән учында яткан төргәкне ачты да Нурулла өнсез калды: бу бәләкәй генә соры тышлы блокнот иде. Шакмаклы блокнот битләренең һәр юлына тыгыз итеп көндәлек язылган. Нинди таныш кул? Кем шулай яза иде? Бу бит әсир көндәлеге. Кырык өчтән кырык бишкәчә, сугышның ахырынача концлагерьда булган кеше көндәлеге. «Илекле кырны күрдем төшемдә. Мин, Нурулла, Әхмәтҗан һәм Хәтирә. Дүртәүләп җиләккә килгәнбез. Дүртебез дә җиләкне өзеп Хәтирә чиләгенә салабыз, ә ул тулмый да тулмый». Гыйндулла?! Гыйндулла әсир төшкәнме? Кайда ул хәзер? Блокнот теге Кавказ кешесенә кайчан килеп эләккән?.. Мең төрле сораулар чолганышында баскан җирендә катты да калды Нурулла.

* * *

— Һунамга бор машинаны...

— Һунам?! Анысы ни? — Олы юлдан машинасын капыл гына борган Илекәй олатасына аптырап карады. — Тәүге ишетәм.

— Һунам — кеше йөрүдән туктаган юл, туруным. — Уйларыннан арынырга теләп, Нурулла селкенеп куйды. — Машина юлы булмаган чакта халык шушыннан йөри. Туры бара ул Илекәйгә.

Яз. Каеннар яфрак яра башлаган. Юл читендә күк умырзаялар, төркем-төркем булып, сары каудан арасыннан баш калкыткан. Тау башларында, соры юрганга салынган ямау кебек, артыш яшәрә.

— Читкә китсәң сагындыра икән, олатай. — Туруның йөрәксеп әйткән сүзләре Нуруллага җан өргәндәй булды: ни генә димә, Илекәй башкарак шул. Гәрәй оныгының ике улы армиядән кайту белән читкә шылды. Озын акча артыннан Себергә сыпырттылар. Илекәй җиргә берегеп, Нуруллага сыенып үсте. Якын аңа Илекәй. Карчыгын югалту кайгысын да шушы бала басты.

— Зәкия оләсәңне онытмадыңмы, балам?

— Аны ничек онытасың, олатай?

— Болай гына әйтәм. Кайбер бәндә армиядән үзгәреп кайтучан.

Калкулыкка менү белән, яшь каенлык, чәч толымыдай икегә аерылып, Илекәйне күз алдына бастырды. И хозур дөнья! Авыл үзе булмаса да, тау-таш әүвәлгечә. Түбәләренә кальгадай кыялар кундырган тау сыртлары, сылу кызлар кигән җиләнгә бизәк өчен тагылган талир тәңкәдәй күлләр, көмеш каештай елгалар. Йорт-кура төзеп, дөнья көтәргә бу җирне сайлаган кеше никдирәк булгандыр инде...

— Кайда алып барыйм, олатай?

— Башта әбилискегә. Өлгерсәк, зиратка да кереп чыгарбыз...

— Әтине әйтәм, шылтырата да башлар инде...

— Шылтыратса кайтырбыз. Ул да бит хөкүмәт кешесе. Әкрен, әкрен генә кер авылга...

— Нигә, олатай?

— Әле дә, балам, миңа алар һаман шушында төсле.

— Кемнәр?

— Рухлар, балам, әрвахлар...

Илекәй олатасына сәерсенеп карап куйды:

— Авылда партбилетын ташламаган бердәнбер коммунист син түгелме, бабай?

— Имансыз кешене, улым, партбилет иманлы итә алмый, иманлыны иманнан яздыра алмый.

...Автомобиль җиз калай белән тышланган обелиск каршысында туктады. Илекәй олатасына машинадан чыгарга ярдәм итте. Нурулла кесәсеннән ак резина бәйләнгән күзлеген алып киде. Илекәй, фуражкасын кулына алып, обелискның ике ягына ике канат рәвешендә сузылган таш стеналарга уелган исемлекләргә карады. Бер якта «Алар Җиңү яулап кайттылар», икенче якта «Алар ил өчен корбан булдылар». Корбаннар — 133, кайтканнар — 24.

— Илекәевләр. 71 Илекәев. Нигә ул шулай күп, олатай?

— Илекәй авылына нигез салучы Илекәй исемле кеше булган. Мондагы халык — шуның нәселе. Чаптаровлар — читтән килгән халык, Киекбирдиннар да. Калганнары — Илекәев. Илекәй картның исемен яңа буын сакласын дип, сиңа Илекәй исемен мин куштырдым.

— Гыйндулла Илекәев... Ул корбан булганнар исемлегендәме?

— Егерме елдан соң гына кайтып төште бит. И-и, балам... Сөйләсәң — сүз. Үзем силсәвит чакта салдырдым бит һәйкәлне. Аның исемен ташка яздырганга силый вой-

на булды. Каршылар күп иде. Имеш, әсир төшкән. Азактан, кайтып төшкәч, мине тереләй җирләгәнсез, дип, ул миңа ачу тотып йөрде. — Нурулла, арып, һәйкәл тирәли тагылган тимер чылбырга чүгәләде. — Сөйләсәң, сүз күп инде ул.

— Олатай, монда кабат авыл салынмас микән, бигрәк матур җир.

— Олы юлдан ерак дип, авылны күчерделәр бит. Бер ямь булып утырып калсын дип, мин өйне күчермәдем, кем белә...

— Мин, олатай, өйне шушында салам!

— Иманлы авызыңнан чыксын, Илекәй... — Нурулла дәртләнеп урыныннан купты, машинага таба тыраклады. — Әтиең эзли башлаганчы зиратка кереп чыгыйк әле.

— Тукта, олатай, үзем. — Илекәй аны янә автомобильгә утыртышты. — Зәкия оләсәйнең хәлен белми кайтмабыз инде, олатай.

— Зәкия оләсәң, әйе, яхшы кеше иде.

* * *

Нурулланы фронттан кайтып барышлый райкомга партиягә учётка керергә барган җирендә үк авыл Советына председатель итеп куйдылар. Кордашы Әхмәтҗанның колхозны җитәкләгәнен ишеткәч, Нурулла артык карулашмады: күз курка — кул эшли, кеше эшләмәгән эш түгел. Әнисенең авыр хәлдә түшәктә ятуын күрү генә авыр тәэсир итте.

— Ирләр күтәрмәстәйне күтәрдек бит, улым, — диде әнисе, хәлсез учларында улының кулын тотып. — Ярый, ярый... Сине көтеп алдым. Инде... үлсәм дә үкенмим. Тик бер...

— Әни! Ул турыда...

— Тыңла әле...

— Әни, менә килен алып бирермен үзеңә... Хәтирә... ул... Әхмәтҗан өйләнмәдеме?

— Туй булса, ишетелер иде. Болай Хәтирәнең тузган дөньясын рәтләштергәне ишетелә Әхмәтҗанның.

— Өйләнмәгән, димәк!

— Юктыр. Хәтирә бит... кордашыңны... Гыйндулланы көтте. Әнисен, Минҗамалны карады... Әле булса көтәдер ул. Мин, улым, сиңа шуны әйтмәкчемен:

Зәкия — акыллы, матур бала. Шул карады бит мине. Үзең беләсең, хатны да сиңа ул язды. Яшь бала бит... Хатларыңны миннән бигрәк ул көтте. Почта ташыган Хәтирәне авылда көтәргә сабырлыгы калмыйча, Тәпәшәк сыртлавык башында көтеп ала иде... Син аны рәнҗетмә инде — өйлән.

— Әни, анысы... — Нурулла ни әйтергә белмәде.

«Гыйндулла юк, юк инде. Исән булса, аның концлагерь көндәлеге ничек кеше кулына эләгер иде? Ул булмагач, Хәтирә, мөгаен, йә Әхмәтҗанны, йә Нурулла244ны сайлар. Әлбәттә, Әхмәтҗан алдан өлгермәгән булса...» дигән уйлар чолганышында ящәгән Нуруллага әнисенең үтенече аяз көндә яшен яшьнәгәндәй тәэсир итте.

Нурулла кайтканны ишеткән халык өйгә тула башлады. Хатын-кыз аш-су тирәсендә чуалды. Кем елый, кем куана. Ашъяулыкны җитез куллы, түгәрәк йөзле, кара күзле, зифа буйлы сылу кыз җәйде. «Берәрсе читтән килен төшерә микән?»

— Агаең белән... күрештеңме, кызым? Зәкия, сиңа әйтәм. — Урыныннан калкынган әнисенең тавышы сискәндерде Нурулланы: «Зәкия?!»

— Оялам ла мин...

Бөтенесенең күзе боларда. Нуруллага, урыныннан сикереп торып:

— Без таныш бит инде. Күпме хат алыштык, — дип, кызның кайнар учын кысудан башка әмәл калмады.

Нурулла үзе табында, күзе ишектә. Әле Әхмәтҗанны күрмәгән. «Кырдадыр», — диделәр. Хәтирә соң? Кулъяулык биреп озатып калган классташын күрергә килмәсме икән? Ә блокнот? Аны нишләтергә? Әсир газаплары, төшләре, бер сынык икмәккә зарыгып үткән көннәре, чирләре. Соңгы вакытта кан төкерүен дә теркәгән ул блокнотка. Димәк, туберкулёз...

Табын шаулый. Әбиләр күчтәнәч — чәй-шикәр, ак калач, монпасиларга кинәнә. Кемнең кеме кайда ятып калган, ә кемнеке бөтенләй хәбәрсез югалган — сүзгә сүз ялгана.

— Бәхетең бар, Хәдичә, — диләр Нурулланың әнисенә. — Ирең кайтмаса да, улың кайтты. Менә минекеләр — оланнар да юк, аталары да...

— Тәүфыйклы гына килен алып җибәрсәң...

— Киленне аны... Нурулла кайтканчы ук алып куйды бит инде Хәдичә!

— Берәү, улы кайткач, әйткән, ди, бит:

Абау, балам, кайттыңмыни —
Бәрәңге дә пешмәгән.
Килен әзерлимен дисәм —
Исемә дә төшмәгән.

— Хәдичәнең бәрәңгесе дә пешкән, килене дә төшкән!

Үзләре турында сүз чыгу белән, Зәкия, йөзен алъяпкычы белән каплап, тышка атылды.

— Йә, оялтмагыз әле яшьләрне!

— Без шаяртып кына бит...

— Шаян сүз көләргә яхшы.

— Уйнап әйтәм, уемдагын әйтәм, диген.

Сагынылган. Авылдашларының көлүе, сөйләшүе, шаярулары күңеленә шундый якын Нурулланың, шундый тансык!

Ул чакта Нурулла үзенең авыл Советы председателе итеп тәгаенләнүен дә, тиздән сугыш вакытында хәлсезләнгән, йончыган авылдашларыннан ит, сөт, май, йон, йомырка кебек авыл хуҗалыгы продукциясен — барын кырып-себереп хөкүмәткә тапшыртырга тиешле кеше икәнен дә онытты. Ахырда ул бу вазифада эшләргә җиңел генә ризалашуына мең тапкыр үкенәчәк — мәгәр терсәк якын булса да, тешли алмаячак.

Авылдашлары таралып, август аеның йолдызлы, өлгергән иген исенә тулган төне җитүгә, Әхмәтҗан килеп керде. Кочаклашып күрештеләр. Аңа дип калдырган кучтәнәчен дә чыгарды Нурулла.

— Миндә дә бар. Сезгә дип сакладым. Инде Гыйндулла да кайтып төшсә. — Кояшта янган чыгынкы яңаклы, эре сөякле Әхмәтҗан стаканга үрелде. — Әйдә, исән-сау очрашу хөрмәтенә.

Нурулла чәкеште. Өлкәнәеп, ныгып, ир уртасы кебек күренгән Әхмәтҗаннан күзен ала алмады. Ябык кына озынторык малай иде бит.

— Фронт... үзгәрткән сине. Икенче җирдә очратсам танымас идем, — диде Нурулла.

— Ә син шул көе, Нурулла. Синең үгез җилкәңне, зур йомры башыңны меңнәр арасыннан таныр идем.

— Шулай инде: «Йомры» кушаматын да син тактың бит миңа.

Әхмәтҗан кулын кордашының иңбашына салды:

— Йомры булу начар түгел, Нурулла. Менә миннән коры сөяк торып калды.

— Эш күп инде.

— Эше — эш. Эштән курыккан кеше юк. Юклык сыртка суга, юклык. Нибары бер трактор, анысы да... — Әхмәтҗан кул селтәде. — Атлар корчаңгы. Үгез җигәбез. Туңга да сөреп калырга кирәк. Аптырагач, бүген бишалты сыерны җиктек. Эшче куллар җитешми. Шуларга камыт кидерергә дә кеше юк.

— Мине авыл Советына сайладылар.

— Ишеттем.

Икесе дә тарта икән. Чыгып, болдырга утырдылар.

— Хәтирә күренмәде...

— Кәефсез ул...

— Сезнең арада... әгәр шулай булса, яшермә, дус... — Нурулла моны әйтә алмас иде — күчтәнәч ачты телен.

— Ул бит Гыйндулланы көтә... Понимаешь...

Нурулла икмәккә төелгәндәй йөткерә башлады:

— «Казбек», каһәр... Әхмәтҗан, — Нурулла бер карарга килеп торып басты, — Гыйндулла бит әсир төшкән. Менә...

Алар шушы төндә теге шакмаклы дәфтәр битләреннән ясалган кечкенә блокнотта язылганнарны җиделе лампа яктысында башларын башка терәп укыдылар.

Шуннан тышка чыктылар. Нурулла атасыннан калган тальянканы кулына алды.

Тын һавада авыл буйлап аның бәрхеттәй йомшак тавышы агылды:

Җиделе лампа якты яна,
Эчендә мае булса.
Җиде уянып, җиде торам
Җиде төн уртасында.
Җиделе лампа — мамык филтә —
Ватылды, җиргә төште.
Уф, йөрәгем, янам, көям —
Иркәм исемә төште.

Адәм баласы утка, янә моңга елыша. Каты йокы вакыты булуга карамастан, алар эргәсенә берән-сәрән килеп кеше җыелды. Зәкиянең ак күлмәге дә чалынды Нурулла күзенә. Чалынды да югалды. Хәтирә дә килде.

— Кайтканыңны ишетмәгән идем. Тавышыңнан... җырыңнан, — дип, күрешергә кул сузды, — кайтуың белән, Нурулла! Үпкәләмә инде шундук килмәгән дип...

— Нигә үпкәләсен, без бит классташлар!

— Игез балалар сымак үстеләр дә инде!

— Инде Гыйндулла да кайтып төшсә!..

Китте хәбәр куерып. Кемдер сыер савар чак җитүен әйтте, ул арада көтүгә чыккан маллар кайта да башлады.

— Сиңа сыер саварга түгелме? — Нурулла күгелҗем таң яктысында йөзе ак мәрмәрдәй күренгән Хәтирәгә күтәрелеп карады.

— Ә, юк. Мин сыер белән күптән хушлаштым.

— Булмаса, йөреп килик. Илекле кыр без юкта урыныннан күчмәгән булса! — Нурулла бер Хәтирәгә, бер Әхмәтҗанга карады. — Ну, ризамы?

— Бик риза. — Әхмәтҗан Хәтирәгә борылды. — Сиңа салкын түгелме?

— Киресенчә.

— Алайса, киттек!

Тальян бакчага сөяп эшләнгән эскәмиядә утырып калды, алар Илекле кырга илткән тыкрыкка борылды. Нурулланың күзенә тагы ак күлмәкле юка сын чалынды. Чалындымы, әллә күзенәме күренде.

* * *

Илекәйдән кайтканда, сарык суелган, казанга салынган иде. Гәрәй, Степан танышының онытгы баягы Семён, тагы бер кеше, ахры, шофёрыдыр, шашлык кыздырып мәш киләләр. Нурулла һич өнәми яшьләрнең шушы шөгылен: элек бит мал суелса, табада чыжлатып сызык куыралар, үпкә-бавыр, йөрәгеннән тутырма тутыралар иде. Шушылай ит кыздырып ашау эшме инде? Эт чаба дип, бет чаба дигәндәй. Кайда нәрсә күрә — шуны кылана хәзер халык. Бар да маймылга әйләнеп бетеп бара. Нәрсәнең яхшы, нәрсәнең начар икәнен уйлаган да юк.

— Озакладыгыз. — Гәрәй боларга сынап карап куйды. — Йоклап калдыгыз дип торам.

— Бездән башка да мәшәкатьләрең башыңнан ашкан. Илекәй буйлап нинди тамга куеп чыктың? Зиратта да шулар. — Нурулла оныгына текәлеп карады.

— Тамга?! — Гәрәй, кара куе кашларын бер ноктага төбәп, маңгаен җыерды. — Ә сез анда нәрсә карадыгыз?

— Ничек «нәрсә карадыгыз»? Ул минем... — Нурулла йортының нигезенә утырды, хәле беткәнен тоеп, сулышын җайларга тырышты.

— Анда нәрсә калган сиңа? — Гәрәйнең күзләре ачулы очкыннар чәчте.

Нурулла үзен тыныч тотты:

— Корт чаккандай кыланма, балам, мин бит...

Ул арада теге Семён, Степанның оныгы якынлашты:

— А-а! Старик! Это же твой дед, Гарай! Давеча я его не узнал, так он у тебя еще молодец! Здравствуй, дед!

— Здраствуй, Симун! — Нурулла, кунакчыллык күрсәтеп, елмаеп күреште. — Какими судьбами в наши края?

— Да вот края ваши приглянулись! А вот твоему внуку какого молодца я пригнал!

— А по карману ему такая машина?

— Карманны зурайтырга була, не так ли, дед?

— Бездә, юрганыңа карап аягыңны суз, диләр.

— Как, как? Юрганыңа карап... А-а! Понял! Вот сын вырос у Гарая. Каков джигит, а? Разве ему не хочется иметь нормальную машину?

— Ладно, ладно, пойдем, первая партия готова! Илекәй, син безнең янга утыр!

Семён Нурулла яныннан китә башлады:

— А чё дедулю не приглашаешь?

— Дедуле на печку пора. — Гәрәй кулын Семённың җилкәсенә салды. — Пойдём, а шофёр твой пусть еще одну партию обжарит.

...Алар киткәч, Нурулла үз өенә керде. Электр чәйнеген куеп, чәй кайнатып алды. Чәйнеккә кипкән карлыган, бөрлегән, кура җиләге яфраклары салды. Өйгә чәй яме биргән тәмле ис таралды. «Илекәй тегеләр янында тормас, хәзер олатай дип, ялт итеп килеп керер», — дип уйлады, үлән пешкән чәйнеген тастымал белән каплады.

Чәй эчеп алгач, Нурулла тәненең талчыгуын ныграк тойды, ашлары пешкәнче ятып торыйм дип, диванына сузылды. Әмма йокы алмады. Картайгач, йокы дигәнең нигә кача икән? «Мәңгегә йоклар чагың җиткән, якты дөньяда чагында хәрәкәт итеп кал» диюе микән бу күктәгенең? «Күктәге» дип сүз ычкындыргалый хәзер Нурулла. «Алла юк!» дип яшә-яшә дә, картайгач, Ходайга сыен, имеш. Бу гомерең буе беркайда эшләмә дә, хәлдән тайгач, буш «Хезмәт кенәгәсе» тотып, пенсия юлларга йөгергән кебегрәк килеп чыкмый микән? Алай дисәң, гомере буе башын намазлыктан аермаган, мәгәр бәндәгә бер игелек кылмыйча, карунның каруны, саранның сараны булып яшәгәннәр азмы? «Ходай бәндәнең йөрәгендәгесенә карармын» дигән, дип сөйләп утырды лабаса Гыйндулла кордашы. Нурулланың яшәгән

еллары өчен үкенерлеге юк та кебек: законнарның иң каты мәлендә дә ике-өч кило бодай, йә булмаса, егылып үлгән колхоз малы өчен беркемне дә хөкемгә тарттырмады, үзе сүз ишетсә ишетте, мәгәр бәлагә тарыганнарны аралап алып кала алды. Хөкүмәт чыгарган акылсыз карарларга да каршы чыккан чаклары аз булмады. Крестьянны аттан аердылар, ахыр кәҗәгә ябыштылар, авыл тирәсендәге җирләрне сөрдереп, бозау куарлык, бәбкә сакларлык та җир калдырмадылар. Авыл Советы председателе буларак, Нурулла хөкүмәт карарларының төгәл үтәлеше сагында торса, Әхмәтҗан, хуҗалык җитәкчесе буларак, эшнең ахыры ни белән очланырын күзәтте. Шуның аркасында ике арада татулык булмады. Азак, аңа, партиянең көймәсе комга терәлгәч, Әхмәтҗан партбилетын тотып атты, ә Нурулла — юк. Җитмеш җиде ел буе халыкның аңына тамчылап күмәк хуҗалык итүне сеңдергәннән соң, бөтенесен янә өр-яңадан, өр-яңа биттән башлауны килештермәде. «Ни өчен шултиклем кан коелды, көч түгелде соң, үткәнне җиңел генә сызып ыргытырга мөмкин булгач, — дип фикер йөртте ул. — Кыйбланы Ленин идеясе белән алыштырдылар, хәзер янә Ленинны инкяр итәләр — маена чыдаша алмый власть бүлешкән түрәләр аркасында халык нигә иза чигәргә тиеш?!»

Әхмәтҗан әнә, бөтен кешене аптыратып, үз акчасына мәчет салдырды. Мәчетенә үзен-үзе имам-хатыйп итеп тәгаенләде. Саруы кайнады Нурулланың. Бергә пионерга, комсомолга кергән чакларын хәтерләде. Немецка плен төшкән Гыйндулланың егерме елдан соң кайтып төшүенә караганда да Әхмәтҗанның хыянәте көчлерәк үртәде күңелен. «Бушбугаз, тутыккан флюгер!» — дип атады ул элекке дустын. Хәер, чын дус булдымы ул Нуруллага берәр заман? Теге чак бит, өчәүләп Илекле кыр түбәсенә баргач, шул Әхмәтҗан алды бит аның бугазыннан... Әй хәтер!.. Уйласаң уелып китмәле. Әнә җырдагы:

> Уйламый гына йөрием —
> Уйласаң кыен була, —

дигән кебек.

...Ул хакта һич кенә дә уйларга яратмый Нурулла. Әле, Илекәйгә барып кайткангамы, тынычлана алмый җәфалана. Хәтере яңарды. Зиһене дә һичкайчан булмаганча ап-аяз.

Әйе, Нурулланың тальянкасы теге чак бакча буенда утырып калды, ә алар, бала чакларындагы кебек тезе-

лешеп, Илекле кырга менеп киттеләр, Алда Әхмәтҗан. Боты озын — адымы зур. Аннан кала — Хәтирә. Иң артта Нурулла. Гыйндулла, гадәттә, сипкелле килешле борынын тарта-тарта, Хәтирәгә кушылып атлаучан иде. Ул юк. Үзе булмаса да, Нурулланың түш кесәсендә теге блокнот ята — әсир көндәлеге.

Тауга сөйләшми менделәр. «Минем барлыкны онытырга ярамый!» дигән кебек, таулар артыннан кинәт кояш калыкты. Калыкты да тирә-якны күзне чагылдырырлык яктыга күмде. Елгалар көмеш каештай ялтырады, күзләрен мөлдерәмә тутырган күлләр балкыды, иген басулары, көтүлек, чабынлыкларны уратып алган таулар күгелҗем сызык булып офыкка ялганды. Сагынудан, туган ягын бер күрергә зар-интизар булудан, хисләре тулышудан йөрәге кысылды Нурулланың. Яшьтән җырлагач, гармунда да уйнагач, андый чакларда күңеленә һәрчак җыр сүзләре килә:

Туган илкәемә кайтыр идем,
Аякларым талса, мүкәләп...

Кайтты Нурулла! Инде ул моннан беркайчан да, бер җиргә дә китмәячәк. Хәтирә дә янында гына. Кулын сузса, куллар кулга, иңнәр иңгә тоташыр кебек. Әхмәтҗан арырак тора. Нурулланың шикләре буш, ахры, алар бер дә гыйшык тотып йөргән кешеләргә охшамаган.

Бөтенесе дә Нурулланың үзеннән тора. Әнә теге чакта да, фронтка киткәндә, Гыйндулла кесәсеннән йөзек чыгарды да Хәтирәнең бармагына кидерде. Ә бит Хәтирә кич уйнарга чыкканда, нәкъ тә Нуруллага гына аталгандай итеп:

Гармунчының исемнәре
Гармун каешларында.
Беребез көн чыгышында,
Беребез баешларында, —

дип җырлаган иде. Хәтирә чаярак булган саен, Нурулла ыграк җебеде. Кыенсынып, рәтләп сөйләшә алмас хәлгә җитте. Ә бүген ул үзендә ниндидер ярсу, башбирмәс тәвәккәллек тоя. Менә бу кайрак ташларны учына кысса, көл итәр кебек. Әхмәтҗан белән бушаткан теге ярты да сәбәп булгандыр инде, Нурулла тимерне кызуында сугарга булды. Бармаклары, үзе дә сизмәстән, Хәтирә бүләк иткән ал кулъяулыкка кагылды. Ничә еллар әле

өмет булып сөйдереп, әле газап булып көйдереп кесәсендә яткан ефәк тукыманы тартып чыгарганын үзе дә сизми калды:

— Менә, Хәтирә, ядкяр әйләнеп кайтты.

Хәтирә ни дә булса әйтеп өлгермәде, Әхмәтҗан авыз ерды:

— Ну, Йомры-ы-ы, ну даёшь!

— Синең шикелле мин качып йөрмәдем, Әрсезҗан. Ачыктан-ачык икебез алдында әйтәм: чык миңа, Хәтирә!

— Нурулла?! — Хәтирәнең күгелҗем күзләре зурайды, нәфис йөзенә алсулык йөгерде дә кинәт агарды.

— Мин синнән бер ел элек кайтсам да, ул сүзне әйтергә кыймадым. — Бурлаттай кызарган Әхмәтҗанның йодрыклары укмашканга охшаган иде.

— Әйтер идең.

— Нәрсә... «Әйтер идең»... Минем кулъяулыкка йөрәк сурәте төшерелмәгән, вот нәрсә!

— Сез... аны да беләсез. — Хәтирә кыяга тотынды да җай гына чүгәләде. — Егетләр...

— Кемнекенә йөрәк чигелгән — ул юк!

— Туктагыз! Сез нәрсә!.. — Хәтирә сикереп торып урталарына басты. — Сез нәрсә?! «Юк» дип әйтергә ничек телең әйләнә, Нурулла?!

— Чөнки беләм.

Әхмәтҗан Нурулланың якасыннан борып алды:

— Син нәрсә... беләсең?!

— Минме белмим?! — Әхмәтҗанның Хәтиргә ялагайланып нигезсез бушны сөйләве Нурулланы отыры ярсытты. — Ә бу, — ул Әхмәтҗанның кулын алып ташлады да кесәсеннән теге блокнотны тартып чыгарды. — Ә бу нәрсә?

— Нурулла! — Әхмәтҗанның тавышы ысылдап чыкты. — Бу ниш-ш-ләвең синең, Нурулла!

— Бүген төне буе җиделе лампа яктысында икәүләп Гыйндулла исемле әсирнең көндәлеген укымадыкмы? Йә, әйт, укымадыкмы?

— Ә-ә-сир... көндәлеген?! — Хәтирәнең күгелҗем күзләрендә соры таплар куерды да күзе тоташ кара төскә керде. — Әсир... Әсирлек... Ә мин... хат ташыйм! Шушы авылга килгән йөз дә утыз өч үлем хәбәрен мин алып кайттым. Гыйндулладан кайчан да булса бер хат килер дигән өмет яшәтте мине. Шул өмет хакына туңсам туңдым, үлем кичеп йөреп, хат ташуымны дәвам иттем.

Авыр тынлык урнашты.

Нурулла иренен тешләде: үзе яраткач, хисләре шартлар чиккә җитеп тулышкач, Хәтирәнең кичерешләрен, бу еллар аралыгында аның ни уйлап яшәвен искә алмаган шул. Ах шул дуамаллык! Шушы дуамаллыгы аз яндырмады аны... Әхмәтҗан, читкәрәк китеп, кыяга утырды. Тәмәке кабыздылар.

— Эх! Хәтирә... — Нурулла үксегән кызны юатырга сүз таба алмый җәфаланды. — Гафу үтенү белән дә... әйткән сүз аткан ук инде... Минем кызулыкны беләсең бит инде...

— Хафаланма, Нурулла, әниең сиңа кәләш әзерләп куйган бит.

— А ты замолчи!

— А ты заткнись!

— Егетләр... болай ярамый... Без бит классташлар, дуслар. — Хәтирә бер минут эчендә олы хатынга әверелгәндәй тоелды. Әллә чәчләре дә көлсу төскә керде... Иреннәре дә...

— Гафу ит, Хәтирә...

— Кайтыгыз, сез кайтыгыз...

— Ә син? — Әхмәтҗан үзен иркенрәк тота. Әлбәттә, ул бит Нурулла хәлендә калмады: серен чишмәде. Абруен саклап калды.

— Мин... — Хәтирә тау башына омтылды. — Мин әнә кайда тиклем барам әле.

— Анда нишлисең? — Әхмәтҗан аңа, балага эндәшкәндәй, йомшак эндәште.

— Кыр кәҗәсенә әвереләм! Кыр кәҗәсен күрсәгез, атмагыз, егетләр, ул мин булырмын. Кү-үп бәрәннәремне ияртеп, таштан ташка, кыядан кыяга сикереп йөрермен!

Ул китте. Әхмәтҗан ачу чәчкән карашын Нуруллага текәде, шуннан:

— Кабахәт, — дигән сүзне сыгып чыгарды.

— Мин пыскып яшәргә күнекмәгән!

Авылга икесе ике сукмактан кайттылар. Ә иртәгесен Хәтирә авыл Советына буш почта сумкасын тапшырды. «Ат ихатада, кереп алыгыз», — диде. Яңа вазифада тәүге эш көнен башлаган Нурулла кызга башын күтәреп төбәп карарга батырчылык итмәде. Бу аның Хәтирәне соңгы күрүе булыр дип кем уйлаган? Кыз хәбәрсез юк булды. Кемдер аны район үзәгендә, кемдер калада күреп калган, диделәр. Хәтта таң атканда Илекле кыр буенда да күрүчеләр булган, имеш. Ул, ахры, хәтта элеккегә караганда да сылуланып киткән.

Тормыш бер урында тормады. Урак бетүгә, Нурулла Зәкиягә өйләнде. Күздә әнисен җирләде. Хәтирәнең сагышын да, әнисен югалту кайгысын да җилдән житез, ефәктән йомшак Зәкия белән басты. Беренче уллары тугач — Куандык дип, икенчесе тугач, Сөендек дип исем кушты. Малайларына шатлыклы исемнәр кушсалар да, тормыш, үкенечкә каршы, гел куанычтан да сөенечтән генә тормады. Куандыкны Чехословакиядән тимер табутта кайтардылар. Олатасы, гитлеризмны дөмектерәм дип, шунда баш салды. Ә улы? Тыныч вакытта Совет Армиясе сафына озатты да инде аны Нурулла! Бу корбанның хакын Нурулла аңламады. Сөендеге Әфганга эләкте. Иттурагычтан үткән кебек туралып, чат яра булып кайтты улгынасы. Өйләнде, Гәрәй туды, тик гомере кыска булды Сөендекнең: яралардан мантый алмый дөнья куйды. Бер Гәрәйгә торып калды Нурулла. Ни теләсә, шуны алдына куйдылар, иркәләп үстерделәр оныкларын. Үзсүзле, аумакайрак малай булды ул. «Тормыш — үҗәтләр өлеше», — дип үзен юатты Нурулла. Артыграк кәеф-сафа корган чаклары да булгалый. Әнә әле Семён белән типтерә. Семёны да чит кеше түгел түгелен, бергә үстеләр. Беренче класска да бергә барган иделәр. Әй тормыш! Күпне күрде Нурулла, күпне кичерде. Күктәгенең үз янына алырга ашыкмавына караганда, күрәчәкләре әле һаман бар микән? Әмма теге ядкярне югалтмады.

— Менә ул. — Нурулла киштә башындагы документлар саклаган тартманы алды. — Менә ята аның яшьлеге, тәүге мәхәббәте истәлеге. Вакыт каралтмады аны, уңдырмады. Зәкия дә «кемнән», «кайдан» дигән сүзләре белән җанын кыймады. Яраткан йөрәктә ялган юк — Зәкия Нурулланы ничек бар, шулай кабул итте. Өлешенә язган җылылыкны азсынмады — барына шөкер кылды, тату яшәделәр.

— Олатай, чигүле кулъяулыкмы? — Янына килеп кергән турунының тавышына Нурулла дертләп куйды.

— Әйе... Әллә кайчангы ядкяр. Сугышка киткәндә бер кыз бүләк иткән иде...

— Синең Зәкия оләсәйдән башка мәхәббәтең булдымыни, олатай?

— Әй балам... Ир-егетләр берәүне ярата, икенчегә өйләнә. Ул миннән генә калмаган!

— Ә мин, олатай, яратканыма гына өйләнәчәкмен, тик аның белән генә бәхетле һәм... синеке шикелле озы-ы-ын гомер кичерәчәкмен!

— Юраганың юш килсен!

— Олатай, мин монда гына ятыйм әле... Теге урыс белән әти кыздылар гына!

— Ят, балам, ят... Мине бүген йокы алмый... Ә урыс дигәнең, ул бит әтиеңнең кордашы, Ыстапанның улы. Ят, балам, ят...

Илекәй яту белән йоклап та китте. Һә-әй, яшь чакта йокы тәмле була ла ул. Нурулла кулъяулыкны кире тартмасына салмады, пинжәгенең эчке кесәсенә тыкты. «Тугызында Илекәйгә барганда шушыны күрсәтеп кызык итәм тегеләрне», — дип уйлады. Элек уртак яр сөю аркасында талаштылар, хәзер аларны шул уртак сөю берләштерә түгелме? Әй гомер!

Нурулла утны сүндерде.

* * *

Кордашларының көтмәгәндә килеп чыгуы Гыйндулланың ялгызак тормышына яңалык кертте. Немецка әсир төшкән, җитмәсә, егерме ел үткәч кенә кайтып төшкән бәндәне беркем дә колач җәеп каршы алмады. Олы туганнары юк, алардан калган яшь-җилкенчәк аны танымый, әнисенең өе җимерелгән. Соңгы елларда аны Хәтирә алып кайтып караганын әйттеләр. Хәтирәнең өе сакланган иде, болдыр янындагы таш астында ачкычы да ята икән. Бөтенесе дә элеккечә. Җыйнак кына, хатын-кыз кулы белән җыештырылган өй. Иясе генә юк. Үзенең өе яшәрлек булмагач, Гыйндулла шушында төпләнде. «Хәтирә кайтып төшсә, күз күрер», — дип уйлады ул. Кызның авылдан ни өчен чыгып киткәне аның өчен һаман сер булып калды. Соңрак авылның эчкечесе Сәхәбетдин, Әхмәтҗан белән Нуруллага җаны көйгәнгәдер инде:

— Харап иттеләр кызны, — ул бер артына, бер алдына карап алды, — Нурулла белән Әхмәтҗан кордашларны әйтәм. То берсе, то икенчесе ияреп йөрсәләр дә өйләнмәделәр. Хәтирә позордан качты. Авылны шуңа ташлады.

— Кеше ышанмасны, энем, чын булса да сөйләмә, — диде моңа каршы Гыйндулла. — Мин Хәтирәне белмимме?

— Мин, агай, кеше сөйләгәнне сөйлим. Теләсә кемнән ишеткәнче, юньле кешенең авызыннан ишет дип әйтүем.

Нәрсә диләр әле син яшәгән илдә? Артыгын ычкындырсам, теге ни... Пардон!

— Мин яшәгән илдә, — Гыйндулла Сәхәбетдиннең кулын борды. — «Пардон»нан башканы да беләләр, — аннары исерекнең арт ягына типте. — Башкача күземә күренмә.

Аксый-аксый олаккан Сәхәбетдиннең:

— Нимес! Фашист! Предатель! Хранцуз! Капиталист! — дип кычкырынганы әллә ни тиклем вакыт ишетелеп торды.

Газаплы юллар, әрнү тулы еллар үтеп сагынып кайткан туган ягы аны менә шулай каршы алды.

Кордашлары Әхмәтҗан белән Нурулла да әллә ни якты йөз күрсәтмәде.

— Тә-әк, — дип сузды бу вакытта инде озынторык егеттән нык гәүдәле, калын җилкәле, авыр карашлы ир уртасына әйләнгән Әхмәтҗан. — Сине нинди эшкә куярга? Каравылга — ярамый. Әсирлектә булгансың. Авыр эшкә яраклы түгелсең икән. Син, Гыйндулла, өйдә эшлә. Әнә кошчылык фермасына каз оясы үр, камыт-дуга, чана, арба яса. Шуннан да уңае булмас. — Шуннан ул Хәтирәнең өенә күз йөртте. — Монда күченгәнсең икән... Ну ярый, саклап тот инде өй кирәк-яракларын. Бәлки, кайтыр...

Гыйндулла батырлыгын җыеп сорап куйды:

— Хәтирә кая китте?

— Әйтмәде.

— Берәрсе җәберләдеме?

— Син нәрсә?!

— Аптыраганнан.

— Сиңа гына аптырамыйлар. — Әхмәтҗан төртмә сүзе белән Гыйндулланың авырткан җиренә төртелде дә ишекне дөмбердәтеп япты.

Нурулла белән очрашу да шул чамалы булды.

— Кайттың булдымы?

— Кайттым.

— Фашистны тукмый алмагач, ичмасам, иртәрәк кайтып, колхозны күтәрешсәң! Әзергә без дә хәзер!

— Нәрсә, колхозны күтәрдек, хәзер полный коммунизм димәкчеме?

— Син нәрсә беләсең, Гыйндулла?! Хәзер нәрсә ул? Сугыштан соң ат юк, трактор юк, машина юк. Сабанга үзебез җигелдек! Бичәләрне җиктек! Ат урынына, үгез урынына — бичәләрне! Понимаешь?! Син, понимаешь,

кайту белән Хәтирә өенә барып кергәнсең — кияү егете. Рөхсәт сораган юк, әйткән юк.

— Рөхсәт? Кемнән?

— Миннән! Понимаешь, миннән! Авыл Советы председателеннән. Илекәй авылының Совет хөкүмәтеннән!

— Сорадым мин рөхсәт...

— Кемнән?!

— Хәтирәдән... Йөрәгемнән... Мин илемә йөрәгем кушуы буенча кайттым, Нурулла кордаш. Хәтирә өенә дә йөрәгем кушуы буенча күчтем.

— Хәтирә юк.

— Хәтирә бар. Ул, — Гыйндулла йөрәге турысын күрсәтте, — ул менә монда.

Шулай очраштылар, шулай аерылыштылар. Шуннан соң бер-берсен урап үтәргә тырыштылар, очрашырга туры килсә, күзләрен яшерделәр.

Гыйндулла башыннан үткәннәрне кешегә сөйләмәде. Авыл халкы болай да берне биш итәргә ярата. Кемгә кирәк аның үткәне? Кемнең итәгенә ут төшә, шул яна бит. Янмаган белми. Белгән сөйләми — менә шул.

Илгә кайткач, иң тетрәндергәне Хәтирәнең авылдан чыгып китүен ишетү булса, икенчесе үзенең фамилиясен үлгәннәр исемлегендә — обелискта күрү булды. «Илекәев Гыйндулла Хәйбулла улы». Обелиск каршысында исен җыя алмый торганда, Нурулла кордашы сүз кушты:

— Үкенәсеңме?

— Нәрсәгә?

— Кайтканыңа!

— Юк, тамчы да үкенмим.

— Һы... — Нурулла обелиск плитәсенә калай савытлы буяу утыртты, кулына пумала алды. — Үзең юасыңмы әллә...

— Нине?

— Исем-шәрифеңне...

— Торса ни булган?

— Кайтмасаң торыр иде. — Нурулла кара буяу белән Гыйндулланың исемен буйый башлады. — Тере кешене сугышта ил хакына башын салганнар белән бергә бутап булмый...

— Бүгенге көн белән генә хөкем итмә — тормыш бит дәвам итә!

Нурулла эшен бетерде дә китте. Әлбәттә, бер буяу да — хәтта кара төстәгесе дә — мәңгелек түгел. Вакыт буяуны түгел, ташны кимерә, вата, ваклый. Буяу ашалып

бетте. Бронза хәрефләр калды. Гыйндуллага да мулла кушкан, кәгазьгә теркәлгән исеменә караганда «Поп Гапун» дигән кушамат ныграк ябышты. Балалар бит аяусыз. Шулар такты исемне. Әлеге дә баягы чит илләрдә яшәп, телләр белеп кайтуы сәбәп булды. Мәктәптә йә немец, йә француз, йә инглиз телен укыталар. Укытучысы йә авырып китә, йә күчә, шул чакта Гыйндуллага киләләр. «Аз гына укытып тор, хәлгә кер!» Гыйндулла бик куанып ризалаша. Укытучыларының белемнәре дә шулчаклы: берәр нәрсә тәрҗемә иттерергә булсалар, Гыйндуллага киләләр. Гыйндулла өчен тәрҗемә эше чүп тә түгел. Тик менә кушаматы...

Муенына тәрене әҗәл түшәгендә яткан Жанна такты. Алтын һәм платиннан эшләнгән бик борынгы тәре иде ул.

– Ул сине саклар. Ядкяр булсын. Төсем итеп так, – диде бичара хатын, тынын көчкә алып. – Ул олатамны, азактан атамны саклаган, хәзер сине сакласын.

Үлгәннәр белән бергә моргка чыгарып ташланган Гыйндулланың тере икәнен шәйләп, алып кайтып өендә тотып, мең газап белән терелтә алган Жанна аның өчен изге җан иде. Сүзен кире какмады, бүләген кабул итте. Жаннаны җирләгәч, аның өч баласын карап үстерде Гыйндулла. Алар үсеп аякка баскач кына иленә кайтуны кайгырта башлады. Кайтты. Хәтирәне, җир-суын, илен-телен сагынып кайтты. Хәтирәнең өендә ул озак яши алмады – колхоз совхозга әйләндерелгәч, үзәккә – Яңавылга күчерделәр. Гыйндуллага да баракның бер бүлмәсендә урын бирделәр. Уңыш җыю вакытында барак шаулап тора, йә берәр төзелеш барса, эшчеләр белән тула, җанлана. Ә күп чакта бөтен барак берүзенә кала. Каравылчы да, слесарь да, мич ягучы да бер Гыйндулла. Азактан, соңгы елларда барак җимерелде, аңа совхозның бәләкәй бер өен бирделәр. Ялгызлыктан аны китап уку коткарды. Совхозга әйләнгәч, хөкүмәт отпуск бирә башлагач, Гыйндулла районга, башкалага барып, Хәтирәне эзләтеп карады. Файдасы булмады.

«Илкәемә кайтып, ун ел яшәсәм, үлсәм дә үкенмәс идем», – дип уйлый торган иде ул Франциядә яшәгәндә. Менә кайтканына да кырык елдан артты, ә үлем килми әле. Хәтирәне күрүдән дә һаман өметен өзмәгән, кордашлары белән дә аңлашмаган. Өчәр мең чакрымнар еraклыкта яшәгәндә алар якынрак булган икән. Көндезләрен Гыйндулланың – хәтерендә, төннәрен төшендә иде алар.

Ярый, Гыйндулла әсирлеккә эләкте, ләкин үз теләге белән түгел бит! Сугышның аяусыз дәреслеген үз күзләре белән күргән Әхмәтҗан белән Нурулла моны аңларга тиеш кебек иде. Бәлки, бу җан өшеткеч салкынлык Хәтирә өчен үч алудыр? Алай дисәң, өчесенең бер кызга гашыйк булуында да беркем дә гаепле түгел. Дүртесе бергә уйнап үсте. Бер урам балалары. Үсә төшкәч, дуслык мәхәббәткә әверелде. Хәтирә ни өчендер Гыйндулланы якын күрде, үз итте. Теге икәү матуррак та, көчлерәк тә, чаярак та иде бит. Җебеклеге өчен җәлләдеме икән ул Гыйндулланы? Җәлләве яратуга әйләндеме?

— Сине... җәлләгәндер ул, — дигән иде бер тапкыр Нурулла, Гыйндулла авыл Советына ниндидер справка өчен килгәч. — Син бәләкәйдән җәлләтә белдең.

— Кемне әйтәсең?

— Хәтирәне.

— Хәтирә мине... яратты.

— Ә менә моны укыса, яратыр иде микән? — Кызарып бүртенгән Нурулла Гыйндулланың алдына блокнот ташлады.

— Бу... минем... син...

— Синеке, синеке! Мин алып кайттым Германиядән. Нюрнбергтан!

— Ул... ничек... Мин бит аны югалткан идем... Лазаретта үлгән дип чишендергәннәр. Туберкулёз белән.

— Беләм, беләм! Укыдым. Вәт, Гыйндулла, очраклы хәлләр булмый, диләр. Ә менә синең белән бер авылда тууым, бер класста укуым, бергә сугышка китүем, хәтта бер үк кызга гашыйк булуым, азактан очраклы рәвештә казармада калуым һәм теге Кавказ кешесен очратуым — болар очраклы хәл түгелме?!

— «На кой чёрт ты мне сдался?» дип әйтәсеңме. — Блокнотны әйләндереп-әйләндереп торган Гыйндулла, башын күтәреп, Нуруллага туп-туры карады. — Син әйткәннәрнең берсе дә очраклы түгел, Нурулла.

— Түгел?!

— Түгел.

— «Бергә үләсебез бар әле» дияргә уйламыйсыңдыр бит?

— Ә нигә? Булуы ихтимал. Тормыш бер бүген белән бетми бит, Нурулла.

Әсирлек салкынлыгы бәрелеп торган блокнотын алып, Гыйндулла тышка чыкты. «Менә ул!» — Гыйндулла, көндәлеген алып, тәрәзәгә якын килде. Күзлеген кигәч,

лупа алды. Бу дәфтәргә ул сирәк кагыла. Бу кечкенә генә блокнотка Казанда офицер мәктәбендә укыганнан, аннан фронтка киткәннән алып Нюрнберг концлагерендагы көннәре һәм француз армиясеннән азат ителүе теркәлгән. Көненә бер яки ике җөмлә язылган — гамәлдә тормышын чәлпәрәмә китергән язмышы. Бу еллар аны яшәешнең икенче ярына ташлады. Ул ярдан Нурулла-лар, Әхмәтҗаннар, Хәтирәләр ярына кире әйләнеп кайту ай-һай авыр. Ә бәлки, мөмкин дә түгелдер?

18.11.43. Ягылмаган суык вагонда Германиягә җибәрделәр. Нюрнбергка килеп җиттек. Юлда тәүлек булдык. Иң якын иптәшем — Уфа егете Сазонов үлде. Палаталарга урнаштырдылар.

19.11.43. Ашказаны авырта. Баракка күчерделәр.

22.11.43. 7 нче блокка күчерделәр, командаларга бүлделәр. Эшкә йөри башладык.

27.11.43. Күкрәк нык авырта. Серб врачы Т. Б. Ц. диагнозын куйды. Йөткерәм.

28.11.43. Эшкә чыгардылар. Беренче тапкыр икмәк ашаттылар.

30.11.43. Тагы авырыйм. Бу юлы лазаретка барырга хәлем булмады. Бер иптәш тә авырый. Немецлар килеп тукмады безне. Безнең өчен бөтенесен дә кичке ашсыз калдырдылар.

2.1.44. Паммиргитейхка китерделәр. Баракка урнаштырдылар, берәү качты. Безне аерым баракка — төрмәгә бикләделәр.

3.1.44. Штелле посёлогына күчерделәр. Кашаев белән дуслаштык. Бәрәңге пюресы ашадык.

17.5.44. Ике кешене бер богау белән богаулап, Германиянең көньягына озаттылар.

20.5.44. Ногбургка килеп җиттек. Эш бик авыр. Рельс, шпал төйибез һәм бушатабыз.

24.5.44. Каты чирлим. Санчастька озаттылар. 3 көннән эшкә чыгардылар.

25.7.44. Вагоннарга төяделәр.

27. 7. 44. Людвигбургка килдек. Бик чирлимен, йөткерәм, ашказаны, бил нык авырта.

15.8.44. Санчастька салдылар.

12.9.44. Гитлер хакында җыр өчен арест.

3.10.44. Гитлерга каршы пропаганда өчен арест.

10.11.44. Төшемдә әниемне, Хәтирәне күрдем. Алар миңа икмәк суза — минем алырга буем җитми. Состав кузгалды. Әнием егылды. Хәтирә елый. Күзеңне сөрт,

дип, Хәтирә миңа үзе бүләк иткән кулъяулыкны суза. Кулъяулык җилгә очты. Авыр тойгы белән уяндым.

Шунда җиткәч, Гыйндулла күзлеген салды. Авыр укыла. Вакыт үтүдән хәрефләр тоныкланган. Шул авыл Советында Нурулла бу блокнотны Гыйндуллага тапшырганда: «Хәтирәгә укытмаганга рәхмәт әйт», — дигән иде. Чынлап та шулай: Гыйндулланың әсирлектәге тормышында, бер-ике тапкыр качуын исәпкә алмаганда, бернинди батырлык юк. Чир дә ачлык, янә авыр эш. Тукмалу. Курку. Сугышка китсә дә, бер фашистны да үтермәде. Теге кулъяулыкны да саклый алмады. Авырудан хәлсезләнгән, яшәү билгеләре булмаган Гыйндулланы, французлар вагоннан бушаткач, җирләргәме, яндырыргамы уйлап чишендергәннәр. Калган хәлләрне ул әсирләр блогында эшләгән Жанна сөйләве буенча гына белә. Менә шундый язмыш. Шулай да кордашларының 9 Майны бергә Илекледә каршыларга чакыруы сөендерде. Күңелен май яңгыры юып үттемени. Май яңгырыннан соң җир яшәрә, тугай чәчкәләргә күмелә. Кордашлары янында әңгәмәләшеп утыру — аның күптәнге хыялы.

Гыйндулла торды. Ике тәрәзә арасына эленгән календарьдан гадәттәгечә пөхтәлек белән тагы бер битне ертып алды, радионы ачты:

Әллә инде бик нык яратканга
Юлларымда сине югалттым. —

Шушы җырдан агылган сагыш тәэсирендә электр чәйнеген куйды. Җырга чәйнек чыжлавы кушылды. Кызганыч, ул җырлый белми. Җырлый белмәгән өченме, күңеле ныграк сагышлана. Аннан яшьләре керфек очына эленергә дә күп сорамый. Тәрәзә пәрдәләрен җилпетеп җил исүендә дә ул Хәтирә кулларын күрә. Әнә ул җырны да Хәтирә җырлый кебек. Әйе, Хәтирәсе аны бик нык яратты. Яшьлек дуамаллыгы аркасында Нурулла белән Әхмәтҗан гына моны сизмәде. Аларның һәр икесе үзләренең ярата белүен генә яратты. Бер-берсеннән Хәтирәне үлеп көнләштеләр, Гыйндуллада үзләре белән ярышырлык көч күрмәделәр. Алар өчен Хәтирә — мәктәптәге иң сылу кыз. Сылу кызның күңелен яулар өчен Нурулла тырышып-тырышып гармунда уйнарга өйрәнде. Әхмәтҗан исә спортка көч салды. Чаңгыда беренче килә дә ялт итеп Хәтирәгә карый, югарыга сикерә дә күзләре белән Хәтирәне эзли. Хәтирә аларны тыңлый,

кул чаба, ә күңеле белән Гыйндуллага елыша. Җиденчедә укыйлар иде. Бишенче дәрес бетте, ә Хәтирә урыныннан кузгалмый. «Әйдә, Хәтирә, — ди Әхмәтҗан, — бер якка кайтабыз бит». «Мин өйгә бирелгән эшләремне эшләп кайтам», — ди Хәтирә. Үзе иреннәрен нык кыскан, чырае агарган. «Әйдә, Әхмәтҗан, йомыш бар. — Гыйндулла дустын тышка өстерәде. — Үзең беләсең, кайтса, Хәтирә бушамый. Математикадан үзенә «икеле» чәпи яздылар бит бүген».

Әхмәтҗан кайтып китте. Гыйндулла кире керде.

— Хәтирә...

— Син ишекне тыштан терәтеп тор, мин күлмәгемнең артын алга киям дә...

Гыйндулла аңлады. Кайтырга кеше аз йөргән аскы урам аша чыктылар, Хәтирә алдын сумкасы белән ышыклап атлады.

Хатын-кыз корына керүенең тәүге көнен Хәтирә шул рәвешле Гыйндулла белән каршылады.

Моннан башка да серләре сыйды Хәтирәнең Гыйндуллага. Физкультура укытучысы аны дәрестән соң очрашуга чакырып язу биргән. Аптыраган, курыккан Хәтирә суга барышлый Гыйндулла янына килде:

— Менә кара... Укы әле, укы!

— Укыдым.

— Нишләргә? Миңа нишләргә?!

— Ал да утка як!

— Ул тагы язачак...

— Директорга бирсәк...

— Аны эштән чыгарачаклар. Аның бит гаиләсе бар. Баласы, хатыны...

— Ә син хатны хатынына бир!

— Ничек? Килешер микә-ә-ән...

— Хатынлы көйгә яшь кызга бәйләнмәскә яхшы булыр.

— Әйе шул, җитмәсә, укучысына! Их, Гыйндулла, син дә шулай булырсың микән?

— Нинди? — Гыйндулла көлемсерәп карады. — Яле, кара әле миңа: мин шундыйга охшаганмы?

— Син, Гыйндулла, беркемгә дә охшамагансың.

Гыйндулла аның кулыннан чиләкләрен алды.

— Куй, Гыйндулла... үзем!

— Мин куй түгел...

— Чынлап әйтәм.

— Әллә суны юри дә ташып буламы?

Бер сәбәпсез, юктан кызык табып көлештеләр. Рәхәт иде икесенә дә: күктә кояш, җирдә ямь-яшел бәбкә үләннәре, янында салкын чишмә. Әй җырлый иде шул чишмә, әй чыңлый иде! Аның моңын башкалар ишетте микән? Әллә ул бары тик Хәтирә белән Гыйндулла өчен җырладымы? Әле дә бар ул чишмә. Илеклегә барып, тыңлап утырганы бар Гыйндулланың аның моңын. Тик чишмә җырында хәзер сагыш көчлерәк, аңа Хәтирә көлгәндәге көмеш чыңнар җитмәгәндәй. Ә менә аның салкын суы Гыйндулланың күңелен баскандай: «Хәсрәтемне басар балам да, сөйгәнем дә юк, ләкин чишмә бар, — дип юата ул үзен. — Хәтирәнең эзләрен саклаган җир бар. Шушы бәхет түгелме?»

* * *

Әхмәтҗан өенә кайтып тормаска булды. Сарайдай өйнең бушлыгы күңеленә үткәннәрнең авыр сулышын өрә. Мәчеткә кеше килә. Әле дә кереп, әрвахлар рухына дога укытып чыктылар. Дөньяви йомыш белән киңәшкә килүчеләр дә бар. Картлыгында япа-ялгыз булырмын дигән уй аның башына да кереп чыкмаган иде. Ә бит сугыштан кайткан чагында аны нигезендә әти-әнисе каршы алды. Атасы, иртәрәк кайткач, Әхмәтҗан кайтуга дөньясын бөтәйтеп, тыныч кына юлга салып өлгергән иде. Кордашлары арасында иң отышлы хәлдәгесе Әхмәтҗан булды, шуңа да кайту белән бишкуллап колхоз эшенә чума алды. Тырышты Әхмәтҗан: чәчүлекләрне иркенәйтте, колхоз малларына абзарлар салдырды, ат малын ишәйтте, яшелчәчелекне көчәйтте, бал кортлары алды, җиләк-җимеш бакчасы булдырды, кош-корт үрчетте. Эш куллары җитмәү ике кулсыз итте, мәктәп укучыларын ярдәмгә чакырды. Алган табышлар миллион сумнар белән үлчәнсә дә, ул җитәкләгән «Кызыл Октябрь» һаман «убыточный»лар исемлегендә калды. Йөрәге әрнеде Әхмәтҗанның: тагын ничек көчәнергә була? Юк, авыл хуҗалыгы техникасына хаклар бик югары, ә авыл хуҗалыгы җитештергәнгә хаклар, киресенчә, бик түбән. Ә менә бодайны тарттырып, он итеп сатса, хәтта икмәк пешереп, шәһәрдә үз кибетен булдырса? Иттән, җиләк-җимеш, яшелчәдән консерва ясаса? Сөттән май аертып, эремчек эретеп, корот кайнатып сатса? Шул уйларын ул райкомга барып сөйләде бер. Тыңладылар. Ахырдан

чак эшеннән бушатмадылар: күз җиткәч, келәтләрен чип-чиста итеп себертеп, игенне алып киттеләр. Әхмәтҗан тешен кысты: гектарыннан егерме биш-утыз центнер бодай алган колхоз кыш буе фуражны хөкүмәттән кыйбат хакка сатып алып ашатты. Колхоз производствосы Әхмәтҗанга цирк атын хәтерләтте: әйләнгәне — бер түгәрәк, үсешкә хөкүмәт үзе комачаулый, дөресрәге, хөкүмәткә үсеш кирәкми, ә үзе план артыннан план җибәрә. Аннан ары, социалистик йөкләмә алуны таләп итә. Сөрерлек җирләр беткәч, су буендагы куакларны, каенлыкны кистеләр, сазлыкларны корытып, инешләрне юкка чыгардылар. Икенче яктан, сугыш бетәр дә, иркен тын алырбыз дип өмет иткән халыкка да җиңеллек килмәде. Хөкүмәт бер чиктән икенче чиккә ташланды, кайберләрен бетереп, авылларны эреләтте. Хәтта бер чорны бодайны бетереп, кукуруз чәчәргә кушты. Фәрманнарның акылсызлыгына исе китте Әхмәтҗанның. Ярый әле янында атасы булды. Тезгенне нык тотты. Чираттагы социалистик йөкләмәдән соң үртәлеп, күтәрелеп-бәрелеп, читкә китәм дә барам, дип кайткан улына:

— Беткә үч итеп, тунны утка ягып булмый, улым. Сиңа халык күз төби. Урыныңа ятлар килер. Ул авыл кешесен син аңлаган чаклы аңлармы? Җиңелне кем сөйми? Кайчан да булса кайтмыйм дисәң дә, бер кайтырсың — намусың газапламасмы? Авылдан качсаң да, үз-үзеңнән качып булмый, улым. Башыңны эшләт. Уңышны ничек бар, шулай яздырма. Ул сиңа нигә кирәк? Бер ел, мактап, медаль бирерләр, икенче ел, шул санга җиткерә алмасаң, башыңа сугарлар. Крәстиян халкы әзрәк хәйләли белергә тиеш. Түрәләр күңелен уйласаң, халык ач кала.

— Кесәмдә партбилет йөртеп, алдашу юлына басыйммы, әти?

— Партбилет «Иман шарты» түгел. Үзең кара...

Менә шулай коммунист намусы һәм тормыш дөреслеге арасында өзгәләнеп яшәде Әхмәтҗан. Озак өйләнмәде. Хәтирә кайтыр дип көтте. Карт буйдак исеме алган Әхмәтҗанның башлы-күзле булуына ярасының гел чиләнеп торуы, төзәлмәве сәбәпче булды. Бәйләтергә дип медпунктка барды. Яңа фельдшер җибәргәннәр, дип ишетүен ишеткән иде, ишекне ачып кергәч, аптырап калды: аны бер аягына протез кидерелгән яшь хатын каршы алды.

— Председательме? — диде ул саңгыраурак тавыш белән.

«Тарта», – дип уйлады Әхмәтҗан, ә күңелендә беренче караштан бу хатынга карата жәлләү тойгысы уянды.

– Кайсы фронт?

– Икенче Украина. Ә сез?

– Белоруссия.

Башта, болдырга чыгып, тәмәке көйрәттеләр. Әхмәтҗан аның яшәү шартларын төпченеп сорашты, ярдәм вәгъдә итте. Шуннан соң аягын бәйләтергә ешрак йөри башлады. Ә беркөнне бөтенләй кайтмады.

Иртән кайткач, әнисе аңа, шелтәле карашын ташлап:

– Нәрсә, улым, чулак атаң каршына аяксыз бичә алып кайтырга булдыңмы?

Әхмәтҗан әнисеннән мондый сүз көтмәгән иде.

– Ә үзең ничек... атайны... иреңне бер кулсыз көе кабул иттең?

– Ул минем ирем!

– Әлфия – минем хатыным!

– Йа Ходай! Картайган көнендә әниеңнең күз яшен алмасаң...

– Әлфия аягын танцыда калдырмаган, әни! Сугыш кырыннан мине дә бер Әлфия кебек кыз күтәреп алып чыкты.

– Тәүбә, әстәгъфирулла! Ул бит сугыш!

– Без, әни, сугышта яраланган иптәшләребезне калдырып качмадык.

Менә шулай килеп чыкты. Әхмәтҗанның Әлфиягә өйләнүен әнисенең отыры каршы булуы тизләтте. Яралы кош иде Әлфия. Сугышка тиклем балет училищесында укыган. Укытучылары аңа сәхнәдә якты киләчәк, баш әйләндерерлек уңышлар юраган. Сугыш башлангач, ике абыйсы, әтисе фронтка киткәч, өйдә кала алмаган, медсестралар курсын үтеп, алар артыннан көнбатышка җибәрелгән. Медальләре, орденнары бар Әлфиянең, тик аягы юк. Абыйсы да, әтисе дә яу кырында калган. Әнисен җирләгән. Япа-ялгыз калгач, шәһәрдән башын алып чыгып киткән.

Яралы кош... Яралыга игътибар күбрәк кирәк иде. Җитмәсә, шәһәр кызы, авыл халкының гасырлар дәвамында тукылган көнкүреше, уе, холык-фигыле аңа ят. Тел белүе дә чамалы иде. Әхмәтҗан әти-әнисен җирләгәнче ике арада яшәде: кунуы – Әлфиядә, көнкүреше – әнисендә. Эш муеннан. Ике ул тапты Әлфия. Әхмәтҗан иңгә-иң терәп аларны караша, тәрбияләшә алмады. Әнисе Әлфияне өенә якын җибәрмәде, үзе дә бармады. Яшь

балалар, эш, җиде ят кешеләр, мәңге колхоз эшеннән бушамаган ир.

— Тоскливо мне, Ахмат, ой как тоскливо! — дия иде ул бик сирәк тыныч булып торган көннәрендә. — Иногда мне на голову приходит мысль, зачем я выжила?

— Син бит хәзер әни кеше. Ничек алай уйларга мөмкин? Мин аңламыйм!

— Я ведь, Ахмат, обе ноги чувствую. Хочу порхать, витать над сценой, как раньше...

— Уф, Әлфия, перестань. Миңа яңа ит заданиесе килде. Яз көне нинди ит булсын?!

— Ит, ит... Пропадаю я, Ахмат...

Әлфия чынлап та чирле иде. Әхмәтҗан аның сулышыннан спирт исе килүен еш тоя — менә үзе әйтте.

— Балалар бәләкәй... Возьми себя в руки!

— Когда ты рядом — мне ничего. Но тебя я почти не вижу. Мне страшно...

Әлфияне ике сабые белән төп йортка күчергәндә, ул инде бу котылгысыз чиргә нык кына бирешкән иде. Спирт булган җирдә йөрмәсен дип, Әхмәтҗан аңа эштән чыгарга киңәш итте. Аннан соң, фельдшерны авыл халкы да исерек күрә, аның эчүе хакында сүз йөртә башлаган иде.

— Дөрес түгел! — диде сүз җиткерүчеләргә. — Ул чирле, ләкин эчкече түгел!

Эштән чыгарса да, авыл хатын-кызларының билгеле бер төркеме Әлфиянең «хәлен белергә» йөри башлады. Берничә тапкыр, көндез кайтып кергәндә, Әхмәтҗан аларны үз күзе белән күрде. Шелтәләде, өйдән куып чыгарды. Ә беркөнне Нурулла авыл Советына чакыртты. Илекле кырдагы теге сөйләшүдән соң, Нурулла белән аралары якынаймаса да, эш буенча сөйләшми булдыра алмадылар. Кәнсәләрне җыештыручы хатын: «Сине силсәвит чакырта!» — дигәч, Әхмәтҗан сагая төште. Көненә әллә ничә очрашалар бит, йомышы булса, нигә әйтмәгән?

— Килдем, түрә, — диде Әхмәтҗан, бусага аша атлар-атламастан. — Кантон хәзрәтләре кебек, чакыртып кына аласың...

— Әйдә әле, Әхмәтҗан, утыр. — Нурулла урыныннан торды, сигарет сузды, үзе тәрәзә янагына сөялде. — Күптән уй бар иде сөйләшергә.

— Сузма, эш — муеннан.

— Эш эш белән. Вакытны сатып алмыйбыз. Ни бит,

син, понимаешь... Бичәңне әйтәм: кайчан эчүен туктата?

— Аңламыйм...

— Эш аңлаудан үткән, Әхмәтҗан Хәйбуллович, бөтен авыл сөйли. Кешене эшкә чыгарып булмый. Утау мәле бит! Әнә председатель бичәсен кара, ди эчкән хатын-кыз.

— Минем хатын гарип. Аны утауга да, печәнгә дә куып булмый.

— Ну бит ул башкаларны котырта! Өенә бичәләр җыя, эчү оештыра! Чарасын күрергә кирәк!

— Күрермен. — Үзе эчкән кеше кебек чайкалып чыгып китте Әхмәтҗан. Башына кан савып кайтып керсә, Әлфия исерек, янында үзе кебек хатыннар.

— Мой Ахмат! Мой спаситель. — Исерек Әлфия урыныннан торырга итте, протезы тыңламады, мәтәлеп барып төште.

— Якын килмә! — Әхмәтҗан аның аркасына чыбыркы белән сыдырды. — Икенче эчәсеңме? Әйт, эчәсеңме?

Ярсыган иде ул. Бу хәл нәрсә булып бетәр иде — малайлары, елап, арага керде. Шуларны кочаклап, үзе дә елады Әхмәтҗан.

Тормышның яме китте. Әхмәтҗан Әлфияне тыштан бикләп йөри башлады. Җитмәсә, көз явымлы килде, үскән уңышны җыеп булмый. Районнан сводка сорап җанны алалар. «Болытны туктатырга мин Ходай түгел. Лафетка чаптырсак, иген шыта башлаячак, чак кына көтик, миңа үземчә эшләргә ирек бирегез», — диде Әхмәтҗан аларга. Шундук уполномоченныйлар килеп җитте.

— Саботаж! Партбилетыңны өстәлгә сал, Илекәев!

— Мәгез, — диде Әхмәтҗан. — Кадалып китегез. — Менә шулай төште ул вазифасыннан. Аңгы-миңге булып кайтып барганда Гыйндулланы очратты.

— Нәрсә, Әхмәтҗан, балтаң суга төшкән?

— Булганга төшә. Синең төшерер нәрсәң булмагач, ике дөнья — бер моржа.

— Кемнең «балтасы» күпме икәнен бер Ходай белә. Хәер, син коммунист бит әле. Ходайга ышанмыйсың.

— Бүгеннән мин коммунист түгел.

— Гаҗәп...

— Чын. Шаяру кайгысы юк.

— Сүз ирке генә түгел, намус ирке дә булмаган җәмгыятьтә, бер уйласаң, гаҗәпләнерлек бернәрсә юк.

Әхмәтҗанның саруы кайнады:

— Ә син яшәп кайткан җәмгыятьтә сүз ирке бар идеме? Намус ирке бар идеме?

— Юк иде дип әйтергә телем бармый, Әхмәтҗан, булмаса, мин илемә әйләнеп кайта алмас идем.

— Предатель! — Әхмәтҗанның авызыннан әчке ярсуы шул сүз булып бәреп чыкты. — Кысылма безнең идеологиягә! Билетым булса да, булмаса да, мин — коммунист!

Әхмәтҗанның әйткәне Гыйндулланың иң авырткан җиренә тиде бугай. Ул да калышмады:

— Бер хатынына баш була алмаган кеше илгә баш була алмый, Әхмәтҗан. Учти!

— Сам разберусь!

— Вот и разбирайся!

«Разбираться» итәргә соң булып чыкты. Әхмәтҗан ачу-ярсу белән кайтып кергәндә, өен ялкын ялмаган иде. Тыштан бикләп киткән иде ул Әлфияне. Малайлар йоклагач, уятмаган иде. Ничек, нәрсәдән ут чыккандыр — ачыклый алмадылар. Әхмәтҗан, хатынының, балаларының кара янган сөякләрен кочаклап, җир тырнап елады, аларны җирләде.

Колхоз өй салып бирде аңа. Әмма тормышына кот кунмады. Председательлектән бушагач, көтүче булып китте. Сарыклар да үзе. Күңелен укуга салды. Партиянең тимер тырнагыннан котылгач, дини китаплар күренә башлады. Әхмәтҗан аларга сусаган кеше комсызлыгы белән ябырылды. Рухи кыйбласыз — партиясез калган авылдашларын Ходай кушканча яшәргә өндәде. Булган акчасына мәчет салдырды. Дөнья кайгыртыр эше юк хәзер. Ахыр килеп, ул Гыйндуллага үтә каты бәрелгәнгә, хәтерен калдырганга үкенде. Әмма терсәк якын да, тешләп булмый. Әхмәтҗан Гыйндулланы «предатель» дип атаса, Нурулла партбилетын ташлаган Әхмәтҗанны «предатель» диде. Нурулла үзен, партбилетын хәтта башкалар ташлаганда да ташламагач, әллә кем итеп тоя. Герой. Өчесендә өч дәреслек. «Ходай өчен генә дәреслек бирәү, — дип уйлый Әхмәтҗан. — Үзенең пәйгамбәрләре аша бирелгән дәреслек — эчтән тазарыну».

Әхмәтҗанның кулы янә теге кулъяулыкка кагылды.

Утта янмады, суда батмады шушы ядкяр. Яшьлегеннән калган бердәнбер истәлек. Дөньялыкта аның зиһенен биләгән берни калмады кебек. «Үзең белән ахирәткә нәрсә алыр идең?» дип сорасалар: «Кулъяулыкны, — дияр иде

ул. — Илекле кырның — туган төягемнең — исен саклаган бердәнбер юанычг».

Вакытында ул медальләрен дә алды, орденнарны да такты, мәгәр Хәтирәне сөю куанычыннан да зуррак куанычны беркайчан кабат кичермәде...

* * *

Нурулла йокысыннан, гадәттәгечә, иртә уянды. Ачык тәрәзәдән кыек кәрнизенә оялаган күгәрченнәрнең гөрләгәне, өйалды бакчасында тургайлар чыркылдашканы ишетелә. Су буенда казлар каңгылдашканы да колакка чалына. Төнлә йоклый алмый яту үзенекен иткән — көтү киткәнгә охшый. Әниләреннән аерылган бозауларның ара-тирә бакыруы гына ишетелә. Әнә сепаратор гүли. Күрәсең, килене Гайшә сөт аерта. Илекәй кинәнер инде. Ярата ул каймакны. Иркә бала бит туруны. Төпчек. Әнә ничек рәхәтләнеп йоклый ул. Нурулла, якынрак барып, күңеле туйганчы карап торды: кашлары куе кара, төз борынлы — болары әнисеннән. Гайшә килене бик чибәр. Ә менә иреннәре — атасыныкы, чәченең куелыгы да аннан. Ә бер карасаң, Илекәй Нурулланың яшь чагын да хәтерләтә. Атлап йөрүе, сабырсызлыгы анык. Нурулла дуамалрак булды инде, Илекәй төпле, акыллы балага охшаган. Яшьлек иләслеге бетсә, менә дигән ир булачак. Авылны яратуы яхшы. Авыл хуҗалыгы академиясенә керде, укуымны дәвам итәм, ди. Төпле бала, төпле. Әнә кичә дә, иптәшләремне күрәм дип, клубка чабып чыгып китмәде: олатасы янына кереп йоклады. Гәрәй эрерәк, һавалырак. Үҗәтлеге көчле. Бу әнисенә тарткан, юаш, инсафлы. Уйлап карасаң, Зәкиясен җирләгәненә дә күпме гомер үтте. Гайшә килене авырсынмый гына карый аны. Нәрсә эчим, нәрсә ашыйм дими, кисә — киеме юылган. Килен каенана туфрагыннан яралган дигәннәре дөрес, ахры. Гайшә нәкъ Зәкия. Аргысыннан биргесе якын Нурулланың. Ярый ла соң тормышы шулай гына тәмамланса.

Шулай да бу немец машинасы шом салды әле күңеленә. «Минеке», — дип шаяртып әйтүе микән Гәрәйнең? Каян килгән аңа шундый машина! Әнә «Нива»сы менә дигән. Пенсиясен җыеп алып биреште шул машинаны. Илекәй кайтса дип салып куйган маясы да бар Нурулланың. Укысын әле, машина качмас. Ул үзе авыл хуҗалыгы

техникумын гына бетерде, анысын да — читтән торып. Әхмәтҗан әнә, арты ныклы булгач, колхозны биш-алты ел җитәкләгәннән соң, Чиләбедә икееллык Югары партия мәктәбен бетереп кайтты. Уку белән генә түгел, яши белергә кирәк. Укыды-укыды да үз теләге белән партиядән чыкты Әхмәтҗан.

Гәрәйне дә укытты Нурулла. Читкә чыгып китмәсен дип, авыл хуҗалыгы институтына җибәрде. Мал врачына укыды оныгы. «Син мине көчләп укыттың!» — дип, кайчак җене куба Гәрәйнең. «Мин сине көчләп булса да авылда калдыра алдым, ә менә үзең малайларыңа хуҗа була белмәдең», — ди моңа каршы Нурулла.

Нурулла, катасын эләктереп, тышка чыкты. Симунның шофёры иртәчел икән, машинасын ялт иттереп юган, эчен тазарта, сөртә. «Пөхтәлек ярата бу», — дип уйлады Нурулла.

— Доброе утро, сынок!

— Утро доброе.

— Как спалось?

— Слава Богу, как мёртвый.

— Еще бы, воздух у нас такой... чистый.

— Да, это так. Что правда, то правда.

Сөйләшеп киттеләр. Теге немец машинасында Симун үзе рульдә килгән. Себердән икән. Шофёры Егорның әйтүенә караганда, Ыстапанның улы, әлеге Симун, бик бай кеше булып чыга. Алтын приискалары бар диме? Ыстапан авылдан ике чемоданын, хатынын һәм шушы Симунны җитәкләп чыгып китте бит. Байлык кайдан? Ә-ә... Хатыны үлгән. Икенчегә өйләнгән. Бизнесмен кызына. Менә ничек... Берне биш итә торган кеше иде бит Ыстапан. Симун атасына охшаса, ай-һай, баер шул. Менә ничек ул тормыш. Кайчандыр, Пугач явыннан соң, аларның ата-бабалары, җәзадан качып, шушы Илекәйгә килеп сыена. Нурулланың олатасы сөйләгән иде. Кузьма исемле урыс крестьяны була ул. Әнә шул яу вакытында таныша алар Нурулланың бабасы белән. Карт үзенең җирен бүлеп бирә, Кузьма тегермән дә салдыра, бик тиз баеп китә, ахырдан Нурулланың бабалары аңа хезмәт итә башлый. Революция, гражданнар сугышы берсен дә аямый. Череп баеган Кузьма нәселен дә Себергә җибәрәләр. Авыл халкы аларны инде оныта да башлаган була, әмма, Кузьманың оныгы дип, Захар исемле егет кайтып төшә. Захар Нурулланың атасына килә. Ул мыеклы, какча урыс мужигын да хәтерли Нурулла, аның

аксыл чырайлы ябык хатынын да хәтерли. Нурулланың атасы, өй салышып, аларны башка чыгара, мәгәр уллары Степан, халык аны үзенчә Ыстапан дип йөртте, Нурулла белән гел бергә уйнады. Хәтерендә: алар балыкка йөрергә яратты. Берчак Нуруллага ике балык эләкте, ә Ыстапанга — юк. Борынын мыш-мыш тартып килгәч, Нурулла моны кызганды.

— Мә, — диде ул. — Берсе сиңа булсын.

Ыстапанның йөзе ачылды:

— Ә син, Нурулла, тегесен дә миңа бир!

— Нигә?!

— Бераүдән ике яхшы. Сиңа ул бер балык нигә?

— Әйе шул, — диде Нурулла, — ал. Чынлап, ул бер балыкны мин нәрсә эшләтим?

Соңгы елларда Симунның бу якларда күренгәне булмады, ә Ыстапанны үлгән диделәр. Нигә килгән Симун? Алай бай булгач, ни йомышы төшкән аның оныгына?

Нурулла беразга Илеклене дә, андагы флажокларны да онытты. Шофёры Егордан төпченеп карады, тегесе: «Дело хозяйское, я человек маленький», — дию белән чикләнде. «Өйрәтелгән, — дип уйлады Нурулла. — Түрәләрнең шофёрлары бичәләре белмәгәнне белә».

* * *

Гәрәй бастырылып уянды. Өстенә ташлар ишелә, борын тишекләренә, күзләренә туфрак, ком тула, ниндидер ыңгырашкан тавышлар ишетелә, ә ул үзе һаман югарыга үрли. Тау ишелә, ә ул шул тауның башына менеп котылып калырга тели...

— Уф! — Ул башын тотып торып утырды. Тәмам уянганына, әле генә кичергән коточкыч күренешнең төш булуына ышангач, җиңел сулап куйды, тирә-ягына күз йөртте: өстәлдә кичтән калган ашамлыклар, яртылаш эчелгән аракы, идәндә янә шешәләр, диванда, чалкан төшеп, коры тегермән ташыдай үкертеп гырылдап, Семён Степанович Зацепин, элеккечә әйтсәң, Симун йоклый. Таң аткан. Сепаратор гүли. Әтәч кычкыра, тавыклар кыткылдаша, саескан шыркылдый. — Нык төшерелгән, — диде ул үз-үзенә. Симунга карап тора бирде. — Каты йоклый. Йә, ярый...

Захар олатасының җирләрен (дөресе, Нурулланың бабасының җирләрен) караштырып, күзәтеп, сорашты-

рып йөри йөрүен, ләкин совет властеның каты чагы. Эндәшеп, сүз әйтеп кара! Тегермәннең дә ташлары гына ята, буа ерылган, келәтләр туздырылган. Тимерче алачыгында бераз эшләгәч, Ыстапанга укырга барырга вакыт җиткәч, Захар авылны ташлый.

Соңрак та аралашты алар. Магнит шәһәрендә металлургия комбинатында эшләгән Захар улын җәйге ялга Нуруллаларга кайтара, «Захар ызнакум» белән дуслык «Ыстапан ызнакум»га, соңрак Степанның улы Семёнга күчте. Гәрәйнең теле «Симун» дип ачылды. Гәрәй Семённан урысча сөйләшергә, Семён Гәрәйдән башкортчага өйрәнде. Нурулла Гәрәй белән Симунның уйнаганын карап торды бер. Тактаны кисеп, әллә трактор, әллә танк ясый болар. Гәрәй берне ясады да тынычланды. Симун икенчесенә тотынды, беткәч, өченчесенә...

— Сиңа нигә шулай күп кирәк? — дип аптырады Нурулланың оныгы.

— Әтием әйтте, — диде Симун. — Берне юкка сана, икене — бергә, өчне — икегә. Белдеңме?

— Белдем.

— Да ничего ты не понял. Если бы ты понял, давно бы ещё и ещё сделал...

Шул Семён ике машинада Яңавылга кайткан хәзер. Әлеге икене бергә санавымы икән?

Өстәлдән «минералка» алып голт-голт итеп шешә авызыннан гына эчте дә калганын битенә койды Гәрәй. Зиһене ачылгандай булгач, аягына басты, өйалдына чыкты. «Иң шәбе, — дип уйлады ул, — күлгә барып су керү». Чынлыкта күл аны мондый хәлдән беренче тапкыр гына коткармый. Авылга иң якыны — сөлекле күл. Суы салкын, таза. Сөлеге бар. Берничәсе тәнгә кадалса, шундук җиңеләйтә, ару да, махмыр бәласе дә ялап алгандай бетә. Ә Семён йоклый бирсен... Шәһәр кешесе озак йоклый. Бәләкәй чакларында да атасы аны авылга китереп киткәндә дә төш җитмичә тормый иде. Ул теге вакытларда гырылдамый торган иде, хәзер янында чыдап ятарлык түгел.

Машиналар урамда. Акбарыс шулар янында йоклаган. Үзенчә каравыллаган. Хуҗасын күргәч, торып киерелде дә кире ятты. Машиналар өчәү. Гәрәйнең «Нива»сы, Семённың «Мерседес»ы һәм «Фольксваген». Немец теленнән әзрәк аңлый Гәрәй. «Фолькс» — «халык», «ваген» — «арба» инде. Халык арбасы. Хәтәр! Бөтен халык миллионнан артык торган шундый «арба» ала алса! Аның ике

улы хәзер ничәмә ел Себердә эшли, мәгәр «Хундай»дан уздыра алганнары юк. Авылга кайталар, халык шуларга хәйран булып хәле бетә. Гәрәй авыл Советы рәисе башы белән «Нива»дан югары үрелмәде. Бер уйласаң, «син үзеңне яратмыйсың!» дип, Симун дөрес әйтә. Мәктәптә укытучылары: «Үз-үзен яраткан кеше эгоист була, бу бик яман сыйфат!» — дип кисәтә килделәр. Кайсысы дөрес?

Гәрәй «Нива»сын кабызды. Акбарыс, гадәтенчә, кереп утырырга чамалады. Хуҗасы кунакчыллык күрсәтмәгәч, кире урынына китте.

Су буе тыныч. Бөтен дөнья яшеллеккә күмелгән. Шомыртлар чәчәккә бөреләнгән. Кыр үрдәкләре бакылдый, кошлар чыркылдый. Кояшның җылы нурлары белән уянган табигать сөю, гыйш-гашрәт кичерешләренә чумган. «Туйларны нишләптер көз ясыйлар, туй яз үтәргә тиеш», — дип фикер җебен сүтте Гәрәй, чишенә-чишенә. Су салкындыр, алай дисәң, алар бала чакта беренче май-дан башлап су керә торган иделәр.

— О-о-о! — Салкын су тәнен өтеп алды. Бер-ике чумгач йөзеп китте. Гәрәйне кеше туена килеп кергән әрсез кунактай күреп, үрдәкләр өркеп качты.

Күп йөзмәде Гәрәй, ярга чыкты. Аяклары, аркасы дерелдәде, йомшак тастымалга уранып алгач, җылы йөгерде, тора-бара тәне тоташ кызып яна башлады. Рәхәт!

Гәрәй аркасын, инде байтак күтәрелеп өлгергән яз кояшының чагылдыргыч нурларына куеп, җиргә сыенып ятып үскән тал-тирәккә утырды, тәмәке кабызды. Семён кордашы белән сөйләшкән сүзләрне ачыла төшкән зиһене җайлап-әзләп исенә төшерә башлады.

— Тачка понравилась тебе?

— «Фольксваген»ны әйтәсеңме, «Мерседес»нымы?

— Ходай ярдәменнән ташламаса, тегесе дә булыр. Я про «Фолькс».

— Яхшы машина — һәр ирнең хыялы.

— Так в чём дело?

— Ты о чём?

— О том же.

— Ну, брат, — Гәрәй уңайсызлануын яшерү өчен көллеккә иелде, — безнең, Семён Степанович, теге ни... Были бы живу — не до жиру дигәндәй...

— Егерме беренче гасыр, Гарай! Кайчанга тиклем нищенский психология белән яшәргә уйлыйсың?

— Байныкы — фәрман белән, ярлыныкы — дәрман белән. Юрганыңа карап...

— Күп әйттең! Юрганны зурайту синең кулда! Бик бай булсаң, ике улың читтә йөрмәс иде. Бусы да чыгып китәчәк. Авыл кешесенең уртача зарплатасы, знаешь, сколько? Отвечу, сам отвечу: две с половиной тысячи! Курам на смех! Илекәй уедет! Помяни моё слово!

— И что ты предлагаешь?

— Вот что я тебе предлагаю, дорогой кореш: продай мне старую деревню, вместе с горой, как его...

— Илекле кыр.

— Да, Илекле кыр.

— Так те флажки... — Гәрәй аптырап Семён Степановичка туры карады.

— Да, мои ребята. Приблизительный план и обмер сделали.

— Так... А зачем он тебе? Там золота нет.

— Не золото я ищу, золото у меня, — ул йонлач симез бармаклары белән муенын күрсәтте, — во! Син, Гарай, вообще вы все, алтын җирнең астында дип уйлыйсыз, алтынны бит җирнең өстеннән дә табып була! — Семён мае саркып торган ит кисәген, сарымсакка кушып, авызына озатты. — Я там хочу построить горнолыжный комплекс!

— Таулар — во! — Гәрәй, Семённың үзе кебек, бугазына күрсәтте. — Төзе, причём монда Илекле, причём Илекле кыр?!

— Э-э... Ты тут братана своего не перебивай: я один такой комплекс уже построил. Монда җир яхшы. А красота! Оттуда такой вид открывается, что в мире нигде больше не встретишь! И всё это даром... пропадает... Я тут такое заворочу!

— На счёт вида ты прав. Син бит сурәт төшерә идең. Пейзаж. Илекле кырның өстенә менеп басасың да көннәр буе мольбертыңа текәләсең...

— Да, да! Между прочим, они, эти картины дали мне эту идею! Через картины я мечтал открыть эту красоту всему миру! Но... зачем создавать картины, когда можно их купить? В общем, как говорится, я пошёл по другому пути: нужна твоя бескорыстная братская помощь...

— Озадачил ты меня... Там... самое главное — не деревня. Деревни нет. Олатайның хибарасы гына утыра.

— Так в чём вопрос? Авыл халкына эш була. Илекәйне беру в управляющие...

— Там... кладбище. Зират.

— Но это же очень... старый, забытый зират!

— Картлар барыбер шунда җирләүне сорый...

— Мёртвые, как говорится, налогом не облагаются, и есть и пить не просят. Там кости, кости — не человек.

— Кайсы яктан карыйсың бит... Авыл психологиясе икенчерәк бит, Семён дус.

— Да, икенчерәк. Ә син үзгәрт! Әнә Уфада элек кала уртасында зират иде. Помнишь? Хәзер өстеннән трамвайлар җилдерә. Беркемнән дә сорамадылар — җир белән тигезләделәр и баста! Хәзер кем белә аның элекке зират икәнен?! У тебя, Гарай, средневековое мышление, а сам руководитель! Өченче тысячелетиедә яшәгән һомо сапиенс, а уровень мышления как у неандертальца... — Семён кискен хәрәкәт белән папирос кабызды. — Как говорила твоя покойная бабушка Закия: ташка үлчим!

— Не горячись, кызма! Может сиңа икенче җирне карарбыз, матур урыннар бездә бер Илекле генә түгел.

— Не надо! Без караган инде, үлчәгән. Монда бер генә тауны — Илекле кырны шартлатырга, калганы — майлаган сымак. Затрат будет меньше, да и города близки, дороги построены. Понимаешь? Мои экономисты на счёт этого не ошибаются, как говорится, в этом деле собаку съели.

— Да...

— Так что — по рукам, братан, и машина твоя! Это, как говорится, прелюдия.

— Дай подумать...

— Чапай тоже думал.

Гәрәйнең уйларын күлгә очып төшкән өч пар аккош бүлде. Икесе кара. Бу кара аккошлар күлдә ике-өч ел эчендә генә күренә башлады. Элек табигатьтә мондый хәл булмагандыр, югыйсә аккош дип аталмаслар иде. «Ахырзаман җитте. Ахырзаманда яшибез!» — ди Әхмәтҗан мулла. Ахырзаманның аккошы да кара микән? Әйе, бер Гәрәй генә ак калып үзгәртә алмастыр заман кушуын. Шушы заман кешесе булгач, заманча яшәмәү мөмкин түгелдер, ахры...

* * *

Илекәй йокысы туеп уянды. Көньякка караган тәрәзәдән кояш кыеклатып бүлмәне яктырта. Бабасының урыны буш. Карт элек тә иртәчел иде, шул гадәтен ташламый икән. Урам ягына караган тәрәзә ачык. Тыш-

та пыш-пыш сөйләшәләр. Тәрәзә буенда эскәмия бар. Олатасының кояшта изрәп утыра торган урыны. Күрәсең, кемнәрдер шунда җыелган. Илекәй, торып, тәрәзә янына барды.

— Ну чё? Уломал?

— Против денег кто устоит?

— Неужели?

— Ну дык...

— Молодец... Я думал, не согласится. Кладбище, память, обелиск — всё такое... Кстати, кладбище огорожено добротным металлом.

— Наверно: вчера я машину Гарая видел у ворот «Вторчермет»а...

— Лихо!

— Тому, как расстаётся с прошлым, остаётся смотреть только вперёд. — Кинәт искән җил бер капкачны шап иттереп ябып куйды.

— Тсс.

— Чего боишься?

— Даже знакомая собака может быть бешеной. — Семён Степанович каерылып өскә карады. — Доброе утро, егет!

— Утро доброе. — Илекәй бөтен гәүдәсе белән алга сузылды. — А отец где?

— Он где-то здесь...

Ул арада әнисенең тавышы ишетелде:

— Әйдәгез чәйгә! Өстәл әзер...

— На завтрак Гарай обещал жареный хариус, пошли!

— Хариус?! Откуда? — Шофёр эт тугрылыгы белән мөлдерәгән күзләрен хуҗасына текәде.

— Их здесь до черта! — Семён хуҗаларча горурлык белән йонлач кулын Егорның аркасына салды. — Тут есть такое, что твоим дедам — помещикам не снилось.

— Ё моё...

Алар атасының өенә ашыктылар. Илекәй, колагына чалынган сөйләшүне ни дип юрарга белми, әкрен генә киенә башлады.

* * *

Кинәт суытып җибәрде. Төньяктан искән салкын җил яшь яфракларны бөрешергә, ачылган тузганак, үги ана чәчкәләрен суыктан корышырга мәҗбүр итте.

Кар бөртекләре дә төшкәләде. «Хәерсез, безнең план барып чыкмас микән, болай булгач? — дип эче пошты Нурулланың. — Көн бозылса, элекке яралар әрнеп сызлый башлый, теге икәү дә шул минем хәлдәдер инде...» — Шулай уйланды Нурулла. Илекәй күрше авылдагы класслашына китте. Әллә шунда кунак булып ята, әллә кияүләп тә йөри. Авыл клубына чыкмавында бер сәбәп бар. Җитмәсә, теге немец машинасын тоттырып куйды аңа Симун. Гәрәй каршы төшмәкче иде, Симун кырт кисте:

— Пусть катается, пусть красуется. Молодым везде у нас дорога!

— Молодой да ул, но ведь он еще зелёный, — дип, инде куәте кайта башлаган каршылыгын белдерде ата кеше.

— Это мы так думаем. Человек армию почти отслужил. Не так ли?

— Так-то оно так. — Гәрәй иңбашын кашыды. — Ярар, тәртипле йөре, улым.

— Пока! Пока, олатай!

Илекәй китте. Гәрәй, Симун, Егор да озак тормый чыгып олактылар. Икешәр-өчәр көн кайтмастан югалдылар. Нурулла килененнән төпченеп караган иде, анысы:

— Мин, каенатам, ирләр эшенә кысылмыйм. Гәрәеңне беләсең, тәртипне баштан шулай куйды, — диде.

— Анысы шулай. Зәкия каенанаң... мәрхүмә... ул да шулай булды бит. «Үзең беләсең, атасы» дияр иде, берәр нәрсә сорасаң.

— «Ирләр эшенә беркайчан кысыласы булма, килен» дип, миңа да гел тукып торды ул, — дип җөпләде аны Гайшә, — мин Илекәй өчен генә борчылам. Кеше машинасында чыгып китте.

— Илекәйнең башы бар, килен. Җиңел-җилпе малай түгел ул, — яраткан оныгы хакында сүз чыккач, Нурулла ирәеп китте. — Без бит теге чак нимес машинасында Илекәйгә барып әйләндек, зиярәт кылдык, әбилескегә бардык. Малай төпле, килен. «Өйне шушында салам» ди. Булыр бала — биләүдән. Бик күңелем булып кайттым...

— Әй, каенатам, өен дә салыр, дөньясын да көтәр иде — эше бармы соң әле?

— Эшне кеше үзе таба. Уйсыз егет түгел. Укуын гына бетерсен. Минем дә әзрәк җыйганым-иганәм бар... Менә Симунны әйтәм, безнең Гәрәйгә аның нинди йомышы төште икән?

— Ир-ат янына ир-ат килә инде, каенатам.

Ике-өч көн суыктан качып ята биргәч, Нурулла түзмәде — Әхмәтҗанга китте. Көне җитеп килә. Сигезе барып кунсалар, тугызы — бәйрәм. Көн яманы китәр, әзерләнергә кирәк.

* * *

— Көн яманы китәр, адәм яманы гына бетмәс, — диде Нурулланы өенең чоланына чыгып каршы алган Әхмәтҗан. — Әйдә, түрдән уз. Мин үзем чыгып әйләнимме дип тора идем. Менә мичкә яктым әле. Өй җылынды, югыйсә суык җелеккә үтә башлады.

— Шомырт салкыны, — диде Нурулла, мичкә якынаеп. — Шомырт чәчәк атканда, эре канатлы кошлар җылы яктан кайтканда гел шулай була. Бүген, шөкер, кояш күренә әле. Иртәгәләргә аязмас микән?

— Мин дә шулай уйлыйм. Гыйндуллага шылтыратам. Килсен, бергәләп уйлашыйк: кем нәрсә ала, кайчан, нәрсә белән китәбез...

— Киңәшле эш таркалмас, — диде Нурулла да, мич буендагы кәнәфигә уңайлап утырып алгач. — Матур яшисең икән. Уңайлы гына...

— Безнең хәзер шул инде: ашау да йоклау.

— Мәчетең бар бит.

— Мәчет, әйе, Аллага шөкер. Көннең күп өлеше шунда үтә. Янә... китаплар. Күз генә начарланды, озак укып булмый, яшьләнә. Син нәрсә белән көн үткәрәсең?

— Минем ни... Ялгызым түгел бит. Бергәләп кайнашабыз. Әле менә Илекәй армиядән кайтты.

— Теге җилле машинада йөргән егет Илекәймени? Мин әйтәм, бу әллә генерал чинында кайтканмы дип торам.

— Атасын... Үзенеке түгел бит ул. Теге... тегермәнче Кузьманың улы Ыстапанның оныгы Симун. Гел сурәт төшерер иде. Искәрдеңме?

— Әйе, әйе... Сезнең ызнакумнар. Шул килгәнмени?! Авылда нindидер имеш-мимеш сүз йөри...

— Нинди сүз?

— Әллә... Мин бит сүзгә... гайбәт тыңласаң, гөнаһы үзеңә була дип, бик колак салмыйм, Нурулла. Ил авызына иләк каплап булмый бит, кеше кирәген дә, кирәкмәгәнен дә сөйли.

— Белмим, кордаш, нәрсә ишеткәнсеңдер, тик Гәрәйнең, хөкүмәт эшеннән бушап, ял иткәне дә юк. Бу арада бөтенләй өйгә кайтып керми.

— Шулайдыр... Әйтсәм әйтим: «Илекле кырны силсәвит Гәрәй сатып ята» дигән сүз йөри. Хәтта тауда нәрсәдер эшли дә башлаганнар, имеш. Үпкәләмә, Нурулла, ишеткәнемне әйтүем.

— Ярый, ярый, — Нурулла башына, битенә ут капкандай эсселәде. — Менә барабыз бит. Үз күзебез белән күрербез. Буштыр ул. Буш сүздер — безнең зират шунда да инде. Аннан соң... Илекле кыр... Әманәт тау бит ул безнең...

Тиздән, катасын кыптыр-каптор сөйрәтеп, Гыйндулла килде. Өчәүләп чәйгә утырдылар. Бүтәнчә беркем дә ул темага кагылмады.

* * *

Язгы көн — ярты акыл, дип бушка әйтмәгәннәрдер. Сигезенче май көнне кинәт җылытып җибәрде. Шуны гына көткән кебек, шомыртлар ап-ак чәчкәгә төренде, нигез буена, кызыл аркаларын ялтыратып, җиңгәчиләр килеп чыкты, күбәләкләр күренде. Нурулла Илекәйнең кайтып керүенә дә куанып бетә алмады.

— Озакладың, балам... Классташыңны күрдеңме соң?

— Күрдем, олатай. Аны да... сеңлесен дә... — Илекәй соңгы сүзне әйтте дә колакларына тиклем кызарды.

— Ә-ә... сеңлесе бармыни?

— Әйе! Быел урта мәктәпне тәмамлый. Уфага медка барам, ди. Отличница!

— Матурмы?

— Матур, олатай. Мин аны электән беләм... хат та язды ул миңа...

— Исеме ничек?

— Олатай, андый исем хәзер юк ул. Бер анда гына. Хәтирә.

— Хәтирә?!

— Әйе, олатай. Матур исем бит! Җыр кебек. «Хәтирә тирәккәем! Тыным белән тартып алып булмый шул, йөрәккәем!»

— Бу җырны син дә беләсеңмени?

— Әй, олатай! Матур кызга күзең төшсә, әллә ниләр белерсең!

— Хәтирә... кызык. Безнең авылда Хәтирә исемле кыз яшәде... Хур кызыдай сылу иде... Без, егетләр, һәммәбез дә аңа гашыйк идек.

— Вот-вот! Әйттеләр! Туган килеп чыга алар. Аның истәлегенә Хәтирә дип кушканнар исемне.

— Менә ничек... — Нурулланың күзе яшьләнде. Түш кесәсеннән теге ал ефәк кульяулыгын чыгарды. — Тормыш дәвам итә, Илекәй. Бәхетле булыгыз, балакай.

— Андый кульяулык, олатай, менә... миндә дә бар. — Илекәй кесәсеннән энҗе кушып чигелгән кульяулык чыгарды. — Армиягә киткәндә бирәм дип чиккән идем, кыймадым, дигән була.

— Син минем юанычым, Илекәй.

— Их, олатай! Әле дә син бар. Серләремне кемгә сөйләр идем, син булмасаң... Олатай, тик син озак яшә инде. Синсез мин бит тормышны күз алдына китерә алмыйм.

— Әй улым, улым-балакаем... Ауган агач тамырларына яшеренә. Син барда мин дөнья белән тыныч күңел белән хушлашам.

— Хәтәр әйттең, олатай. «Ауган агач тамырларына яшеренә». Син миндә яшәвеңне дәвам итәсең булып чыгамы?

— Шулай, балам. Мин бик күптәннән синдә яшим. Инде, улым, мине, кордашларымны Илекәйгә илтеп куй. Төенчегем төйнәлгән. Мылтыкны гына алып чык атаң ягыннан. Кешегә күрсәтмә, сиздермә. Патроннар сал.

— Ул нәрсәгә, олатай?

— 9 Майда салют бирәбез әбилиске каршысында. Без өчебез дә яугирләр. Ил өчен кан койган солдатлар.

— У-у-у... әтием белсә...

— Мин сине тукмактан аз араламадым, инде үзең зурайдың. Аннан... атаңның вакыты да юк шикелле. Табан астына ут капкан кебек йөри...

— Мылтыкны алырмын. Илтеп куям, барып алырмын. Кал дисәгез, янызда калырмын.

— Калу кирәкми. Без бер өч-дүрт көнгә китәбез. Көтүчеләр бар — хәбәр җибәрербез.

— Олатай, бу Семён Степанович белән Егор Ефимович сәер нәрсәләр сөйләште.

— Сәер?

— Әйе, акчамы-ниме... Акчага сатылмаган кеше юк ул, дигән кебек аңлашылды миңа.

— Илекәй, эндәшмирәк тор. Минем колакка да әйлешәйле хәбәрләр ишетелде. Сабыр булыйк, син тик безне Илекәйгә алып барып кына куй.

...Сәгать ярым тирәсе вакыт үткәч, өч фронтовик картны утырткан «Фольксваген» Илекәйгә карап юл алды.

* * *

Илекәй машинаны кинәт олы юлдан ташландык юлга борды.

— Бу бала безнең борынгы юлны да белә икән... — Әхмәтҗан, аптырап, Гыйндуллага карады.

— Мин үзем дә шуңа исем китеп утыра идем. — Тәрәзәдән күзен алмый утырган Гыйндулла алда утырган Нуруллага эндәште: — Малай кайдан белә безнең юлны?

— Һунам гына буйлап берәү килә, мосафирмы икән, кунакмы, дип җырлаганы истә атамның, — диде Нурулла, боларга каерылыбрак карап. — Азагын искә төшерә алмыйм...

— Ә менә без кем, алайса? — диде Гыйндулла, Әхмәтҗанга борылып. — Мосафирмы, кунакмы дигәндәй...

— Безме? — Әхмәтҗанның тәсбих тарткан бармаклары беразга туктады. — Мосафир түгелбез. Кунак дисәң, үзебезгә, яшәп киткән авылыбызга, әрвахларыбыз янына баргач, кунак та түгелбез. Чынлап, без кем соң?

— Без — хуҗа, — диде Нурулла. — Мосафир да, кунак та булмагач, ул хуҗа була. Без — бу җирнең хуҗасы.

Автомобиль каенлык эченнән бара башлады. Өстә Бурлы бия таулары. Әнә Ак сыер яланы, аннан Купец күпере, Мәмилә... Әй, уйлап карасаң, һәркайсысының үз тарихы, үз даны. Һәрберсе тыңлаган кеше өчен олы хикәят, көйле бер әсәр.

Кыш буе өеннән чыкмаган картларның, яшьлегендә йөргән җирләрен күреп, йөрәге җилкенде. Иңнәреннән бер җилкенүдә ике дистәне сыпырып ташлагандай булдылар.

— Нурулла кордаш, җырла әле бер җырыңны?! — Моны Гыйндулла белән Әхмәтҗан икесе бергә диярлек әйтте.

— Һи-и-и... Тавышым булса-а-а. — Шулай да Нурулла тәвәккәлләргә булды:

Әй, Уралым, синнән кисеп алсам
Ат куарлык сары талларны, —
Очларыннан аның тамып кала
Ата-бабаларның каннары...

— Һә-әй, көй икә-ә-ән, — дип, аңа дәрт өстәде Әхмәтҗан. — Тавышың бар әле синең, иншалла.

— Тын кыскарган. — Нурулла тирләгән маңгаен учы белән сыпырды. — Дәрт бар да, теге ни... дәрман азрак.

— Булганына шөкер. Сезнең токым әүвәлдән җырчы бит — Илекәй улым җырлыймы?

— Олатайдан откан бер-ике җыр беләм, — диде Илекәй. — Тик кеше алдында җырларга оялдыра.

— Өйрәнерсең, башың яшь әле. Мин дә башта кычкырып аять укырга да ояла идем. Дөнья өйрәтә ул.

Шушы җирдә, тауга менеп җиткәч, ак каеннар, аккош канатына охшаган сызык ясап, икегә аерылды — алда түбәләре белән болыт айкап, зур бер түгәрәк ясап күккә ашкан таулар дөньясы балкыды. Һушны алырлык, акылдан язарлык матурлык!

— Рәхим итегез, Илекәевләр! Илегезгә китереп җиткердем! — Йөзеннән елмаю китмәгән Илекәй олатасына карады: — Кайда туктыйсыз?

— Өйгә алып бар, — диде Нурулла. — Аш салырга кирәк. Учакка ягарга. Син кайт, балам. Кеше автомобилен алып киттек бит... Йә эзләп чыгарлар...

— Ярый, ярый, олатай. Әзрәк ярдәм итим. Балта алганмын, ичмасам, җитәрлек утын кисеп биреп, су алып кайтыйм.

— Илекәй... — диде Гыйндулла.

— Илекәебез, саумы?! — диде Әхмәтҗан.

* * *

— Монда кемдер йөргән. — Идәндә аунаган буш шешәләргә, бушаган тәмәке, печенье, консерва савытларына карап, Нурулла баш чайкады. — Ичмасам, җыештырып китсәләр...

— Борчылма, олатай! — Илекәй йөгереп йөреп өйне себереп чыгарды, казан астына ут якты, әнисе биргән сарык итен пешерергә салды.

Ул арада чәйнек кайнап чыкты. Нурулла җыеп, бәйләп киптерергә чөйләргә элгән үләннәрен кушып чәй

пешерде. Гыйндулла белән Әхмәтҗан өстәлгә үзләре белән алып килгән ризыкларны куйды. Тышта яз, өйдә кояш, күңел ап-аяз!

– Илекәй, чәй эчеп кит!

– Юк, олатайлар, юл кешесенең юлда булганы яхшы. Минем әле әнием белән, күзгә-күз карап, бер утырып чәй дә эчкәнем юк.

– Йә, ярый, кайт. Аннан килеп алырсың безне...

– Аннан?

– Аннан...

Шулай хушлаштылар. Өйгә тәмле ис таралды – ит кайнап чыкты. Стенада Нурулла белән Зәкиянең, янә улларының зурайтылган рәсемнәре. Тәрәзәләрдә пәрдәләр. Идәндә кулдан сугылган чүпрәк паласлар.

– Болар синең малайлармы? – Гыйндулла лупалы күзлек аша стенага текәлде.

– Иде, – диде Нурулла. – Берсе Чехословакиядән табутта кайтты. Кечесе Әфганда алган яраларыннан мантый алмады. Аннан калган ир бала – бер Гәрәй үсте. Шулай, нәселне бик ишәйтеп булмады, кордашлар.

– Кайгым кайгыларга охшамый, кайгы савытларым бушамый дигәндәй, мин әнә сугышсыз да икене җирләдем, әниләре белән. Эчкечелек корбаннары... – Әхмәтҗан кульяулыгын чыгарды, күзләренә тидереп алды.

– Ул кульяулыкны, кордаш, саклагансың икән. – Нурулла мактанырга форсат тапкан сабый баладай канәгать йөз белән үзенекен кесәсеннән алды. – Менә... минеке дә исән-имин.

Гыйндулла шым гына утыра бирде дә Нуруллага кул сузды:

– Тотып карыйм әле... – Ул кульяулыкны күзенә якын ук китерде, сурәтенә текәлде. – Минекенә йөрәк чигелгән иде. Саклый алмадым.

– Әйе... Гыйндулла кордаш, синең хәл аянычрак. Без, ичмасам, бала сөю бәхетен татыдык, исем-шәрифебез, кайда барма, үзе ишек ачты. Ходай сиңа сабырлык биргән, иншалла.

– Әллә тагын... Мин үземне бәхетсез санамыйм ул. Йөрәгемдә Хәтирәмә, туган туфрагыма сөю бер минутка да сүнмәде. Яраткан йөрәк бәхетсез булмый ул!

– Алай дисең... – Нурулла уйланып утыра бирде. – Менә Илекәй өйләнсә, үзегезне туена чакырам. Өчебез аерым гына минем өйдә утырырбыз. Илекәй киленне

алып кереп күрсәтер. Исеме – Хәтирә. Безнең Хәтирәнең туганы тиешле кешенең кызы.

– Ш-шулай... матур диме? – Әхмәтҗан, бөтен гәүдәсе белән алгарак иелеп, колагын куйды. – Ш-шуны сорадыңмы?

– Кәнишнә, сорадым. Минем Илекәй чибәр түгелгә карыймы соң? Үзе әнә нинди!

– Мин... никах укырмын. – Әхмәтҗан шатланып кулларын угалады.

– Йа Ходай! Авылга кот кайта икән! Сөю коты! – Гыйндулла урындык артына ирәебрәк сөялде. – Тормыш дәвам итә бит, кордашлар! Мин Хәтирәгә дип алган алтын алкаларны бүләк итәрмен...

– Әллә берәр йөз грамм төшерәбезме? – Нурулла пакетка үрелде. – Ул нәрсәне Җиңү көнендә күтәрербез дип алдым мин...

– Юк-юк, башта бүген, ит пешкәнче, кояш баеганчы, зиратка барыйк. Азактан ихтыярыгыз. – Әхмәтҗан моны бик җитди әйткәч, беркем дә карышмады.

– Шулай... дөрес әйтәсең, кордаш, бөтенебезнең дә туганнар шушында бит. Малайларыбыз да, oләсәйләре дә. – Нурулла урыныннан тора башлады. – Күмер төште, казан җай гына кайнар әле...

* * *

Зиярәт кылганчы, авылны урап чыкканчы, байтак вакыт үтте. Һәр өй нигезе янында тукталдылар, анда-монда ялтыраган пыяла ватыгына, серәеп утырып калган багана йә кирпеч өеменә карап, әллә никадәр хәтирә-истәлек сөйләнелде. Өй алларындагы агачлар гына тере. Талы – тирәккә, сирене куаклыкка әйләнгән. Шомыртлар бар, алардан тирә-якка хуш ис бөркелә.

– Тегендә, – диде Гыйндулла, күзлеген туктаусыз ышкып, – Германда, Франциядә, дим инде... яше буыннар исәбе белән үлчәнгән йортлар бар. Һәр йорт – гаилә тарихы. Гаилә тарихы илнекенә ялгана – шулай дәвам итә дә итә. Хәтта вакыт туктап калган сымак. Өйләренә керсәң, әллә никадәр буын элек яшәгән ата-бабаларының портретлары. Безнең ил капитансыз кораб сымак. Кайдан килгәнен, кая киткәнен беркем белми. Авылларны йә ереләтәләр, йә кечерәйтәләр, йә бөтенләй җир өстеннән юк итәләр. Җиргә бер көн халык хуҗа, иртәгәсен ул җир

синеке дә, халыкныкы да түгел. Адәм, дүңгәләк сымак, ары чаба, бире чаба — тукталышы юк.

— Тукталышы әнә, — Әхмәтҗан ияге белән зиратка ымлады, — әле без булган җир.

— Әйе, әле зират бар. Тарихның дөресе — ташларга уелганы. — Гыйндулла тынды. Ары табан, Нурулланың өенә кайтып кергәнче, тавыш-тынсыз атладылар.

Аш өлгергәч, өстәл тирәли утырыштылар. Әхмәтҗан ит турады, Нурулла тәлинкәләргә шулпалы салма салды. Килене һәммәсен хәстәрләгән: шырпыны да, борычны да, тозын да. Әхмәтҗан кружкасына су салды, Нурулла белән Гыйндулла «солдатский сто грамм»да туктадылар.

— Менә... — Әхмәтҗан өй эчен күз уңыннан үткәрде. — «Илеклене күчермим» дип каршы торуыңның файдасын күреп утырабыз. Синең өй булмаса, болай итеп утыру кайда?

— Анысы шулай. Карагач өй бит бу. Әле тагы йөз ел утырыр. Түбәсен генә алмаштырганда...

— Шушы өй өчен силсәвитлектән алдылар инде сине...

— Ә син, — Гыйндулла көлемсерәде, — минем мәсьәлә куелган сессиядә мине яклашмадың, кордаш...

— Минем партбилетны бирүне син дә аңламадың бит... Нәрсә, гомер буе силсәвит булып утырырмын дигән идеңме?

— Юк, мин болай гына, — диде Нурулла. — Арыган идем мин ул эштән. Аның каравы колхозга нинди җимеш бакчасы үстереп калдырдым!

— Үткән эштән төш яхшы, кордашлар. — Гыйндулла икесенә дә сынап карады. — Алайга китсә, мине кем аңлады?

— Ә син пленнан... хет качып карадыңмы? — Нурулла калагын җамаяк кырына сөяде. — Син, кордаш, бу сорауны биргәнгә мине гафу ит. Теге блокнотта ул турыда ләм-мим...

— Аны язмыйлар. Ул минем... — Гыйндулла янә һәр икесенә карады. — Күрсәтсәм, кыен, ну менә уңайсыз... оят булмас микән?

Әхмәтҗан урыныннан тора башлаган Гыйндуллага карап сукранды:

— Син булсаң, оялмас җирдән оялырсың.

— Бигайбә... Үзегез сорадыгыз, үпкәләштән булмасын. — Гыйндулла чалбарын төшерде, шуннан ак ыштанын шудырды да арты белән боларга әйләнде.

— Ташка үлчим! — Әхмәтҗан чытырдатып күзен йомды.

— Гафу ит, кордаш. — Моны әйткәнче үк Нурулланың күзеннән яшь атылып чыкты. — Нигә аны... күптән әйтмәдең?

— Бөтен кешегә артны ачып күрсәтеп булмый бит... — Ике арт битенә ике йолдыз кыздырып басылган Гыйндулла, әнисенә үпкәләгән малай сымак, мыш-мыш киенде. — Кешегә сөйләмәгез инде, зинһар. Һәр качкан өчен немецлардан берәр йолдыз! Хәтирәгә өйләнергә дә оялып идем мин...

— Без бүген бер-беребездән бернәрсә дә яшермибез, үпкәләмибез дә... — Әхмәтҗан сүз таба алмагандай тамак кырды. — Ни дип әйтмәкче идем...

— Бәхилләшәбез димәкчеме? — Нурулла моны шым гына әйтсә дә, бөтенесе дә ишетте.

— Бәлки, бәхилләшербез дә... Дөнья хәлен белеп булмый, тик мин, Гыйндулла кордаш, синнән тагы бер нәрсә сорармын дигән идем.

— Сора! — Киенеп өлгергән Гыйндулла кире урынына утырды. — Сездән яшерер серем юк.

— Син нинди исәпкә акча күчерәсең ул? Ай саен, пенсияне алу белән...

— Ятим балалар фондына күчерәм. Үземә тотарлык кына алып калам да калганын — аларга.

Тагы тып-тын калдылар. Тынлыкны Әхмәтҗан бозды:

— Яшьлеккә кайтырга туры килсә, Хәтирә, мөгаен, янә сине сайлар иде ул, Гыйндулла. Синдә ниндидер тирән, тыныч йомшаклык бар. Ышанычлы йомшаклык дип әйтимме — син үзең башка бер.

— Рәхмәт! — Гыйндулланың да бу юлы тавышы калтыранды. Янә кабатлады: — Рәхмәт.

Аңлашу өлеше беткәч, теле ачылган ветераннар фронтта күргән-кичергәннәрен сөйләүгә күчте. Кайчак көлделәр, кайчак еладылар. Әгәр элеккечә авыл исән булса, урамнан үткәннәр туктап колак салыр иде, мөгаен. Аннан йә башкортча, йә урысча җырлар да агылды:

Забота наша такая,
Забота наша простая,
Жила бы страна родная —
И нету других забот...

Йә булмаса:

Җил, жирәнем, егетеңне
Җиткер җил җитмәс җиргә —
Яланда түгел, яуда да
Гел икәү булдык бергә...

Керосины беткән лампа җилпелдәп сүнгәч кенә, таң яктысы беленер-беленмәс булып Илекле кыр түбәсен яктырта башлагач кына йоклап китте алар.

— Илекәйнең туена чакырмасаң... — Әхмәтҗан моны йокы аралаш әйтте.

— Хәтирә киленне күрсәтмәсәгез... — Гыйндулла тыңлаусыз бармакларын йодрыкка укмаштырып маташты. — Капут сиңа, Нурулла. Йомры баш...

— Армиясе генә... — Нурулла йоклый иде инде.

* * *

Иртән алар формада иде. Нурулланың да, Әхмәтҗанның да хәрби киемнәре кайчандыр сыймый иде: тазардылар, ит кунды тәннәренә. Хәзер шул киемнәр таман.

— Җиңү көне хөрмәтенә сакалыңны кырабызмы әллә, Әхмәтҗан? — Нурулла үзе кырынып алгач, яшәреп тә китте, кием дә килешә.

— «Сакаллы солдат» дип көләргә сездән башка кеше юк.

— Шуннан, Гапун? Син нәрсә киясең? — Әхмәтҗанның шаяртуына Гыйндулла үпкәләми бүген. Хет нәрсә дисеннәр: боз эреде, күңелләрдә тамчы да юшкын калмады.

— Менә одеколонны да сөртеп җибәрик әле. — Нурулла аларга тәмле ислемай суын сиптертте. — Илекәйнең бүләге. «Олатай, шушыны сөртеп йөр» дигәч, алган идем.

— Яраган, яраган. — Пөхтә Әхмәтҗан кинәнде коенып. — Матур ис күңелне күтәрә.

Мылтыкны да алып, сәгать төгәл 10 га алар обелиск каршысына килделәр. Сафка тезелделәр. Өлкән сержант Әхмәтҗан бирде фәрманны:

— Ветераннар! 1941—1945 елларда фашист Германиясенә каршы Бөек Ватан сугышында үзләрен корбан итүчеләр һәм илбасарларны җиңеп кайтканнар хөрмәтенә куелган «Дан» обелискына карап тигезләнергә! Смирно!

— Есть тигезләнергә. — Хәрби киемдәге Нурулла Илекәев һәм штатский киемдәге Гыйндулла Илекәев команда буенча башларын күтәрде.

— Рядовой Нурулла Илекәев! Бөек Җиңүнең 65 еллыгына багышлап салют бирү бурычы сиңа йөкләтелә.

— Есть салют бирергә! — Язгы һавада, иртәнге тынлыкны бозып, өч тапкыр мылтыктан ату тавышы яңгырады.

— Вольно!

Бәйрәмнең рәсми өлеше тәмам булды. Инде һәрберсе ташка уелган исем-шәрифләрдән үз туганын эзләде, аларга бәйле истәлекләр яңарды.

— Син мине тагы бер тапкыр гафу ит, Гыйндулла. — Нурулла аны иңбашыннан кочаклады. — Иң авыр чагында мин, исәр, синең исемеңне карага буяп йөрдем.

— Уңмый торган буяу, төзәлми торган яра юк, Нурулла. Һәр эш азагы белән хәерле: хәзер без бергә. Аңлаштык. Мин дә бит күп нәрсәгә үземнең яшем биеклегеннән карарга өйрәндем. Күңел тыныч булса, бәндәнең бер көне мең елга торышлы.

— Әйе, вакыт бөтенесен дә үз урынына куя. — Әхмәтҗан кулларын кордашларының җилкәсенә салды: — Без без инде. Без аңлашырга тиеш тә идек: мөселман кешесенә ике көннән артык ачу сакларга, үч тотарга ярамый.

Көн матур торды. Картлар җәй килүнең һәр мизгеленә сөенделәр. Чәчкәгә бөреләнгән һәр үлән, кышкы йокысыннан уянып кояшка чыккан һәр бөҗәк шатландырды аларны. Элекке урамнар буйлап кулларын артларына куеп ашыкмый гына атладылар. Һәр нигезнең кем өе булганын ачыкларга тырыштылар. Хәтирә нигезе янында өнсез басып тордылар. Кызның, чыгып: «Көттердем, ахры, сезне, китә торсагыз да булыр иде», — дигәне исләренә төште. Тәүге сөю, тәүге кичерешләр. Әнә шомырт чәчкә аткан. Ул шомыртны күмәкләп утырттылар. Малайлар чокыр казыды. Өч төп шомырт. Хәтирә су сипте.

— Җимеше пешкәч, бакчаңа керәбез инде, Хәтирә!

Хәтирә көлә:

— Үзем китереп бирермен!

Шомыртлар сакланган, куерган, тоташ шомырт урманына әйләнгән.

Кузгалдылар. Башта беркем бер сүз эндәшмәде.

— Теге чак шомырт утыртып дөрес эшләгәнбез икән, — диде Нурулла шуннан.

Шуннан соң янә әңгәмә яңарды, тыныч-әкрен генә сөйләшеп ары киттеләр.

Чәй эчеп алгач, сәкегә сузылып, ял итәргә яттылар. Нурулла гына башын учлары белән терәтеп утырган килеш калды.

— Әллә йоклап киттең, Нурулла? — Гыйндулла, янында яткан Әхмәтҗан кордашын уятмас өчен, шыпырт кына эндәште.

— Мин йокламыйм. Намазга торам. — Ул, торып, тәһарәт алырга чыкты.

— Нурулла... Син нәрсәнедер әйтеп бетермисең, ахры...

— Тсс... — Ул ишеккә ымлады. — Мулла намазын укысын... Син дә чукынып ал, Гапун.

Нурулланың шаяртуына Гыйндулланың җаны үртәлгәнме, юкмы — йөзенә чыгармады, мәгәр бик җитди тавыш белән:

— Бөтен адәми зат өчен, Нурулла кордаш, үлем бер булган кебек, Ходай да бөтен Яшәеш өчен бары бер генә, — диде.

— Бигайбә, Гыйндулла кордаш.

— Бигайбә, Нурулла: Ходайның кальгасы — бәндәнең йөрәге.

Әхмәтҗан намаз укып бетергәч, Гыйндулла да урыныннан торды:

— Нурулла, без тыңларга әзер.

— Зиратта... аннан авыл арасында... флагларны күрдегез.

— Күрдек.

— Алар гади билге түгел: минем оныгым Гәрәй бу җирләрне Симунга сатарга йөри.

Әхмәтҗан тамак кырды:

— Алайса, теге хәбәр чын булып чыгамы?

— Чынга охшаган.

— Нишлибез?

— Уйлашыйк. Барын уртага салып сөйләшик.

— Илекәй иртәгә килә...

— Иртәгә.

Нурулла тәрәзә пәрдәләрен тартты — өйдә тып-тын булып калды. Стеналарның да колагы бар, диләр бит: монда кеше барлыгын белмәгәннәре яхшы.

Кояш баер алдыннан алар янә тышка чыкты. Баеп барган кояшның кызгылт нурлары Илекле кыр түбәсен алга күмгән. Әнә анда бер, ике... өч... дүрт сын пәйда булды — илекләр-кыр кәҗәләре. Кыр кәҗәләре кайткан туган җиренә! Әллә алар... күзгә генә күренәме?

— Илекләр!
— Дүртәү...
— Иншалла!
— Хәтирә... Илеккә өйләнәм, дигән иде. Хәтереңдәме?
— Хәтеремдә.

Кыр кәҗәләре югалды. Картлар өйалдындагы эскәмиядә караңгы төшкәнче һәрберсе үз уена чумып утыра бирде...

— План барып чыгарга тиеш, — диде Нурулла ахырда.

— Иншалла. — Әхмәтҗан кабаланды: — Намаз вакыты җитте.

* * *

Илекәй кояшның тәүге нурлары белән уянды. Уянучы бер ул гына түгел икән: өй алды бакчасында тургайлар сайрый, кәрниздә күгәрченнәр гөрелди. Сепаратор тавышы ишетелми, әнисе сөтен аерткандыр. Илекәй тәрәзә капкачларын тышка этәрде, өй эченә язгы сафлык белән коймак исе тулды.

Әнисе коймак пешерә, димәк. Аның коймаклары кәгазь хәтле генә юка, ә тәме телеңне йотарлык була. Их! Шулчак Хәтирә дә янында булса! Илекәй аның әрем күклеген җыйган күзләренә чумар да кабат чыкмас иде, мөгаен. Илекәй тагын биш көннән частена барып җитәргә тиеш. Хәтирәне тагын биш ай күрми ничек түзәр икән ул?! Хәтирә хакындагы уйлар аны һавага гына чөйми, утка да сала, суга да төшерә. Матур шул кызыкай. Матурлар янында төрлесе чуала. «Акылсыз кыз түгел Хәтирә, — дип юата ул үзен, башына күңелсез уйлар дулкыны килеп керсә, — тик Ходаем аны көтелмәгән бәлаказадан сакласын».

— Хәерле иртә, әни! — Салкын су белән юынып, тастымал белән тәнен кызартканчы ышкудан кәефе яхшырган Илекәй әнисен җилкәсеннән кочаклады. — Әй сагындырдың, әникәем. Әти кайда?

— Йоклый әле ул. Кичә Җиңү көнен, ахры, артыграк бәйрәм иткән. — Әнисе Илекәйнең битеннән үбеп алды. — И-и, балам, төпчегем лә...

— Йә, елама инде, әни...

— Еламый — үстерәсең дә очырасың... Абыйларың әнә елына бер кайта...

— Мин китәргә кайтмаган. Килен алып бирәм үзеңә. Тик син аны, әни, бик иртә уятмассың...

— И балам! Килен дә үз балаң бит инде ул. Сине иртә уятканым бармы?

— Син мировой әни! — Илекәй коймакны йомарлап авызына озатты.

— Тукта, балам, майлаганны көт.

— Бисмилла дигәнче вакыт үтә бит, әни!

— Үтми торсын әле...

— Тегеләр кайда?

— Симунны әйтәсеңме?

— Әйе, Семён Степановичны.

— Алар бүген килә. Атаң кызу итеп мунча ягарга кушты. Син ашап ал да мунчаны кабыз. Су багын да тутыр. Аннан... ишегалдын себер. Кала кешеләре чисталык ярата бит.

— Чисталык яраткан кеше чисталыкны үзе булдыра, әни...

— Ярый... Кунак бит. Ит бетсә дә, бит кала, ди. Кунак дәшми таптыра. Йөз кызарырлык булмасын ул...

— Слушаюсь и повинуюсь, әни. Коймак зерә тәмле.

— Аша улым, аша...

Гәрәй шешенгән йөз белән болдырга тартырга чыкканда, Илекәй әнисе кушкан йомышны эшләп бетергән иде: мунча яна, ишегалды себерелгән, су багы мөлдерәмә.

— Әти...

— Нәрсә?

— Тегеләр нинди акча хакында әйтте икән?

— Нәрсә дип?

— Акчадан җиңелмәгән кеше юк, дигән кебек булды алар. Мин ишетеп калдым. Кемгәдер ришвәт биргән кебек күрдем аларны...

— Кеше акчасында ни эшең бар?

— Минем... эшем юк.

— Шуннан?

— Шуннан... Илекәйгә борылган юл читенә тыю билгесе куелган.

— Шуннан?

— Элек юк иде, шуңа әйтәм.

— Башка кайгың юкмы?

— Әлегә юк.

— Булмаса, миеңне черетмә. Синең эш — шагом марш: айт-два! — Атасы кулъюгычка таба юнәлде. — Илекәйгә юлны оныт. Ишеттеңме?! — Фәрман каты янгырады.

Илекәйгә бу тавыш яхшы таныш: өч ул үстергән Гәрәй — каты куллы ата. Олатасы булмаса, Илекәй сыртында каеш биюеннән туктамас иде. Илекәй эндәшмәде. Хәтерне фәрман белән җуйдырып булмый: Илекәй зиратында аның җандай күргән Зәкия олэсәенең сөякләре ята. Ә обелиск? Анда 71 Илекәев фамилиясе чүкелгән…

Атасы өйгә кереп китте. Әнисе, иренең кәефен көйләп, алдына ни куеп, ни алырга белмидер инде. Ә Илекәйгә атасы тыйган урынга тагы бармый булмый: картларны алып кайтырга кирәк. Машинаның ачкычы әтисендә. Каян алырга, ничек итеп сиздерми чыгып китәргә? Ул арада атасы киенеп килеп чыкты.

— Карт кайда? Нигә күренми?

— Бәйрәм итә.

— Ничек... «бәйрәм итә»?

— Бәй, Җиңү көне — аларның бәйрәме.

— Чёрт... котларга да онытылган. Гайшә, матурлап... чәй эчер картка. Син, Илекәй, кереп караштыр, моңарчы тормагач... үлеп ятмасын. Булыр шунда бәйрәм. — Ул «Фольксваген»ны кабызды. — Ит салыгыз, тегеләр бүген монда куна.

Атасыннан җилләр исте. Машинаны алып китте. «Нива»ның ачкычы да үзендә. Әйе-е-е, башта бөтенесен дә рөхсәт иткән кеше кинәт саранланды. Кунакның кадерле чагы өч көн, диләр бит. Кадерле чагы үтеп тә китте микән Илекәйнең?

* * *

Картлар кәҗә сукмагы буйлап, текә урыннарны сөзәкләр аша урап үтеп, таута үрләделәр. Башта бик авыр булса да, бара торгач, билләре язылып, сулыш киңәйдеме — элеккечә шәбәеп киттеләр. Үзләре белән алган ризык, кием-салым, мылтык та җәяүлегә йөк. Әй-й-й! Бар иде бит шушында кәҗә бәрәне шикелле таштан ташка сикергәләп уйнап йөргән чаклары.

— Ходайга шөкер, иншалла, — диде Әхмәтҗан, тынын көчкә алса да. — Гыйндулланы бераз көтик...

— Болай булгач, шөкер, — диде Нурулла да, кыяга утырып. — Болай булгач, кордашлар, Илекәйнең туен күрәбез.

Өскә менгән саен авыррак. Менми хәл юк. Югарырак күтәрелгән саен, дөнья матурлыгын күбрәк ача. Әйдә,

кара, күзең генә талмасын. Тау башларында язгы кар мәрмәрдәй ялтырап кояшта чагыла, алардан агып төшкән күз яшедәй саф чишмәләр тоташ тауларны кояшта чагылдырып нурга күмә. Урал батыр эзләгән Самрау иле әллә шушы үземе? Их, күз дә җитте күрсә!.. Шушы матурлыкны бер генә күрер өчен дә дөньяга туарлык.

Картлар утыра-тора һаман югары үрмәләде.

* * *

Семён Степанович белән Егор Ефимович төш аугач кына килделәр. Болар янында атасы майлаган кебек — биеп кенә йөри, иртәнге дорфалыгының эзе дә калмаган. Илекәй боларны читтән генә күзәтә. Олатасы әйтмешли, бу байларның ни йомышы төште икән этисенә? Әнә мунчага этисе берьюлы өч ямь-яшел миллек кертеп чыкты, парлангач, яфрак исе урамга бәреп чыкты. Их килештерәләр, эчәргә нәрсә генә алмаганнар — ишегалдындагы өстәл муллыктан сыгыла.

Бер кат чабынып, зур йомшак сөлгеләргә уранып чыктылар, өстәл тирәли утырыштылар, атасы яннарында бөтерелә, сыйлый, кыстый.

— Казылык? Даже кымыз бар? Ә кыз кайда? — Семён Степанович шофёрына күз кыса. — Я говорю: казылык есть, кумыс тоже, но вот девки нет — не гоже...

— Что правда, то правда... Семён Степанович... Девок нет...

— На счёт этого у вас как, Гарай? Проблема?

— Будет день, — Гәрәй Илекәй ягына шыпырт кына карап алды да моның колагына үрелде, — будет и пища!

— Ха-ха-ха! Молодец ты, Гарай! Свой парень!

Илекәй сикереп торды. Ашаудан, эчүдән башканы белмәгән иманеч җан ияләре Хәтирәне күрсә нишләрләр иде? Атасы да бит: «Будет день — будет и пища», — дип авыз ера. Карап торуы чирканыч. Әнисе ишетмәсен инде...

— Эти, мин йөреп килим әле?

— Йөр! — Аптыраган төсле булып, ул Илекәйгә карады. — Мин сине тотып тораммы?

— В чём проблема, джигит? — Егор Ефимович бер Гәрәйгә, бер Илекәйгә күз йөгертте.

— Да машину просит...

— «Просите и дано будет» сказал Господь — на! — Ул Илекәйнең учына ачкыч ташлады. — Пацан у тебя — во!

— «Мерседес»а не жалко?

— Для такого.— нет. У меня три дочери. Возьму да его зятем сделаю, а?!

— Идея недурна, Ефимыч. — Семён Степанович аның аркасыннан какты. — От смешания кровей красивые и умные дети рождаются! Вот с Илекле кыр покончим, дело в ход пустим и свадьбу! Хороша идея?

— За такую идею надо пить стоя!

Илекәй ачкычны учына салды: картларны алып кайтырга кирәк. Ә болар бит уйнап сөйләми. «Илекле кыр белән покончим». Ул ни дигән сүз?! Ә флажоклар, ә юлдагы тыю билгесе? Ул бит әле Илеклегә борынгы юлдан — турыдан гына, көньяк тау түбәнлегеннән барып керде, ә тауның төньягында, көнчыгышында ниләр бар? Атасы — хәйләкәр кеше. Кеше уйламаганны белә, кеше белмәгәнне эшли.

— Да уже вчера с этим можно было покончить...

— Вчера нельзя было. — Атасы янә пышылдауга күчте. — В праздник нельзя было. Сегодня ночью пожалыста. Ночью!

Илекәй тышка атылды. Башта борынгы юл белән авылга керде — тынлык. Өй эче буш. Чип-чиста итеп җыештырып чыкканнар. Аптырагач, тау тирәли китте. «Һо-о-о! Монда-а-а!» — Күз алдында ачылган күренештән аның исе китте: кеше яши торган вагон тора, әллә никадәр техника, хәтта бораулау машинасы. Илекәйне күреп, бер ир каршысына чыкты:

— Чего тебе? — Ул машинага ымлады. — Я подумал, Степаныч приехал.

— Он у нас. В деревне. А здесь чё делаете?

— Гору... верхушку снимем. Строительство горнолыжной трассы начнём. Степаныч не говорил что ли?

— Да нет... — Илекәй агарынды, моны бу кешеләр дә күрде бугай.

— А сам на его тачке катаешься.

Илекәй кырт борылды, машинасына юл тотты.

— Ты куда?

Ул таугa ымлады.

— Дело есть.

— Какое дело? Гора заминирована. Да и в ямки тол заложили. Туда нельзя! Ждём только сигнала.

— Там люди!

— Какие такие люди?! Там никого нет!

— Есть там люди!

Илекәй селәүсен тизлеге белән машинасына керде, моторны кабызды. Машина җилле — артыннан йөгергән адәм тузан эчендә калды.

— Олата-а-ай! Сез кайда, ола-та-ай! — Илекәй кычкыра-кычкыра тауга үрмәләде. Шулчак кыя артыннан тавыш ишетелде:

— Илекәй! Якын килмә! Бөтенесенә дә җиткер: якын килмәсеннәр. Авыл Советы председателе Гәрәй Илекәев килсен сөйләшүгә. Мөһере белән. Ул килмичә, без моннан төшмибез!

— Тауны шартлаталар, олатай! Мина салганнар, бораулап, шартлаткыч салганнар! Олатай!

— Әйткәнне үтә, Илекәй! Без карарны үзгәртмибез.

— Ходай безнең белән!

Коты алынган Илекәй машинаны авылга куды. Хәбәрне ишеткәч, кызмача кунаклар, әтисе бер машинага төялде. Илекәй ут кебек алдан атылды. Ул менәчәк! Картлар ялгыш кына җиргә ут төшерсә, Алла сакласын, учак якса, көлләре күккә очачак. Тегеләргә бит кнопкага басарга гына калган. Җитмәсә, бәла килсә, каравыл тавы башында ут ягу йоласы бар. Башкортлар кардәш ыруларны шул рәвешле ярдәмгә чакырган.

— Олатай! — Илекәй, машинадан төшеп, кыяга үрмәләде. Аста атасының тавышы ишетелде:

— Илекәй! Төш аннан, Илекәй!

— Әнә тау башында ут көлтәсе күтәрелде. Ут, кауланны ялмап, тау итәгенә төшә башлады.

Мылтыктан ату тавышы яңгырады. Бабасының кычкырганы ишетелде:

— Без кораллы. Пичәтсез якын килмә, Гәрәй Илекәев. Илекле кыр, Илекәй, зират — халыкныкы. Алар — халык иманы. Шушы иманга кагылмаска кул куеп, мөһереңне бас, Гәрәй Илекәев!

— Утны сүндерегез! Менә мөһер! Илекәй, улым!

Бу якларда мәңге ишетелмәгән гөрселдәү һаваны яңгыратты, колакларны тондырды. Таудан югары күтәрелгән үгез зурлыгындагы ташлар тау итәгендәге техниканы, йомычка кебек изеп, аска тәгәрәде. Гөрселдәү, канонада кебек, озак дәвам итте: тау тишеп әле бер, әле икенче чокырга салынган шартлаткычлар берәм-берәм шартлап, тау йөрәген калтыратты.

— Иле-кә-әй! — Җавап булмады. Гөрселдәү ничек кинәт башланса, шулай кинәт тынды.

* * *

Илекәй, Нурулла, Әхмәтҗан, Гыйндулла Илекәевләрне халык тау башына җирләде. Борынгылар әүлияларын шулай биеккә җирли торган булган.

Гәрәй башкача авылда күренмәде. Берәүләр, ул байлык артыннан Симунга ияреп чыгып киткән, диде, икенчеләр, тегеләрнең ачуы килеп, башын капчыкка тыгып киткәннәр, дип сөйләде. Кайсысы дөрестер — бер Алла белә.

Гайшә сулды. Дәртле сылу хатыннан коры сөяк кенә калды. «Җиргә дә яхшы кирәк, — дип юата, диләр үзен. — Ходай дөньяны яхшыларның җаны белән тазарта». Бәлки, дөресе шулдыр. Болай халык аның сүзенә колак сала...

Тау башындагы каберләргә кемдер яз саен чәчкә утырта, тәрбияли. Авылда Хәтирәне белгән кешеләр: «Хәтирәнең рухы йөри», — ди. Бәлки, дөрестер дә: каберләргә килгән яшь кыз Хәтирәгә ике тамчы су кебек охшаган, диләр бит. Дөрестер. Кеше беркайчан да юкны сөйләмәс...

2011

ХИКӘЯЛӘР

АСЫЛ ТАШЛЫ МУЕНСА

Беренче тапкыр гына мәҗлестәш булганга күрә, хуҗалар да, кунаклар да бер-берсеннән тартыныбрак өстәл тирәли утырышты. Сый мул әзерләнгән. Хуҗабикә, Нәфисә ханым, һөнәре буенча табиб-терапевт, үзе утырып та тормый диярлек: өстәлгә әле берсен, әле икенчесен куя, йөзендә канәгать елмаю, бар булмышы — ягымлылык, ерактан килгән кунакларның кәефе кырылмасын дигән кебек, сакчыл-ихтирамлы мөгамәлә.

Ире, иллене узган, чәчләренә сирәк-мирәк чал төшә башлаган таза гәүдәле, яшькелт-соры күзле, куе кара кашлы Динислам, хатыныннан аермалы буларак, аз сүзле. Зур бер оешмада бухгалтер булып эшли. Кәсебенә күрә холкы микән, бәлки, әле теле ачылырлык хәлгә җитә алмыйчарак утыруыдыр. Әмма аның килеш-килбәтеннән, кунаклар ягына сирәк-мирәк ташлаган карашыннан, нечкә билле рюмкаларга эчемлекне аеруча бер дикъкать белән салуыннан аның да хәл-вакыйгаларның шундый үсеш алуына канәгать икәне сизелә.

Хәл-вакыйгалар дигәннән, мәҗлес юкка оештырылмаган. Өстәлнең бер башында пар күгәрчен кебек утырган ике яшь кеше — егет һәм кыз сәбәпче моңа. Гөлфия белән Иршат икесе бер төркемдә медицина академиясенең бишенче курсында укый.

Гөлфия һәм Иршат. Гади дуслыкның мәхәббәткә әйләнгәненә ни гомер... Нәфисә, кызының сөйләве буенча, Иршатны нәкъ менә шундый итеп күз алдына китерә иде дә: буйчан, какча, туры борынлы, үткер карашлы, җиңел сөякле. Кыскасы, кино актёры. Балаң — бавыр итең сайлаган икән, артисттай матур булмаса да яратыр идең, әлбәттә. Ә бу кызлар бәгырен өздерерлек егет шул. Гөлфия дә чибәр. Гәүдә коеп куйгандай. «Кызың, Нәфисә, артистка булыр, ахры. Күз тимәсен, бигрәк сылу!» — дияр иде ахирәтләре. Юк, Гөлфия әнисенең юлын сайлады. Туа-туганнан гел дәвалау турында сөйләшкәнне тыңлап, үсә төшкәч, медицина буенча китаплар укып, Нәфисә ханымның яшәү рәвешен якын күрде, өйрәнде һәм үзенеке

итте. Моңа, әлбәттә, сиксән яше тулганчы хастаханәдә рентгенолог булып эшләгән Сабира картәнисе дә булышлык итми калмады. Гөлфия картәнисе Сабирадан, бәлки, күбрәк тә алгандыр. Картәтисе үлгәннән соң, Сабира Шакировна күңелен оныгына бирде. Әти-әнисе эштән бушамаган һәр гаиләдәгечә, кызыкай, асылда, картәнисе карамагында үсте. Уйнаган уенчыклары — курчак — пациент, шприцлар, ампулалар, таблетка да бинт... Гөлфиягә картәнисе адым саен: «Атадан күргән ук юна, анадан күргән тун тегә. Кыз бала өчен анадан өйрәнгәне — ярты институт. Өйрән!» — дияр иде. Сабира картәнисе күрше подъездда аерым яши. Өстәл башындагы буш урындык — аның өчен калдырылган урын. Нишләптер кереп җитә алмый. Гөлфия генә беләбу соңлауның сәбәбен: ул өенә парикмахер чакырткан. Һәрчакта да бик төгәл Сабира картәнисе соңлый икән, димәк, моңа парикмахер гаепле. Ул вакытында килмәгән.

Яшьтән үзен бик купшы, ыспай тотып күнеккән табиб мондый дәрәҗәле (бердәнбер һәм яраткан оныгы кияүгә чыга!) мәҗлескә һөнәр остасы ясаган причёскасыз килүне килештермәстер...

Бу — танышу мәҗлесе. Икенче төрлерәк, борынгычарак әйтсәң, кызны кодаларга килгәннәр. Иршатның әти-әнисе Гөлфиянекеннән күп булса биш-алты яшькә яшьрәкләрдер. Иршат нәкъ атасы. Суйган да каплаган. Заман исемле бу ир дә табиб икән. Мөлаем ак йөзле, тәбәнәгрәк буйлы, һәрчак елмаеп торган хатыны Вәсилә дә табиб.

— Ике табибтан табиб туа инде, — диде Вәсилә ханым, иренә ялт итеп карап алып, — икәү идек, Алла бирсә, дүртәү булырга торабыз.

— Әйе, әйе, бирсен Ходай, — дип җөпләде булачак кодагыен Нәфисә ханым. — Оныкларыбыз булып, алар да шул юлдан китсә, потомственный табиблар булабыз.

Шунда кызның атасы да сүзгә кушылды:

— Уже потомственный: Гөлфия — өченче буын табиб.

Шул сүзне генә көткәндәй, кунаклар өстәл тирәли утырган залга гәүдәсен бик туры тотып, таягына сизелер-сизелмәс кенә таянып, өлкән яшьтәге, ләкин бик ыспай киенгән, какча аксыл йөзенә килешле причёскалы ханым килеп керде.

— Саумысыз?! — Ул туп-туры үзенә әзерләнгән урынга юнәлде. — Яхшы гына килеп җиттегезме? Юл арытмадымы?

— Рәхмәт, — диеште кунаклар. — Машина өчен ерак ара юк. Выжылдап килеп җиттек.

— Ярый... — Ул килене Нәфисәгә каерылып карады. — Соңлаган өчен гафу үтенәм.

— Гафу итмибез, штрафной сиңа, — дип елмайды улы Динислам.

— Ярый, улым, әниең бер соңлаган икән... Синең отчёт белән утырган чакларыңда... Бөтен мәҗлес сине көтеп, синсез үтеп китә. — Ул инде кода-кодагый тиешле кешеләр ягына карап алды. — Сөйләшә, аңлаша торсыннар дидем. Тудырган, үстергән сабыеңның нинди гаиләгә баруы мөһим, бик мөһим мәсьәлә.

— Курыкмагыз! — Васила ханым янәшәсендә утырган бер хатынның беләгенә җиңелчә кагылып алды. — Менә — Нәзифә. Килен булганыма егерме биш ел. Курыкынычмы мин, Нәзифә?

— Җиңги дип тә уйламыйм. Син миңа туган апаем кебек. Менә Газиз дә шуны әйтер. — Нәзифә, күп сөйләп ташламадыммы дигән кебек, иренә карады. Ире Газиз башын утырганнан бирле беренче тапкыр күтәрде.

— А Васька слушает да ест. Балык тәмле. Килгәндә бер күл аша үттек. Бу...

— Шуннан, шуннан... — Динислам, кунакларны сөендерә алуына шатлангандай, сүз кыстырып калырга ашыкты. — Балыклы. Күлнең исеме шулай.

Кыстатып, назланып кына, кунак, җитмәсә, булачак кода-кодагыйлык бәхетен белеп кенә, тагы бер-икене күтәрделәр. Азлап кына салатлардан авыз иттеләр. Каклаган каз, казылык кисәкләренә дә чират җитте — алар да тәлинкәләрдә эреп югалгандай кими башлады.

Табынның төп ризыгы бишбармак килүгә, башта ятсынып, чит кешеләр кебек утырган кунаклар да, хуҗалар да ачыла төште. Тартыну, каушау кимеде. Бишбармак килер алдыннан ирләр тартырга, хатын-кыз үзләренә генә билгеле «хәбәр сәфәре»нә чыкты. Сабира Шакировна да язылды. Үз гомеренә ул тәрбияле, зыялы кешеләр белән мәҗлестә аралашуны яратты. Ошады, ахры, аңа булачак кодалары. Нәфисә килене моны карчык алдындагы фужерның икенчегә бушавыннан аңлады. Компания күңеленә хуш килмәсә, шәрабны ул авызына да алмый. Кешеләргә дә, коллегаларына да таләпчән булды карчык. Сиксән яшьтән ашканчы бер урында эшләп ялга киткәненә дә ике генә ел. Нәфисә аннан курыкты да, ихтирам да итте. Тора-бара бу бәллүрдәй саф күңелле,

гаиләсе, оныклары өчен җанын бирергә әзер хатынны яратты да. Хәзер, каенанасы олыгайгач, аңа карата ниндидер балага караган кебегрәк наз да барлыкка килде. Хәтта ире Динислам әнисенә турырак бәреп, катырак әйтсә, Нәфисәнең үз йөрәгенә энә кадалгандай:

— Чү, Динислам, әниең булырга кирәк әле сиңа, — ди ул мондый чакта иренә. — Кайнәм кебек хатыннарны «җир тозы» диләр.

— Тозның тәмен син беләсең инде, — ди ире. — Син аның белән күбрәк аралашасың.

Иренең нәрсәгә төрттергәнен Нәфисә яхшы аңлый: яшьрәк чакта каенанасының туры сүзе, төртмә теле аны аз елатмады…

— Үткән эшкә салават, — ди Нәфисә мондый чакта. — Тоз үзенең сыйфатын җуйса — яндырмаса, әчеттермәсә — аннан ни кала? Халыкның иманы бит алар, кайнәм кебекләр…

Менә шулай яшәделәр киленле-каенаналы Нәфисә белән Сабира. Гөлфиягә дә бу тәрбиянең йогынтысы эләкте. Оныгын ничек кенә яратса да, урыны-урыны, вакытывакыты белән чакмый калмады әбисе. Бәлки, шуңадыр да Гөлфия, ахирәтләрем тарта дип, тәмәкегә үрелмәде; бәлки, шуңадыр да, ахирәтләрем кия дип, кендеген күрсәтеп йә кендектән түбән аска төшереп чалбар кимәде.

— Миннән «архаизм» дип көләләр. — Гөлфия әбисенә үпкәләгәнен белдерергә булды бер. — «Музей экспонаты» диләр.

— Тәкә теләгән кәҗәләр генә койрыгын күтәрә, балам. Булачак табиб — син моны белергә тиешсең. — Җавап шундый булды.

Сабира каенанасының гасырга якын гомерендә ни генә үзгәрмәде дә, ни генә югалмады — мәгәр ул үзенчә калды. Күпләр өчен ул үзе хәзер музей экспонаты.

* * *

— Әйдәгез, утырышыйк. Бишбармакны суытмыйк.

Нәфисәнең ихлас чакыруына кунаклар да, хуҗалар да урыннарына юнәлде. Яңа суелган сарык итеннән пешерелгән ашның исе борынны ярып керә. Динисламга да шактый җан кергән:

— Әйдәгез. Менә борыч, корот…

— Динислам, син рюмкаларны кара. — Нәфисә Динисламга булачак кияүнең дә, аның әти-әнисенең дә ошавын

иренең хәрәкәтләренә, йөзенә чыккан сизелер-сизелмәс елмаюына, әзрәк каушаганда өске иренененң тартышыбрак куюына карап белә. — Бишбармак астында калдырыйк. — Ул үзе дә фужерга үрелде.

— Әйдә, кайнәм, берне күтәрик. Бәлки, «Уел»ыңны да сузып җибәрерсең...

— «Уел»ны мин... моңланган чакта сузам. — Ул яшьләргә елмаеп карады. — Ә сезгә карап шатланасы килә. Шатланганда... биисе килә. Шулай түгелме?

— О, картәни! — Гөлфия аны иңбашыннан кочаклады. — Туйда, һичшиксез, биетәбез сине!

— Туй... — Бөтенесе дә кашыкка үрелде. Сабира Шакировнаның карашы гына бер ноктада эленеп калды. — Туй...

Бишбармакка ябырылган халык Сабира Шакировнаның каршы бер ноктада туктаганын да, аның алдындагы кашыкның кыймылдап та карамаганын, тәлинкәсенең тулы килеш мөлдерәп утырганын да шәйләмәде. Карчыкның күңелен булачак кодагыеның ачык изүеннән күренгән алтын чылбырга тагылган кулон биләде. Баярак ул күренмәгән иде, әле хатын, эсселәп, кофтасын салган. Ах! Ул кулонны икенчеләр белән бутап булса!

1943 ел. Сабира — Ташкент каласында хәрби госпитальдә шәфкать туташы. Институтның өченче курсында укыган чагында, ахырда укуны дәвам итү шарты белән, аны шунда эшкә җибәрделәр. Динисламның атасы Гимадислам белән дә алар шунда танышты. Авыр яраланган иде егет. Сабира аның Башкортстаннан икәнен белгәч, аңа тиз ияләште, аеруча якын күрде.

Сабира Ташкентта госпитальгә якын гына яшәгән Мөхәммәтсадыйк дигән үзбәк бабаенда фатирда тора иде. Карт, астма белән чирләгәнлектән, аеруча шәфкать туташларын фатирда тотарга тырыша. Сабира аңа укол кадады, чирнең көчәюеннән сакларга тырышты. Карт — оста ювелир. Сугышка тиклем заказга кытлык булмаган. Беләзек, алка, йөзек кебек бизәнү әйберләре ясаган. Сугыш башлангач, кешедә икенче уй. Төп хәсрәте — азык табу. Сабираның игелегенә җавапсыз каласы килмәде картның. Ул үзендә булган ташлардан, калган көмештән тырышып-тырышып нидер чүки башлады.

— Их, алтын да булса... чак кына алтын, — диде ул беркөн Сабирага.

Кыз, уйлап та тормастан, кулындагы йөзеген салып бирде:

— Шушы алтын микән? Булса, ал. Сез бит миннән фатирда торган өчен бер тиен дә алмыйсыз. Ичмасам...

— Мин бу әйберне, кызым, сиңа дип ясыйм. Кулымнан күп затлы әйбер үтте. Дөньяга таралды. Берсе дә юк үземдә. Бу — соңгы эшем. Изге күңелле кыз син. Соңгы эшем, соңгы сулышым синең күкрәгеңне бизәсен.

— Ай, олатай! Андый затлы әйбергә мин хаклы түгел лә!

— Хаклысың. Йөрәгеңнең җылысы белән соңгы көннәремне яктырттың. Теге иптәш егетеңне китереп күрсәт. Фатихамны бирәм.

Гимадислам госпитальдән чыккач, икәүләп килделәр карт каршысына. Шунда үзбәк карты Сабираның муенына шушы кулон кидерелгән көмеш чылбырны такты.

— Алмаз — борынгы таш. Оста кулына килеп кергәч, ул гәүһәргә әверелә, — диде оста. — Кызлар да шулай: яхшы кешегә барсалар, байбичәгә әвереләләр, яманга эләксәләр, бичара хәленә төшәләр. Сабира — саф алмаз, аннан гәүһәр ясау синең кулда, егет.

— Рәхмәт, олатай, — диде Гимадислам, колакларына тиклем кызарып. — Васыятең итеп кабул кылам сүзеңне.

Яз иде. Җимеш агачлары котырып чәчкә аткан мәл. Сабираның өстендә ак җирлеккә сандал кызыл вак чәчкәләр төшерелгән кыска җиңле ситсы күлмәк. Биленнән түбән төшеп торган калын чәч толымнары, ачык изүеннән йә гранат тамчысыдай балкыган рубин, йә ямь-яшелгә төренгән язгы дөньядай ачык яшел хризопраз, йә күкнең һәм җирнең барлык төсләрен үзенә җыйган гәүһәр йә бер, йә икенче кыры белән күзне чагылдыра.

— Матур, әйе бит, — ди Сабира, муенындагы асыл ташка карап.

— Син үзең дә шушы асыл ташларга охшагансың, — ди Гимадислам. — Гәүһәр тамчы кебек син, Сабира...

Куллар җитәкләшкән. Дулкыннарын ашыгып-ашыгып каядыр илткән арык буйлап атлады алар. Өскә карасаң, өрек чәчкәләре болыты. Гимадислам савыгып чыкты, Сабираның ялы. Әгәр егетнең кесәсендә кич китәчәк поезд билеты ятмаса, алар шулай барыр да барыр иде, мөгаен.

— Синең күзләрең хризопразга, иреннәрең рубинга, чигәләрең шушы гәүһәргә охшаган.

— Исәр. — Сабира бер кайгысыз рәхәтләнеп көлә.

— Асыл ташлы муенсам син минем!

Сәгать көндәгедән шәбрәк йөгерде, поезд кузгалды.

Поезд Гимадисламны көнбатышка — фронтка алып китте.

Сугыштан соң Гимадислам белән өйләнештеләр, бик тату яшәделәр. Башта Фәхрислам, аннан Зөбәйдә, шуннан Динислам туды. Фәхрислам буй җиткерүгә, Әфган сугышы (хәзер «кампаниясе» диләр) башланды. Ул шунда ятып калды. Зөбәйдә укытучы һөнәрен сайлады. Урал аръягында интернат-мәктәптә эшләде. Шәһәрдән ерак түгел зур, данлы күл бар икән. Балаларның җәйге ялын шул күл буенда оештырганнар. Бер бала еракрак йөзеп киткән, бата башлаган. Зөбәйдә, ярым-йорты йөзүенә карамастан, баланы коткармакчы булып суга ташланган.

Гимадислам белән Сабира барып җиткәндә, Зөбәйдәне дә, баланы да тапкан иделәр. Икесе дә моргта. Кызына унсигез яше тулган көнне шушы кулонны — асыл ташлы муенсаны бүләк иткән иде ул.

— Нигә үзең такмыйсың, әни? — дип сораган иде Зөбәйдә.

— Минем асыл таштай балкыган мәлләрем үтте, балам, — диде Сабира, кызының иңбашыннан кочаклап. — Син так хәзер, зур үстең бит инде. Мин...

— Ә син, Сабира, минем өчен һаман Ташкент вокзалында кулыңны болгый-болгый поезд артыннан йөгергән кызыкайсың. — Гимадислам иренен Сабираның чәчләренә тидерде. — Чәчләреңнән дә һаман Ташкент өрекләре чәчкәсенең хуш исе килә, асыл ташкаем минем...

«Баламның шешенеп төсе бозылган булса, муенындагы кулоннан танырмын. Ул кулон дөньяда берәү генә», — дип уйлаган иде Сабира. Әмма... кызын чәченнән таныды: муенында чылбыры бар, ә кулон юк иде...

— Кайнәм, аһ-аһ, нигә авыз да итмәгәнсең ул бишбармактан?!

— Минем өчен борчылмагыз. — Сабира, көчләп булса да, шаяруга борырга тырышты. — Ашарымны ашаганмын. — Үзе мәҗлестәге сүзгә колак салды: сүз ни хакында, нәрсә сөйләшәләр... Туйның вакытын билгелиләр, ахры, Сабира җайлап аңына килә башлады, хатирәләр чолганышыннан котылмакчы булып башын чайкады. Тормышта беткәнме очраклы хәлләр. Ул күлнең исеме колак төбендә. Кайдан гына килмиләр анда. Дулкын бәреп чыгарса, яр читеннән табып алулары да бар. Әй кеше язмышлары...

— Институттан соң шул калага җибәрделәр һәм шунда калдың инде? — Динислам моны булачак кодасыннан сорады.

— Шунда, — булды җавап. — Василә — терапевт.

— Ә сез? — Сорауны кинәт сүзгә кушылган Сабира Шакировна бирде. Карашы үткер, бораулый, чәнчеп еккандай. Бөтенесе дә сагайды, хәтта кода булачак әзмәвердәй ир дә каушый төшкәндәй. Бу караш төбәлсә, рентгенның читтә торсын. Юккамыни аның хастаханәдәге кушаматы «Рентген карчык».

— Мин ни... Моргта. Табиб-патанатом.

— Алай... Ә егерме ел элек анда кем эшли иде?

— Егерме өч, юк... Егерме дүрт ел эшлим мин анда. — Заман, сүзен дөресләтүгә шаһит эзләгәндәй, хатынына карады.

Василә сүзне шундук эләктереп алды:

— Заман Вахитовичны... бик ихтирам итәләр. Ул бик көчле диагност. Менә улыбыз, Алла бирсә, укуын бетерсә, атасы кулы астында тәҗрибә туплар дип торабыз. Атасы юлын куар...

— Әни, син допрос алган кебек сөйләшеп, кодаларны куркытып куйма. Ишетеп утырасыңдыр, бер айдан туй. Безнең дә, аларның да отпуск. Балалар да каникулга кайта.

— Алай... — Сабира бер кулы белән — таягына, икенчесе белән өстәл кырына тотынып торырга чамалады да кире утырды. — Мин сезнең моргта бер булган идем. Балаларның атасы белән...

— Әни... әллә кайчангыны... Тапкансың вакыт... — Динислам ризасызлыктан җыерылган йөзен әнисенә борды.

— Бала... — Сабира Шакировна, һава җитмәгәндәй, тирән сулады, — бала кайгысын вакыт дәваламый, Динислам улым.

— Ярый, ярый. — Заман Вахитович, карт әни өчен кичерү сорагандай, карашын Динисламга төбәде. — Без бит табиблар. Мәҗлестә дә, өйдә дә, хәтта йоклаганда да шул хәлдәбез...

— Минем сеңелкәш... күлдә... батып үлде. Сезнең кала янындагы күлдә... Бер укучыны коткарам дип.

— Ә-ә-ә! Ул укытучы! — Василә, нидер исенә төшерергә тырышып, иренә карады: — Син хәтерлисең аны! Озак эзләделәр. Таба алмагач, унике икмәк пешереп, көймә белән күл өстенә ыргытып чыктылар. Икмәкләр бер урынга җыелган урыннан таптылар... Укытучыны да, укучыны да, алар...

— Анысын мин белми идем. — Сабира Шакировна ка-

рашын янә кулонга төбәде, шуннан күзләрен егете белән ни хакындадыр пышылдашкан Гөлфия оныгына күчерде, тагы Заманга карады. Ул ашый башлаган бишбармагын кашык белән бутый, бутый да бутый, маңгаеннан бөрчек-бөрчек тирләр бәреп чыккан. Мондый чакта маңгай салкын була, җан тире бәреп чыкканда, ул гел шулай була.

— Ничек оныттың син аны? Бөтен район гүләде... — Василә, шаккатып аптырап, башкаларга күз йөгертте. — Дөнья тар, шундый тар! Менә бит...

— Дөнья тар гына булса бер хәл. — Сабира Шакировна башын күтәрде: — Ул — куласа. Ә куласа, әйләндереп килеп, бер баса. Туй... ахры... булмас.

— Син нәрсә? — Динислам сикереп торды.

Гөлфия әбисе янына ашыкты, учы белән әбисенең битеннән тотып, күзенә карады:

— Син бит шаяртасың? Шаяртасың бит, әби?

Каенанасының баядан бирле үз-үзенә охшамый утырганын тойган Нәфисә генә кымшанмады: белә ул карчыкны. Ничәмә дистә еллар килен булу өстенә бер коллективта эшләделәр. Тузга язмаганны сөйләми кайнәсе. Ул үз гомерендә буш сүз сөйләмәде, сәбәпсез кеше рәнҗетмәде.

— Мин... берни аңламыйм, — диде Василә. — Иршат, әллә син... берәр... — Ул, сагаеп, җавап көтеп, улына карады.

— Мин үзем берни төшенмим. — Кияү егете Иршат аягүрә басты. — Мин Гөлфияне... җанымдай күрәм!

Заман... Заман Вахитович кына эндәшми, маңгаеннан бәреп чыккан тир бөртекләре инде күз кабакларына төште, чигәсе буйлап агып, ап-ак күлмәгенең якасына тама башлады. Хатыны түзмәде, урыныннан торды:

— Заман, сиңа ни булды? Саңгыраулландыңмы әллә?

Картәни дә шулай ук урыныннан торды:

— Мин... кайтам инде. Тик... бер соравым калды сезгә. — Таягының очлы ягын ул Заманга төбәде. — Кулон белән бергә... нигә чылбырын да салдырмадың Зөбәйдәнең? Затсыз диденме?

Василә күкрәгендәге гәүһәр, хризопраз, рубин ташларын алтын белән бизәкләп, могҗизалы сырлар ярдәмендә купшылап эшләнгән кулонга ябышты:

— Кулон?! Аны бит син, Заман, көньяк кешесеннән сатып алдым, дигән идең. Мин... — Ул, яклау эзләгәндәй, тирә-ягындагыларга карады. — Моны ничек аңларга?

— Эти! — Иршат, сикереп торып, кинәт тышка атылды.

...Әле генә кояш нуры уйнаган табынның яме бетте. Әйтерсең уйламаганда килеп чыккан кара болыт табын өстенә кара япма ташлады.

КЫЗЫЛ БАШМАКЛАР

Сәрия, чалкан яткан килеш, стена, түшәм буйларын күздән кичерде. Кая карама, калын-калын үрмәкүч оясы асылынган. Боларга күзләре аның күптән ияләнгән. Почмакта караеп күренгәне ни тагы? Ул йә ике песи баласының башын хәтерләтә, йә, укмашып, йон йомгагы булып тәгәри. Шулай да нәрсә бу: песиме, йомгакмы?

Кызыксыну кинәт курку белән алмашынды: теге кара әйбер дәү бер песи булып чыкты. Менә ул Сәрия өстенә сикерде дә буа башлады. Кычкырырга, ярдәм сорарга иде дә, тавышы чыкмый. Әнә ишектән Исламның такыр башы күренде. Юк ла, ул ат башы икән. Хайван, арткы аякларында торган килеш, тешен ыржайтып, шаркылдап көлә, үзе, таптамакчы булып, Сәрия өстенә менеп килә.

— Ис-ла-ам! — Хатын үз тавышына сискәнеп китте. Ислам да, песи дә дулкын югандай юк булды. Сәрия маңгаена салкын тир бәрүен тойды. Ислам? Чынлап килдеме ул, әллә күзенә күрендеме? Кирәкми. Ислам да, берсе дә кирәкми. Эчәсе генә килде, сулышы иреннәрен көйдерә.

Сәрия, Ислам белән кичәге сөйләшүне исенә төшерергә тырышып, маңгаен җыерды. Бу аның Исламнан тәүге тукмалуы түгел түгеллеккә. Шулай да ызгыш нәрсәдән башланды соң әле?

...Ире кабереннән кичләтеп кайтты Сәрия. Кемдер каберне киртәләгән. Кәсле туфрак өстендә бер төп яшь каен яфрак ярып утыра. Кемнәрдер онытмый икән әле Әлмөхәмәтен. Сәрия, бер уч туфрак алып, учына кысты: «Әй, Әлмөхәммәт, Әлмөхәммәт, яныңа килергә дә хакым юк бит минем...»

Сәрия үз гомерендә мәет озатып, зиярәт кылып йөрмәде. Нәсел-нәсәбе булмады. Хәтта әбисенең — бердәнберенең — кабере кайда икәнен дә белми.

Яшәү турында уйланмаган кебек, үлем хакында да баш ватмады ул. Әле менә бүген таңда гына сагышланып уянды. Көне буе өендә ямь таба алмый җәфаланды. Кемгәдер барасы, сөйләшәсе килде, утырып уйлагач, барыр кеше тапмады. Кемгә барасың, аның ишеген бит күптән беркем дә шакымый... Шуннан, җаным теләгән җирдә йөреп киләм дип, урамга чыкты. Аяклар шушында китерде...

Кичлеккә туплана башлаган каргалар тавышына сискәнеп, Сәрия урыныннан торды. Шәфәкъ нурларын этәреп, күктә кара болыт агыла, кабер өстендәге яшь каен җилдә тирбәлә. Хатын кинәт капкага ташланды...

Тәрәзәсендә утны күреп, ул туктап калды. Җаныңны җылытырдай ут түгел бу, Исламнан башка аның өендә этем йөрсенме? Күл ягыннан искән салкын җил Сәриянең ялангач беләкләрен, балтырларын сыпырды, үзе, өшүдәнме, куркуданмы, теше тешкә тими калтыранды. «Әллә өйгә кермәскә инде?» — дип икеләнә эчке бер тавыш. «Кайтмау беләнмени — үзеңнән үзең качып буламы икән?» — дип мыскыл итә икенче тавыш. «Китәргә иде миңа, балаларымны табарга иде. Бәлки, Ислам ярдәм итәр?» — дип өмет уята тәүге тавыш. «Тот капчыгыңны, көт Исламнан ярдәм!» — дип шаркылдап көлә икенче тавыш, усал тавыш, үзенә буйсындыра, ихтыярын сындыра торган тавыш.

Ябылып җитмәгән ишектән үз-үзенә нидер сөйләнеп, хәмер чөмергән Исламны күргәч, Сәрия иплэп кенә баскычтан кире төшә башлады.

— Тукта... Үт, кодагый, үт, урының түрдән... — Ислам күксел калын иреннәренә елмаю галәмәте чыгарды: — Нигә шулай, асрау хатын шикелле, читтә генә моңаеп утырасың? Әллә Әлмөхәммәт белән яшәгәндә хәлең шуннан узмадымы?

Сәрия үзенә дип салынган аракыны читкә этәрде. Менә хикмәт: кичтән баш төзәтергә әмәл тапмый йөдәде, хәзер күрүгә укшыта. Җитмәсә, колагына карга тавышлары чалына, яшь каен җилдә чайкала... Исламга Сәриянең үзен тотышы, әлбәттә, ошамады:

— Нәрсә тәре кебек каттың? Берәүне кешегә санап, баш кода килгән, ә ул... Нигә куанмыйсың? Өйләнәм дисәм, Исламга юньлерәкләре бетмәгән, синең урыныңда башка берәү булса, каршымда күбәләктәй бөтерелер иде әле.

— Үзең өй салгач, бөтенләй барып керерсең. Бу йорт —

балаларныкы. — Сәриянең тавышы әкрен, ләкин каты чыкты.

— Бәй, шулаймыни?! Нигә аны күптән әйтмәдең? Син шулай изгелекле әни дәмени әле?!

— Ничек тә син сукбайга хөкем итәргә түгел. Минем башны ашаганың полный җиткән, балаларымны өлешсез калдырырга булдыңмы?

Ислам иреннәре калтыранган Сәриянең беләкләреннән чытырдатып тотып алды.

— Баш төзәтергә рәт тапмадыңмы әллә бүген? Агаең белән иплерәк сөйләш, башың ике булмаса... Бәй, әйтергә иде, башыңа тимәгән булыр идем. Ха-ха-ха!.. — Ул гыжылдап, буылып көлә башлады. — Башы эшләгән кеше кырык эттән калган кәнтәйгә өйләнер идеме? Ух-ха-ха...

— Әлмөхәммәт якты өметләр белән тормыш корган иде! — Сәрия, баягыдан да ныграк калтыранып, кулын ычкындырырга маташты. — Минме кәнтәй? Минме кырык эттән калган? Уналты яшемдә намусымнан көлүче син түгел идеңме? Эчү дә, азу да синнән башланды. Ишетәсеңме, күралмыйм мин сине! — Сәрия, бер кулын ычкындырып, өстәлдәге шешәгә омтылды.

— Ә-ә! Эчәсең киләмени? Бая ук шулай дими...

— Эчәсем түгел, үч аласым килә. Балаларым, Әлмөхәммәтем, тапталган бәхетем өчен үч... Мә, хәшәрәт, дөмек!

— Эһем. — Ислам чайкала-чайкала аягүрә басты. Аннан ашыкмый гына җәрәхәтләнгән баш түбәсен сыпырды. Учында кан күрү аны бер секундта ерткычка әйләндерде: — Ислам белән шутки плохи. Ислам белән шаярмыйлар. Ну, каналья, держись!

Ислам аны күпме, нәрсә белән тукмагандыр — Сәрия хәтерләми. Күз алдында Исламның шашкан карашы гына тора. Янында аягы сынган өстәл аунап ята, ишек яңакларына кан чәчрәп каткан. Күк җирлеккә эре кызыл чәчкәләр төшерелгән мендәр — каенанасы бүләге — ватык шешәләр арасында ауный.

...Кайчан гына әле Сәрия, күпереп торган шушы мендәргә басарга кыймый, бусагада туктап калган иде.

— Үт, килен, үт. Төкле аягың белән! Нәкъ уртасына бас әйдә мендәрнең. Төшкән җирендә таш бул, — дип өтәләнеп, ихлас каршылаган иде аны Бибизата карчык.

Өй иркен. Ике бүлмәле. Яңа буралган карагай исе сулышны киңәйтә. Сәриягә чәй ясарга кушып, каенанасы түргә менде. Әлмөхәммәте самавыр артына, кәләшенә каршы утырды.

— Тәүге чәйгә юри кешегә әйтмәдем, — дип, талгын гына сүз башлады каенанасы. — Шушы рәвешле чәй эчеп утырырга күпме хыялландым. Иншалла, теләгем кабул булды: улымны хәләл мал белән башка чыгардым. Уйладым-уйладым да үзем әлегә иске нигездә калырга булдым. Өйрәнгән күрше-күләнне дә, килен булып төшкән тупсамны да ташлап чыгу җәл. Балаларыгыз туса багармын, дөньягызны да күтешермен. Тату гомер итсәгез, иң зур куаныч миңа шул булыр. — Бер йотым чәй белән тамагын чылаткач, каенанасы янә сүзгә кереште: — Син, килен балакай, сугыштан соң тугансың. Ачлык касәфәтләрен, Аллага шөкер, татымагансыңдыр. Шулай да борынгыдан калган мәкальне оныгмагыз: адәм баласы юклыкка түзә, барлыкны күтәрә алмый. Нотык укуым түгел, олы буларак, киңәш итеп әйтүем генә: әзер дөньяга төштем дип, алдын-артын уйламыйча мал туздырма. Хәләлне хәрәмгә әйләндерүдән сак булыгыз.

— Ярар, әни, ул тиклем хафаланма.

Тагы бер чынаяк чәйне корылай гына чөмерде дә каенанасы кайтырга ашыкты.

— Сез, яшьләр, үзегез генә утырасыгыз киләдер. Кода-кодагый булса, иркенләп гәпләшер идек тә, ярый, насыйп булмагандыр.

Сәрия әсәренеп китте. Шулай да «Әнием бар минем!» дип әйтергә теле әйләнмәде. Әнисе Сәриягә өч яшь тулганчы кияүгә чыккан. Кайдадыр Үзбәкстанда яшәгән ана башта хат язгалап торган, азактан аннан хәбәр-хәтер булмады. Сәрия әбисенә «әни» дип үсте. Бик иркәләде үзен әбисе, теләгәне алдында булды. Моны күргән күршеләре: «Кызыкай, әнисенә охшап, төскә бик матур. Холкы белән дә охшамагае... катырак тот, кызга кырык җирдән тыю, ди», — дип кисәтә килде.

Күршеләренең киңәше борынына ис керә башлаган Сәриягә ошамаса да, төс-башы хакында сөйләнүләре буш түгел. Сәрия аны үзе дә тоя. Ундүрт яшендә ул ахирәтләреннән шактый аерыла иде: йомры тар гына җилкә, нечкә бил, биек, киң янбаш, сары чәчләре ефәктәй йомшак, кулбашларына килешле дулкын ясап төшеп тора, зәңгәр күзләрен каймалаган керфекләре, дугадай чөелгән кашлары чәченнән күпкә коңгырт; иреннәре дә янып күпереп тора. Һәрхәлдә, Сәрия көзгедәге үз рәсеменә сәгатьләр буе текәлеп утырса да туймый. Тик әбисенең идән юып алган акчасыннан әллә ни өмет итеп булмый шул инде, өсте-башы гына кәефне кыра.

Сигезенчене, артык күңел салмый, этеп-төртеп бетергәч, Сәрия кабат мәктәпкә бармаска карар итте. Бөтен тормышын оныгының күңелен табуга корган әбисе каршы килмәде:

— Абау, укымасаң ни... Үзем бер класс бетермәсәм дә яшәп ятам әле. Мондый чибәрлегең белән парта артында кибеп утырмассың инде. Йчмасам, эшләп өстеңне бөтәйтерсең.

Сәрия, әбисен юатыр өчен түгел, үз тәртибен аклар өчен генә:

— Кичке мәктәпкә йөрермен шулай да, — дигән булды.

Кичке мәктәпкә йөрү кайда — шул җәйне үк, ял йорты ашханәсендә официантка булып эшләгәндә, озын буйлы, үткер карашлы җитез егет Исламны очратты. Очрашканнарына ай да үтмәде, Сәрия коеп куйган сылуга әйләнде дә куйды! Алтын алка-йөзекләр, модалы ефәк күлмәк, француз туфлиләре кемгә килешми? Эштән соң табигать кочагына чыгулар, ай яктысында күлдә су керүләр, өшегән тәнне генә түгел, җанны эретерлек тәмле эчемлекләр... О, бай иде ул чакта Ислам! Тәкәббер, эре иде. Сәриягә карата мәрхәмәтле, игелекле иде Ислам...

Гомере буе очын очка ялгап көн күргән әбисе кызының булачак киявенә сөенеп бетә алмады.

— Сәриям, Аллага шөкер, яхшы кешегә юлыкты, — дип масаер иде, күрше-күләнгә кич утырырга кергән чакларында, — барның барлыгы тия шул: гел затлы әйбер алып бирә кызыма.

Затлы әйберләрнең хәрәм юлдан яуганын гына шәйләмәгән алар. Азактан Ислам Сәриянең үзен дә «мал табучыга» әйләндерде. Юк, Сәриягә артык хафалы эш кушмады ул: бары ресторанга кергән калын кесәле клиентны шәйләп, башын әйләндерү.

Сәрия Әлмөхәммәтне дә ресторанда эшләгән чагында күрде:

— Үтегез, теләгән өстәлне сайлап утырыгыз. Бә-әй, бик кыюсыз күренәсез... Бездә беренче тапкырмы әллә?..

Егет, таптана торгач, иң читтәге өстәл артына утырды.

— Ашханәләр ябылган. Монда тәүге керүем.

— Менә меню.

Сәрия каршы утыргычка утырды да ягымлы карашын егеткә төбәде:

— Авылданмы?

— Авыл-да-ан... Шифер яздырткан идем, складтан алып чыгарга өлгерми калдым.

— О-о! Өй саласыңмыни?

Шулчак Әлмөхәммәт илгәзәк кызның йөзенә күтәрелеп карады. Әйтер җавабы әллә кая очты: киң ачылган кара күзләрендә соклану, гаҗәпләнү, оялу — бөтенесе бергә шунда агылды! Бу караштан күпне күргән Сәриянең дә керфекләре дерелдәп куйды...

Егетнең гайрәт, ихласлык бөркелгән йөзенә Сәрия башкача күтәрелеп карамады. Нидәндер курыккандай, җәһәт кенә кухняга кереп китте, Әлмөхәммәт алдына ашамлыкларны да сүзсез-нисез тезде.

— Рәхмәт...

Тавышын ишеткәч, беразга, бары бер секундка поднос тотып китеп барган җиреннән Сәрия туктады. «Кайда ишетте әле ул бу тавышны? Бәлки, берәрсе белән бутыйдыр... Юк, хыялында гына ишетелгәндер бу аваз. Чуалган аның язмышы, буталган. Анда хыял кичерешләренә урын юк. Әйдә, егеткәй, аша да юлыңда бул. Югыйсә, Алла черем иткән чакта, шайтан ниләр кылмый...»

Күңелсез уйларыннан арынырга теләп, Сәрия башка клиентларга ашыкты.

* * *

Сәрия баягы аунап яткан мендәргә кул сузарга иткән иде, тәнен каты авырту телгәләде. Уң кулы хәрәкәтләнми, янбашы чыккандырмы, сынгандырмы, күкрәкне нидер кыса, бөерләр таш кебек каткан, тын алдырмый.

Хатын, ыңгырашып, карашын баягы кара ноктага күчерде. Нәрсә соң бу? Шушыңа кадәр бер дә абайламаган. Өй эчендә җиһаз бетте. Кайсыларын кәеф-сафа кылырга килгәләп йөргән Ислам кырды, кайберләрен арзан хакка үзе җибәрде. Ялангач стенада эленеп торган бердәнбер әйбер булганга теге кара нокта игътибарын тартып тик тора. Менә ул янә зурая башлады. Бәй, плащ чабуларын җилфердәтеп кемдер килә бит. Ерак булганга ул нокта булып күренгән икән.

— Кем ул? Тукта!

— Сәрия, бу мин бит! Әллә танымыйсыңмы?

Йөзенә тимгел-тимгел кызыл таплар бәреп чыкты, Сәрия керүчегә омтылмакчы иде, кузгала алмады. Ул бит, ул — Әлмөхәммәте каршысында тора!

— Син ничек килдең? Кабереңне кичә генә үз күзем белән күрдем.

— Их, Сәрия! Анда мин тыныч күңел белән ята дисеңме? Үлем кызулык белән булды. Бөтенесе бергә бугаздан алды бит: әниемнең үлеме, син, Ислам... Зиһенем түнә башлагач, кызларымның тавышын ишеттем. Үкенечтән күзләремә кан саулы — бер хәл дә кыла алмадым, сине дә сагынам...

— Сагынасың... Мин бит җинаятьчеләргә булышкан өчен хөкем ителгән адәм идем. Эштә безне химичкалар дип йөрттеләр. Срогым тулгач, кайда, кемгә барып борын төртергә белми идем. Син үзегезгә чакырдың...

— Чакырдым шул. Тәү күргәндә үк күңелемдә ташкын ясап, давыл куптарып киттең бит. Эзләдем мин сине, таптым... Таптым да югалттым. Үземне дә югалттым. Балаларны... Аналык хисе күңел юшкыннарыңны юар дигән идем. Газаплардан җиңел котылмакчы булганмын. Ятимлеккә чик куям дип, җанын фида кылган атам рухына хыянәт иттем. Бер баласын адәм итәргә бөтен гомерен багышлаган әнием рухымы рәнҗемәс? Ах, шул кулыма аркан алып каенлыкка ашкынган минутларымны кире кайтарып булса...

— Көтәр мине, Әлмөхәммәт?

— Көтәргән идем мин сине, Сәрия! Ал кояшым, берләнберем итеп көтәргән идем!

— Ах, китәсең дәмени, Әлмөхәммәт?.. — Иреннәрен өткән шушы аваз Сәрияне сискәндерде, айнытып җибәрде. Шешенгән кабаклары астыннан тирә-ягын күздән кичерде: беркем юк. Кайта торган җиргә китмәде бит аның ире. Килмәде ул, килмәгән. Бөтенесе дә үз урынында, һава гына Әлмөхәммәт калдырган сагыш белән тулы...

Хәтерләүдән Сәриянең тыны кысылды, теге кара нокта да тирбәлеп куйды. Беренче баласын тапкач, Әлмөхәммәт хатынын кулларында тибрәткән иде.

— Алтыным син минем! Моңарчы мин иген басуыннан да матуррак нәрсә күрмәдем. Алтын башаклар төсе сабый чагымнан күңелемә сеңгән, синең чәчләреңдә дә бит өлгергән иген төсе. Әллә шуңа бер карауда әсир иттең микән?

Ә Сәрия эчә иде бит! Сөюеннән исергән Әлмөхәммәт башта моны абайламады. Аңлагач, болай диде:

— Өйдә ялгызың булганга теләсә нинди уйлар башыңа киләдер. Гөлчибәргә яшь тулгач, фермага барырсың. Эш авыр түгел, күп нәрсәне машина башкара. Ичмасам, күмәк кеше арасында күңелсез уйларыңнан арынырсың.

...Иренең сүзен тотып, Сәрия эшкә дә чыгып кара-

ды. Пенсиягә киткән савымчының менә дигән төркемен бирделәр үзенә, сөт әйбәт булгач, кеше арасында йөзе дә якты. Электән эшләгән савымчы хатыннарның үзләре арасына алырга, ярдәм кулы сузарга тырышып торулары да күңеленә хуш килде. Тик менә кунак-төшем булганнан соң иртәнге дүрттән торып фермага китүләре кыен икән! Баш кургаш дыңгычлагандай авыр, буын хәлсез, ярый да яшереп куйган баш төзәтерлегең булса. Мондый чакларда савымга күбрәк Әлмөхәммәт китәр иде. Үзе болай авырсынмады, каенанасы гына бер килгәндә уратыбрак сүз башлады:

— Улым, яман баеп барасыз түгелме?

Әлмөхәммәт, сәерсенеп, өй эченә күз йөртеп чыкты.

— Әллә тагын, әни. Үзең биреп чыгарган мөлкәт инде, шуның белән көн күргән баш...

— Алайса, буштыр. Кеше телендә, Әлмөхәммәт яман баеган икән, катнашмаган туйлары, котламаган кешеләре юк, дигән имеш-мимеш хәбәр йөргәнгә генә соравым. Киленне дә фермада әледән-әле югалталар икән. Сиңа, улым, «Сәриянең сменные» дигән кушамат такканнар, имеш...

— Кеше ни сөйләмәс. — Колакларына тиклем кызарган Әлмөхәммәт әнисеннән карашын яшерде. — Син хатын-кыз сүзенә әзрәк колак сал, әни...

— Ярар. — Бибизата карчык улының бөгелеп төшкән гәүдәсенә тутырып карады да, чигә тирәсенә яулыгын кыстырып, китәргә җыенды. — Ярар, син әйткәч, колак салмам. Шулай да үпкәләмәгәе шартлагыз, уйлаганымны әйтәм: кичә үлсәм, хатын-кызның эчеп эшкә чыкмый ятканын белми китәр идем, билләһи.

Үзләре генә калгач, көйсезләнеп, кыза алмый яткан учактагы утыннарга карап тынып калдылар. Сәрия, уңайсыз тынлыкны бозарга тырышып, иренә эндәште:

— Утыны да коры, әллә нигә янмый?..

— Учак ягуның да үзенә күрә рәте бар шул, бичәкәй. Тырым-тырагай яткан агачлар дөрләп китә алмый.

— Сезгә ни булды бүген? — дип, иренен бүлтәйтте Сәрия. — Әниең дә, син дә киная белән сөйли башладыгыз.

— Кинаяләү түгел, әнием дөрес әйтә. Тик син үпкәләмә. Гомер бакый дөнья йөген берүзе тарткач, тынгысыз шул карчык. Эндәшмәсәм дә, үзем дә ул турыда күптән уйлана идем, Сәрия...

— Әйдә, карчык-корчыкны күбрәк тыңла, учагың җәһәт кызар.

— Каенанаң сиңа карчык-корчык түгел. — Кичә гараж тыкрыгыннан килеп чыксам, байтак ир-ат, кино башланганын көтеп, клуб янында тора. Болар мине күрми. Шунда, нигез буенда, бер кәҗә игез бәрән китергән. Берсе шунда: «Их, боларны Әлмөхәммәт белән Сәрия белми ятадыр инде, елтырны җигеп, хәзер котларга килеп җитәрләр иде», — дип ычкындырды. Шаркылдап көлгәннәрен ишетергә теләмичә, кире борылдым, өйгә абзар артыннан урап кайттым.

— Харап инде. Көлә бирсеннәр. Безнең татулыкны кеше күралмый.

— Куйчы, бичәкәй. Моңарчы кеше көлдереп яшәмәдем. Атасыз үскәнгәме, яман гарьчел бит мин. Узган ел әнә, юк сәбәпне бар итеп, Почёт тактасында ун ел торган рәсемемне алып ташладылар. Урак җиткәч, гарьлектән йокыдан яздым, әмма колхозда түгел, районда беренче урынга чыктым. Үлемнән оят көчле, Сәрия.

Сәрия Әлмөхәммәтнең дерелдәгән иңбашыннан кочаклады:

— Ярар инде, тынычлан. Моннан соң эчү мәҗлесләрен кыскартырбыз. Култыклашып кинога гына йөрербез, яме?

Әлмөхәммәт хатынын күкрәгенә кысты:

— Их, Сәрия, Сәрия, татлы да, ачы да язмышым минем...

* * *

Шушы сөйләшүгә күп тә үтмәде, Сәрия халык хуҗалыгына мәҗбүри эшкә җибәрелгәндә бер тулай торакта яшәгән ахирәтеннән хат алды. *«Сине бәрәү килеп эзләп йөрде. Үзен Ислам дип таныштырды...»* Бу юлларны укыгач, Сәрия урындыкка лып итеп утырды. Ислам? Ирекккә чыгар вакыты җитте дә микәнни аның? Әй вакытның үтүе... «Җәһәннәм тишегеннән дә эзләп табармын сине. Башың ике булса, көтми кара», — дигән иде ул хушлашкан чакта. Ауга эләккән кошчыктай тыпырчынды Сәриянең җаны. Тәне бер өши, бер яна...

Коты очып, күпме хәрәкәтсез утыргандыр, Әлмөхәммәт кайтып, ут кабызгач, аптырап китте:

— Бәй, син өйдәмени? Ни булды? Нигәдер төсең качкан...

— Чирләп торам, — диде Сәрия, телен көчкә әйләндереп. — Урын җәеп бирче...

Әлмөхәммәт аны эчке бүлмәгә кертеп салды, үлән чәе кайнатып эчерде, табаннарына җылыткыч куеп, өстен япты.

Йокысыз үткән төн бу юлы кыска тоелды. Әллә ничә кабат Әлмөхәммәтне уятырга, хәлен сөйләргә талпынды. Тик иренең бер йөрәген күпме телгәләргә була? Соңгы вакытта болай да эштән көяләнеп, кәефсез кайта. Ремонтта утыралар. Запчастьлар җитешми. Урак башлангач, шуның аркасында җандай кадерле көннәр әрәмгә китәчәк дип уфтана. Аннан соң... аңлармы ул Сәрияне? Исламның коточкыч кеше икәнен Сәрия төшендерә алырмы Әлмөхәммәткә? Төшенгән хәлдә дә, сабыйдай беркатлы кеше күтәрерме моны? Исламнар дөньясы бөтенләй ят бит аның иренә, бөтенләй ят... Ни кылырга, ярдәм сорап кемгә барырга? Сәрия шушы төндә моңарчы көчле дип табынган иренең көчсез ягын ачты: Әлмөхәммәт пычраклык каршында югалып кала. Юк-юк, сөйли алмый ул боларны иренә!

Яңа таң көнне яңа мәшәкать белән тутырды. Сәрия күңелен хәмергә бушатты...

* * *

Эшнең дә рәте китте. Карау җитәрлек булмагач, сыерлар да сөтен киметте.

— Оятың кайда синең? Аракыга алмаштырдыңмы? — дип, ферма мөдире дә өскә очып килә. — Куйчы, куйчы... Илне дә, ирне дә котайта торган бичә түгелсең.

Сәрияне эшкә салкын караганы өчен җирле комитетка тикшерүгә куйдылар. Халык алдына бу көе чыга алмасын белеп, эчеп килде ул.

— Кайдан килгән суфилар! — дип шаркылдап көлде Сәрия үзен шелтәләп чыгыш ясаучылардан. — Әллә авылыгыз белән Мәккәгә барып, хаҗ кылып кайттыгызмы? Алай дисәң, кибеткә килгән бер машина аракыны, атна ахырына да җиткерми, мин генә эчеп бетерәмме?

— Син бездән сорау алма. Монда синең тәртибең тикшерелә, син үзеңнән генә түгел, авылның абруйлы кешесе — каенанаңнан, шушыңача бөтен халыкка үрнәк булган иреңнән дә көләсең.

— Нигә, ирем белән каенанам жалу белән килделәрме сезгә? Эшли алмасам ни, чыгарыгыз, ыһ та димәм. Мал астын тазарту өчен иргә чыкмаган...

— Закон төзәтә алмаганны, — дип кул селтәде фер-

ма мөдире. — Өч елны сиңа матур булганга биргәннәр дисеңме?

Сәриянең авырткан җиренә кагылдылар! Күзен кыса биреп, ферма мөдире каршысына барып басканын үзе дә сизми калды.

— Ах, шулаймыни? Миндәй бичә үзеңә тәтемәгәнгә көнләшәсеңме? Әйе! Хөкем иттеләр мине. Корт та бит алманың асылына төшә. Ә синең кәкре аяк бичәңне май сылап ташласаң эт тә яламас!

— Синең телеңне эт яламас! — Мөдир ишекне шартлатып ябып чыгып китте.

Җирле комитет нинди карар чыгаргандыр, мәгәр Сәрия башкача фермага ике аягының берсен дә басмады...

Хәзер аңа ике дөнья бер морҗа: диңгез тубыктан. Әнә ул ава-түнә атлый, үзе кемнәрнедер сүгә йә шаркылдап көлә. Өенә җиткәндә, аяклары бөтенләй тотмас булды. Дүрт аякланмакчы була — хәленнән килми. Каршы чыккан Әлмөхәммәтнең дә кулын этәрергә тырыша:

— Кит... Берегез дә пычагыма да кирәк түгел, сез — фәрештә, мин — фахишә. Химичка!

— Әйдә инде кереп ят, бөтен кеше безгә карый!

— Төк-кердем мин кешегә. Ха-ха-ха! Күрсеннәр! — Сәрия кофтасын чишеп ыргытты, аннан күлмәгенә ябышты. — Күрсеннәр! Сәриянең кем икәнен...

Аннан соң ул Әлмөхәммәтнең коточкыч булып үзгәргән йөзен генә шәйләп калды...

Күпме вакыттан уянгандыр, каршысында йончыган, агарган йөзле, җилкәләре салынып төшкән Әлмөхәммәт утыра. Сәрия, ыңгырашып, күзен кире йомды.

— Нәрсә кирәк? Су китеримме?

— Юк.

— Кай төшең авырта.

— Авыртмый.

— Суктым бит сиңа, бичәкәй...

— Кыен булса, сукмадым дип уйла.

— Ни эшлибез, Сәрия? Бәлки, дәваланырсың?

— Булмый. Дәваланып карадым инде мин, яшь чакта ук. Киредән эчкәннән соң шулай булдым.

— Соң, эчмәгән чакларың да булды бит, Сәрия...

Шулчак ишек ачылды. Бусагада Гөлчибәрне җитәкләгән каенанасы күренде.

— Сөенче! Торналар аяк ташлап китте кызыма, сөенче...

Әлмөхәммәт кызын баш очына чөйде. Гөлчибәр, чыр-

кылдап көлә-көлә, атасының көчле кулларына ябышты. Боларга карап каенанасы да елмая:

— Аякларың талу белмәсен, колынчагым — тулмас орчыгым.

Өч яше тулса да, һаман атлап китә алмый иде Гөлчибәр. Әле менә каенана кешегә карап торсаң, күзгә яшь килә: әйтерсең лә Гөлчибәр түгел, үзе беренче тәпи баскан.

Әлмөхәммәт чәй әзерләде. Сәрия инде торып утырдым дигәндә, йөрәк астында тыпырчыну тойды.

— Әлмөхәммәт! — Сәрия агарынып, сикереп торды.

— Йа Ходай! Ни булды, килен!

Сәрия тышка атылды. Нәрсәгә юрарга белмәгән Әлмөхәммәт хатыны артыннан иярде. Бакча артындагы күлгә җиткәч, Сәрия яшь үләнгә чүгәләде:

— Нишләргә миңа, нишләргә?..

— Ни булды?

— Булмады. Булачак. Бала булачак... тагы.

— Шуңарчы белмәдеңме?

— Белмәдем, уйламадым.

— Шулай инде, уеңда тик баш төзәтү булгач, буеңда таш ятса да белмәссең.

— Гөлчибәр таза-сау бит, — дип, үзен якларга тырышты Сәрия. — Әнә атлап та китте...

— Син мине дөрес аңла, Сәрия. Эчүеңне ташласаң, хет унны тап, шатланырмын гына.

Азга гына булса да, ир белән хатын арасына аллыгөлле салават күпере тартылды...

* * *

Бала туды. Сәрия эчүен барыбер ташлый алмады. Акушерка аңа имезмәскә кушты. Бу сүз каенанасын чыгырыннан чыгарды:

— Аһ-аһ, нинди кыямәт бу, духтыр, ә?! Туу белән әни сөтеннән аер әле... Әлмөхәммәтемне өч яшенә кадәр имездем, ташлаткач, иту йөрәгем сызлады. — Арык иңбашларын дерелдәтеп, каенанасы елый иде. — Менә сиңа бер бичә! Сугыш вакытында бригадир булдым, төрле кыз-кыркынны күрдем, мондыйны — юк. Көне буе ат урынына җигелеп эшләүләре җитмәгән, төн буе йон тетәләр, илиләр, фронтка оек-бияләй әзерлиләр. Үзләре бит итекне яланаяк кия!

— Барча хатын-кыз синең килинең кебек түгел бит, әбекәй.

— Кемнең итәгенә ут төшә, шул яна шул, духтыр кызым. Шул бичәләр белән нинди генә авырлык та җиңеп чыгылды, хәзер менә бер киленемә баш була алмыйм. Тыныч күңел белән теге дөньяга китәргә дә форсат юк...

* * *

Баласына яшь тулгач, Сәрия, тагы дәваланып карамакчы булып, шәһәргә китте. Шәһәр сагындырган. Ни дисәң дә, бала чагы, яшьлеге шушында үтте бит.

Менә бакча. Әнә теге тирәк төбендә бермәл аны тәүге очрашуга чакырган классташ малай көтеп торган иде. Тездән өстә иске күлмәк, тапталган үкчәле кара туфли кигән килеш егет каршысына барып басарга гарьләнгән иде ул чакта Сәрия. Өй почмагыннан гына күзәтте ул аны. Фәнилнең өмет белән янган күзләре әле булса күз алдында.

Менә ресторан... Үзен эшкә алуны сорап, ишек бусагасын кыюсыз гына атлаганы хәтерендә.

— Нигә безгә эшкә килергә булдың? — Ягымлы карашлы мөдир хатын аңа елмаеп карады.

— Гәзиттә укыдым. Официантлар кирәк икән. Аннан... өйгә дә якын.

— Кемнәрең бар?

— Әбием генә.

...Моннан соңгы мизгелдәй алышынган истәлекләр күңелне юатмый. Әнә бульвар. Иңбашына ялкындай сибелгән чәчләрен таратып, урман юлыннан бер кыз килә. Аның башы аска иелгән...

Өермәгә эләккән тузандай әйләндерде аны язмыш. Айнысаң, күңел әрни, әле дә хәмер булды дөньяда! Ирләр аның бер карашыннан эреде. Ислам гына... Бәгырьсез Исламнан гына курыкты ул. Үзе алып биргән асыл киемнәр хакын бишләтә түләтте инде Ислам Сәриядән.

* * *

— Соня?! — Таныш тавыш истәлекләрдән арындырып җибәрде. — Кара син аны, ничек эреләнгән кешеләр! Баядан бирле күзәтәм, шәйләми дә...

— Ислам?! — Тәне эсселе-суыклы булып, Сәрия эндәшүчегә йөз белән борылды. — Ислам...

— Ислам да Ислам... Мин, Аллага шөкер, кырык ел инде Ислам. Менә син кем икән бу заманнарда.

— Мин... — Гөлчәчәккә дип алган кызыл башмакларын угалап, Сәрия каушап калды. — Мин... менә... кызыма...

— Кы-зыма? О-о! Балаң да бармыни шулай? Хәләлдәнме, хәрәмнәнме дигән шикелле, сер булмаса?

Исламның кысык күзләрендә сикерешкән мыскыллы очкыннарны күрмәмешкә салышты Сәрия. Тавышын көрәйтә биреп:

— Ике кызым үсә инде, — дигән булды.

— Ну-у?! Шәп, шәп! Просто молодец... Минем кайтканны итәк тулы бала-чага белән каршыларга булгансың икән.

— Ислам, оныт. Кирәкми. Үткән эштән төш яхшы, — дип кабаланып пышылдады Сәрия. — Ирем, балаларым хакына оныт.

— Куйчы әле! Ирем... балаларым... Кемгә сөйлисең син? Элекке нимфадан болай да коры сөяк калган.

— Нимфалык чоры үтте инде, Ислам. Аның өчен без җәзасын алдык.

— Җәза, имеш... Исламга ни булсын? Дуслар, Аллага шөкер, фатихасыннан ташламый. Әйдә, — Ислам ресторан ягына ымлады, — үткәннәрне искә төшереп, бер типтереп чыгыйк.

— Юк-юк! Миңа кайтырга вакыт, аннан соң эчәргә дә ярамый.

— Йә, изге булып, ялындырып торма. Соңыннан үзеңне таксида гына илтермен оргачыларың* янына, хи-хи...

— Кирәкми. Каенанам чирле. Ирем яшь бала белән калды. Җибәр син мине, Ислам! Үтенәм синнән!

Исламның ияге югары чөелде, күзләре, кысылып, ут ноктасына әйләнде. Бу минутта элекке — Сәрияне «заданиегә» җибәргән Исламга әверелде ул.

— Йә! Бер әйтәм... ике...

Буыны калтыранып, Сәриянең хәле бетте. Беләгеннән кысып тотып алган Ислам:

— Иске мәхәббәт тутыкмый ул, — дип, зәһәр пышылдады.

* * *

Ул көнне кайта алмады Сәрия. Иртән торгач, гарьлегеннән тагы эчте. Шулай атна үтте. Авылдан милиция аша эзләтеп таптылар...

---

* **Оргачы** — ана җенестән; саулык бәрән.

Ах! Хатын күкрәге кысудан күзләрен чытырдатып йомды, һава җитми, ишекләр шар ачык булса да, тыны буылып бара. Почмактагы теге кара әйбер янә чайкала башлады. Әнә тагы кемдер әкрен генә аңа якынлаша.

— Кем син?

— Мин — Бибизата.

— Кайнәм? Син бит үлдең?

— Тәнем җир астына китте, анысы хак. Җаным үземә урын тапмый, өзгәләнә.

— Син миңа бәхиллек бирмәдең, бәлки, шуңа... Синең белән хушлашырга бөтен авыл килде. Мин дә тордым шунда. Күзләрем белән мине кичерүеңне ялвардым... Син ул карашны тоймадың да...

— Тойдым мин, килен. Ә бәхиллек бирмәвемә барыбер үкенмим. Хәзер, Әлмөхәммәтем үлгәч, бөтенләй үкенмим. Балалар таптың — бакмадың. Улымны кабергә тыктың.

— Ах, кирәкми! Кит... Син үлгәч, вөҗдан газабыннан котылдым дигән идем, ә син һаман күләгәм шикелле калмыйсың минем арттан.

— Синең, килен, күләгәң дә юк хәзер, дөресе — син үзең күләгә. Сабыйларың ими сорап елаган, ә синең исереп аунаган чакларыңда үләр алдыннан «авызына тамчы су тамызыр җан иясе булмасын каршыңда» дип каргадым мин сине. Каргышларым фәрештәләрнең «амин» дигән чагына туры килгән икән.

— Тизрәк, тизрәк китсәмче. Үз җанымны үзем алырга да хәлем юк бит!

— Ашыкма, килен. Тыңлап бетер мине. Егерме бер яшемдә тол калып, Әлмөхәммәтемне кеше итәргә бөтен ихласымны салдым. Минем дә җиләктәй чакларым булды. Эчемдә җаным да бар иде. Соратучылар килде — кире кактым. Ирем вафат булганга унбиш ел үткәч, берәүне яраттым. Җаным-тәнем белән тартылдым мин аңа. Төнлә ишегемне шакыды ул кеше — ачмадым...

— Тик... нигә соң ләхетеңдә тыныч ятмыйсың, алай языкларың да булмагач?.. Әлмөхәммәт, ярый инде, балалары өчен өзгәләнә, син бит аналык бурычыңны үтәгәнсең?

— Авырткан җиремә бастың, килен. Дөрес, буен үстердем, акылын камил кылдым, намуслы яшәргә өйрәттем. Хәрәм күрсәм, ирем белән Әлмөхәммәтем күзеннән ышыкладым. Явызлыкның изгелектән әрсезрәк, үрчемлерәк, хәтта кайбер вакыт көчлерәк булуын гына төшендермәгәнмен...

— Кайнәм?! Киттең дәмени...

Сәрия үксеп еламакчы була, тик күкрәге кыса, ирек бирми. «Балаларым, нишләдем мин?» — дип кыймылдый күгәргән иреннәре. Суд залында, сезне миннән аерганда, йөрәгемә кан сауганын тойдыгызмы, сабыйларым? Юк, тоймадыгыз, сез миңа карамадыгыз...

Анда кемнең ни сөйләгәнен дә хәтерләми Сәрия. Иң алгы эскәмиядә утырган кызларына карады да катты. Сабыйларның йөзләре сулган, карашлары игътибарсыз.

Гөлчәчәге күрше хатын Җамал алдында утыра. Ул авылның хатын-кызлар советы рәисе дә. Сәрия аунап ятса, килеп җитәр, балаларны үзләренә алып кайтып йоклатыр иде. Депутат. Орденнары бар. Киенеп чыгып китсә, берәү дә алты бала әнисе димәс. Шул, әлеге Җамал, башын иеп, тынып калган. Алдында утырган Гөлчәчәкнең зәгыйфь аякларына аның күзеннән терекөмештәй яшьләр тама.

* * *

— Толна! Толнакай! — дип өзгәләнә иде ул тавыш. — Аяк билеп китегезче минем туганыма!

...Сәрия тавыш килгән якка ыргылды, сөттәй ак сулышын бөркеп яткан күл буйлап туганын күтәргән Гөлчибәр йөгерә. Сөртенеп егыла, янә торып баса. Ул арада, сызгыртып йөгереп, һавага күтәрелгән торналар төркеме күренде. Баягыдан әчерәк тавыш бәгырьне телде:

— Толналал! Касмагыз, толналал! Мин сезгә тимим, аяк кына билегез. Туганым кызыл басмаклалын киеп йөли алмы-ый!.. — Гөлчибәр үләнгә егылып үкседе. — Үзең соламыйсың да бит. Белүзем кыскылгас, ис-стмәделәл... Әбием әйтте бит: миңа да аякны толналал билде, дип. Аңгыла, син, миңгеләү!

Юк, аяк калдырмаячак торналар аның Гөлчәчәгенә. Теге чакта врачка күренгәч:

— Өченче стадиядә синең чирең. Галлюцинация башланган. Бала табарга ярамый да бит, авырың зураеп киткән, — диделәр.

Сәрия бу турыда Әлмөхәммәткә әйтмәде. Ире, бала тугач та, сабый янына килергә курыккан кебек йөрде. Терсәк якын да, тешләп булмый. Гөлчәчәккә яшь тулды, тәпи басмады, икесен тутырды — атларга уйламый да. Кып-кыска, кәкре аякларына баса да алмый, теле дә ачылмый. Әгәр шушы ятудан тора алса, тумыштан

зәгыйфь балаларны тапшыра торган йортка да бирмәс иде Гөлчәчәген Сәрия.

Хатын кибеп киткән иреннәрен ялады. Судтан соң булган вакыйгаларны хәтерләүдән күз алды томанланды.

— Туктагыз! Ни эшләвегез бу?! — Сәрия Гөлчәчәген киендереп булашкан Җамалга ташланды. — Кит моннан! Кагылма минем балаларыма!

Милиционер егет аның юлын бүлде:

— Комачауламагыз! Сез аналык хокукыннан мәхрүм ителдегез.

Әниләрен исерек дип белгән балалар Җамалның итәгенә сырышты. Олысы кычкырып елый башлады, аңа кечкенәсе кушылды. Ишегалдына җыелган хатын-кызлар үкси. Милиция киемендәге кеше юлларында тормаса, айһай, Сәриягә хатыннар нәфрәтеннән имин калулар тәтер иде микән... Сәрия кызыкайларын алып киткән машина артыннан йөгерде. Сөртенеп егылды, эңгер төшкәнче ятты шунда. Берәү дә торгызмады, берәү дә кызганмады...

Сәрия күзләре белән янә почмактагы кара әйберне эзләде. Шик юк, бәләкәче Гөлчәчәгенең бер тапкыр да киеп йөрергә насыйп булмаган кызыл башмаклары иде алар. Пычрак ябышудан, тузан утырудан алар карайган, төсен җуйган. Күпме вакыт шуларга карап бер саташып, бер янып, бер өшеп ни икәнен төшенә алмый җәфаланды ул.

Сәрияне кинәт шул башмакларны үрелеп алу теләге биләде. Башмаклар, өшеп, җилдә калтырана кебек тоелды аңа.

Бөтен көчен җыеп, хатын терсәгенә күтәрелде. Уң кулы җансыз асылынды. Күз алды аллана, янә караңгылана. Тагы... күп калмады. Чак кына калкына бирде һәм... Сәрия сау кулы белән караватк кырына тотынды. Зиһене югалып, кулын ычкындыра язды. Хәзер, башымны чак кына калкытсам, аякка басам. Бәбкәчемнең башмакларын куеныма алып, җылытып кына ятыйм...

Башмаклар белән аның арасы бер буй җитмәслек ерак, бер яп-якын сымак. Чак кына, тагы ча-ак кына, дип ялвара чатнап ярылган көлсу иреннәре. Сабыйларына барып җитсә, Әлмөхәммәтенең рухы рәнҗемәслек итеп яшәр иде ул...

Торып килгән җиреннән, кулы таеп, Сәрия башы белән тимер караватк читенә бәрелде.

— Ах!

Гөрселдәүдән тәрәзә пыялалары чыңлады. Нәни башмаклар төсле кып-кызыл кан идән буйлап бусагага акты...

— Сөмбел!

Сыртын кабартып әллә кая ашыгып чапкан җәнлекне хәтерләткән кауланлы далага карап катып калган хатын башта сискәнде, шуннан артына әйләнде:

— Аһ! Сез?!

— Кем уйлаган, кем уйлаган... — Олпат гәүдәле, әллә кайдан күзгә ташланып торган матур йөзле Сәмигуллинның якынлашуы Сөмбелдә үзенә хас булмаган каушау тойгысын уятты. «Шушындый мәлдә... кырда очрамаса!..» — Хатынның башыннан шуңа охшаш уйлар йөгереп үткәнче, Сәмигуллин, атыннан сикереп төшеп, Сөмбелнең җилкәсенә кулын салып та өлгерде: — Кая юл тотыш?

— Һы... — Сөмбел куе кара керфекләр белән каймаланган ачык соры күзләрен кыса төшеп көлемсерәде, — әкияттәге егет кебек торам әле: юлның кайсысы...

— Безгә борылганы! — Сәмигуллин ап-ак, тип-тигез тешләрен күрсәтеп, җанны эретердәй итеп елмайды. — Нәрсә, әллә Күчтәнне урап үтәр идеңме?

— Планда... — Сөмбел янә каушады, үзенең каушавыннан үзе тагы ныграк оялды.

— Планны ни... үзебез төзибез бит! — Сәмигуллин арбага ымлады, — йөгең юк...

— Әлмөхәмәткә чыккан идем дә, авыл бәләкәй, әллә ни майтарып булмады.

— Аның каравы безнең авылдан ике планлык әйбер төяп китәрсең!

— Әллә...

— Оештырырбыз! — Сәмигуллин янә Сөмбелнең җилкәсеннән кочаклады. — Әллә... каралып та киткән инде...

— Каралмассың! — Сөмбел, исен җыеп, үз булмышына кайта башлады. — Ха-ха-ха! Карадыр-корадыр, кеше арасында торадыр!

— Кузгалдыкмы? — Авыл Советы рәисе өзәңгесенә басты да атына атланды.

— Әйдә! — Сөмбел дә җиңел генә итеп арбасына сикереп менде, ләкин утырып тормады, аягөсте торган көе кола биясенең кабыргасына нәзек кенә тал чыбыгы белән сыдырды. — На-а! Где наша не пропадала! Бегом марш, кола бия!

* * *

— Алама җыючы килгән! Алама җыючы! Чүпрәк-чапрак, сөяк-санак — бөтенесен дә ала! — Авыл буйлап сөрән салып чапкан малайлар тавышында әле бу, әле теге капкадан башлар күренә башлады.

— Нәрсәләре бар икән? — Әмма малайларда туктап сүз сөйләү кайгысы юк. Алар өчен иң шәбе шул: пәке, сыбызгы бар. Балчыктан ясалган әтәч! Буяу исе аңкып торган шул әтәчләр галәмәт шәп кычкыра. Үзләре төрле-төрле: кызыл, яшел, күк, сары...

Күп тә үтми, урамда шарлар да күренә башлады. Шарның да ниндие — һавасы чыкканда чыелдап күккә очканы!

Иске-москы тапшыручылар арасында арбага якын бара алмыйча, үрелеп, «Йон буявың юкмы?», «Баш тарагы бар, дигәннәр иде...», «Кәҗә тарагы алып килми» кебек сүзләр ишетелде.

Сөмбел аларның һәрберсенә кычкырып, көлә-шаяра җавап бирә:

— Йон буявы? Кайсы җиреңне буярга? Карасы бар, яшеле. Сары матур, сайласаң, сарысы кирәкмиме?

— Атың тибенмиме?

— Курыксаң, якын барма!

— Тешләшә торган гадәте юкмы?

— Нигә, әллә берәр салынып торган артык җирең бармы? Өзеп алыр дип куркасыңмы?

— Моның кадәр алама, сөяк төяп юл йөрергә ничек курыкмыйсың?

— Иһи-и! Боларга ияреп күпме җен китә авылыгыздан! Җеннәр саклый мине.

— Җенле бичәсең икән, алайса!

— Җенгә җен ияләшми!

Ул арада киеме генә түгел, бите дә буялып беткән җиде-сигез яшьлек малай, кеше арасыннан кысылып үтеп, үзе кебек үк пычракка буялган учын ачты:

— Шар бир!

— Акчаң... шушы гынамыни?

— Шушы.

— Бер тиенгә шар тими бит!

— Тия.

— Кая, кит әле, комачаулама!

— Син үзең комачаулама!

— Кит, диләр сиңа!

— Үзең кит.

Сөмбелнең ачуы килде, үзе бер карыш, ә теле!.. Әмма малай моның белән генә калмады, арбаны уратып алганнарның колагын ярырдай итеп:

— Алама җыйгыч, алама җыйгыч, бичура баш, арты кыеш!.. — дип такмаклый башлады.

Аңа тагы бер-ике бала кушылды. Сөмбел аларның тавышын ишетмәгәнгә салыша, менә ул җыелган халыкны көлдерә-көлдерә үзе такмаклый:

Кики-ри-күк!..
Әтәч бездә бик кү-үп!
Шары өч тиен акча,
Алтын тарак — башка,
Алып булмый бушка!
Кики-ри-күк, кики-ри-күк!
Әтәч бездә бик кү-үп!..

* * *

Буявы да, тарагы да, уенчыклары да булгач, алама, чүпрәк-чапрак җыю бөтен авылга таралды. Инде беркемнең дә бер җирендә дә иске-москы яшеренеп калмагандыр. Хәтта чүпрәк палас өчен әзерләнгән йомгаклар да төшкәләде Сөмбел йөгенә. Кардан әле яңа гына ачылган җир сөяк җыючы бала-чага ябырылуыннан чуарланды. Кызыл, яшел саплы пәкеләре дә, бུяу каләмнәре, балчык әтәчләр, шарлар үзенекен эшләми калмады: кыш буе сугым ашы ашаудан җыелган тубык сөякләреннән алып чыгышы һәм вакыты Нух заманнарына тоташкан, саргаеп-караеп яткан сөякләр дә — барысы да яткан урыннарыннан кузгатылды.

— Эш барамы? — Колак төбендә генә Сәмигуллинның тавышын ишетүдән Сөмбелнең гадәттәге аралашу ысулы — шаян сүзлелеге шундук юкка чыкты.

— Бара... — Эчке бер калтырану белән җавап биргәнен, бәлки, бу юлы да Сөмбел үзе генә тойгандыр. Сәмигуллин да баскан җирендә таптаныр да ары китәр. Китсен. Шулай яхшырак булыр. Район үзәгендә очрашкан чакларында ул гел шулай итә: ана каз янында бөтерелгән ата каз шикелле таптана. Шуңа гына аптырый Сөмбел: Сәмигуллин янында ул башка бер ир-ат янында каушамаганча ояла... Китсен иде, тизрәк китсен! Сөмбелгә үзенең чая сәүдәгәрлек рухыннан һич кенә дә тайчынырга ярамый. Халыкның арба яныннан

китмәвенең сәбәбе — Сөмбел үзе. Сөмбелнең чаялыгы, шаянлыгы, сүзчәнлеге һәм хәтта... чибәрлеге җибәрми аларны!

Әмма «сәвит власы» китәргә ашыкмады, чигәсе белән Сөмбелнең чигәсенә тигәнче иелеп пышылдады:

— Кичә... авылга шылтыратырга кирәк, дигән идең бит. — Ул, нидәндер курыккандай, кинәт турайды.

— Әйе... әйткән идем шул... Тә-әк, дустым, пәкегә җитми бит әле акчаң. — Сөмбел чүпрәк-чапрак үлчәтеп янында торган малай белән сөйләшә, үзе күзенең кыры белән Сәмигуллинны күзәтә.

— Сөяк алып килимме?

— Җыеп өлгерсәң... Пәке бетеп бара бит!

Сәмигуллин Сөмбелне уратып алган юеш борыннарның тиз генә бетмәсен аңлады шикелле, ул янә иелеп кайнар сулышын бөркеде:

— Киттек... кәнсәгә!

— Боларны нишләтергә?! — Сөмбел аптырап тирә-ягына күз йөртте.

— Минем хатын... Гәүһәр апаң кабул итеп торыр.

Шунда гына Сөмбел ат артындарак битараф йөзле, озын какча буйлы Гәүһәрнең торганын күрде дә, аңа карап, гаепле кеше кебек уңайсызланып елмайды:

— Мин... озакламам, бәяләре язылган. Малай авырыбрак калган иде. Шуңа... Мин хәзер!

* * *

Арба белән кәнсәләр арасы бик якын кебек тоелды Сөмбелгә. «Бармыйм, шылтыратмыйм!» дияр иде, үзе өчен нишләргә белмәгән Сәмигуллин алдында уңайсыз. Әнә кичә дә бит атны үзендә тугарттырды. Ахырдан бияне ат сараена илтеп куйды, ат караучының күз алдында солы бирдертте, вакытында эчереп, яхшы карарга боерды. Хатыныннан мунча яктыртты, аш салдыртты. Мунчадан соң табынга ярты утыртты һәм кыстый-кыстый Сөмбелне сыйлады. Ә башка авылга алама җыярга барсаң, җенпәри ияртеп йөрисең дип, кеше фатирга да кертми. Монда Сөмбел әйтерсең лә алама җыючы түгел, нәкъ хан кызы!

Мунчадан соң аруы язылып, йөз грамм белән кәефе күтәрелеп киткән Сөмбел сәке түрендә ашъяулык янында утырган җиреннән ипләп кенә Сәмигуллинның хатынын күзәтте. «Болай матур гына, — дигән карарга килде шун-

нан. — Тик бик сүрән. Күзләрендә ниндидер бушлык, битарафлык. Хәрәкәтләре дә бик әкрен, сүлпән. Бу тиклем чибәр иргә хатынның да яхшы аттай уйнаклап торганы кирәк булгандыр да бит. Кызык, Сөмбел Гәүһәр урынында булса, яши алыр иде микән? Бу хатын Сөмбелдән яшьрәктер дә әле, мөгаен, яшьрәктер...»

Йокларга яткач та, Сөмбел иләс-миләс уйларыннан арына алмады. Менә сиңа... көтмәгәндә-уйламаганда дигәндәй... Күчтәнгә килү уенда да юк иде бит. Сәмигуллин Сөмбел язмышында бу авылның нинди урын биләгәнен, әлбәттә, белми. Ул да, аның боек чырайлы хатыны да.

Барысын да Сәмигуллинның юлда очравы хәл итте. Еланнан сихерләнгән куяндай, ничәмә еллар буена урап үтеп йөргән авылга уйсыз-нисез килде дә керде. Ә Сәмигуллин өчен Сөмбелнең килеп чыгуы, бирәм дигән колына чыгарып куяр юлына, дигән кебек булды шикелле. Районда очраган саен, ул Сөмбелне, рентгенттан үткәргәндәй тикшереп карап, урыны туры килсә, капшап китә торган иде. Сәмигуллин өчен Сөмбел кемдер, нәрсәдер — анысы караңгы, мәгәр Сөмбел өчен Сәмигуллин — каршысында үзе каушап кала торган бердәнбер ир.

«Тыныч йокы! — Сөмбел маңгаенда Сәмигуллинның кайнар сулышын тойды. — Изге төш!» — Аннан соң пышылдауга күчкән тавыш: «Төшеңдә мине күр!» — дип пышылдады. Эссе бәрелеп торган йөгерек бармаклар Сөмбелнең күкрәге тирәсендәге юрганны кымтырыклады. Бу хәлдән котылу өченме, уңайсызлануданмы, Сөмбел: «Тыныч йокы!» — дип әйтеп салды. Тавышы да сатарга гына тора бит әле: карлыгыбрак, калтыраныбрак чыкты. Ә хатыны чаршау артында гына, уфтанганы да, көрсенгәне дә ишетелә...

Кызык, менә хәзер алар авыл урамы буйлап парлап баралар.

— Кичәге төн үтмәс кебек иде! — Сәмигуллин, иелә биреп, Сөмбелнең күзенә карарга тырыша.

— Малай... авыртыбрак калган иде, — Сөмбелгә сүзен адәм рәтле итеп әйтеп бетерергә янә калтырануы комачаулады, — әбисе белән генә бит...

Кәнсәләр эченә килеп кергәч, Сөмбел үзен кечерәеп, тәбәнәкләнеп киткән кебек тойды. Яшел постау ябылган өстәлдә телефон. Стенада юлбашчы сурәте. Аның астына акка кара белән «Безнең намус партия намусы белән үлчәнә» дигән сүзләр язылган.

— Утыр... — Сәмигуллин аны иплән кенә мич бу-

енда торган эскәмиягә этәрде. — Әтү озын булып үсеп китәрсең!

— Үссәм ни... Ха!.. — Көлү дә, шаяртуга шаярту белән җавап бирү дә килеп чыкмады.

Сөмбел баш-күз алырга да, контора һавасына ияләнергә дә өлгермәде, Сәмигуллинның кочагында калды.

— Их! — Елгыр, көчле куллар аның биленнән эләктерде, иреннәре кызган келәшчә хөкемендә калгандай булды.

— Аһ! — Нидер әйтергә теләде Сөмбел, ләкин әллә тавышы чыкмады, әллә... — Юк! Ыһ!..

Кайда булды аның батырлыгы, эрелеге, ирләргә баш бирмәс чаялыгы? Нигә әле ул шушы әрсез, комсыз, оятсыз гәүдә астында кечерәйгәннән-кечерәя, көчсезләнгәннән-көчсезләнә, мескенәя, хәлсезләнә.

— Ой! — Иреннәре бер мәлгә генә ычкынган арада Сөмбел тагы нидер әйтергә талпынды. Бәлки, аның авызыннан «Болай булыр дип уйламаган идем, көтмәгән идем» дигән сүзләр чыгарга теләгәндер.

— Курыкма... ишек эленгән...

— Се-ез...

— Бетте, бетте...

Әйе, бетте. Сөмбел үзе белән ни булганын аңлый да, төшенә дә алмый яткан арада, Сәмигуллин, торып, үзен рәткә китереп өлгерде. Җәһәт кенә ишек келәсен ачты да өстәл артына барып утырды. Әнә ул берни булмаган тавыш белән:

— Алло! Коммутатор! Коммутатор! — дип, Сөмбелнең йомышын үтәргә дип, телефон белән бәйләнешкә керә.

Сөмбел исә оялуыннан идән ярыгына керердәй булып эскәмиянең как тактасыннан башын күтәрде, үзенә буйсынмаган куллары белән кендегеннән өскә үк күтәрелгән күлмәген сыпырып төшергән булды...

— Теймәс белән тоташтыр әле, каракаш! — Сәмигуллин телефонистка белән сөйләшкән арада, Сөмбелгә карап күз кысты, янәсе, ашыкма, абыең барда борчылырга урын юк...

* * *

Төшке чәйгә чакырып Гәүһәр килсә дә, Сөмбел бармады. Шулай яхшырак. Балалар да туктаусыз агыла, үзенә дә юлга чыгарга, кояш баеганчы Ирәндекне кичеп өлгерергә кирәк. Бүген ул монда кунып калмаячак.

Сөмбел, атын җай гына атлатып, урамның икенче очына, авылдан чыккан олы юл ягына юнәлде. Җыйган кадәресе дә җиткән бит, ләкин йөкне зур төяп өйрәнгән ул. Кеше бер норма үти алмый – ул икене бирә. Юккамыни аның рәсеме биш ел рәттән Мактау тактасыннан төшми. Менә ул арбада, гәүдәсен туры тотып, аягөсте килә, үзе көлә, үзе такмаклый:

Пи-ип... Таптатам!
Пәке сорап килгәннәрне
Тарак биреп озатам!

Сөмбел үзе көлә, үзе такмаклый, тик күзләре генә нигәдер яшьләнә. Язгы җилгәдер, мөгаен, кояшы көлеп торса да, җиле бит аның ачы була... Ә теге шапшак малайга ни калган инде? Атның алдына төшеп чаба, такмаклый-такмаклый Сөмбелдән үчен ала:

Алама җыйгыч, алама җыйгыч!
Бичура баш, этегыш!

– Кара моны, тотып алып!.. – Сөмбел, арбасыннан сикергән иде, малайларга җитә калды, хәзер инде кемузардан бергәләп үчекли башладылар:

Алама җыйгыч, алама җыйгыч!
Кашы кыйгач, арты кыеш*!

* * *

Сөмбел арбасына кире утырды. Тагы бер тыкрык – бер борылыш үтсә, шуннан соң авыл артта торып калачак. Тик менә... каенлы йорт... тәрәзә капкачлары да сап-сары... Бәй, ул авылның очындарак иде лә... Әйе, әйе, очта иде... Хәер, гаиләләр ишәя, йорт салалар...

– Буявың... бетмәдеме әле?

Тутыккан ишек күгәнедәй көчәнеп шыгырдаган тавышка сискәнеп, Сөмбел артына әйләнде:

– Бар әле, әзрәк кал... – Ике кулы белән дә таякка таянып, үзенә текәлеп торган карчыкны күргәч, Сөмбел телдән язды. Йа Ходай! Шул! Үзе! Коры сөяккә калган үтә ябык бармагындагы йөзеккә тиклем «Бу мин! Үзем!» дип кычкырып тора.

---

* Кыеш – кәкре, чалыш, кыңгыр, кыйшык.

Сөмбел үзе дә сизмәстән арбасыннан төште, кабалана-кармалана чемоданын ачты һәм кирәге чыкса дип калдырылган дүрт пакет буяуны баягы йөзекле бармак хуҗасының учына салды:

— Башка юк...

— Хакын...

— Кирәкми...

— Үзгәрмәгәнсең. — Карчык моны аермачык әйтте, Сөмбелгә ул «Таныдым, шундук таныдым!» булып ишетелде. — Алама җыючы килгән, хатын кеше, Сөмбел исемле, дигәч үк, синдер, мөгаен, дидем... Исемең сирәк бит...

— Әллә тагын... Сөмбелләр белән дөнья тулган...

— Хи-хи, — карчык бер теше калмаган авызын ерып көлүгә охшаган аваз чыгарды, — кайда барсаң да, кара сакалың үзеңнән калмый инде ул!

Ул арада арба янына бала җитәкләгән яшь хатын килеп туктады:

— Ой! Әллә инде китеп тә барасыз? Бу балага шар...

— Шар юк, бетте... сөяккә биргәч, шундук алып бетерделәр.

Бала әнисенең итәгеннән тарткалый башлады:

— Әни, бу инәй сөякне нишләтә?

— Тапшыра...

— Ә нигә?..

— Шуннан тарак, пәке сабы ясыйлар, янә төймә...

— Тагы?..

— Тагымы? Он ясыйлар, сөяк оны.

— Нәрсәгә?

— Малга, кош-кортка ашатырга...

Башка вакыт булса, Сөмбел сүзгә кушылыр, баланың сорауларына үзе җавап бирер иде, әле аның кайгысы юк. Карчык та китәргә уйламый. Урыныннан кымшанмый да хәтта. Ә бит Күчтәнгә килеп кергәч тә, Сөмбелнең башыннан карчык инде күптән гүр иясе булгандыр дигән кебегрәк уй да йөгергән иде...

— Сәмигуллиннарга төшкәнсең икән. — Карчык Сөмбелгә тагы якынрак килде — Шәрифә карчыкның кирәге беттеме инде хәзер?

— Нишләп... — Сөмбел Шәрифә карчыкның сасы сулышыннан арткарак чигенде, — Сәмигуллин таныш бит, район үзәгенә отчёт би... — Әмма аңа сүзен әйтеп бетерергә бирмәде:

— Үзе таныш, хи-хи... хатыны — байгыш!

— Хатынында минем эшем юк! — Сөмбел өйрәнелгән хәрәкәтләр белән йөген рәтләргә кереште: сөяк тутырылган капчыкларны аска, чүпрәкләрен өскә салды. Калган печәнне үзе утырасы җиргә әйбәтләп түшәде.

— Ирең... бармы?

— Бар.

— Алдыйсыңдыр...

— Нигә?

— Нигә дип, нинди ир бичәсен мир буйлатып чыгарып җибәрсен?!

Ул арада кемдер Сөмбелнең җиңеннән тартты:

— Әтәч бир әле!

— Юк! Бетте! Китәм! — Боларны Сөмбел чемоданын карап та тормый кычкырды.

— Абау-абау! — Карчык арбасына менеп барган Сөмбелнең итәгенә ябышты. — Кал бүгенгә! Сөйләшеп ятарбыз! Карт дөнья куйды, ялгызмын...

— Авыр туфрагы җиңел булсын. — Арбасына күтәрелгәч, Сөмбел үзен иркенрәк хис итте.

— Малай тәки өйләнмәде.

— Нигә?

— Җүнле кыз бармы? — Карчык таягы белән түбән очка күрсәтте, — әнә син төшкән Сәмигуллинның сеңлесен ярәшик дисәм: «На чёрт миңа сдалась — ике бидрә сөт!» — диде дә куйды. Аптырыйм: элек ирләр хатын-кызның түшле-башлы булганын ярата торган иделәр, бу коргыры... Аптырагач, прыкашшикның кызын яучылыйк, дип карадым. «Нужна! Бер арба сөяк!» — дип мәсхәрә итте, хаин... Хатын булып, бала табып куйса, ит кунар, дип тә карадым — тәки риза булмады.

— Мин ашыгам, инәй...

Шәрифә карчык моны әллә ишетмәде, әллә ишетмәгән булды:

— Сөяк дигәннән... син дә малай-шалайдан авыл тирәсен весь чукыттың, әллә инде Күчтәндә сөяк дигән нәмәстә калмасын дисеңме?

Карчыкның соңгы сүзләре йөрәген телеп үткәндәй булса да, Сөмбел сер бирмәде:

— Сөякне ни аны... җыеп торасың — чыгып тора! — Сөмбел, дилбегәне бөтереп тартып, атның башын олы юлга борды. — На, малкай!

Шәрифә карчыкның мондый очрашуга һәм хушлашуга риза булмаганы йөзенә бәреп чыкты:

— Китсәң кит! Тоткан кеше юк! Тик әлеге... бер кирәк кеше гел кирәк, дигәнне онытма!

— Юл кешесенең юлда булганы яхшы, дип тә әйтәләр!

Авыр йөк күтәргән тәгәрмәчләр астында таш шыгырдаганы, колак ярырдай балчык әтәчләр кычкыруы, шарларның чыелдап һавага күтәрелүе, малайларның «Алама җыйгыч, алама җыйгыч!» дип кычкырулары астында арба кузгалып китте. Ат кәнсәләргә җиткәч, Сөмбел башын күтәрде. Болдырда ул тора — Сәмигуллин. Менә ул елмаеп Сөмбелгә каршы атлады:

— Мин дә бүген юлга чыгам, район үзәгенә!

— Шулаймыни?! — Сәбәбен аңлата алмаса да, Сөмбелнең йөрәгенә җылы йөгерде. Шәп! Шәп бит бу?!

— Тик мин... — рәис бер үк вакытта көрсенгәндәй дә, елмайгандай да булды, — бу яктан, Сибай юлыннан китәм. Төрекмәндә иптәшләр көтә, шулар белән чыкмакчымын...

— Ә-ә... Әлбәттә, әлбәттә...

Сөмбелнең үтә дә ягымлы, ваемсыз тәтелдәве Сәмигуллинны аптырата төшеп шикелле. Капыл җитдиләнеп:

— Безгә кереп чәй эч, Гәүһәргә әйттем, — дип кычкырды.

— О, юк! Өч сәгатьтән мин өемдә әнием, улым белән аяк сузып утырып эчәчәкмен! На-а-а, кола бия! Шагом марш, малкай!

Кола бия әллә кичтән солы ашап хәл җыйганга, әллә хуҗабикәсенең хәлен аңлап, авыр йөген курчак кадәр дә күрмәгәндәй, Күчтәннән уйнаклап чыгып китте.

* * *

Күчтәннән чыгып, Ирәндеккә җитәр-җитмәстән, ат үшәнләнә башлады. Бу яктан Ирәндек озын — күтәреләсең дә күтәреләсең. Җитмәсә, юл начар, тау куеныннан ургылган йөзләрчә чишмәләр юлны юып, ташлары калыккан. Монда арбаң ватылса...

— Тфү, тфү, — Сөмбел җилкәсе аша карап төкеренде, — мин уйламадым, шайтан уйлады.

Халык телендә «Купис күпере» дип йөртелгән кичүгә җиткәч, Сөмбел атын туктатып, арбасыннан төште. Элек, сугышка тиклем, атасы белән ялан ягына утын, миллек, балан сатарга йөргән чакларында, шушында туктап, чәй

кайнатып эчеп, ат эчереп китә торганнар иде. Аннан бирле күпме вакыт үтте, ә елга шул ук, аның эчендәге ташлар да... Су төбеннән бер уч таш алып, Сөмбел аларны тәү күргәндәй җентекләп карый башлады. Нинди генә төсләр юк монда! Кызыл, сары, яшел, күк, кара, ак... Хет муеныңа муенса итеп тезеп так! Әмма алар, судан чыккач, җилдә кибә, тоныклана, табигый матурлыкларын җуя башлады.

— Их! — Сөмбел көрсенде. Менә аңа да күңелендә сөюгә охшаш тойгы йөрткәндә рәхәт иде, яшәве күңелле иде. Әмма күңелен ачуы булды — хисләре сүрелде, күңеле ташландык кош оясына охшап калды. Хәзер инде ул районга «Бәлки, Сәмигуллин очрар...» дигән җылы өмет белән юл тотмас. Һәм, гомумән, бармы икән ул мәхәббәт? Бәлки, ул, шушы су төбендәге балкыш кебек, алдакчыдыр.

Әлбиртнең атасы белән дә Сөмбел яратып кушылмады. Утызга җитте, сөяргә баласы юк. Үч иткәндәй, күршесенең улы туды. Бер кергәнендә Сөмбел бишектә яткан баланы күтәреп алды да күкрәгенә кысты:

— Их, исләре!..

Күршесе ана арыслан җитезлеге белән баланы Сөмбел кулыннан тартып алды:

— Бәби теләсәң, үзең тап!

Көтелмәгән мөнәсәбәттән Сөмбел рәнҗеде:

— Ярый, — диде ул, берникадәр вакыт таш сын кебек катып торганнан соң, — табармын!

Һәм тапты. Күршесенең ирен бер төнгә кертеп чыгарды. Бары бер төнгә. Хәзер әнә, шул төннең шаһиты булып, күршесенең малаена ике тамчы су кебек охшаган Әлбирте йөгереп йөри...

* * *

Су эчеп, тамагын чылатып, юынып-чистарынып алгач, Сөмбелнең кәефе күтәрелә төште. Аның күңелен күзгә кергән чүптәй кырып торган вакыйгалар елганың теге ярында калгандай булды. Хәзер иң мөһиме — йөкне исән-имин көе кирәкле урынга илтеп бушату. Ни дисәң дә, хөкүмәт әйбере бит. Элегрәк, яшьрәк булдымы икән, курыкмый иде, хәзер шүрли. Аннан соң Әлбиртенә самокат алу-алмау да шушы йөкнең язмышына бәйләнгән. Күршенең малаенда ни күрә, шуны сорый бит шул бала! Сөмбел үзе дә аны аталы балалардан ким киендермәскә, ким йөртмәскә тырыша. Тик тырышу беләнме? Бәндә уй-

лый — Ходай боера дигәндәй, былтыр тик торганда сыеры казаланды. Аптырагач, башмак кына булса да, сыер сатып алдылар. Бөтенесе бер кесәдән чыга. Дөресрәге, кереп тә өлгерми — чыга. Самокатка дигән акчаны да ул авызыннан өзеп җыйды, үзе бит оекның оегын ямау өстенә ямау салып кия...

Ләкин Сөмбелгә үз уйларына бирелеп, оеп озак барырга туры килмәде. Кола бия башта азга, Ирәндектән ераклашкан саен, озаккарак туктый башлады. Әллә... Сөмбелне ул күптән шикләндерә: көзен рәиснең кара айгыры тирәсендә күп уралды. Аңламаса аңламый икән хайван: күпме колын салды! Эх, малкай... син дә колынчак ияртеп, кешнәшеп өердә генә йөрер идең дә бит. Кая инде, атлар җитешми. Бия дип тормыйлар — тоталар да җигәләр... Ә табигать барыбер үзенекен итә...

Йөген этеп, арба артыннан килгән Сөмбел юл читендә үскән умырзаяларга күз салды: әнә алар да, вакытлары җиткәч, кар ачылыр-ачылмастан күксел күзләрен күк дөньяга ачканнар да үзләре бер бөек ямь, бөек мизгел ясап утыралар. Сизә Сөмбел: атының хәле беткәннән-бетә. Ә шулай да рәхмәт сиңа, кола бия! Яхшы-яман каршында сынатмадың, Күчтәннән патшабикә утырткан тарантасны тарткан канатлы ат кебек атылып чыгып киттең!

* * *

Сөмбел инде итегенең куныччыннан баткак ерып, арбаны куллары белән генә түгел, бәлки, иңбашы белән дә этеп килә.

— Әйдә, малкай! Әйдә, акыллым! Ирәндекне менеп алсак, калганы сөзәк бит, ничек тә атларбыз, барып җитәрбез! — Сөмбел маңгаеннан күзенә агып төшкән тирләрен кул аркасы белән җәһәт кенә сыпыра да янә чытырман кебек арбага ябыша. — Йа Ходай! Әлбиртемнең бәхетеннән генә атыма көч бир инде! Шулкадәр йөк белән кырда кундырма инде... Инде Сөмбел кай тирәдән барганын да абайламый, этә дә этә. Менә кола бия шып туктады. Эре сөякле ябык башын түбән иеп, чайкала биреп торды да ава башлады. Сөмбел җәһәт кенә ияр бавын чиште, дугасын ычкындырды...

— Всё! Приехали! — Йөк өстенә бая салган печәнен алып, Сөмбел ат алдына салды. — Аша, малкай, ял ит, бәләкәчем...

* * *

Атын ял иттерергә куйгач, Сөмбел тирә-ягына күз салды. Кая карама, каеннар, тау-таш, кыялар... Янында гына зур бер чокыр, бирерәк җиргә ятып дигәндәй үскән карт каен. Утырып хәл җыярга да, ятып ял итәргә дә ничек тә уңайлы. Җылы кояш нуры, зәп-зәңгәр күк гөмбәзе астында берьялгызың бер кайгысыз утырсаң да утырсаң иде! Арыткан. Буыннар, сулкылдап тартышып сызлап, ял сорый. Арбада суы да бар шикелле — торасы килми. Шушы килеш ойыйсы, тынасы, йоклыйсы, онытыласы... Әнә каеннар кебек. Тып-тыныч, ап-ак каеннар кебек. Юк, алар да әйләнә, имеш! Аһ, аһ... Болар чокыр тирәли әйләнә, әйләнү генә түгел, җырлый да башладылар. Сөмбел дә түгәрәккә басты. Үзе әйләнә, үзе сугыш вакытында бала гына көе отып алган җырын җырлый:

Әлиләү-бәлиләү — кырлары,
Бәлиләү-әлиләү — урманнары.
Бөтенесе утын кисә Башкирия кызлары,
Бөтенесе ударница Башкирия кызлары...

Кинәт Сөмбел үзенең башка кызларга охшамаганын аңлап калды: алар барысы да актан киенгән, бер ул гына кап-кара. Аякларында итекләр, өстендә сырма тун... Юк-юк! Китәргә, качарга...

— Тукта әле, кызыкай! Артыңнан чак куып җиттем, ничек шәп киткәнсең!

— Аһ! Син?!

— Мин, мин, Шәрифә апаң.

— Син нигә...

— Нигә дә нигә... Нәрсәң торып калды миндә?

— Ә-ә... йөзекме? — Сөмбел, теге кашыннан нур чәчеп торган йөзекне күрергә теләп, карчыкның кулына иелде, ләкин...

— Бала?! Нигә китерден аны монда?!

Шәрифә карчык кызлар кебек кеткелдәп көлеп җибәрде:

— Имезеп бир.

Сөмбел өйрәнелгән хәрәкәт белән әле бер, әле икенче күкрәген капшады: сөте бармы икән соң?

— Тиз бул! — Сөмбелнең борынына карчыкның сасы сулышы бәрелде. — Арттан бит куа төштеләр!

— Бир! — Сөмбел сабыйны карчык кулыннан тартып дигәндәй алды. Алды да аптырашта калды: баланың

күзләре нәкъ умырзая, юк, чын умырзая! — Балам! Сабый гынам!..

Сөмбел кызын имезә дә башлады, ул арада икенче күкрәге дә тулып китте, аннан туктаусыз сөт ага... Әнә ул, җыелып, күлләвек ясады. Шәрифә карчык учлап-учлап шуны эчә?!

— Нишләвең бу, инәй?!

— Агарам, тазарынам...

— Нәрсәдән?

— Ничек «нәрсәдән»... Баланың сөякләрен төяп киттем дә котылдым дигән иденме? Эч, син дә эч, тазарын! Баланы бит... икәү үтердек!

— Ләкин ул тере! Менә ул! Менә!

— Кайда?! — Кара карчык тешсез авызы белән хихылдап көлә. — Кайда?! Сөмбел бала тоткан кулларына карады, ләкин алар буп-буш. Йөзеге генә тора бармагында. Атасы бүләк иткән, кашлы, нур чәчеп торган йөзеге.

— Балам!!!

Үз тавышына дертләп уянган Сөмбел күзләрен ачты. Аһ! Кайсы... Йа Ходай... Төш икән! Абайламый утырган икән, бу каенга сыенып үскән икенче бер каеннан сут тама, Сөмбеләнең иңбашы ару гына юешләнеп тә өлгергән...

— Төш!.. — Сөмбел карашын атына күчерде: кола бия ашыкмый гына печән ашый, колын салырга җыенуы, шөкер, тоелмый. Арба да, йөк тә урынында, кояш кына менә баюга табан нык кына авышкан... Кисәк кенә җил исте. Яфраклары уяныргa өлгермәгән урманнан нindидер таныш ис бәрелде. Бу ис җирнең эченнән, карынынан килә бугай. Әйе, әйе... умырзая исе бу! Җир карынын төртеп чыккан тәүге чәчкә исе. Яңа гына туган сабый да шулай аңкый. Күчтәндә ятып калган сабыен Сөмбел үзе күрмәде. Сабыйның дөньяга чынлап та тууының бердәнбер дәлиле булып шул ис саклана аның күңелендә. Әлбиртенең дөньяда барлыкка килүенә дә, бәлки, шул ис сәбәпче булгандыр... Әчке бер сагыш белән шул исне сагынгандыр. Төш төш инде, аның нindие юк. Мәгәр әле күргән төше Сөмбел күңеленең иң тирән төркеменә бикләнгән хатирәләрне кузгатты. Аяз көндә көтмәгәндә калыккан болыт кебек, йөрәгенә шом салды.

Күчтәнгә ул чак Сөмбел төнләтеп килеп җитте. Авыл йоклый иде. Иң читтәге өйнең генә тәрәзәсендә яктылык күренгәндәй. Сөмбел кыюсыз гына тәрәзә шакыды.

— Кем бар анда? — Карлыгыбрак чыкса да, хатын-кыз

тавышын ишеткәч, аның йөрәгенә җылы керде: мөгаен, җәлләр, мөгаен, кертер...

— Инәй, мин — Сөмбел! Кунарга керт инде, зинһар!

— Тагы кем бар?

— Ялгызым.

Карчык Сөмбелгә үзенең хәлләрен чәй артында ук сөйләп бетерде. Карты фронтта, ләкин сугыш барган җирдә түгел, урман күп җирдә агач кисә. Агачны ул сугышка бармаса да кисәр иде. Нигә алдылар икән? Ялгыз улы бар, аны Магнитка ФЗӨгә алып киткәннәр. Ходай үзенә нишләптер кыз бирмәде. Җәлләде. Сөмбел ише генә кызы булса, ялгызлыкның ни икәнен дә белмәс иде Шәрифә...

Сөмбел дә үз чиратында үзе турында сөйләде. Әтиәнисенең бердәнбер баласы. Атасы сугышта иде, әле әнисе «хәбәрсез югалды» дигән хат алган. Көчкә йөргән әнисе хәзер чирләп түшәккә егылган. Сөмбелне урманда агач кисүчеләргә кеше тапканчы гына дип аш пешерүче итеп җибәргәннәр дә онытканнар. Атасы хакында хәбәр килгәч кенә, әнисе силсәвит аша кайтаруларын сорап хат җибәргән. Хәзер менә Сөмбел кайтып бара. Тагы утыз чакрым юл үтсә, әнисе янында булачак.

Әгәр дә вакыйгалар шулай гына барса, Шәрифә белән яшь кыз чөкер-чөкер сөйләшерләр дә, башлары ястыкка тигәч, арудан эреп, йокыга китәрләр иде. Әмма башта мич башында яткан песи туп кебек сикереп төште, аннан тамак төбе белән мияулап, Шәрифәнең өстенә сикереп менде.

— Ой, коргыры! — Кисәк куркып торган карчык аны ишек төбенә атып бәрде. — Кышкы чилләдә ишегемне тырнагач, җәлләп керткән идем, әллә буаз булган инде?!

Сөмбел аны ишетә дә, ишетми дә кебек: күз кабаклары үзләреннән-үзләре йомыла, җәяү килүдән кан сауган аяклары таштай катты. Песи инде аның аяк очында мырылдагандай...

— Ой, хәшәрәт!

Шәрифәнең тавышынамы, әллә үзенең авыртуыннанмы, түзә алмыйча, Сөмбел күзләрен ачты, сәкедәге җиделе сукыр лампа тонык кына яктылык чәчә, каршысында Шәрифә карчык, кулында кыскыч.

— Нишлисең син, инәй?! — Коты алынган Сөмбел торып утырды.

— Тукта, буялып куйма, менә ләгънәт куеныңа балалаган бит...

— Ой! — Аптыраган, чирканган Сөмбел арткарак чигенде.

— Утыр, утыр, икәү генә калды. — Карчык чеп-чи, ләкин кыбырдап торган ит кисәген, кыскычы белән кысып, ишек төбендәге сулы чиләккә чумдырды. — Берәрсен алып калмакчы идем дә, рәтләләрен тапмадым. — Шәрифә соңгы тере йомгакны да чиләккә чумдырды.

— Ыһ! — Сөмбел каты итеп биле тотудан боргаланды, — уй-й-й...

— Аһ, аһ... курыктыңмы әллә?!

— Эчем! Билем...

— Ай-й-й... Өч йөз чакрымны җәяү кил дә, уен эшме! Җитмәсә, ала кар мәле. Вис кенә суык тидереп беттең инде... Эй-й... минем балам да әллә кем тупсаларында, әллә нишләп кенә ятадыр инде... Әле бит синең урман кисү түгел, курчак уйнап кына утырыр чагың...

— Уй! Үләм, үләм...

Юрган ябынып яткан карчык янә торды.

— Бер дә басылмыймыни? Кая, салават әйтеп, сары май белән биленне уам... Бисмилләһир-рахмәнир-рахим. — Кисәк Шәрифә кулын утка пешкәндәй тартып алды... — Бәтә-әч... авырың бар әллә?!

— Нәрсә?

— Аны нигә күптән әйтмәдең?!

— Нәрсәне?

— Корсагыңны!

— Мин... корсаклы?!

— Абау-абау... Инде хәзер миннән сорый... Мавыккан нәрсәң булгандыр?

— Юк! Юк! — Сөмбел акырып елап мендәргә капланды... — Юк!

— Абау-абау, кыз килеш корсакка узмый кеше, йоклагансыңдыр. Әллә берәү ябештеме?

— Җиде ай элек, урманга баргач та, ыһ... ул... нишлим, нишлим, инәй... Үләм... үләм дә куям...

— Ай әттәгенәсе... керт сезне фатирга... — Шәрифә, торып, нигәдер киенеп алды. — Авыртмаган башка тимер таяк булдыгыз бит!

Инде Сөмбел үзен-үзе белешми бәргәләнә, үрсәләнә, акыра. Менә ул, бәргәләнә торгач, сәкедән идәнгә егылып төште, идән генә түгел, стена, мич канга манчылды.

— Әни!.. Үләм, әни!.. Әни-ии!!!

Кинәт борынына ят, ләкин... таныш ис бәрелде. Җир карынын ярып чыккан умырзая исе иде бу.

— Ой-й-й... — Сөмбел тынды.

Һуштан язган Сөмбелнең истә калганы әнә шул ис булды.

* * *

— Кызыкай, ач күзеңне! Син тереме, юкмы! Үлеп китсәң, башкынаемны ашыйсың бит! Йә, кем ышана, баласы үзе төште, дигәнемә?! — Сөмбел күзен ачмакчы да, булдыра алмый. — Кызыкай... Сөмбел! Бердәнбер баламның бәхетеннән ач күзеңне!

— Су...

— Ә?! Су ярамый сиңа... Иренеңне генә чылатам...

— Мин... кайда?

— Абау... миндә. Шәрифә инәңдә...

— Мин... нишләп монда?

— Нишләп дип... үзең килеп кердең бит. Бәбәйләдең.

— Бәбәй?!

— Әнә ята, әнә! Җитлекми туган, песи баласыннан чак зуррак...

— Юк! Дөрес түгел! Юк! — Сөмбел аңы керделе-чыктылы хәлдә якын-тирәсендәге чүпрәк-чапракны алып ата башлады. — Юк минем балам! Мин үзем бала! Әни!..

— Ай! Гөнаһ шомлыгы... Бала бит ул! Кызың! — Карчыкның кемгә төбәп, ни өчен шулай кычкырганын Сөмбел аңламады...

* * *

Уянгач, Сөмбелнең тәүге уе шул булды: рәхәт кенә итеп, йокысы туйганчы йоклап алды. Тик нигә өй шулай караңгы? Ә әби нигә мич алдында моңаеп утыра?

— Инәй...

Карчык дертләп сикереп торды:

— Син...

— Нәрсә булды?

— Үлдең дип уйлаган идем. Закон каты бит хәзер! Ак тәүбә, кара тәүбә! Инде дә фатирга кеше кертсәм! Инде дә Ходайга кызым юк дип зарлансам!..

Сөмбел торып утырды. Үтереп ашыйсы килде.

— Мин ачмын.

— Бер токмачлык кына итем бар, малай кайтса дип саклаган идем.

— Ә нигә тәрәзәләр корулы? Төнме хәзер, әллә...

— Уй-й-й... Тәрәзә дисең, — карчык сулкылдап елап җибәрде, — баш китә иде бит! Баш...

— Ә... — Сөмбел фатир хуҗасыннан, ни булды, ни өчен көяләнәсең, дип сорамакчы да — нидер тыя. Әле аңа бик тыныч, бик әйбәт. Озын юл да, ару да — берсе дә булмаган кебек. Карчык та аңа ифрат мөлаем күренә, әйтерсең лә ул беркайчан да... песи балаларын кыскыч белән кысып, сулы чиләккә батырмаган. Песи балалары исенә төшкәч, шулай да Сөмбелнең тәне буйлап көзән җыергандагы сымак калтырану үтте. Кинәт зиһене яктырды да, идән тулы кан, үзенең ыңгырашып-елап шул кан эчендә боргалануы исенә төште.

— Инәй?!

Сөмбелнең, коты алынып, кычкырып җибәрүенә карчык аптырамады да шикелле:

— Оныт, — диде ул Сөмбелгә якын ук килеп, шуннан теге песи балаларын батырган чиләккә ияге белән ымлады. — Барысы да... Бергә түгелде инде, абзар артына, чүплеккә... Оныт...

— Инәй!!!

— Әй бала... — Фатир хуҗасы аңа мәтрүшкә исе аңкып торган чынаяк сузды. — Эч шушыны... Гөнаһын икәү күтәрдек. — Шуннан ул Сөмбелнең бармагындагы йөзегенә төбәлеп каравын сизде микән, тизрәк аңлатма бирергә ашыкты, — идән ярыгыннан таптым, берәрсенеке төшеп калдымы, әллә... синекеме?

— Минеке иде, әтием бүләк иткән иде, сиңа булсын... — Сөмбел чынаягына агып төшкән күз яшьләренә кушып, мәтрүшкәле чәен чөмерде.

— Йә, ярый. — Инде Шәрифә шактый җылы эндәште. — Тагы ике көннән кайтып китәрсең. Шул якка олау бара, сөйләшкән идем...

* * *

Әле күргән төше һәм истәлекләр әсирлегендә калган Сөмбел янә төяп килгән йөгенә карады. Бәлки, шушы йөкне бу тирән чокырга бушатырга да өстенә борынгы дәрвишләр кебек биек итеп таш өеп китәргәдер? Шул рәвешле күргән төшен дә, күңелен сырландай сырып алган хатирәләрен дә күмеп, җирләп китәргәдер? Шә-

рифә карчык картайган, нык бирешкән. Күпкә барыр дисеңме? Йа Ходай! Кайчандыр рәхмәтләр әйтеп бетерә алмаган кешесенә Сөмбел бүген үлем тели түгелме?

— Тфү, тфү... Кичер мине, мәүла?! — Сөмбел беркавымга йөк белән чокыр арасында икеләнеп тора бирде: бу йөкнең дә үз урыны, тәгаенләнеше бар шул, авылдан авылга йөреп, хөкүмәт товарына алмашып җыйган йөк.

Ул арада ашап туйган ат эчәсе килеп пошкырды. Сөмбелнең күзе янә аяк астындагы умырзаяга төште. Шулчак колагына әнисенең:

Умырзая гөлнең гомеркәе
Кар сулары агып киткәнче.
Елар гына идем, ай, туйганчы —
Яшькәйләрем кибеп беткәнче, —

дип җырлаганы чагылгандай булды.

Әйе, Сөмбел күзләрендә дә яшь күптән кипкән. Күрендә, агач кискәндә коелып бетеп калдымы ул, әллә Күчтәндә, Шәрифә карчык өендә кот очмалы төн алып калдымы... Бүген генә Күчтәндә ни сәбәпледер яшьләнеп алды, күрәсең, яз шулай тәэсир итәдер. Ярый әле кола биясе сынатмады. Сөмбел тәвәккәл хәрәкәтләр белән камыт бавын бәйләде, инде кич, мөгаен, Теймәскә яктыргач кайтып керерләр.

— На-а, малкай!

Сөяк, иске-москы төялгән арба, ташлы баткакта авыр шыгырдап, чирәмнән юлга төште. Сөмбелдә хәзер бер генә теләк: аты гына тартсын, йөген исән-сау бушатса, улы самокатка атланыр. Үзе исән чакта, Әлбиртен аталы балалардан ким яшәтмәс.

Кояш баерга бер аркан хәтле калды. Сөмбел, йөген йә арттан этеп, йә яннан булышып, итеген аягыннан суырып алырдай булып ябышкан баткакны ерып, алга бара. Читтән караганда, йөк аны сөйриме, әллә ул йөкнеме — әйтеп булмый...

АЙЛЫ ТӨН

Аларның өе Хәләф Уелдановларныкыннан тик стена белән генә бүленсә дә, тыштан ук аерылып тора. Уелдановлар бу йорт салынып бетү белән ничек чыкканнар, шулай тора бирәләр. Шул вакыт эчендә өйнең алдында да, артында да җимеш бакчасы барлыкка килеп, биек рәшәткә белән уратып алынган, ихата эчендә дә бөтен нәрсә ялт итеп тора, монда чәчелеп-тузгып яткан әйберләрне күрмәссең. Совхоз ике катлы йортлар салдыра башлагач, бухгалтер буларак, Хәләфкә беренчеләр рәтеннән үк фатир тәкъдим иткәннәр иде, ләкин ул баш тартты.

Дүрт бүлмәле йортның калган ике бүлмәсе, киресенчә, хуҗалардан уңмады: күчеп килә-китә тордылар, рәшәткә эчендә кычыткан, алабута котырып үсә, кайчандыр акка буялган өйнең балчыгы кубып-ярылып беткән, тик мәктәп балалары утырткан тирәкләрнең өч-дүрте генә исән калып, ихатаны икегә ярып, шаулап яфрак ярып утыра.

Өйнең икенче яртысында кайчан, кемнәр яшәп киткәнен бәйрәмнәрдә шактый кызмача булып алган Хәләф белән хатыны Фәрхиҗамал гына искә ала.

— Теге Галимнәрдән соң торган Нәкыйп ни дип җырлый торган иде әле?

— Хәтерең бар булгыры... — Хатыны, яулык очы белән авызын каплап, җырын исенә төшерде:

Мулла, мулла — мутына,
Мулла тәмуг утына...

— Ә-һә-һә... Белдем... искә төште, — дип җанланып китә Хәләф Борһанович.

Муллабызның күзе төшкән
Остабикә ботына.

— Эхе-хе-хе-хе!.. Шулай итеп, син дә, Фәрхи (хатынына кеше юкта ул шулай эндәшә), симереп киттең, ә? Симерми, картыңның җилкә нык шул, эх-хе-хе-хе...

Моңа каршы күңеле күтәрелгән Фәрхиҗамал да башы белән тоташ иңбашларын селкетә:

— Нәкыйп җырлар ул. Шуннан башка нәрсәгә ярый ул?

Хатыны авызыннан ишетергә теләгәнен ишеткәч, Хәләф, диван очында яткан зур ястыкка янтая биреп, йомшак йон оек кигән аякларын өскә ала.

— Шуның ише эшлексезләргә эләксәң нишләр идең, ә, Фәрхи? Май эчендә йөзгән бөер шикелле яшисең бит... Теге чак атаң, карун Борһан малаена бирмим, дип, дау куптарган булды. Хәзер кызының тормышын күрсә, ни дияр иде икән, ә?..

Фәрхиҗамал, көлүеннән туктап, бик сирәк җылына торган кара күзләрен тутырып, иренә карый:

— Шулай инде, юк талаштыра, бар ярәштыра, иншалла, булганына шөкер.

— Ту-ты... Кешечә яшәр өчен барысыннан элек баш кирәк бит, башың йомры булмаса... — Хәләф Борһанович, тамак кырып, яткан җиреннән торып утыра, каплаган чынаягын кире утыртып, хатынына этә: — Булмаса, берне яса әле...

Бу гадәттәге тормыш икенче якка яңа күршеләр күчеп килгән мәлдә генә бераз бозылып тора. Уелдановлар мондый көннәрдә теге якны күзәтә. Бу хәл күршеләрендә үзләре көткән нинди дә булса бер кимчелекне (эчкечеме, ялкаумы, ялганчымы) күргәнгә тиклем дәвам итә. Үзләре көткән «прогноз» дөресләнсә, Хәләф Борһанович аеруча җанланып, шул ук вакытта җитдиләнеп китә. «Фәһем ал, гыйбрәт ал!» — ди аның бөтен булмышы. Шулай дими, кеше тормышын чагыштырып карамый торып, үз тормышыңның бөтенлеген, ныклыгын кайдан беләсең?

Мондый чакларда ир белән хатын аеруча дуслашып китә, йоклар алдыннан да, ашаганда да сүз шулар хакында бара.

Әле дә алар теге якта дөбер-шатыр килә башлагач, песи шикелле басып, стенага колакларын терәп, тынып калдылар. Күрше якта әйбер күчергән, чөй каккан, балаларның көлгән-шаярган тавышлары ишетелгәч, авызыннан имчәген тартып алган баладай турсаеп, кире урыннарына утырдылар. Башта Хәләф Борһанович, телгә килеп, кул селтәде:

— Һи, күпкә барырлар дисеңме?

Фәрхиҗамал да, бәйли башлаган оегын кулына алып, иренең сүзен җөпләде:

— Әй-йе, тәүге эш хакы алганчы инде, күченеп килгән машиналарын бушатканнарын карап тордым — затлы бернәрсәләре дә юк, шакы-шокы да тимер-томыр.

* * *

Уелдановлар көткән эчкечелек, ыгы-зыгы күрше якта акча алган көннәрдә дә, аннан соң да булмады. Көн дә иртән кечкенә гәүдәле юка хатын, капка тышына ук чыгып, үзеннән ике тапкырга озын, киң җилкәле көләч чырайлы ирен озатып кала да соңрак, ике кызын җитәкләп, балалар бакчасына юнәлә, үзе шуннан кире кайтмый, эшкә китә, күрәсең. Бүген дә моны күзәтеп торган Хәләф Борһанович хатынын, ымлап, тәрәзә янына чакырды:

— Тагы чыкты... Ирен озатырга чыкты...

— И-һи-һи, шулай бер алдына, биш артына чыгып ярамаса, әзмәвердәй ир бу күрексез-чирләшкә хатын белән ни дип торсын? Тәнендә чеметеп алыр ите дә юк, китче...

Хатынының тапкыр сүзенә күңеле күтәрелгән Хәләф Борһанович, җанланып, иртәнге чәйгә утырды, тыныч кына сөйләшеп ашагач-эчкәч, өй эчендәге мөлкәтен барлаган төсле, тирә-ягына канәгать караш ташлады, аннан, кикереп, урыныннан торды:

— Эш күп бүген, бичәкәй. Ай азагы, отчёт бирәсе бар. Син сыердан күзеңне алма, бозауларга итсә-нитсә, үземә шылтырат...

* * *

Күгәрчендәй җилпенеп, сылу кыздай бизәнеп-талпынып килгән яз ае — май үтеп китте, җирне куе яшелгә манчып, чәчкә-үләнгә төреп, җәй килде. Хәләф Борһановичлар ягында артык үзгәреш күренмәсә дә, күршеләрендә әле бер, әле икенче нәрсә яңарды: башта төсен җуйган рәшәткәләр зәңгәргә буялды, өйалды бакчасына ике зур, ике бәләкәй (соңгыларын берсеннән-берсе кечкенә кызыкайлары ясады) түтәлләрдә чәчкәләр күренде, алар янында дүрт төп яшь алмагач яфрак ярды, капка баганаларына кагылган колга башларындагы сыерчык ояларында кош балалары чыркылдашты. Күршеләре нәрсәгә тотынсалар да, нәрсә кыбырдатсалар да, ишектән дүртесе бергә чыгып, бергә кайнашалар. Чыр-чу килгән балалары янында әниләре дә нәкъ сабый бала төсле кылана: алар чәбәкәй итсә, чәбәкәй итә, бергә куышып-уйнап китә. Бер эш эшләгәнче мыжгып, бер-берсен күралмас хәлгә җиткән Уелдановларга бу да сәер тоела. Әле дә, тегеләрнең ишегалдына чык-

канын күреп, гөлләргә ышыкланып, тәрәзәгә капландылар.

— Кара әле, Фәрхи, ничек очына теге бичә ире тирәсендә? Май күбәләгемени? Балалары да атасының авызына гына карап тора.

— Әниләре өйрәтә инде, — дип әләктереп алды Фәрхиҗамал, — икенчегә мавыгып китсә, кызларын җәлләр, ташламас, ди торгандыр. Бахыр хатын, бигрәк юк инде, тик чыкмаган җаны гына бар.

— Бичә шулай була икән дип тора да тора микән бу ир? — Аннан Хәләф Борһанович, кулын селтәп, тәрәзә янынннан китеп үк барды. — Һә-ә!.. Юридер ул, тыштан гына яхшатлана торгандыр. Шофёр кешенең авыл саен сөяркәдер әле...

* * *

Шулай бермәл күрше яктан ир кеше иртән балалары белән үзе генә чыга башлады, эштән кайта да, кызларын җитәкләп, кулына сумка тотып, үрге очка хастаханә урамы буйлап китә. «Менә хәзер күрсәтә инде ир кеше, — дип, мыек астыннан көлемсерәде Хәләф Борһанович. — Хөррият. Курку-мазар юк...» Үзе дә яшьрәк чагында, районга отчёт белән барган мәлләрендә, шаяргалап алгалый торган иде. Хәзер дә райбюджетта эшләгән, кочакласаң, колач җитмәс тол хатын Сәвия Хәмитовнаның чәйгә чакыруыннан баш тартмый. «Эһеһе, эһем», — Хәләф Борһанович кулын угалап, ары-бире йөрештереп алды, аннан аш-су тирәсендә булашкан Фәрхиҗамалы каршысына барып утырды.

— Күз алдында әрәм булып йөри бит ирнең асылы, ә, Фәрхи? Күршене әйтәм... Сырхау бичә белән гомеренең заяга үткәнен сизми микән ахмак?!

Фәрхиҗамал да, ире каршысына утырып, сүзгә куәт бирде:

— Урамга чыксалар, парлап атларлыгы да юк, ирне ир иткән дә, хур иткән дә бичә шул. — Ул, тулы беләкләренә кигән көмеш беләзекләрен сыйпап, елмаюын күзенә яшереп, иренә карады. — Ашап алмыйбызмы?

* * *

Алмагачларда җимешләр тулышып, җим җыеп, балачага күзенә чалына башласа, тынычлыгы югала Уелдановның, йокысы качып, төнге берләргә кадәр бакчасын-

нан керә алмый азаплана. Башына мондый төннәрдә төрле уйлар килә, бакча почмагындагы эскәмиягә утырып, мал-туарын, агач-ташын, отчёт, дебет-кредитларын күңеленнән кичерә, үзе буйсынган түрәләрнең холык-фигылен айкый. Шуннан, үзеннән тәмам канәгать булып, ай яктысында моңаеп торган алмагачларына кинәнеп карый-карый, җылы түшәк көткән өенә юнәлә. Нигә? Канәгать булмаслыкмыни? Җиде класс белеме булса да, шоп-шома итеп эшләп килә ул. Яхшымы-яманмы, ни дисәң дә, «тавык» түгел, ә «әтәч». Ул эшләгән дәвердә түрәләрнең ниндиләрен генә очратмады — барысына да мәгәр ярады! Бөтенесенең дә хикмәте башта, дип уйлый ул. Атасы әйтмешли, кәлләнең* йомры булуында. Башың булмаса, егерме ел бер урында, суга баткан таштай уелып утырыр идеңме дә хәвеф-хәтәрсез дөнья көтәр идеңме? Балалары гына булмады аларның... Анысы да әллә ни зур кайгы түгел. Хәзерге заманда бала асрап кем игелек күргән? Болай тыныч та, мәшәкать тә юк. Әнә агасының өч улы бар, өчесе өч яктан тарткалый, бәрәңгесен дә, онын да, акчасын да, башкасын да бир генә.

Үз уйлары белән күңеле хушланган Хәләф Борһанович, торып, сөякләрен шыгырдатканчы киерелеп, өенә керергә иткәндә, койма артында, тирәкләр янәшәсендә хатын-кыз тавышы ишетеп, шып туктады: «Әһә! Әйттем бит... Әнә күр... Әтнәкәсез кеше булмый ул...»

— Юк, Акназар, син күккә бакчы, ул тоташ ак нур җептән сугылган, җирдә дә, күктә дә ак нурлар...

Уелданов үзе дә сизмәстән башын күтәрде: күктә ни булсын — шул котсыз ай тора, ул шундый чекерәеп яктырта, хәтта йолдызлар, тайчынып, төпкә качкан төсле. Ул арада баягы тавыш тагы да хисләнебрәк эндәшә:

— Ә йолдызлар ай белән качышлы уйный, тирәк яфракларына очып кунган. Тыңла әле... Ишетәсеңме? Алар яфракларны йолдыз яме, йолдыз чыңы белән тутырганнар... — Беразга хатынның тавышы өзелеп торды, тыныч төндә тик яфрак кыштырдавы гына ишетелә. — Яфрак түгел, ә йолдызлар шулай чыңлый, Акназар...

Уелданов, тын алырга куркып, җиргә чүгәләде: куе кура җиләге куаклары аша берни күрерлек түгел. Йөрәк тамак төбендә үк типкән төсле. «Йолдыз, имеш... — Хәләф Борһанович кычкырып, юк-бар сүз әйтүдән көчкә ты-

---

* Кәллә (*фарс.*) — баш.

елып калды. Ул утырган җиреннән кул селтәде. — И-и, юньлерәген тапкандыр дисәм, тәмам хыялыйга охшаган монысы...»

— Нинди айлы төн бу! — Хатын хисләргә буылып тынып калды.

Хәзер инде ир кеше телгә килде:

— Үләсем килә хәтта бу чакта...

— Тик мәңгегә түгел, бер минутка...

Шунда ике тавыш бергә әйләнеп пышылдады:

— Бер минутка — синең кочакта!..

Юк! Бу тиклене сабыр гына тыңлап утырырга көче җитмәде Уелдановның. Ни булса, шул булыр дип, битен-кулын сыдырган ботакларга да карамый, коймa янына шуышты. «Кызык та инде, — дип исе китте аның. — Такмак белән (җырны да, шигырьне дә ул шулай атый) сөйләшә башладылар бит. Уендагы (янәсе, спектакльдәге) сымак...» Уелданов койма ярыгыннан тегеләрне күрүе булды, дыңк итеп җиргә утыра язды: әзмәвердәй ир кулында сабый төсле изрәп күккә карап яткан хатын... күршесенең үз хатыны иде. Хатынының янып торган дымлы иреннәрендә, киң ачылган күзләрендә энҗе-йолдызлар җем-җем килеп бии төсле. Ире, Хәләф Борһанович күз алдына китергәнчә, һушы китеп, бер дә күккә бакмаган, ә ай нурында чаларып күренгән дулкын-дулкын чәчләрен тузгытып, хатынының күзләреннән, битләреннән шашып-шашып шул энҗе-йолдызларны чүпли, ә алар чүпләгән-үпкән саен күбәя генә...

— Җибәр, исәр, авырттырасың, канатланып очтым-киттем булыр, — дип көлә тегесе, үзе иренең муенын нечкә куллары белән ныграк коча.

— Җибәрмим, Газизәм, йолдызга да, айга да бирмим, син минем йолдызым, үземнеке генә, дәваханәдә яткан-да...

Газизә кечкенә кулы белән иренең авызын каплады:

— Кирәкми, Акназар, без бергә, ай да, йолдызлар да, хәтта бөтен галәм безнең белән!..

— Газизәм... — Акназар, хатынын күтәргән килеш бөтерелә-бөтерелә, өенә юнәлде, тегесенең колынчактай чыңгылдатып көлгәне ишетелде...

— Аһ! — Уелданов, коймадан аерылып, маңгаен сыпырды — кулы салкын тиргә тиде, беркавымга, миңгерәгән балыктай, хәрәкәтсез утырды, шуннан, оеган аякларын көчкә сөйрәп, бакчадан чыкты.

— Һы, карачы әле... — Хәләф Борһанович, туктап,

җилкәсендә кәбестә кучәнедәй тыгыз утырган башын күтәреп, күккә карады, өйалды баскычына менгәч тә, ишеккә арты белән борылып, тыныч төнгә колак салды: яшь үләнгә туйган сыерның уфылдаганы, кәҗәләрнең мырт-мырт күшәгәне, канат астыннан туганнары этеп чыгарган каз бәбкәсенең пипелдәп әнисен чакырганы ишетелде. Уелданов, шушындый гаҗәп төнне калдырып өенә керергә кыймагандай, кулын артына куеп, арыбире йөренгәләп алды, аннан, баягы «такмакны» исенә төшереп, баш чайкады: — Үләсем килә хәтта, диген, ә... Ну, ма-ла-ай... — Уелданов бөтен битенә җәелгән елмаю белән ишеген ачты — борынына тынчу өй һавасы бәрелде: җиденче төшен күреп йоклап яткан Фәрхиҗамалының кемгәдер сукранганы ишетелде. Хәләф Борһанович, күзләре караңгыга ияләшкәч, диван читенә утырып, ашыкмый гына чишенә башлады.

Бичәсе уянып, йокылы тавыш белән:

— Бакчаны нык бикләдеңме? Сыер кереп, түтәлләрне таптамасын... — дип мыгырдады.

— Япты-ым. — Хәләф Борһанович, кинәт күңеле төшеп, ачуланып, хатынына терсәге белән төртте: — Кит тегеләйрәк! Ни, туйган сыер шикелле уфылдап ятасың...

Фәрхиҗамал, көчкә кыймылдап, гәүдәсен эчкәрәк күчерде, аннан:

— Төне буе йөрергә этем кушкандыр сиңа, — дип мыгырдады да йоклап китте.

Уелданов, хатыны җылыткан урынга яткач та, күтәрелеп тәрәзәгә карады — анда тәрәзәгә елышкан яфракларның әкрен генә кыштырдаганы ишетелде. Бу тагы да Газизәнең, елар чиккә җитеп: «Нинди айлы төн бу!» — дип пышылдавын искә төшерде.

Хәләф Борһанович, йоклый алмый, урынында боргаланды, торып, йокы даруын эчеп карады. Җибәрмәде. Зиһен чәчелгән счёт төймәләредәй таркалды, җыеп алып, тәртипкә китерер әмәл юк. Ай яктысында тагы да күркәмрәк, мәһабәтрәк булып күренгән өй җиһазлары да күңелгә көндәгедәй рәхәт бирми, җылытмый. Нәрсә бу — көнләшүме әллә? Уелданов, йөрәген тотып, түшәгеннән торып утырды. Шуңача үзенең бәхете камил булуга ышанып яшәгән Хәләф Борһанович... көнләшәме? Юук!.. Тирән күлдәй тыныч күңеле искән җил — бер хыялый хатынның исәр сүзләренә болганырмы? Әйе-әйе, бөтенесе дә элеккечә... Шыксыз ай белән ач бүре күзедәй елтыраган йолдызларда ни эше бар аның? Хәтта бөтен

галәм безнең белән, имеш... Дөньяң бөтен булмаса, төпсез галәмнән ни файда?!

Уйлары белән мавыгып, күңеле тынычлана төшкән Уелданов хатынының җылы аркасына шуышты. Әллә дару тәэсир итте, күзен йокы баса башлады...

...Ул гаҗәп төннән соң байтак вакыт үтте. Алмагачларда сусыл, тыгыз, балавыздай сары алмалар өлгерде. Хәләф Борһанович төннәрен һаман шул эскәмиясендә утыра, нидер аңларга, нидер төшенергә тырышкандай, бихисап йолдызлар уйнаган күккә бага. Караган саен, ниндидер олы куанычның (бәлки, бәхетнең?) үзен мәңгегә читләп үткәнен ныграк тоя...

Хәзер ул теге чак, койма артында тавыш ишетелү белән, өенә кермәгәненә дә үкенә. Үкенсә дә, җир белән күк арасы нур белән тулган чакларда, алма каравыллаган сылтау белән бакчага чыкмыйча, йолдызларга бакмыйча булдыра алмый...

ЯЛГЫЗ БӨРКЕТ КҮКТӘ БӨТЕРЕЛӘ

Күренде. Әнә ул Караташ ягыннан болыттай кабарып килеп чыкты да биеклеккә омтылды, аннан Бөркетле авылының өстендә диярлек талгын гына бөтерелә башлады.

Инсаф утын ярып торган җиреннән туктап, бу тирәдә күптән түгел пәйда булган кош патшасын күзәтә. «Кызык, — дип уйлый ул эченнән. — Бөркетлегә бөркет килгән дисәм, кешеләр ышаныр микән? Мөгаен, ышанмаслар. Ә ул чын бөркет булмаса? Беткәнмени бөркеткә охшаган кошлар? Кеше ышанмастай сүзне чын булса да сөйләмә дигәндәй, әллә серне ачмый тору хәерле булырмы?»

Дөресен әйткәндә, Инсафка көзгә унсигез тула, ә үзенең кешедән яшерердәй сере булганы да юк. Серне ул берәүнең берәүгә гашыйк булуы итебрәк күз алдына китерә. Гыйшкы аның, бәлки, булыр да иде, авылларында яшь-җилкенчәк юк. Бөркетледән унбиш чакрым ары яткан Яңавылга кино-фәләнгә йөрсә, кызы да табылыр иде ул — инде ничәмә ел түшәктә хәрәкәтсез яткан әнисеннән китә алмый. Ничәмә ел дигәннән... әнисенең дә кузгала алмый ятканына быел көзгә унике ел була

түгелме? Уникe ел... Ә Инсафка әнисе гомере буе кеше кулына калып яткан кебек.

Әнисенең зәгыйфьләнүе Бөркетледәге сыер фермасын Яңавылга күчергән елда булды. Бу хәерсез ел Инсаф күңеленә уем-уем истәлек рәвешендә уелып калган. Ферма күчкәч, атасының Яңавылга йөреп эшләгәне хәтерендә. Малларны ул кичкегә ашатып япканнан соң, төнләтеп кайтып керер дә таң яктысыннан янә атын җигә башлар иде. Атасының йөреп эшләп арыганына зарланганы, әнисенең Яңавылдагы ферма өенә күчәргә риза булмый сукранганы да исендә Инсафның.

Шулай беркөнне Инсафларның өе каршысына «Беларусь» тракторы килеп туктады. Арбасы да бар. Эшләрдәй кешесе күчеп беткән, карт-корыга карап калган авылда трактор күрену дә сирәк күренешкә әйләнә башлаган иде — Инсаф белән абыйсы Ансаф шундук декабрь суыгы рәсем төшерә башлаган тәрәзәгә капландылар. Тракторның кабинасыннан аталары сикереп төшкәч, малайларның гаҗәпләнүенең чиге булмады: вәт, ичмасам, аларның атасы трактор да йөртә белә икән!

Шул арада ишек ачылды, чабуына суык болыты уратып килеп кергән аталарының чырае караңгы иде. Менә ул кискен хәрәкәт белән идәнгә әллә аркан, әллә дилбегә ташлады да, аш-су тирәсендә йөргән әниләренә тишәрдәй итеп карап:

— Нәгыймә, олау алып килдем. Йә хәзер әйберләреңне төйи башлыйсың, йә минем шушы бауга асылынып торган гәүдәмне иртә таңда каенлыкта эзлисең! — диде.

Гадәттә, «күчү» дигән сүз иренең авызыннан чыгарчыкмастан чәчрәп чыга торган әниләре эндәшмәде, ишек кырындарак эленеп торган фуфайкасын киде дә башына чуклы шәлен ябынды, караватка өелгән мендәрләрнең челтәрле тышларын салдырып бәрәмләп тышка ташый башлады. Аталары башта учак янында чүгәләгән килеш папирос тартты, ахырдан сүзсез генә хатынына булыша башлады. Күп тә үтми, аларның ташынганын күреп, күрше Сөнәгать, Ишбулды карт килде. Инсаф белән Ансаф, тәрәзә төбенә утырып, өй эченең бушый, ялангачлана барганлыгын шым гына күзәттеләр. Әйбер-кара чыгып беткәч, аталары ялангач сәке аша малайларга үрелде дә капыл кулын кире алды:

— Сөнәгать, — диде ул, — болар бүгенгә сездә калсын инде. Өйне җылытып, әйберләрне урнаштырыйк башта. Төнгә каршы бала сөйрәп йөргәнче...

Шуннан барысы да ялангач сәкегә утырышты. Ишбулды карт, дога кылып, амин тотканнан соң, тынлыкны бозды:

— Син дә киттеңме инде, Кәүсәр?

Аталарының тавышы карлыгып, саңгырау чыкты:

— Күчү-күчмәү безнең ихтыярда түгел, шәт, агай.

— Туган төягегезне шулай да онытмагыз, оланнар.

Шулай диде дә Ишбулды карт торды, аның артыннан башкалар да кузгалды. Өйдә малайлар да Сөнәгать кенә калды. Тракторны кабызуга, тәрәзә пыялалары зыңгылдады, тиздән әле генә җир селкетеп гөрселдәгән техника урынын кышкы төннең куе караңгылыгы биләде.

Аннан соңгы вакыйгалар бер сугылуда бөтен авылны түбәсез калдырган гарасат рәвешендә хәтерендә калган Инсафның. Беренчедән, Ансаф белән Инсафны иртәгесен дә, аннан ары ике көндә дә ат белән дә, «Беларусь» белән дә (Инсаф әтисенең нәкъ трактор белән килеп алуын көткән иде) алырга килмәделәр.

Инсафларның барлы-юклы әйберләрен төяп алып киткән трактор дүртенче тәүлек дигәндә генә килде. Гаҗәп, аның кабинасыннан атасы түгел, мыеклы бер агай сикереп төште. Сөнәгать агаларының тәрәзәсеннән чыга язып карап торган балалар ни уйларга да белмәде.

— Әтием кайда икән соң? — Инсаф, эне кеше буларак, абыйсыннан җавап көтте.

— Әти ни... бушамыйдыр. Эштәдер инде. Әйдә, сырмаңны ки! Абый кеше синең мыштырдаганыңны көтеп тормас, — диде дә Ансаф идәнгә тып итеп сикереп тә төште.

Инсаф абыйсы артыннан ашыгып китәргә ашыкмады, чөнки трактор хуҗасы кабаланганга охшамый иде. Башта ул тәмәке кабызды, авылның аркылы-торкылы такта кагылган тәрәзәләренә, почмаклары чыгып торган нигезгә карап торды, шуннан, кинәт бер карарга килгәндәй, Сөнәгатьләргә юнәлде.

Сөнәгать, ул чакта әле өйләнеп өлгермәгән яшь егет, әнисе белән генә яши иде. Кунакны ул чыгып барган җирендә — ишек төбендә каршы алды.

— Болар... Кәүсәрнең балаларымы?

Сөнәгать «әйе» дигәнне белдереп баш селкеде. Абый кеше түргә үтәргә уйламады да — ишек тоткасын кулыннан ычкындырмады.

— Дустым, чыгыйк әле.

Бу сәер сөйләшүне авызларын ачып күзәтеп торган ба-

лалар кия башлаган кирәк-яракларын ни киеп бетерергә, ни салырга белмәделәр, идән уртасында торган көе йә Сөнәгатьнең, йә теге агайның кире кергәнен көттеләр.

Менә берчак трактор янә һава ярып гөрелдәде, малайлар тәрәзәгә капланды. Бәй, Сөнәгать капканы шар ачып маташа! Күрәсең, тракторны арбасы-йөге белән ишегалдына кертергә чамалыйлар болар. Керттеләр. Сөнәгать Инсафларның ишегенә эленгән зур йозакны ачты, теге ят агай арбаның ишек ягына караган кабыргасын ычкындырды. Менә алар паласка уралган озын бер нәрсәне сак кына өйгә кертә башладылар.

— Чыктык! — Инсаф абыйсының җиңеннән тартты. — Чыктык! Әтиләр кире күченә!

Ансаф кузгалмады, шуннан кинәт тәрәзәдән аерылды да лап итеп утырды, ә агарынып киткән иреннәре, апачык итеп:

— Әти үлгән! — дип пышылдады.

...Тагы бер ун-унбиш минуттан аларның өенә авылда торып калган карт-коры, гарип-гораба агылды, кемдер учак астына ут якты, кемдер суга китте, ә теге трактор хуҗасы, арбасына Сөнәгатьне, янә ике картны утыртып, зиратка кабер казырга китте.

Тагы бер-ике сәгатьтән аталарының әлеге паласка төрелгән гәүдәсен тагы «Беларусь» арбасына чыгарып салдылар.

Трактор шул китүдән авылга башка әйләнеп кайтмады.

Тагы да бер айдан ак машина туктады аларның өйалларына. Машинадан ак халатлы ике хатын-кыз, бер агай сикереп төште. Болар, машинаның арткы ишеген ачып, носилка чыгара башладылар. Тәрәзәдән карап торган Ансаф идәнгә төште:

— Әнием кайткан!

Әниләре, чынлап та, кайткан иде, тик аның аяклары йөрмәс булып кайткан иде.

Ә теге күчену төнендә алар белән ни булганын Инсаф ахырдан төшенде. Аталары күченер өчен бергә эшләгән иптәшенең тракторын сорап алып китә. Төнге юл авыр, җитмәсә, «Беларусь»ның фаралары эштән чыга. Тауга күтәрелгән чакта трактор юлдан чыга да арбасы-ние белән аска тәгәри. Аталары башы белән сугылып шундук үлә, әниләренең умыртка сөяге, аяклары имгәнә. Менә шуннан бирле Инсаф әнисен карый, ә укып йөргән Ансафны балалар йортына алып киттеләр. Мәктәпне бетергәч,

ул бер ел СПТУда укыды, шуннан армиягә алынды. Хезмәтен бетергәч кайтып тормады, БАМда калды.

Баштарак ул сирәк булса да кайткалады, посылка, хат салып торды. Бер хатында «өйләндем» дип язды. Өйләнгәч, үзе дә кайтмас булды, хатлары да сирәгәйде. Ә көннәрнең берсендә хатыны Римманың: *«Сезне кайгыртмаска теләп язмый торган идем, килешмәс төсле: Ансаф эш урынында авариягә очрап вафат булды. Үлгәненә скоро алты ай була. Үземнең дә саулык «не ахти». Врачлар серьёзно лечиться итәргә кушалар. Җәй, отпуск алгач, возможно, Снежананы сезгә илтеп куярмын»*, — дигән хаты килде.

Хатны алгач, әнисе көн-төн елады. Ансыз да чак яткан кеше бөтенләй хәлдән тайды, куллары кашыкны көчкә тота башлады. Врачлар килеп карап, чирең нервыдан, диделәр, борчылмаска куштылар. Хәле бар чакта Инсафның өс-башын ямый, оегын, бияләен бәйли торган иде, хәзер бөтенләй имгәк булып ята.

Абыйсының үлеменә Инсаф та нык кайгырды. Мәскәүдәге бер профессорга хат язган идем, җавап килсә, әнине кайтып алырмын, дип язган иде ул бермәл. Хәзер булмый инде. Абыйсының үлеме Инсафны, әнисе аякка басса, мин дә кешечә яшәрмен дигән соңгы өметеннән яздырды...

Ә инде җиңгәсенең җәйгә кайтарып куячак кызы да, үзе дә Инсафта бернинди дә сөенеч тә, көенеч тә уятмады. Гомердә күрмәгән туганыңа йә җиңгәгә карата нинди тойгы булсын инде? Аннан соң Инсаф карт-коры торып калган авылда кеше белән әллә ни аралашып та үсмәде, үз эшен үзе белеп эшләп, үз кирәген үзе юллап тик йөрде. Ярый әле ул укыганда авылда өч класслы булса да мәктәп бар иде. Инсаф шуны бетереп калды, хәзер әнә анысы да юк: каршы йорттагы Сөнәгать абыйларының өлкән кызы былтыр укырга төшәргә тиеш иде, мәктәп булмагач, укый алмый утыра.

Менә шушы үлеп бетеп барган авыл өстендә бу тирәдә күптән юк саналган кош бөтерелсен әле! Үзе көннән-көн биегрәк күтәрелгән кебек бит әле. Бөркет хакында Инсаф әллә ничә тапкыр әнисенә сөйләргә талпынды да, әмма үзенә генә билгеле серне чишүе, бөркетне күргән саен серле рәхәтлек тойгысы кичерүне югалтудан курыккан кебек эндәшмәде.

Ә менә авылның ни өчен Бөркетле дип аталганын белә. Бәләкәйрәк чагында аңа тәмләп-тәмләп әнисе болай сөйләгән иде: «Элек, бу җирләргә әле адәм аягы басмаган

чорда, монда тик бөркетләр генә яшәгән. Корылыктанмы качып, ишле мал-туарына көтүлек эзләпме, бу якларга килеп чыккан бер ыру шунда туктаган. Өерелеп очкан бөркетләрне күреп, бу җирне Бөркетле дип атаган. Ташлы-таулы, кара урманлы бу төбәкне халык башта бер дә өнәмәгән. Елкы көрәеп, мал-туар ныгыгач, килгән ягына — далага кире китәрбез дип уйлаган. Ә менә ырудагы бер егеткә, үткер күзле, чичән телле Җангүзәйгә, урманлы-кыялы, елгыр бөркетле, чәчкәле-тугайлы бу төбәк искитмәле гүзәл тоелган. Алай гына түгел, гашыйк булган егет бу җиргә. Гашыйк булмаслыкмыни? Югарыга карасаң, бүрегең төшәр биеклектә кат-кат кыялы, карагачлы-каенлы таулар; кыялар астында чәчен тузгыткан су анасын хәтерләткән җәйрәп яткан тирән күл. Җитмәсә, шул күлгә иртә саен нечкә билле, калку күкрәкле яшь бер чибәр, керт-керт басып, чулпыларын чылтыратып, суга килә... Йөрәгенә сыймаган шатлык, матурлыкка манчылган бу сөенеч, егет күкрәген ярып чыгып, җыр булып баягы кыяларга бәрелгән, нур булып бөркетләр чаңгылдаган күккә ашкан:

> Һа-ай! Иртәнчәкләй торып, бер карасам,
> Уң кулында көмеш йөзек, куш беләзек,
> билкәй нәзек...
> Чаңк-чаңк итә Ирәндек бөркете, һай!
> Чаңк-чаңк итә Ирәндек бөркете!

Көтмәгәндә куанычлы җыр-аваз ишеткән кешеләр, кинәт сискәнеп, уянып киткәндәй була, тирә-юньнәренә кыю караш ташлый, ә ырудашларының билен язуын күргән чичән тагы да ярсыбрак җырлый:

> Һа-ай! Өмет өзмә, дуслар, бу дөньядан,
> Бәйрәм булып китәр беркөнне...
> Чаңк-чаңк итә Ирәндек бөркете, һай,
> Бәйрәм булып китәр беркөнне...

Җыр тудыруга сәләтле җир кеше җанын сихерләүчән була. Шулай итеп, халык иркен дала төсе сеңгән күңеленә кыялар горурлыгын, бөркетләр бөеклеген кушып, нәселыру җәелдереп, авыл-авыл оешып, шушы җиргә берегеп, өйрәнеп, тавына Өйрәндек, ягъни Ирәндек дип исем кушып яшәп киткән».

Инсаф үзе исә авылы тирәсендә ат кешнәп, сыер мөгрәп, сарык-кәҗәсе агылып торган чакларны төшендә

күргәндәй генә хәтерли. Авылның клубын, авыл Советы йортын, медпунктны сүтеп, совхоз үзәгенә алып киткәннәре чак-чак исендә. Авыл очындагы «мөгәзәй»* дип йөртелгән иген келәтен дә җимереп, эре-эре агач бүрәнәләрен каядыр ташыдылар. Шул мөгәзәйне бозгач, авыл буйлап күселәр таралды. Инсафларга да килеп тулды шул мәлгуньнәр. Малайның көчсезлеген шәйләп калдылармы, тиз арада аннан курыкмый башладылар. Аннан бирле ничәмә ел үтте, авылда кеше кимегәннән-кимеде, ә алар, киресенчә, үрчегәннән-үрчи. Инсаф шуларга капкын куюдан бушамый хәзер.

— Инсаф! Авызыңа май булгыры... Кайда син?!

Сөнәгатьнең хатыны Салиха җиңгәсе тавышына сискәнеп, Инсаф уеннан бүленде, балтасын түмәргә батырды да капкага юнәлде:

— Нәрсә бар?

— Җиңгәң килеп ята! Әнә каршы чыгып ал!

Ул арада җиңгәсе үзе күренде. Капкадан кергәч, сумкаларын җиргә утыртты, кулының сырты белән маңгаена тибеп чыккан тир бөртекләрен сыпырды:

— Син Инсафмы? Менә туганыңны алып килдем. Помощница булыр үзеңә.

Инсаф шунда гына аның артында җебеп торган зур зәңгәр күзле, алты-җиде яшьләр чамасындагы юан гына гәүдәле кыз баланы шәйләде.

— Абыең белән поздоровайся, Снежана! Ул әтиеңнең бертуган братишкасы. Әнкәй өйдәме?

Инсаф өйдә дигәнен белдереп баш селкеде, кирәккә-кирәкмәгәнгә тамак кырды, ят кунаклар белән моннан соң мөгамәләне ничек корырга белмичә, килешсез хәрәкәтләр ясады. Моны күзәтеп торган Салиханың түземе җитмәде, ахры:

— Боларга карап торсаң! — диде дә сумкаларны җилтерәтеп эләктереп өйгә атлады. — Әйдәгез! Әйдә! Карчыкның шәп чагы булса-а. Әллә кайчан каршы чыгып йөгерер иде лә!

Кунаклар артында тәбәнәк өйгә ялгап салынган чоланның такта ишеге шапылдап ябылды.

Дөресен әйткәндә, кунаклар килү вакыйгасы Инсафны артык кызыксындырмады. Әлбәттә, егермеләп өй торып калган, Салихаларны исәпләмәгәндә, тик карт-ко-

---

* Мөгәзәй — халыкның иганә ашлыгын саклый торган бина.

ры яшәгән авыл өчен Себер чаклы җирдән кунак килеп төшү үзе бер олы вакыйга инде ул. Күрше-тирә, ерактан килгән, моңарчы күрмәгән киленне күрик әле дип, килеп тә чыккалады. Ә Инсафка нәрсә? Авызын чия кызыл буяуга буяп, күзен-башын уйнатып, шәрә түшен калкытып, башкортчасын, татарчасын, русчасын бергә бутап сөйләп, колак ярысын ярырдай итеп шаркылдап көлеп йөргән Римма белән ни уртаклыгы бар аның? Римма болай идән дә юа, өйне дә җыештыра, ашарга да пешерә. Инсафка да үткән саен сүз кушкан була. Беркөн хәтта лапас астында утын ярган каенише янына чыгып та утырды. Дөресрәге, башта утырды, ахырда Инсаф үзенә ял итәр өчен ясап куйган сәкегә чалкан төшеп ятты да:

— Скучно тут у вас! — дип зарланды.

Инсаф моңа карата әйе дә, юк та димәде — аның бит эш муеннан. Утынны берьяклы кул пычкысы белән кискәнче генә дә ярты җәең үтә яза. Ә печәне? Берүзе чаба, җыя, өя. Баштарак печәнне ике тәгәрмәчле арбага үзе җигелеп ташып җәфаланды, ахыр, Ишбулды карттан күрмәкче, сыерын җигәргә өйрәтте. Аннан башка бит әле бәрәңге бакчасында да берүзе эшли. Шулай булгач, күңелсезләнергә вакыты каламыни аның?!

— Кроме стариков авылда беркем дә юкмы?

— Юк.

— Инте-ресно... — Римма бераз тынып ятты да, терсәгенә таянып, башын калкытып, янга, Инсафка таба әйләнде. — Ә авыл артында йөргәннәр что за кешеләр?

— Буровиклар.

— Да? Нәрсә, әллә монда нефть запасы тапканнармы?!

— Нефть түгел — су. Су яман күп ята ди аста.

— Ә ул су кемгә кирәк?

— Рудникка диләр шикелле.

Дөресен әйткәндә, Инсаф бу хакта үзе дә юньләп белми. Алардан сорамадылар бит. Килделәр дә казый башладылар. Авылдан алып рудникка хәтле юан торба да сузып яталар. Авылның олы кешесе Ишбулды карт кына: «Табигатьтә буш урын булмый, суны суырып алсалар, авыл зираты-ние белән җир астына убылып төшәчәк!» — дип, әллә кайларга барып йөреп караган иде — рәт чыгара алмады.

— Да-а... — Ята торгач, Римма янә Инсафка эндәште: — Ә син үзең? Эшләми тик ятасыңмы?

— Эшлим... — Инсаф көлемсерәде. Ни дисен инде? Аның эше дә шул, ашы да шул. Моннан ике ел элек Яңаулдан килгән авыл Советы рәисе беткән мәктәпнең ачкычын тоттырып китте.

— Мәктәп бинасы клуб хезмәтен үтәр. Онытканда бер кино китерсәләр дә, идәнен себереп, карап тор, — диде.

Кыш утын булмагач, клуб бикле тора, җәй анда-санда кино китерәләр, көтү чыгар алдыннан бер җыелып алалар, шуның белән вәссәлам. Инсафка клубның ачкычын саклаган өчен кырык сум акча түлиләр.

— Ә нәрсә эшлисең? — Кызыксынуы шултикле көчле булдымы, Римма хәтта торып утырды.

— Клуб карыйм.

— Клуб?! Ә кайда ул?

— Теге очта. Элекке мәктәп. Әле анда буровиклар яши.

Инсаф ни тиклем аз сүзле булмасын, Римма аны һаман сөйләштерергә тырыша. Менә ул, сәкедән торып, утын түмәре өстенә килеп утырды:

— Слушай... Күршегез Салиха да ялгызмы? Карчык түгел бит әле ул.

Инсаф балтасын кулыннан ычкындырмый гына эшеннән туктап торды:

— Салиха җиңгиме? Аның ире Сөнәгать агай калага чыгып китте. Күптән инде... бер ун ел буладыр. Фатир алгач, җиңгәне кайтып алам, ди. Җиңги бармаска итә шикелле...

— Вот дура!

Инсаф тагы эндәшмәде, эшен дәвам итте. Салиха китсә, Инсафларга кыен булыр дип уйламыймы икән бу? Бөркетледәге лавкада сату иткән дә, төрле яңалыкны халыкка җиткереп торган да шул. Өстәвенә Инсафка кием алып бирешә, әнисен ике атнага бер мунча кертә, киеменә тиклем юып биреп тора.

Сүзгә саран каенише янында алга таба торуның мәгънәсен тапмадымы — Римма урыныннан торды, артка каерылып киерелеп алды да, үзалдына сөйләнгәндәй итеп:

— Пойду! Суга барыйм, заодно Снежанку искупаю, сама искупаюсь, — дип, утынлыктан чыгып китте.

* * *

Елгадан Римма кичләтебрәк кайтты, юган керен капка киртәсенә элгән арада, сыер савып утырган Инсафка:

— Инсафчик! Видео килгән. Клубның ачкычын сорыйлар! — дип кычкырды.

— Видия? Анысы ни?

— Так вот, буровикларга күрсәтергә видеофильм китергәннәр. Хакы бер сум, ди. Так что собирайся, барабыз!

— Әллә... Әнием акча бирсә...

— Ха-ха! Әни... Ә мин ни өчен? Беләсең килсә, Снежанага атасы өчен чыккан пенсиясе әниең белән икегез алган акчадан күбрәк. — Римма муенына нәзек бау белән генә эленеп торган, кара-кучкыл күкрәк очларын да капламаган күлмәктән Инсаф янына чүгәләде. — Шуннан, барабызмы?

Җиңгәсе ягына карамаска тырышса да, үзенә якын ук килгән шәрә тәнле, алай гына түгел, ялангач күкрәкләрне күрүдән Инсафның колагына ут капты, сөтен чиләккә түгел, әллә кая читкә сава башлады.

Болар, гомумән, әллә нинди шәрә халык. Снежанасы кигән күлмәге инде, ташка үлчим, ботының төбен дә капламый. Үзе әллә кайдагы җир читеннән берне генә дә түгел, ике зур курчак алып кайткан бит әле. Көннәрен әнә шуларны бер киендереп, бер чишендереп үткәрә кызыкай. Курчакларның төсе дә хатын-кыз тәненә охшагач, Инсаф шуларга карарга да читенсенә.

— Итак, решили: барабыз! — Римма Инсафның кулыннан сөтле чиләкне алды. — Мин синең ак күлмәгеңне юдым, шуны киеп ал да гуляй, Вася!

Күлмәкне кидергәч, җиңгәсе, шаркылдап көлә-көлә, Инсафны әйләнеп чыкты:

— Ну вот! Чем ты не егет? Менә дигән егет! — Шуннан кинәт учы белән авызын каплап арткарак чикте. — Инсаф... Да ты же на брата своего здорово похож!

Бу сүзгә урын өстендә яткан әнисе дә кыймылдап куйды:

— Охшамаска әллә... Абыйсы булгач охшар шул, — диде. Тавышында канәгатьлек чагылды.

Күз алдында һаман киң кара кашлы, үткер карашлы, биек текә маңгайлы, яшь, көчле булып басып торган Ансаф абыйсының чалымнарын җиңгәсенең үзендә табуы Инсафка да тәэсир итми калмады, олпат-кискен хәрәкәт белән аллы-гөлле күлмәк киеп өйдән чыгып барган җиңгәсе артыннан атылды.

Алар клубка барып җиткәндә, халык әле җыелмаган иде. Кино күрсәтергә килгән егетләр «Жигули»ларыннан әллә ниләр бушаттылар, эчкә кертеп урнаштырдылар. Киноның башланганын көтеп утырган арада, Римма бу-

ровикларның әле берсенә, әле икенчесенә сүз кушты. Боларның сөйләшкәнен тыңлап утырып, Инсаф буровиклар тормышының җиңгәсенә ят түгел икәнен, үзенең дә шундыйрак җирдә ашханәдә эшләвен төшенде.

Кино башланыр алдыннан гына янә бер кеше килеп керде, ул да булса Ишбулды карт. Кергәч, кычкырып сәлам бирде, шуннан, тирә-ягын караштырып торды да, таныш йөзләр бүтәнчә күренмәгәч, Инсаф янына кунаклады.

— Карап карыйк әле, — диде ул, сызлаган аягын рәт арасына ипләп урнаштырып куйгач, — гурыт халкы нәрсә белән көн уздыра икән...

Менә галәмәт, кино Инсафның моңарчы күргән-ниткәннәренә бер дә охшамаган иде, һи!.. Болар белән чагыштырганда, Римманың ярты күлмәк киеп йөрүе әлхәмделиллаһи икән әле. Болар ни... анадан тума шәрә! Теге... Снежананың курчаклары кебек. Чәчләре дә шуларныкы ише тузгып тора. Ә кылган кыланмышлары... Шуларны карап утыра торгач, Инсафның тамагы кипте, тәненә ялкын капты, күз аллары томаланды. Күңеленнән ул бу тамашаны карап утыруы оят икәнен сизә, сизсә дә чыгып китми, әллә нинди тойгы урыныннан кузгалмаска, экрандагы ир белән хатынның бер-берсеннән юаныч табуын карарга мәҗбүр итә. Нindiдер сәгать ярым эчендә унсигез яшенә җитеп, хатын-кызның тәненә түгел, беләгенә дә ялгыш та кагылып карамаган Инсаф әллә нишләде. Моңарчы аның һәр әгъзасы үзенчә, берберсенә буйсынмыйча яшәгән кебек иде, хәзер инде бар булмышы дөрләп торган зур бер утка әверелде. Инсаф үзендә яңа кеше уянганын тойды.

Ут кабынганда, Инсаф янындагы Ишбулды карттан җилләр искән иде. Кай арада чыгып тайгандыр ул...

Үзендәге үзгәрешне башкаларның күреп калуыннан курыккандай, күтәрелеп карарга кыймыйча, абына-сөртенә Инсаф ишеккә атлады.

Менә ул урамнан килә. Аяк астында күпереп яткан йомшак үлән, баш очында кинодагы ак чәчле кызның җемелдәп торган тешләрен хәтерләткән йолдызлы күк. Һава шундый җылы, шундый йомшак, хәтта ки ул шул кызның кабарып торган күкрәкләрен хәтерләтеп борынга тула, әллә йөткертмәкче, әллә төчкертмәкче була. Җиңгәсе куып җитмәсә, Инсаф, йомшак үләнгә ятып, йә елар, йә улар иде, мөгаен.

— Ну как? Кино ошадымы? — Римма йөгергән, күрәсең, ах-ух килә.

Менә ул, ялгыш басып, тотынып җир эзләде, әллә култыклап алырга итте – Инсаф үзе дә сизмәстән янтаеп өлгерде.

— Кыргый! — Җиңгәсе моннан соң үпкәләде микән, эндәшмирәк барды. Шуннан, кеше бакчасына үрелеп, шомырт ботагы сындырып алды да, черкиләрдән җиңелчә җилпенеп, үзалдына сөйләнгәндәй итеп: — Да... живут же люди! — дип көрсенде. Аннан Римманың кәефе кинәт үзгәрде, гәүдәсен турайтып, сыгылмалы хәрәкәт белән алга омтылды, танцыдагы шикелле әйләнеп алды. — Китәм мин! Хватит! Снежанку пока у вас оставлю. Абыең исән чакта бала белән горя не было. Калдыра да сыпырта торган идем. Ну что за отдых с ребёнком?! Не правда ли, Инсафчик?

«Инсафчик» янә эндәшмәде, күзләре җиңгәсенә карап торса да, асылда, ул теге кызны, аның коңгырт тәнле ир куенына елышкан еландай сыгылмалы, шома тәнен күрә иде. Клуб белән өй арасы бу юлы Инсафка бик озын тоелды, тәнендә баш күтәргән кайнар кан бер калтыратты, бер яндырды.

Төнне ул лапас астындагы сәкесендә йокламый үткәрде.

* * *

Ә бөркет һаман бөтерелә. Җирдән аерыла алмыйча сөйрәлеп яшәргә мәҗбүр затларны көнләштергәндәй, көннән-көн биегрәк күтәрелә. Аңа карап Инсаф «Өмет өзмә, дуслар, бу дөньядан!» дип җырлап җибәрер иде дә, янында дәртлегә дәрман биргәндәй зифа буйлы, шомырт кара күзле, кара кашлы кызлар юк. Булмаганга хөкем дә юк, диләр дә бит, йөрәк дигәнең аңа карап ярсымый, типми тормый бит әле, нидер даулап, нидер яулап, нидер таләп итеп, ашкынып тибә бит әле шул йөрәк!

Бөркеткә карап торып күзе талгач, Инсаф йомырка карарга тавык кетәгенә керде. Бармакларының җылы, йомры җисемгә кагылуы булды, бөтен тәне буйлап нидер чемердәп үтте, йөрәге калтырап, еш-еш тибә башлады.

Ниндидер көч түгәрәк шул җисемгә кулын бәйләдеме — ул беләге буйлап сыек сары саркынды акканда гына уянып киткәндәй булды. Чи йомырканы уч белән сытып булмый дигән булалар — менә бит!

Ул үзалдына елмаеп абзардан чыкты.

* * *

Римма юлга җыена да башлады шикелле: әйберләрен юа, үтүкли, дыңгычлап сумкасына тутыра, шул арада кызына әледән-әле үгет-нәсыйхәт бирергә дә онытмый:

— Башыңа киеп йөр! От молока не отказывайся!

— Ты об этом уже сто раз говорила!

— А ты слушай!

— А я чё делаю?

Ул арада ишектә Салиха күренде:

— Өйдәләрмесез? Инәй, ни хәлдәсең? Инсаф, җиңгәңне безгә алып бар. Абыең да кайтты, бергәләп утырып алабыз. — Шулчак аның күзе Римманың тутырылган чемодан, сумкаларына төште. — Бәрәкәт... Әллә китәсең дә инде?!

— Китәм, бер атна тордым бит инде.

— Снежанаңа төс керә генә башлаган иде...

— Ул калыр, диңгездән кайтышлый алып китәрмен. Дикарём бит еду, бала белән канительно будет.

— Йә, ярый, юлың уң булсын! — Салиха, әнисе алдына ашъяулык җәеп, үзе китергән токмачны куйды. — Китәм дигән кешене тотып булмый инде. Әнә минеке дә йөри бит. Әйтеп торам, совхозга гына эшкә төш тә куй, дип, юк, имеш, калага өйрәнгән...

Римма, тәрәзә рамына көзгесен урнаштырып, чәчен кабартырга, иренен буярга керешге:

— Боже упаси авылда яшәргә! От голода подохнешь!

Салиха, чыгып барган җиреннән туктап, итләч муенын борды:

— Нәрсә, әллә ачтан үлеп барганга охшыйбызмы?

— Голод дигәндә сез, бахырлар, ашауны гына уйлыйсыз шул инде. Киттек, Инсафчик. Снежана, пошли в гости, тёт Салиха зовёт!

Инсаф аларга иярмәде, капкага кадәр барды да торып калды: кешегә чәйгә йөреп гадәтләнмәгәч, аягы тартмады.

Ялгызы торып калгач, Инсаф янә утынлыктагы сәкесенә егылды. Башында «Голод — ачлык, ачлык — голод» дигән сүзләр тезмәсе өерелде. Шуннан җиңгәсенең «Голод дигәннән сез, бахырлар, ашауны гына уйлыйсыз шул!» дигәннең мәгънәсен төшенүдән башына ут капты. Аптырагач, кулына балтасын алып карады — эш бармады. Кире ятты, тагын торды.

* * *

Капка төбендә ишетелгән тавышлар Инсафны сискәндерде. Ә... тегеләр кайтып килә икән. Җиңгәсе гадәттәгедән кычкырыбрак хихылдый, Салиха исә кунакларын капка төбеннән генә озата. Ире, Сөнәгать, Римма артыннан җайлап кына ияреп килә торгач, Инсафларның өй янына ук килеп җитте. Үзе болар янында көчен нәрсәгә сарыф итәргә белмәгән нәсел үгезе кебек кылана. Менә ул Снежананы бер кулында гына күтәреп күккә чөйде, көлә-көлә очынган кызыкайны икенче кулы белән елгыр гына эләктереп алды. Шуннан ул, ныклыгын тикшергәндәй, капка баганасын селкетеп карады. Кара, бүтән чакта мыштым гына йөргән кешене танымассың да, күзләр очкын чәчә, кашлар җәядәй язылган, мыек көлеп, бөтерелеп тора. Сөнәгатьнең такылдавыннан Римма да кинәнеч таба, ахры, көлеп рәхәтләнә.

— Көрәшкә чыкканың бармы-ы? — ди ул.

— Һы! Булмыйча.

— Для интереса бер карап торсаң иде!

— Әллә үзеңне егып күрсәтимме?!

— Хи-ха-ха!

— Һа-һа-һа!

Шуннан Римма йөзенә уенчак җитдилек чыгарды:

— Может, безгә дә кереп чыгарсыз? Вот и Инсафчик с нами посидит...

Сөнәгать төймәләре ычкындырып җибәрелгән күлмәк эченнән күпереп чыгып торган йонлы түшен сыпырыштырды:

— Рәтең бармы соң?

Римма янә хихылдады:

— Как можно авылга рәтсез килергә?! Правда... не водка.

Җиңгәсенең «не водка» дигәне Сөнәгать күзләрендәге утка керосин сипкәндәй булды:

— Что-нибудь покрепче? Тукта, мин бичәкәйгә...

Сөнәгать авызын ачканчы, Римма кычкырып та өлгерде:

— Соседка! Айда и у нас посидим!

Салиха ияге белән урамга ымлады:

— Үзегез генә утырыгыз инде, мунчаны өлгертергә кирәк.

Сөнәгать хатынын кыстап тормады. Артына әйләнеп, ярар инде, бичәкәй, чакыргач, ничек бармыйсың дигән

төсле, кетер-кетер көлгән булды да капкадан кереп барган Римма артыннан иярде.

Инсаф өчен бу рәвешле кунак чакыру чын-чыннан ят иде. Элегрәк, әнисе сау чакта, алар да кунак җыя торган иде.

Мондый чакларда әнисе иртәдән әзерләнә башлар иде: камырын баса, ипи сала, майда юача-бавырсак чыжлата, токмачын җәеп, киптереп, кисеп куя; идәннәр юылып, мич агартыла, кулъюгыч янындагы чөйгә сөлге-тастымал эленә, таска кадәр ышкып ялтыратыла.

Кунаклар килгәч, яше-дәрәҗәсенә карап урын бүленә, һәр кунак үзе өчен әзерләнгән ас мендәрдән урын алгач, ашъяулык түшәлә, табак белән салма китерелә, ит турауны кемгә тапшыру мәсьәләсен табындагылар күмәкләп хәл итә...

Менә җиңгәсе чоландагы иске генә өстәлгә ашык-пошык кына табын әзерләде, юан корсаклы шешәдәге эчемлекне өч кырлы стаканга чиреген кадәр салып чыкты.

— Что-ж, әйдәгез, за знакомство! — Сөнәгать беренче булып стаканны авызына каплады.

— Ә син нишләп утырасың? Эч! — Римма стаканны Инсафның авызына якын ук китерде. — Эч, а то авызыңа коям! Җиңгәңне уважать итмисең что-ли?!

— Җиффәр дә ку-уй! Без синең яшеңдә-ә... — Кызмача башына ут өстәгән Сөнәгать кулын Инсафның җилкәсенә салды. — Яле, җебеп утырма. Егетме син, түгелме?

Эчте Инсаф, йотып җибәрүе булды — күзеннән яшьләре атылып чыкты. Бераздан тәненә — җылы, җанына битарафлык йөгерде. «Аңгыра сарык бәрәне мин, — дип тиргәде үзен эчтән, — шундый әйбәт нәрсәне эчми утырганмын». Шулчак ачык өй ишегеннән әнисенең:

— Инсаф, балам, кил әле монда! — дигәне ишетелде. Тапкан чакырыр вакыт! Утырган җиреннән үрелеп, Инсаф ишекне гөрселдәтеп этеп куйды. Ә инде җиңгәсенең:

— Вот молодчина! Теперь закусывай, закусывай скорей! — дигәне ничектер ерактан ишетелгән кебек тоелды Инсафка. Шулай да ягымлы бу Римманың тавышы, колакка ятышлы. Ул әле изүе ябык кофта кигән, ә Инсаф (гаҗәп!) аның күкрәкләрен теге чак сыер сауган чактагы кебек шәрә килеш күргәндәй...

— Ну чё ты уставился? — Җиңгәсе үпкәләгәндәй итте. — Женщин что ли не видал?

Сөнәгатькә җитә калды, кетер-кетер көлде:

— Кайдан күрсен? Монда кругом картлар да карчыклар!

Римма житдиләнеп киткәндәй булды, күзен кыса төште:

— В Якутии мужчины тоже нас не балуют. Посёлоклар арасы икешәр йөз километр!

Сөнәгать кабарга җыенган консервалы калагын кире өстәлгә куйды:

— У-у... не густо, оказывается, у вас! Ә ничек... — Ул Римманың колагына авызын терәп диярлек нидер пышылдады да, көлеп, артка чигенде.

— Ничек дисең? — Римманың күзендә очкыннар сикерешге: — Инсаф кебек инсафлы булып йөрсәң, әлбәттә, беркем дә китереп тоттырмый. Чослык кирәк! Хи-хи-хи!

— Чослык диген, ә? — Күренеп тора, җавап Сөнәгатькә галәмәт нык ошады. — Ишетеп утырасыңмы, Инсаф? Җиңгәң белеп әйтә ул. Дөнья күргән кеше дөнья күргән кеше инде!

Ул арада Римма янә шешәсенә үрелде:

— Ну что ж, повторим?

— Сорап биргәнче сугып бир, диләр бездә. — Сөнәгать кеткелдәде.

Инсаф әллә чынлап, әллә әдәп өчен:

— Миңа җитте, — дигән булды. Ә үзенә рәхәт. Бөтен тәнен рәхәт кенә җылытып-изрәтеп гизеп йөри эчкәне.

— Как «җитте»? — Моны Сөнәгать белән Римма икесе берьюлы кычкырды.

— Нас что ли не уважаешь?

Әллә кем кебек кыстатып утыруы да уңайсыз бит әле: Инсаф Римманың салганын төбенә кадәр эчеп куйды. Ярый, дип уйлады ул эченнән, ике стаканнан нәрсә булсын, алай гына бал да, аракы да эчеп караганы бар инде... Ләкин, менә хикмәт, Инсафның капыл гына буыны йомшады. Ипи кисәргә пычак кирәк дигәч, өйгә кермәкче иде, атлый алмады, килешсез чүгәләп, аркасы белән ишеккә бәрелде. Үч иткәндәй, ишеге ачылып китте, Инсаф лап итеп тышка чалкан барып төште.

— Так, он пьян! Исергән! — Римма, чәбәләнеп, аның янында бөтерелде.

— Сам деле... — Сөнәгать аның аякларыннан тотып, чоландагы караватка өстерәде. — Кара әле, Инсаф, ятып тор, — диде ул бирешмәскә, торырга маташкан Инсафка. — Эчми эчкәнгә шулай ул... спирт, каһәрең, астыртын нәрсә шул...

Инсаф барысын да ишетә, җавап кайтарырга теле әйләнми дә, торырга итсә, аяклары тотмый. Ә менә карават үзенә тарткандай, йоткандай. Шушы иске карават теге авариядән соң аларның йөгенә ияреп килгән иде. Күрәсең, Яңавылда аларның әйберен йә бер келәткә, йә тулай торакның берәр буш бүлмәсенә бушатып торган булганнардыр. Кире төяп җибәргәндә, шушы караватны ни сәбәпледер бергә салганнар. Инсаф исерек булса, боларны хәтерләр идеме? Юк, ул исермәгән, арыган гына. Бик нык арыган.

Ә теге икәү өчен ике дөнья — бер моржа. Араларындагы урындыктан Инсаф торып киткәч, җилкәгә җилкә, башка баш терәп янәшә утырып алдылар. Римма Сөнәгатькә әллә ни сорап инәлә. Ә-ә... җырлавын сорый. Тегесе озак ялындырып тормады, Риммадан читкәрәк янтаеп, тамак төбеннән гыжылдап чыккан тавыш белән җыр башлады:

Каз канаты кат-кат була,
Ир канаты ат була.
Чит илләрдә күп йөресәң,
Үз туганың ят була.

Җырның соңгы юлларында Римма кушылырга итте — барып чыкмады, әллә җырның көен, әллә сүзләрен оныткан булып чыкты. Шуннан:

— Ах, душу... душу раздираешь, Сөнәгать! — дип, аның җилкәсенә сулкылдап ауды.

— Син нәрсә?! Әллә елый инде... Беднушка ты моя... — Инсаф тирән, татлы йокыга китеп барган чагында Сөнәгатьнең Римманың башта битеннән үбеп алганын, аннан ирененә үрелгәнен шәйләде. — Беднушка...

* * *

Инсаф күзен ачканда, өстәл тирәсе буш иде. Ябылып бетмәгән өй ишеге аша көңгер-каңгыр сөйләшкәннәре ишетелә. Салиха җиңгәсенең тавышы. Мөгаен, ул Инсафның әнисенә чәй эчерергә кергәндер. Әнә аның:

— Эчәр идең, — дигәне ишетелде.

— Эчтем, килен, рәхмәт. Иткән изгелекләрең Алладан кайтсын үзеңә. Бала-чагаңның рәхәтен күреп, ирең белән бергә картаерга язсын...

— Әллә инде...

— Әллә дип, ни.

— Кала дигәннәренә бер дә җаным тартмый, җиңги.

— Өйрәнерсең. Сөнәгатуллага да ни үпкә. Ялгыз яшәгәненә ни заман!

— Анысы шулай да...

— Балаларың бар. Бер түгел, өчәү.

— Өчәү... Булдырсаң, дүртенчесе дә булырга тора.

— Аһ-аһ, шулаймы?! Бирсен Ходай!

— Күбәеп китә бит, җиңги?! Сөнәгатькә фатирны да ике генә кумыт бирәләр, ди.

— Тере җанга урын табылыр, һәр туар җан үз ризыгы белән килә.

— Әллә, мин балниска барырга җыенып беттем инде.

— Гөнаһ алма, килен.

— Гөнаһ дип ул чаклы... тумаган баланың дигәндәй... Сөнәгатьнең каладагы туганы «Нечего нищету разводить» ди әле.

— Ничек ялгыша... Әй, килен... Кешене тыңласаң ул... Мин дә бит бер шулай ялгыштым. Ирем бар көйгә менә Инсафымнан соң, бер ахирәтемнең сүзен тыңлаган булып, балниска барып кайттым бит, тинтәк! Әнә шул сабыйның каргышы төшкәнгә дә ирдән калып, аяктан язып ятамдыр мин!..

— Куй, җиңги, көяләнмә! Үткән эш өчен ни... яшеңне әрәм итмә.

— Елыйм дисәм, яшьләрем дә чыкмый шул инде минем, килен! Ансафымның үлемен дә шул сабыйның рәнҗеше төшүеннән күрәм...

— Колхозны бетереп, совхозга әйләндермәсәләр, авыл корыр идеме дә, адәм тырым-тыракай таралып бетәр идеме?

— Алай да гөнаһым зур минем, килен!

Боларның тынычлана башлаганын ишетеп, Инсаф урыннан торды. Тамак кипкән. Баш зыңлап тора. Ишекне ачты, сәке кырыенда җиз самавыр чыжлый. Сәкенең бер читендә Снежана йоклый. Ике ягында ике курчагы. Шулардан ул йоклаганда да аерылмый.

— Әйдә безнең белән. — Салиха түр яктан зур чынаяк алды. — Нәрсә, баш авыртамы?

— Юк ла... сусаткан гына.

— Бугашаган... — Әнисенең иң ачулы чагында әйтә торган сүзе бу.

Элегрәк булса, Инсаф, мөгаен, кызарыр иде, әле нишләптер уңайсызланмады, комсызланып чәй чөмерүен белде.

— Тегеләр кайда соң? — Сусыны басылгандай булгач, Инсаф җиңгәсенә күтәрелеп карады.

— Әллә тагы... — Салиха алмаш-тилмәш урам якка һәм ишегалдына караган тәрәзәләргә күз ташлады. — Агаең Ишбулды кайнаганың хәлен беләм дигәндәй булган иде. Анысы да тапкан вакыт. Якты күздә мунча кертим дисәм...

Сүзгә әнисе кушылды:

— Ир кешенең ни, йомышы күптер. Кайтмаганына да ике җомга булып китте түгелме? Каен утынының кызуы бер-ике сәгать торганнан сүрәнәеп китмәс әле.

— Анысы шулай да... Ир кеше барында сине дә мунча кертеп чыгарыйм дигән идем бит әле.

— Куй, куй! Килен китсен әле. Кунак барда олы мәшәкать ясавым охшамас. — Әнисе тагы нидер әйтмәкче иде дә тыелды.

Салиха, беләзекле беләкләрен күкрәк астына кушырып, янә сүз башлады:

— Әллә инде... Тагы печән вакыты җитте. Сөнәгать быел чапмыйк, ди. Аптыраган әле ул...

— Күчеп китсәң дә чәчеп кит, дигән борынгылар. Эчегезне тишмәс, кирәге чыкмаса сатарсыз.

Сүз шул җирдә янә өзелде, һәркем үз уена чумды.

Болар китсә, алга таба ничек яшәрләрен күз алдына да китерә алмыйдыр инде әнисе. Ул турыда уйлый башласа, Инсафка гел дә кыен була. Калган чәен шөперде дә чыгарга җыенды.

— Бозауга үлән йолкыдыңмы? — Бу әнисенең һичбер вакыт хәтереннән чыкмый торган хәстәре. Ни өчен дигәндә, тирә-якта бүре күбәйгән дигән хәбәрләр ишетелә, бозауны иркендә йөртергә куркалар.

— Хәзер йолкам.

— Бар, бар, караңгы төшкәнче җәһәтлә.

Келәткә кереп, печәнгә йөрткән капчыгын алды да абзар артына, су буе әрәмәлегенә юнәлде Инсаф.

Әнисе караңгы төшүдән шулай да тик юкка курка. Инсаф бу урынның һәр ташын, һәр әрәмәсен күзен йомып та эзләп таба. Элек монда үлән ул тиклем шәп түгел иде, каз үләне генә яшел келәм булып җирне сыра иде. Хәзер, мал азайгач, кеше таптамагач, үлән галәмәт шәбәйде, кычыткан, кара курадан урман барлыкка килде. Әмма бозауга ашатыр өчен үләнне түбәннәнрәк җыярга кирәк— Челтәрбаш ни житте үлән ашамый.

Ә бозауны үстерми чара юк: сыер картайган. Ничәмә ел рәттән үгез бозау китергәннән соң, тәүге теше бозавы. Инсафлар киләсе елга сыерны суеп, монысын алып калырга торалар.

Инсаф, туктап, тирә-ягын айкады: кичәге җиргә барса, ераграк, аның каравы үләне шәп — ул шунда тәвәккәлләде.

Күпмедер баргач, әрекмәннең котырып үскән җирендә, сәер бер тавыш-өн ишетелгәндәй булды. Бу тирә чүп-чар оясы — берәрсенең малы казаланып ятамы әллә? Инсаф, үреләбиреп, тавыш килгән якка төбәлде. Бәйбәй... Куе үлән аша кешенең кулымы, ботымы күренә түгелме?! Ул инде «Әй, кем бар анда?» дип тавыш бирергә уйлаган иде генә, зур әрекмән яфрагы астында Римманың бөтеркәле башын күреп калды. Тагы бераз калкынган иде, бөтенләй телдән язды: менә сиңа Ишбулды картның хәлен белергә киткән Сөнәгать! Яткан җирләрен әйт әле?! Элек бит бөтен авыл тиресен, бөтен пычрак-шакшысын шушында китереп түгә торган иде. Инсаф бит бу җирдән үтеп киткәндә дә бисмилласын өзлексез әйтеп, чир-зәхмәт кагылмасын дип, сакланып-куркып кына йөгерә торган иде. Аптырауның аръягына чыккан Инсаф байтак кына кузгала алмый торса да, җиңгәсе аны шәйләмәде кебек. Менә ул Сөнәгатькә нидер пышылдады, тегесе тамак төбеннән аңлаганын белдергән тавыш чыгарды. Инсаф, дөпелдәп типкән йөрәгенең тавышы ишетелүдән куркып, тын да алмыйча икенче сукмакка борылды.

* * *

Инсаф капчыгына үлән тутырып кайтканда, Римма өйдә иде инде. Печәнне бушаткач, ишегалдында аунаган түмәргә утырып, җиңгәсенең һәр хәрәкәтен күзәтә башлады. Күренеп тора: Римма эчсә дә артык исермәгән, өйгә бер кереп, бер чыгып, каты басып йөри. Менә ул, салкын төште, өшерсең дип, Снежанасына җылы кофта кидерде, суга барып килде. Яңадан самавыр чыжлатты. Аертылмаган сөткә генә дөге ярмасыннан ботка пешереп алды.

Бераздан капка төбенә Сөнәгате дә чыкты. Монысы, күрәсең, мунча кереп, чабынып алган — йөзе, муены түтәлдә пешкән помидор кебек алланып тора... Ул Инсафлар ягына карап тәмәкесен суырып торды да, тышкы

бакча коймасына терәп эшләнгән эскәмиясенә утырып, балалары белән сөйләшергә, шаярырга тотынды. Снежана да шунда бөтерелә. Телне юньле-башлы белмәсә дә, ул Салиха җиңгинең балаларыннан аерылмый диярлек.

Аптырады Инсаф, алҗыды: бөтенесе дә элеккечә, бөтенесе дә гадәттәгечә. Әйтерсең әрәмәлектә әле генә берни булмаган. Ә бәлки, Инсаф үзе юкны күргәндер? Ә бәлки, бөтен кеше, шулар шикелле, тыштан бер төрле, эчтән икенче тормыш белән яшидер? Аның адәмчә яши белмәгәненә, бәлки, болар гаепле дә түгелдер?

Узган ел су ятмасын караргамы, запасын билгеләргәме авылга ике-өч кеше килде. Кырык яшьләр чамасындагы юан бер марҗа Инсафларда фатирда атнадан артык торды. Бермәлне, әнисен Салиха җиңгәсе мунча кертергә алып кайтып үзләрендә йокларга калдыргач, шул хатын аңа ишарә ясады, Инсаф исә аңламаганга салышты, якынаймады. Алай гына түгел, марҗа кайтып киткәнче калган ике көндә аңа күтәрелеп тә карамады...

Караңгы төште. Инсаф һаман өйгә керми, суза. Сөнәгать тә күптән кереп китте, капкаларын бикләп, йокларга яттылар. Бу төннең нәрсә китерәсен Инсаф үзе дә белми — күңелененңме, тәнененңме шушы төнне көтеп зарыгуын тоя.

Күңеленнән шушыларны кичереп утырганда, Инсаф тагы шуңа игътибар итте: Риммага карата бернинди дә туганлык тойгысы кичерми икән дә ул. Риммага да, бер җире белән дә абыйсын хәтерләтмәгән аның баласына да. Бу тойгы, бәлки, абыйсын хатыны белән беркайчан да янәшә күрмәүдән киләдер? Шулай булгач, нәрсәдән курка соң ул? Янә калтырата башлады. Йөрәгенең калтыравын җиңәр өчен, ул үз-үзен: «Ә нәрсә, башкаларга ярый бит!» — дип юатты. Аңа җиңги булса ни, Римма Сөнәгатькә дә җиңги, алар да бит Инсафларга якын кардәшләр...

Ниһаять, Римманың чоландагы тимер караватка чыгып ятканы ишетелде. Кайтканнан бирле ул шунда йоклый. Кызы йокыга киткәнче генә ята да, ахырдан чоланга чыга. Монда йоклавы рәхәт, һава саф, ди. Ни булса, шул булыр дип, ярсып типкән йөрәгенең көче белән ишекне этәреп ачты Инсаф.

Җиңгәсенең тәненә кагылуы булды, йокыга китеп барган Римма дертләп китте:

— Кто там?!

— Мин, җиңги...

— Ә-ә... Инсаф... споткнулся что ли?

— Юк, сиңа килдем, — аннан ары сузарга көче җитмичә, Инсаф янып барган иреннәрен Римманың ялангач күкрәгенә батырды, — сиңа!

Башта җиңгәсе каушап, аптырап калгандай булды, аннан Инсафның башын күкрәгеннән җан көченә карышып аерып алды:

— Дурак! С ума что ли спятил?!

— Ә нәрсә? Башкаларга ярый бит, — монысын Инсаф әйтермен дип уйламаган иде, моны Римманың бик җирәнеп карышуы әйттерде.

— Башкаларга... — Римма инде изүе тирәсенә юрганын тартып торып утырган иде. — Куда ты полез? Балбес син, поросёнок! Үзеңнең көчең җиткәннәрне кара син! Понял?! — Шуннан җиңгәсе тынычлангандай булды — сулыш алуы тигезләнә башлады. Инсаф та тәнендә нәрсәнеңдер өзелүен, суынуын тойды. Римма, куркыныч беткәнен аңлапмы, әллә шуны аңлатырга теләпме, кире түшәгенә ауды. — Тем более я сегодня не го-лод-ная!

Инсафның колакларына ялкын кабынды:

— Беләм.

— Белсәң, мин дә беләм: я чувствовала рядом человека. — Шуннан ул терсәгенә таянып калкына төште: — Только об этом ни Салихе, ни бабушке — ни, ни! Слышь, ни-ни!

Инсаф башкача эндәшмәде, эндәшерлек сүз дә тапмады: Римма аны күргән! Күрсә дә, хәтта күрсә дә...

Ул әллә караңгыдан, әллә зиһене томаланудан, абынасөртенә, тышка ашыкты.

* * *

Римма киткәч, өй бушап калгандай булды. Хәтта бөтен дөнья мәгънәсез бушлыкка әйләнгәндәй. Снежана торып калса да, исәпкә юк: бөтен көне Салихаларда үтә.

Үзенең балалары белән тиң күреп бага шул кызны җиңгәсе. Снежана кайвакыт йокларга да кайтмый, аларда кала.

Ә күңелдәге бушлык көчәйгәннән-көчәя, артканнан-арта. Китапка күңел салыр идең — китапханә юк. Салиха җиңгәсенең кызларын укырга өйрәтер өчен алып кайткан китапларын Инсаф күптән яттан белә.

Гәзит-журнал сымак нәрсә дә алдырмый Инсафлар: әнисенең пенсиясе белән үзенең алган кырык сумы

ашаудан, кием-салым, кирәк-ярак алудан артмый. Киноның инде авылга күптән килгәне юк, теге видеоларын да, авылыгыз «некассовый» дип, башка китермәс булдылар.

Авыл астындагы суны суыра башласалар, эш көчәер, яшьләр кайтыр дип көткән иде Инсаф, анысы да бушка булды: нибары бер насос станциясе төзеделәр. Анда да кешене эшкә авылдан алмыйлар, ди. Шәһәрдән машина белән китереп, кире алып кайтып йөртергә итәләр, имеш, дип сөйлиләр.

Ары сугылды Инсаф, бире сугылды, аңгы-миңге йөри торгач, теге көн җиңгәсеннән торып калган юан корсаклы спирт шешәсенә юлыкты. Литрлы савытның бер чиреге эчелми калган! Инсаф озын-озак уйлап тормады, шешәне алып, утынлыкка чыкты.

Тәүге салып эчкәне үткәндәге сымак оетты-изрәтте. Икенчесе уятып, кәефен күтәреп җибәргәндәй итте. Әмма җырлыйсы килсә дә җырламый ул — көе юк. Ә менә гармун тарткан кеше булса, биер иде ул. Ирәндек итәген бер итеп, әнә бөркет әйләнгән күккә җитәрлек итеп сикереп биер иде! Атасы биюче булган аның. Абыйсы Ансаф та укыган елларында каникулга кайтса, Ишбулды картның төлке бүреген сорап алып торып клубта бии торган иде. Эх! Уңмаган бер адәм булган шул инде Инсаф. Дәрте бар да, дәрманы юк.

Юк, чынлап: тотып эшлим дисә — эше, сөям дисә, кызы юк, ә бит теге кинодагы егеттән бер генә дә ким җире юк Инсафның... Үзен жәлләүдән күңеле тулышты, күзеннән аккан эре-эре яшь бөртекләренә кушып, калган спиртны чөмерде Инсаф.

Бер мәлгә янә күңеле киңәеп, тыны иркенәеп киткәндәй булды, тамырларында кан ташты, беләк-йөрәгендә көч-куәт артты. Ә нигә? Ул кемнән ким? Әнисе әйтмешли, бу дөньяда гел бәхетле юк. Әнә Ишбулды картның карчыгы инде унөч ел түшәктә ята. Әнисе соң? Алар белән чагыштырганда, Инсаф бит әле, Аллага шөкер, алты әгъзасы төгәл. Төскә дә яман түгел икәнен белә ул, ә инде башкасы... Җиңгәсе теге чак ни диде? Көчең җиткәннәрне кара, дидеме? Во-во! Көчең җиткәннәрне чамала, диде... Әгәр дә җиңгәсе килеп күзен ачмаса, тормыш шулай була икән дип яшәп ятар идеме икән ул? Шулай да видеодагы теге ак чәчле кызмы, әллә Риммамы шәбрәк?

Уй-дәрья шул җиргә җиткәндә генә, Снежананың кинәт кычкырып елап җибәргәне ишетелде. Каршы ба-

рырга талпынган иде, буыны тотмады — сәкедән мәтәлеп барып төште. Ахырда яткан җиреннән:

— Ни булды, Снежана?! — дип кычкырган иде, үз тавышы үзенә ят тоелды.

— Ножку, ой, больно ножку!

— Кил монда! Иди сюда!

Бер кулы белән тубыгыннан байтак өстәрәк урынны каплап, икенчесе белән курчакларын кочаклаган килеш сыктый-аксаклый, Снежана абыйсы янына килде.

— Ни булды?

— Ужалила! Оса укусила!

— Шөпшә агуын чыгарырга кирәк. Бире кил! Близко иди, әйтәм! — Күлмәген эченә тиклем күтәреп, балтырын ялангачландырган кызыкай агасының башта шөпшә чаккан җирне сыйпавын, аннан соң шул урынны суыра башлавын тойды:

— Больно! Ой, мамочки, больно! Мамочка-а-а!..

Мәгәр Инсаф кечкенә туганының ялваруын ишетүдән үткән иде инде. Юк иде аның туганлык тамырлары белән тоташкан сеңлесе. Аның урынын әллә ни арада теге видеодагы ак чәчле кыз биләп алды. Күпме көтте аны Инсаф! Тик нигә кычкыра ул?! Шундый кирәк чагында нигә аңламый ул Инсафны?! Менә ул янып барган иреннәре белән кызыкайның авызын каплады, тегесе аның әллә телен тешләде — чырылдап кычкырган чагында кан бөркә башлады.

— Син шулаймы әле?! — Инсаф куш учы белән кызыкайның муенын кысып тотты. — Карышасыңмы?! Кеше сайлыйсыңмы?!

Һәм бетте. Ләкин, күп тә үтми, яңадан башланды. Унсигез яшьлек егетнең сүнмәгән дәрте төне буе яңгырдан соң ярларына сыймый дулаган елгадай дулкынланды, бурандай котырды, тауларны калтыратырга мәҗбүр иткән яшендәй яшьнәде. Ахырдан хәлсезләнде. Кайвакыттадыр, ничектер йокыга талды.

* * *

Инсаф күзен ачканда, кояш Караташ өстеннән аркан буе күтәрелергә өлгергән иде, һава зәп-зәңгәр. Эчтә ниндидер бушлык, җиңеллек, баш кына томаланып тора. Ул тагы күккә карады. Әлеге бөркет. Ул бу төбәккә адашып килеп чыкканмы, әллә инде туган ягы белән бәхилләшергә

кайткан карт бер мосафирмы? Һәрхәлдә, аны күрү Инсаф күңелендә өмет уяткан иде, аның исемен авылыннан киткән бәхетнең кире кайтуы белән бәйләгән иде. Тукта... Нигә әле ул дөньядан бөтенләй өметен өзгән кеше кебек уяткан иде, бәйләгән иде дип уйлап ята? Кичә аткан таң белән бүген атканы арасында аерма бардыр шул. Юкса...

Юк, бөтенесе дә үз урынында: бакча артында елга чылтырый, иртәнге һаваны яңгыратып, узыша-узыша әтәчләр кычкыра. Ишбулды картның әтәче өстерә шуларны. Бер кычкыра башласа, бөтен авылны әтәч моңына күммичә туктамый. Шулчак якында гына, баш очында диярлек, ямьсез тавыш ишетелде. Козгын! Рогаткадан ата торгач, биздергән иде шуны, тагы килгән икән әрсез нәрсә...

Инсаф кузгалды. Кузгалгач, өшегәнен белде. Бераз гына түгел, нык өшегән. Ә нигә ул монда ята әле? Сәкедә дә түгел, бөтенләй... җирдә?! Ни уйларга белми, ялгызы аптырап ятадыр бит ул? Аның торып утыруы булды — күзе кулындагы кан тапларына төште. Монысы ни?! Инсаф тирә-ягына күз салырга иткән иде, үзеннән ерак та түгел әчке күлмәге башына капланган Снежананың ипсез булып йөзтүбән ятканын күрде:

— Снежана! — Бер секунд эчендә йөзе көл төсенә кереп агарынган килеш Инсаф кызыкайга иелде. — Снежана! — Аның алҗыган карашы сабыйның шәрә тәне буйлап йөгерде, бәлки, ул түгелдер?! Шулчак ул хәрәкәтсез кызның уң аягында баш бармак уемы зурлыктагы нәкъ «и» хәрефен хәтерләткән миңне күреп калды. — Ансаф.

Абыйсының да нәкъ шул җирендә нәкъ шул зурлыкта миңе бар иде бит! Шуңа күрә дә Инсаф аны «ишәк» дип үчекләр иде, ә әнисе «Балам илсөяр булыр, Ходай мөһер баскан!» дип куаныр иде...

— Снежана! Туганым!!! — Ертылган күлмәге бер җиңендә генә эләгеп торган баланы Инсаф чалкан әйләндерде, бите аның танырлык түгел, газапланган көе катып калган күз алмаларының әллә яше кипмәгән, әллә чыкка манчылган. Шулчак сабыйның битенә өстән бер тамчы кан тамды, Инсаф шул бер тамчы канның тимер тәмен үзенең авызында тойды.

— Ах! — Шул алсу кызыл бер тамчы Инсафның спирт шаукымыннан томаланган зиһенен тәмам айныткты, ул егерме өйле, иртәнге тынлыкка чумган авылны тетрәндерерлек итеп кычкырып җиргә ауды: — А-а!!! Нишләдем мин?! Әни, Ансаф! Нишләдем мин!!!

* * *

Ә бөркет һаман бөтерелде. Күз күреме биеклектә чаңкылдап, әллә кардәшләрен эзли, әллә шуларны туган төбәгеннән яздырган язмышын каргап, ялгыз калган үзен, әллә мәгънәсез сераеп торган кыяларны жәлли...

Ә бәлки, ул, бөркетләр генә күтәрелер биеклектә торып, кайчандыр, гасырлар төпкелендә, җиргә һәм мәхәббәткә дан җырлап, ырудашларының күңеленә дәрт, мәхәббәт, бөеклек чәчкән эче-тышы белән якты чичән бер егетне эзлидер...

Ә бәлки, ул туган туфракларын ташлап чит-ят җирләргә сибелгән ир-егетләргә «илегезгә кайтыгыз, нигез-ыруларыгызны, күркәм гореф-гадәтләрегезне корытмагыз» дигән горур оран ташлыйдыр.

Ирәндек бөркете бүген һичкайчан булмаганча ачыргаланып чаңкылдый...

БАЛ ДИП ҮРЕЛГӘНЕМ...

Нур белән кар кушылудан кызыл ялкын булып күзне камаштырган озын юлны күзәтәм. Тигез юлда ялгыз чана табаны астында тынлыкны бозып кар шыгырдый, бу юлның да, чана белән кар чыгарган бу көйнең дә игечиге булмас кебек...

Янымда толыпка уранган әнием йокымсырап килә, ә бәлки, йокламыйдыр да, шул ялан юлы төсле иксез-чиксез уйларына юлыккандыр.

Ә менә толып чабулары белән кар сыпырып, әледәнәле янтайган чананы авудан саклап атлаган, зәңгәрсу-яшькелт күзләрен генә калдырып, сакал-мыегына бәс сарган баһадир гәүдәле ир — минем әтием ул.

Чанадан артта калып, тагы берәү юлга буран салган көрт белән алыша — анысы безнең ут күрше Бибинур апай. Кат-кат бала итәкле күлмәк, күк фуфайка өстеннән сугылган ак мамык шәл ябынган, ирләрчә киң адымлап, нык басып атлаган, безгә туган тиеш шул апайны кеше елый белми икән дип сөйли. Шунысы да чындыр: бер-берсен куып үсеп килгән өч кызлы бу өйгә мин дә кереп йөрим. Кергәндә дә, тышта йөргәндә дә мин аның тик шаярганын гына ишетәм, хәтта эштән кайтканда да ул кешечә атлап түгел, сөрән салып, такмак әйтеп, биеп кай-

тып керә. Дөресен әйткәндә, анын ире сугышта үлгән, үзен өч бала белән егерме дүрт яшендә тол калган, диләр. Бибинур апай үзе: «Балаларның атасы сау, кайтачак», — ди. Көтә. Кызларын да көттерә. Хәтта кышкылыкка суйган казларын да ашап бетермиләр, җәйгә калдыралар. «Монысын әти кайткач, бергәләп ашарбыз», — диләр. Менә шул Бибинур апай китеп бара безнең белән. Кая дисезме? Кунакка. Җитмәсә, ни җитте авылга түгел, Сибайның үзенә! Шунысы да мәгълүм булсын: чакырылып. Чакыру хатын укыганнарын үзем тыңлап тордым. Әниемнең бертуган сеңлесе чакырып язган, көнен, сәгатен күрсәткән. Ул хатта Бибинур апайга сәлам язылган иде, әтием нигәдер бу сәламне Бибинур апайга икенче төрлерәк җиткерде:

— Җыен, карендәш, Сибайга чакырганнар. Әйдә, эчеңне бушатып йөреп кайт.

Бибинур апай үзе дә «Чынлап чакырганнармы? Мине дәме?» дип төпченеп тормады, идән тактасын сындыра язганчы тыпырдап бер биеде дә давыл шикелле бөтерелеп чыгып та китте. Миңа исә Бибинур апайның талымланып тормый-нитми кунакка барырга риза булуына караганда, әтиемнең «эчеңне бушатып» дигәне сәер тоелды: кунакка кеше, киресенчә, эч тутырырга бара түгелме?! Менә әле дә иртән иртүк ашыгып кына капкалаган ризыктан эчем өзелеп килә, алда сыйланачак тансык шәһәр сые күз алдыма килеп күңелне җылытмаса, тын юлда ялгыз ат белән илле чакрымны үтүе авырга туры килер иде әле ул...

Шәһәргә килеп җиткәнне дә, өйгә ничек кергәнне дә белмим — йокланылган. Уянып киткәндә, мәҗлес кызган иде. «Кызган» дип шуңа әйтәм: җыр-бию тавышыннан стеналар яңгырап тора иде.

Кунак-төшем вакытында балалар игътибардан читтә калучан. Шуңа күрә дә үз күңелемне үзем күреп, тамак ялгап алу нияте белән, өстәл артында утырганнарның игътибарын җәлеп итүдән, табын яныннан куылып китүдән куркып кына, әнием утырган җиргә якынайдым.

Авыл кунагындагы шикелле, коштабак-коштабак ит бүселеп утырмаса да, юача-бавырсак ише нәрсә өстәлдә чәчелеп ятмаса да, сый дигәнең байтак иде монда. Минем күз төшәрлек ашамлыклар да хәтсез күренә: прәннеге, кәнфите, күпереп торган ак калачлары бар. Бәләкәй пыяла савытларга саргылт-соргылт сыекчалар салынган, повидломы, вареньемы дигәннәре микән? Алай купшы

гына савытта ятарлык булгач, берәр тәмле нәрсәләрдер инде ул...

Әнием миңа бер сынык икмәк алып бирде дә үзенең чынаяк тәлинкәсенә чәй койды, шуннан соң минем турыда әйтерсең бөтенләй онытты. Чынаяк тәлинкәсендәге чәй белән бер сынык икмәк озакка бармады, шулай да, күңел күрәя төшеп, өстәл тирәли (шәһәр мәҗлесе өстәл тирәли корыла икән) утырганнарга күз ташларлык хәлгә килдем.

Монда ирләр белән хатыннар аерым-аерым түгел, Бибинур апай әйтмешли, «пупалам» утырышкан. Минем әти — тирә-якта дан тоткан җырчы. Ул әле «Урал»ын, «Түрәкәй»ен, «Сибай»н калдырмый сыздыра гына! Җырны бию алыштыра. Ирләр әледән-әле: «Кодача биесен әле! Ерактан килгән кодача биесен!» — дип кычкыралар. Ерактан килгән кодача — Бибинур апай — инде утырдым, чәй эчәм дигәндә кире төшә биергә. Биеп китә, такмагын коеп китә:

Кодачалар, кодалар!
Сездә ничек, бездә шулай —
Биеп күңел ачалар!
Һи-и! Ки-йыу!..
Тра-та-та-та, дигән чакта
Тырылдата гына бас!
Әйе-әйе, дигән чакта
Эйелдерә генә бас!

Килештерә! Өзеп баса. Әйтерсең лә бүген бата-чума, җәяүләп илле чакрым үтмәгән, ә киенеп-ясанып, укалы камзуллар, челтәр-кашмаулар киеп шушы мәҗлестә биер өчен генә күктән килеп төшкән. «Ерактан килгәннәр менә шулай ул!» дигән масаюлы карашымны алда утырган юан-юан кодачаларга төбәп-төбәп алам, ләкин алар моны сизмәмешкә салыша, Бибинур апай биергә чыкса, берберсенең кабыргаларына төртешеп, иреннәрен бүлтәйтеп, аптырап китәләр. Ә бу кодачаларның ирләре тәкатьләре корып биючене мактыйлар:

— Ходай бирсә бирә бит!

— Әйтерлек тә түгел, шәп кодача!

— Җил-ле-е!..

Әтиемне туганының осталыгы куандырса да, чәй эчә алмый аңгыраеп йөрүе ошамады шикелле.

— Чәй эчеп алсын әле! Кайнар итеп кенә чәй ясап китерегез Бибинурга!

Бибинур апай урындыкка утыруга, бөтен ир затының игътибары тагын аңа төбәлде.

— Менә симез бавырсак сиңа карап ята, кодача!

— Мампасины алдына куйыйм әле!

— Кодачага вареньены үз кулым белән каптырыйм әле!

Уф! Кара янды бит кодачалар. Ирләренең юмартлыгын, кунакчыллыгын болар нигә хупламый икән? Үз чиратымда мин дә Бибинур апайны, форсат чыкканда, мактап калырга булдым һәм, теге юан кодачалар гына ишетерлек итеп:

— Ә ул елый белми, — дип хәбәр салдым. Үземә калса, кеше өлешенә төшкән иң зур мәртәбә шул еламаудыр дип саныйм мин. Үземнең бит ике күз дә башның иң сулы урынына уелган.

Кодачаларның берсе минем сүзгә игътибар итте:

— Кемне елый белми дисең, акыллым?

— Бибинур апайны әйтәм: аның еламаганын авылда бөтен кеше белә!

Сүзгә инде икенче юаны да кушылды:

— Шулай ук бер дә еламый диме, үскәнем?

— Бер дә! Анттыр!..

Бу кодачалар минем белән шулай шыпырт кына сөйләштеләр дә янә шым булдылар. Ә ирләренең күзе Бибинур апайда!

— Кодачама повидлоны якынайтыйм әле!

Иркәй юка гына пыяла савытка салынган көрән сыекчаны Бибинур апай алдына эткән арада, миңа «үскәнем» дип эндәшкән кодача баягы бәрәкәтле савытка салынган саргылт сыекчаны Бибинур апайның алдына ук куйды һәм, беренче тапкыр кунакчылланып:

— Тәмләп эчәр идең, кодача, баллап, — диде.

Аңа икенчесе кушылды:

— Әйе лә соң! Капкалап эчәр идең, калагың юкмы әллә?

— Бар, бар! — Кыстатырга яратмаган Бибинур апай баягы кечкенә савыттагы сыекчаны калак тутырып алып авызына озатты.

Бу чакта ирләр аны шаулап кыставын белде, теге ике кодача тантаналы рәвештә ирләренә карады, сагайдылар. Бибинур апайның күзләрендә яшь тулышты да бите буйлап агып китте.

— Аһ-аһ! Нигә елыйсың, кодача?!

Мәҗлес тынды. Бибинур апай яшь катыш чәен чөмерде дә әтиемә карады:

— Елыйм шул. Бер биюем биелми калган — шуны жәлләп елыйм! — диде.

— Нинди бию?! — Әтием урыныннан сикереп торды.

— Нурфаизә!

Һәм китте Бибинур апай тыпырдап. Болыттай ургылды, өермәдәй бөтерелде, тирән күлдәй оеды... Такмагы да бит әле нинди:

Үлгән кеше торып бии
Нурфаизә көенә!

...Кунак булып, кайтыр якка елдам юырткан ат чанасында килгәндә, мин тагы бер сөйләшүнең шаһиты булдым:

— Агай, — Бибинур апай йокымсырап килгән әнием ишетмәслек итеп кенә эндәшә, — теге... бәләкәй савыттагы сары нәрсә булды ул?

— Нигә?..

— Миңа теге юан бичәләр шуны каптырды бит...

— Һа! Горчица ла ул!

— Горчица?!

— Молодец, кире төкермәдең!

— Төкермәү беләнме?! — Бибинур апай моны бик ачынып әйтте, күрәсең, еламый яшәп-яшәп бөтен кеше алдында, җитмәсә, табында, күз яше күрсәтүенә каты гарьләнә иде.

...Бал дип үрелгәнем агу булган чакларда сине хәтерлим, Бибинур апай. Күз яшьләремне тыю кодрәтемнән килмәсә, үлгән кешене терелтердәй такмакка — тормыш такмагына биергә тотынам.

ИСЛЕ ГӨЛ

Ачык тәрәзә аша кергән төнге салкынча һава сулышны киңәйтеп җибәрде. Түр бакчада үскән куаклар, дымлы һавада сафланып, тагы да көчлерәк аңкый; юл буе сузылган колхоз басуында бытбылдыкларның «юк булдык» дип качышлы уйнаганы, басу башындагы күл буенда бакалар бакылдаганы ишетелә. Мин, көлемсерәп, ялангач йомры беләкләрен кушырып, йолдыз яуган

күккә караган Сандугач апама карыйм. Бала чакта апамнан (ул чакта да икәү бергә шулай тын төнне тамаша кылган мәлләр булгандыр инде) бакаларның ни турында гәпләшкәнен төпченгәнем искә төште. Ул бөтен кош-кортлар, киек-хайваннарның телен белә торган иде. Бу юлы да аптырап калмады.

— Әни бака, — диде ул, күзләре белән көлеп. «Кәкре-бөкре ботыма читек кидермисең», — дип такмаклый, ә ата бака: «Саб-ы-ы-ыр ит...» — ди. Әнисе: «Ялпак-йолпак башыма калфак алып бирмисең», — дип үпкәли. Атасы тагы: «Саб-ы-ы-ыр», — дип юата.

Мескен әни баканы жәлләп тә куям: берәр нәрсәне бик булдырасың килеп тә булдыра алмасаң, кыен бит ул. Мондый хәлләр минем белән дә булгалады. Мондый айлы төннәрдә күк капусы ачылып-фәлән китсә дип, теләгән теләкләремне пышылдап, аз бактыммы бу күпне вәгъдә иткән серле күккә? Күпме генә көтсәм дә, күк капкасы ярылмады, чынга ашмаган теләк-хыялларым шул килеш кала, вакыт кояшында уңа-кибә торды, алмашка яңалары килде, көйдерә-яндыра бирде...

Шулчак күл буйлап бер рәт кенә булып сузылган авылның аргы очында кемдер гармун телләренә басты. Башта кыюсыз гына агылган моң көчәя төште. Төнге һаваны, күңелне шул моң телгәләде.

— Менә шулай гел уйный ул. «Исле гөл»... — Мин онытылып торган җиремнән ни дисең дигән сымак, Сандугач апаема карадым. — Гармунчыны әйтәм. Хатыны үлгәч, читкә чыгып киткән иде, ел да отпускага кайта. Һәр елның шушы мәлендә шушы көйне тыңлап... юанам.

Мин төбәлебрәк апаема карап куйдым. Чәчләренә еллар көмеш ука тарткан, йөзенә тамга-җыерчыклар салган, гәүдәгә дә калынаеп, авыраеп киткән. Иллене куа шул апаем. Яшь чагында бик сөйкемле, ягымлы булды, җитез. Минем хәтердә аның шаянлыгы, чаялыгы калган. Апаема текәлеп карап, башта аның әйткәннәрен искәрми тордым. Аннан кинәт шундый сорау туды башта: нигә «юанам» диде әле ул? Кинәнәм, рәхәтләнәм, сокланам йә тагы шулар ише сүз беткәнме? Юанам... Миннән байтакка олы, аралар ерак булгач (ул яшь кенә көе эшкә киткән җиреннән кайтмады, шунда кияүгә чыкты), апаемның тормышы белән бигүк кызыксынмаганмын, күрәсең. Янына әллә нигә бер генә килеп кителәә, тормыш мәшәкатьләре сагынудан да көчлерәк була бит

кайчак... Биш бала тәрбияләп үстерде ул. Ире, безнең олы җизни, абруйлы, күркәм холыклы кеше. Бу йортка кайчан килеп кермә, якты йөз, өстәл тулы сый булды. Килгән-киткән арада, Сандугач апамның тормышыннан зарланганын хәтерләмим.

...Көй әкренәя барып туктады. Апам әллә җил туздыткан чәчләрен, әллә җилсенгән күзләрен сыпырды. Тәрәзәгә тагы күл җиләслеге сирпелде — борынга хуш ис бәрелде. Исле гөл менә шулай аңкый. Шунда мин бу исне түр бакчадагы куаклар түгел, тәрәзә төбендәге гөл — исле гөл таратуын төшендем.

«Шуны тыңлап юанам». «Исле гөл», — күңелем дертләп, йөрәк лепердәде. Әллә... мин теге, бала чакта...

Апам, тәрәзә яңагыннан аерылып, йокы бүлмәсенә үтте. Егерме елдан артык вакыт онытылып торган вакыйга кинәт кенә ап-ачык булып исемә төште. Күлдән искән дымлы, җиләс җил исле гөл яфракларын сыйпамаса, билләһи, исемә кабат төшмәс иде. Вакыйга дисәң — вакыйга, мәзәк дисәң, мәзәк түгел. Ни булса да, уеннан — чынны, әкияттән — тормышны, зурдан — бәләкәйне, актан караны аера белмәгән гамьсез бер чак иде инде.

Әйтергә кирәк, ишле генә гаиләдә төпчек бала булып, иң иркәсе, иң үзсүзлесе мин идем. Хәзер мине күп кеше олы апама охшата. Сүзсез генә, күзләр белән аңлашкан чаклар бар. Ә ул мәлдә? Минем үзсүзлелек белән Сандугач апамның чаялыгы артык тынышып яши алмады шикелле. Бу юлы да...

Кыскасы, апам еракка эшкә китәр алдыннан аулак өйгә кызлар чакырырга әзерләнде. Көн кебек ачык: башта ул мине юмалап-юхалап йомыш-юлга йөртәчәк, аннан, кызлар килер мәл җиткәч кенә, ниндидер сихри көч белән миннән котылачак. Әле дә кырып юган иДәннәр балавыздай җемелдәгәч, җиз поднос кояштай ялтырагач (анысын мин тырыштырдым), кызарып пешкән пәрәмәчләр мичтән алынгач, апам коты алынган бер кыяфәттә өйгә йөгереп килеп керде:

— Ой! Уй! Җәһәтрәк урманга кач! Пәрәмәч тот та ычкын!

— Ни булды?! — Мәгәр каты тормакчымын. Шул җыенның түрендә үк булмаса да урын, мич буенда утырып булса да, кызларның биегәнен, серләшкәнен тыңлар өчен күрше авылга киткән әнием артыннан иярмәдем түгелме соң? Юл йөрү, сәфәр чыгудан бизгән юк иде әле.

— Минем... баш авырта. Мин бүген... өйдән дә чыкмыйм, беләсең килсә! Валлаһи, билләһи, бер калак кан эчтем*...

— Бә-әй! Әллә ишетмәдеңме?

— Нине? — Үзем борынны мышкылдата ук башладым, мондый очракта үкереп елауның бермә-бер файдасы тия торган иде, әле анысы запаста.

— Авылга кызлар сөннәтли торган баба килгән бит! Әллә белмисеңме?!

— Һе-е-е... Кем әйтте? — Елау кайгысы бетте, кикерик шиңде.

— Очтагы Кәбирәнең туганын утыртканнар да инде, әле Сабирага киттеләр.

Мин, өтәләнеп, абына-сөртенә киемнәремне эзли башладым. Уен эш түгел. Былтыр баба дигәннәре абыемны әнә нишләтеп чыгып китте! Атна буена малай башы белән апаемның күлмәген киеп йөргәне җитмәгән, Ходайның биргән ямьле көннәрендә урамга чыга алмый зар-интизар булып ятты...

Сандугач апаем юка кофтамны китереп тоттырды. Ызгышып кителсә дә, үз апаең үз апаең инде ул. Жәлли. Әнә, елап җибәрмәс өчен, авызын яулык очы белән каплаган. Юатып, бер-ике авыз җылы сүз әйтәсе килеп китте үзенә...

Кайнар пәрәмәчне (хәтта читләре көйгәнен түгел, әйбәтен) итәгемә салып, апаем ишекне ачты:

— Шәбрәк йөгер инде, акыллым. Килсәләр, күрше авылга кунакка китте, бүген кайтмый диярмен.

— Шулай ди күр инде, апаем-әйбәтем. Әйтә генә күр...

Очтым гына. Апаемның:

— Китсәләр, үрдән кул болгармын, яме?! — дип кычкырган тавышы юлны аркылы чыгып барганда гына куып җитте.

...Каенлыкка килеп җиткәч, бөдрә каен төбенә утырып хәл алдым, аннан ашыкмый гына юмарт апаем биргән түптүгәрәк пәрәмәчне «бөктем». Эш тә бетте шуның белән: үләнгә сузылып ятып, күкне күзәтә башладым, «Могҗиза җирдә» дигәннәре — буш сүз. Могҗиза күктә! Җирдәге бер затның, бер хайванның бертөрледән икенчегә әверелгәнен күргән юк әле. Әверелүен әверелә ул, тик... йомшак кына бәбкәләрнең кыртыш күзле ата казга,

* Борынгы башкортларда ант итү ритуалы.

мөлдерәп торган күзле шаян бозау, бәрәннәрнең тискәре үгез, сөзгәк тәкәгә әверелүе кемгә кызык. Андый әверелүләрнең, ташка үлчим, булганыннан булмаганы хәерле. Ә күктә? Монда бөтенләй икенче дөнья! Серле дөнья...

Әнә әле уңда чыңгыр-чыңгыр чыңгырдап ат көтүе килә. Кинәт бер ажгыр айгыр, Акбүз аттыр, мөгаен, үрә торып каршыларына басты — тавышыннан күк йөзе дерелдәп, атлар калтырап китте. Менә ул, әйләнеп, тоягын алга сузып, җирне тырнады — әһә! Яннан һөҗүм итәргә торган алгыр бүрене каршы алырга — алышка әзерләнде, артындагы бияләр, өркеп, түгәрәк ясап укмашты. Шулчак ажгыр айгыр, җир тетрәтеп кешнәп, үрә басты, алтмыш колач ялын туздырып, күзләреннән ут бөркеп, дошманына ташланды. Бүре, янтаеп, төлкедәй шуышып кача башлады. Әкәмәт! Күзең талмаса, монда кызык бетмәячәк, тик нигәдер авырайта, йокы баса башлады.

Шулай да бирешмәскә тырышам, әвен базарына китеп, апаемның үрдән кул болгаганын күрми калуым бар. Кем белә, бәлки, мәҗлеснең ахырына булса да өлгерермен әле. Күккә карап яту ни тиклем мавыктыргыч булмасын, өйдә калган пәрәмәчләр, җиләк бәлешләре, уен-көлке аралаш сер сөйләп (сер дигәннәре егет сөйләү була аның) чыркылдашкан җиткән кызлар эчне тырный. Сер дигәннәре артык кызык та булмый аларның. Җае чыкканда посып тыңлап яткан да бар. Тик нигә шуны яшерми генә, сер итми генә сөйләмәскә?! Ул чагында якын да бармас, теңкәләрен дә корытмас идем. Алар яшерә, шуның белән минем җанга тия. Имеш, минем тешем сирәк, авызымда сүз тормый. Минемчә, монда эш минем тештә түгел, ә сөйләгән сүзләренең юне юкта. Юньле сүз кайда да, шул исәптән минем авызда да, үз урынын табар иде ул. Яңарак апаем ахирәтен кунарга чакырды. Тегеләр килгәнче үк чыбылдыклы карават түренә, стена буена сыенып яттым. Күрсәләр дә тимәсләр, изге бер кыяфәттә «йоклап ятам». Килделәр. Кулларына бәйләмнәрен алып, сер сандыгындагы хәзинәләрен барларга тотындылар. Шул чактагы аптырауларымны күрсәгез! Хәтта сикереп торып, бот чабып көләр хәлгә җитештем. Апаемның ахирәте былтыр бер шулай тыңлаганымда күршесе Насыйбулла агайдан «түтүт күз» дип көлә иде. Моны ишеткәч, Насыйбулла агайның эштән кайтуын көчкә көтеп алып, үзен күрү белән «түтүт күз», «түтүт күз» дип ычкындырган идем. «Кем өйрәтте? Кем әйтте?» — дип җикеренде шунда бу миңа. «Кем әйткәнен әйтмим. Беләсең килсә

(үзем ялт итеп Бану апайлар ягына карап алдым!), уң як күршеңнән сора», — дидем. Насыйбулла агаем бурлаттай кызарды да куйды, күзләре шардай булды. Шунда аның күзләренең, чынлап та, автомобиль фараларыдай янып торганын шәйләдем. Нигә? Рас әйткәннәр. Исеменә күрә самай. Кыз дип, кызыл теленнән кыркылмаска әйбәт булыр моннан ары. Менә шул хәлләрдән соң Бану апайның әле килеп: «Ах, Насыйбулла!» — дип өнсез калуларының шаһиты булып ятсаң, аптырамас идеңме? Шаккатарлык бу! Җитмәсә, күзеннән әллә чын, әллә юри (мин үзем апайларымны җиңә алмасам йә сораган нәрсәмне ала алмасам, юри елыйм) яшь агыза. Минем апай да... куйсаңчы! Бер хатны биш укып уфтана, аннан Бану апайга: «Исле гөл»не җырлачы?!» — дип ялына.

...Сагынганда шуңа карыйм —
Ул синең төсле була...

Тапкан охшатыр нәрсә! Кешенең гөлгә охшый торганы бармы? Йә, шуннан, исәр димә боларны... Кайчак куркып китәм: әгәр бөтен кызлар да болар ише үскән саен тилерә торган булсалар, мине дә шундый ук киләчәк көтә түгелме? Юк, болар хәленә калганчы, мәңге шул килеш калырга риза булырсың, билләһи. Мин ул чакта, тегеләрне тыңлап та бетерми, урын ярыгына кысылган килеш, йоклап киткәнмен. Әле дә җиләстә изрәп, күзләремне кабат ачарга көч җитмәде...

— Нишләп ятасың монда, кызым?

Янымда гына ишетелгән тавышка сискәнеп, иләсмиләс булып торып утырдым. Каршымда чыбык-чабык күтәргән күрше карчыгы — Зөбәрҗәт инәй тора. Тамак кипкән, беләкләр оеган, баш та, тән дә авыр...

— Чирләп-фәлән киттеңме әллә, Зәлифә? — Зөбәрҗәт инәй, йөген җиргә куеп, яныма чүгәләде. — Тегеннән үк карап киләм. Елан-чаяннан курыкмый, кем баласы йоклап ята дим. Чынлап, сырхап тормыйсыңмы?

— Юк ла. — Мин күңелсез генә авыл ягына ияк кактым. — Бабадан качып ятам.

— ?!

— Әйе, кызлар сөннәтли торганы килгән.

Зөбәрҗәт инәй, арык гәүдәсен тоташ калтыратып, тешсез авызын яулык очы белән каплап, кычкырып көлеп җибәрде.

— Кем әйтте?

«Тычканга үлем, мәчегә көлке», — дип уйлап алдым эчтән.

— Көл-көлмә, килгән инде. Кәбирәнең туганын уже... — Мин кул гына селтәдем.

— Кит!.. Дөресен сөйлисеңме? Кем әйтте?

— Апаем! Сандугач апаем.

— Әниең беләме?

— Белергә... Күрше авылга сугырга биргән паласын алырга китте лә ул.

— Син ничек иярмәдең, койрык?

— Һе... Апаем кызлар чакырды ла минем! Аулак өйгә... (Монысы иң кызыгы, шуңа шым гына әйттем. Чәй мәҗлесендә биешү, уен-көлке булмый ул.)

— Шулаймыни? — Зөбәрҗәт инәйнең кысык күзләре хәйләкәр көлемсерәде. — Алайса, апаең алдаган сине.

— Ничек «алдаган»? Үзе...

— Шулай. Тоткан да алдаган. Җиткән кызлар, үзең беләсең, бүрәнәнең башы артык булганны яратмый. — Зөбәрҗәт инәй торып чыбык-чабыгын җилкәсенә салды: — Әйдә, кызым, кайтыйк. Бала кешегә кырда йокларга ярамый. Йә берәр чир йогар. Кызларны бабага утыртмыйлар ул. Апаеңның кызлары да күптән таралышты. Үзе бая ук Бану белән елга буена кер чайкарга төште. Әйдә, кызым...

Мин Зөбәрҗәт инәй артыннан ук кузгалмадым. Юк, әтием дә, әнием дә ихтирам иткән күрше инәйгә ышанмаудан түгел, киресенчә, Сандугач апаемның алдаганына ачуым килә. Бу тиклем юләргә калган юк иде әле! «Тукта, — дидем, тешемне кысып, — без дә ата баласы! Юк, апакаем, сине дә төп башына утыртмасаммы, тамагыңа кайнар пәрәмәч булып тормасаммы!» Хәзер үк, шушы минутта шаккатарлык итеп үч аласы килә апайдан. Дөнья эшен дөньялыкта кайтарган яхшы! Бәлки, Бану апай белән пыш-пыш килеп чиккән яулык-янчыкларын җәһәннәмгә олактырыргадыр? Сикереп торам. Әле алар кер чайкаган җиреннән тиз генә кайтмаслар. Керләрен куакка элеп, кипкәнен көтеп ятарлар. Гадәтләрен беләм дә инде. Шулай да... Туктап калдым. Олактыруын олактырырмын... әти белеп калса? Баштан да сыйпамаслар, рәхмәт тә әйтмәсләр. Болай да апаем читкә китәргә уйлагач «Сандугач балакаем» дип өзелеп торалар. Бер уйласаң, читкә китү дә начар түгел икән. Ни тексәләр дә, ни кузгатсалар да — апаеңа! Әллә миңа да тотарга да кайтмаскамы? Шушы уем тәүгесен шундук сүндерде.

Юл уртасында туктап калдым: яланаякларны туфрак пешерә, йөрәкне канмаган үч, хурлык көйдерә... Әйдә эзләсеннәр! Алдап, качарга мәҗбүр иткән сөекле кызларын тиргәсеннәр. Апаем да, мине табудан тәмам өметен өзеп, ник алдаган көненә төшеп, терсәген тешләрдәй булсын... Үз уйларымның шәплегенә хәйран булып, тезләрем калтырап, тузанлы юлга утырдым, аякларымны кочаклап, уйга калдым. Качуын качылыр, тик менә төнен урманда куркытмас микән? Шушы әрәмәлек эченнән аккан тар гына елгада ике кичү бар. Берсен — Озын Шүрәле, икенчесен Кыска Шүрәле диләр. Тикмәгә кушмаганнардыр мондый исемнәрне. Урманда ялгыз башың төн уздырганда каршыңа ереле-ваклы шүрәлеләр килеп басмас димә! Әллә инде сиздерми генә үзебезнең өй башына менеп, алам-салам арасында кунаклыйсы?.. Үземне ничек эзләгәннәрен, кемнең ничек кайгырганын да белеп ятылыр... Таң атуга, өйдәгеләр йокыда чакта, кире урманга кителер дә ахырдан килеп чыгылыр...

— Саумы, кызылбаш!

«Кызылбаш» — минем иң теңкәгә тигән урам кушаматы. Урам, диюем шул, өйдәгеләр миңа төрлечә эндәшә: чебеш, черәкәй, черек күкәй, койрык һ. б. Ә Кызылбаш диярга өйдәгеләрдән беркем батырчылык итми, хәтта абыем да. Ачу килмәслек тә түгел: бөтен авылда бер минем чәч адәмнекенә охшамаган. Бу сүзнең миңа ничегрәк тәэсир иткәнен белсә дә, бер Алла белә. Шуңа да, килүчене күрмәс элек үк «энәләремне тырпайтып», еш-еш тын ала башладым. Ә инде каршымда ят киемле таныш түгел агай күргәч, беразга аптырап тордым: бәй, чит кеше минем зәһәр кушаматны кайдан белеп алды икән?

— Нигә шаккаттың? Мин шулай куркынычмы әллә?

Ул тигез ак тешләрен күрсәтеп елмайды. Ныклап карагач, аңардан ерак түгел машина туктап торганын күрдем. Эчендә шофёры утыра. Үзләре дә, машиналары да безнең якныкына охшамаган. Башка чак булса, ят кешегә ихтирам йөзеннән битемә уч-уч булып салынып төшкән чәчләремне кулымның сырты белән булса да артка ташлар, рәтләр идем. Җиде ят алдында оятка каласы килми бит ул... Тик менә күрәләтә Кызылбаш дип торган бәндә алдында ни дип купшыланмак кирәк?

Чәч арасыннан гына тегеңә текәлдем: моңа миннән ни кирәк?

— Матуркай, әйт әле, Сандугач апаеңны белмисеңме?

— Белмәскә... Минем апай бит ул!

— Шулаймыни?! — Агай кеше шатлыгыннан чак кычкырып җибәрмәде, тавышы күкле-яшелле булып чыкты. — Алайса, мин аны авыл бетереп эзләдем, кая киткәнен берәү дә белми.

«Белмәве гаҗәп түгел, — дип уйлап алдым. — Менә «Кызылбаш»тан «Матуркай»га әйләнү гаҗәп. Үзеңә кирәккәндә сайрый беләсең болай. Тик «Кызылбаш»ны бу онытыр димә. Ул сүз өчен малай-шалай белән тиңсез алышка ташланган бар...»

Агай кеше, яныма чүгәләп, күзләремә карап (әле дә бәхет бар, күзләрне чәч каплаган), елмаерга итә:

— Бәлки, беләсеңдер, бәләкәй кеше барысын белеп-күреп тора бит ул.

«Баба белән куркытып башыңны урманга алып барып тыксалар белерсең, белми ни!» — Монысын да кычкырып әйтмәдем, эчтән генә уйладым.

— Нигә эндәшмисең? Телеңне йоттыңмы әллә?

«Әйе, йоттым, — дип уйладым. — Кайнар пәрәмәчкә кушып, сиңа да шундый бәхет язсын, Кызылбаш өчен».

Агай кеше әрсез адәм булып чыкты, ахрысы, һаман үҗәтләнә:

— Белсәң, әйдә, янына алып бар мине. Ерак булса, — ул машинага ымлады, — ат җигүле!

— Атың җигүле дә, аяк тышаулы.

— Ничек?

— Шулай. — Үзем «әле генә нәрсә дигәнеңне оныттыңмы?» дигән төсле тегеңә акаям. Каршыга башта ук исем тагып, кара ягып кил дә ахырдан ялынып утыр. Әкәмәт адәм...

— Алай булгач, туганым, кайда икәнен әйт кенә син, әйт кенә?!

Ваемсыз бер кыяфәттә учыма вак таш чүпләп алып күккә чөйдем.

— Ансат... Белсәм дә әйтмим. Сиңа кирәк бит ул, үзең тап.

Агай кеше каршыма чүгәләде. Ул да кулына вак таш алган булды. Шунда гына мин аның йөзенә игътибар иттем: кәкре борынлы, кара-кучкыл йөзле, борын астында, бармак уемы җирдә, мыек ишарәсе бар. Тапкан үстерер урын! Үзебезнең борын асты еш кына пөхтәлек белән мактанырлык булмаса да, яхшыдан шакшыны аера беләбез азрак. Ә менә күзләре — ачык яшел төстәге киң ачылган күзләре җәлләтә. Баштук Кызылбаш дип ычкындырмаса, әллә...

— Йә, әйт инде. Ни сорасаң, шул алдында булыр. Беләсеңме, хәзер үк магазиннан бер итәк кәгазьле кәнфит алып бирәм үзеңә? — Монысы нәкъ тә теге «Әйтче, дустым, кәнфит бирәм, апаең кемгә бара?» дигән кәмит такмактагы сымак яңгырады. Кәнфит әйбәт нәрсә инде ул, сүз дә юк. Шулай да нәфсене тыя беләбез. Тәм-том дип болай да чамалы абруйны юкка чыгарып булмый да инде!.. Шуңа күрә дә, исем китмәгән бер кыяфәттә:

— Кәнфит ашаган ба-ар, — дип суздым.

— Алайса, купшы күлмәк алып бирәм, кирәкме?

Мин апаемның кечерәйгән күлмәген бозып тегелгән кыска итәгемне тарткалаштырып куйдым:

— Өйдә күлмәк — бер сандык.

Агай кеше тагы, иелеп, минем күзгә карап күрсенде. Үзе көлгән була:

— Кара әле, кызыкай, нигә әйтергә теләмисең? Мин карак, угры түгел.

— Шулай да бик үк тугры түгел, — дип җаваплардым, тегеңә тишәрдәй итеп карап. Чи надан түгел икәнне белсен, әкият ишене кышкы төннәрдә әти белән ишәбез генә...

— Юк, чын, апаеңны урлап алып китмәм. Аңа бик ашыгыч сүзем бар... Апаең кая эшкә китә?

— Белмим, — бер ташым агайның борын очын тырнап ук очты, — эшли торган җирен әти белән барып күреп килде. Е-ра-а-ак, ди.

— Менә бит, — агай ашыгып арлы-бирле йөрештереп алды, — еракка китә, дисең, күрергә иде бит үзен. Юлым бик ашыгыч. Хәрби кеше мин. Бу якларга инде тиз генә килә алмам...

«Сүзеңә куәт» дигәндәй, машина кычкыртты. Агай ялт итеп борылып карады. «Хәзер, хәзер!» дигәнне аңлатып, кул болгады.

— Әйт инде, туганым. Киләсе ел үзеңне калага алып барырмын, матур бакчаларга алып йөрермен.

Болай ялынгач, апаемның бер бик кадерле кешесе — сере шулдыр әле, дип уйлап алдым. Апаемны хәтерләү «кызлар бабасы» вакыйгасын да кылт итеп искә төшерде, күңел рәнҗүләремне өр-яңадан яңартты.

— Йә инде, туганым, әйт инде?! — Ят агайның тавышында чиксез ялвару чагылды.

— Нәрсәне?

— Соң, апаеңны?

— Әйтмим, дидем бит.

– Ни-гә-ә?

– Тик!

Агай, капыл омтылып, кып-кызыл ялкын булып битемне каплаган чәч көлтәләремне сыпырып, күземә карады:

– Гомер буе рәхмәт әйтермен үзеңә, яхшылыгыңны мәңге онытмам. Бары ике авыз сүз әйтергә кирәк аңа, бары ике авыз...

Бер минутка икеләнеп-каушап калдым. Әйтсәм, монысын да, тегесен дә җиңел генә гафу иттем дигән сүз. Моннан соң эте дә, бете дә мине «Кызылбаш» дип кимсетер, «баба» белән өркетер.

– Юк, әйтмим.

– Аһ! – Агай кеше, кулларын тезенә шапылдатып, капыл җиргә чүгәләде. – Ни тиклем тискәрелек! Кайсы җиреңә сыя диген... – Ул, гәүдәмне аркылыга-буйга үлчәгәндәй, үтәли тишеп карады. – Соңгы тапкыр үтенәм: әйтәсеңме, юкмы?

Мине ниндидер тупас, битараф һәм гамьсез тойгы биләп алды. Үземнең искиткеч арыганымны, ачыкканымны тойдым шунда. Нигә бөтенесе бергә җәһәннәмнең үзенә олакмый? Инде бернәрсә дә уйламыйм, иреннәр генә үзләреннән-үзләре:

– Юк, юк, юк, юк, юк... – дип кыймылдый.

«Би-ип! Би-и-ип!» – Агай кеше, күзләреннән ачулы очкыннар чәчеп, кулындагы ташларны атып бәрде:

– Каһәр генә төшсен сиңа. Кадал, күземнән югал!..

Шуны гына көткәндәй, бөтен көчкә авылга атылдым, аяк астындагы очлы ташның ялантәпиләргә аяусыз кадалуы да туктата алмый.

– Тукта! Китмә! – Көчле тавыш мине каерылып карарга мәҗбүр итте. – Әйт апаеңа: исле гөлне сулдырмасын! Зинһар, әйт, сулдырмасын!

Машина китте, артында тузан бураны гына уйнап калды. Мин кинәт хәлсезләнеп җиргә чүгәләдем, аннан, юлга сузылып ятып, сулкылдап елап җибәрдем, ахмакка калу, үч алу, ахыр килеп, жәлләү һәм үкенү тойгылары күз яше булып битем буйлап актылар да, тузанлы юлга төшеп, кара борчак булып төергә әйләнделәр. Шушы минутта Җир шарында миннән дә бәхетсез, миннән дә юньсез, миннән дә көчсез кеше бар идеме икән?!

– Кем булды ул? Кем белән сөйләшә идең?

Туфрак белән яшькә буялган йөземне күтәреп карасам, миңа түгел, кызгылт тузан өермәсе калдырып күздән

югалган машина юлына карап, Сандугач апаем тора. Теләр-теләмәс кенә урынымнан тордым. Минем кайгы һаман төштән соң икән әле — апаем күбенгән йөземә күз дә төшермәде. Әле генә үз-үземне йолкыр чиккә җитеп үкенсәм дә, апаемның миңа карата битараф булуы яңадан отыры ярсытты: кешене көнозын интектерүе җитмәгән, җәлли дә белми бит, ичмасам!..

— Сиңа әйтәм, кем ул?

— Шофёр. Юл сораша.

— Өйрәттеңме? Әйттеңме соң? — Күренеп тора: бер юлаучы миңа караганда мең тапкыр кадерлерәк.

— Әйттем. Әйтми ни...

Апаем, күзен юлдан аермыйча, иреннәрен кыймылдата:

— Нәрсә диден? Нәрсә диден әле?..

— Урманга кызлар бабасы килгән, ипле генә йөре, дидем.

Әйттем дә оныттым, һәр яңа көн өр-яңа куанычлары, үкенечләре һәм язык-казыклары белән килгәндә, бер урында таптанып, тик бер нәрсәне уйлап йөреп буламы икән? Җитмәсә, Сандугач апаем да тәгаенләнгән җиренә эшкә китте. Кәкре борынлы хәрби егет шул гомер эчендә тик бер тапкыр гына үзен хәтерләргә мәҗбүр итте.

Машина безнең өй янына туктаганда, әтием белән өйтүр бакчада рәшәткә төзәтеп, мәш килеп йөри идек. Машинаны таныгач, песи җитезлеге белән койма аша урамга сикердем. Нигә? Теге хәлне агай кеше онытмаган булса? Ул чагында әтиемнең киң аркасы да саклап кала алмас. Әлбәттә, ул чактан бирле тоташ бер көз, бер кыш, бер яз үтте. Тагы бер җәй инде көзгә авыша. Шулай да дөнья хәлен белеп булмый... Койма ярыгыннан тегеләрне күзәтәм: агай кеше һич тә үзгәрмәгән, шул киемнән. Менә ул киң атлап әтием каршына килеп басты, күреште. Күңеле көрдер, йөзе якты күренә. Нидер әйтте. Әтием җавап кайтарды. Агай кешенең капыл төсе бозылды, таянырга терәк эзләгәндәй, тирә-ягына каранды. Әтием тагын нидер әйтте. Ят агай, ашыгыч кына хушлашып, кабинага кереп утырды.

Куркыныч бетте. Иркен тын алып кире урамга чыкканда, машинадан җилләр искән иде...

Әтием шул якка озак кына карап торды.

— Да-а-а... — Нигәдер тирән көрсенде.

Безнең янга, биләүдәге курчактай кызын күтәреп, кунакка кайткан Сандугач апаем чыкты. Ул да кара-

шын машина киткән якка төбәгән, тик теге чакта миннән төпченгәндәге сымак «Кем ул, кем булды?» дип төпченмәде. Әтием, ул сорамаса да, читкә карап кына:

— Читтән килгән кешеләр. Юл өйрәтеп җибәрдем, — дип мыгырдады.

Сандугач апаемның киң ачылган ачык соры күзләрендә көз илчесе — сары яфраклар шәүләсе уйный. Миңа калса, дөньяда аннан да бәхетле кеше юк кебек: ни дисәң дә, аның бәләкәч кенә, алсу гына кызы бар. Нәкъ җанлы курчак! Шушы бәби аркасында үземнең дә абруй күтәрелеп китүен сөйләп тә тормыйм. Сабыйның булган һәм булмаган кыланышларын сөйләгәндә, безнең урам кызлары авызыма карап шаккаталар, кабатлап күрсәтүемне үтенәләр. Анысы инде һәркемгә тәтеми, кемгә күрсәтәм, кемгә юк — форсат минем кулда. Ә теге хәрби кешене мин тагы шундук оныттым...

Офык аллана, алара да башлады — җәйге кыска төн үтеп тә киткән икән. Әмма яңа көн килүе бүген мине куандырмый. Әйтелмәгән сәлам — тапшырылмаган әманәт яткан бит йөрәктә! Апаемның тынлык, чәчкәләр һәм башаклар исе тулы, җанны-тәнне тоташ сафландырыр, иркәләр төндә китек күңел белән гармун моңы тыңлавына мин, минем бала чактагы әнә шул гамьсезлегем сәбәп булмады микән? Шулай булса, төзәтә алмаслык хата — язмыш-ялгыш ясаганмын түгелме? Бәлки, соңлап булса да шул сәламне тапшырырга, сүнгән учак төбендә җемелдәгән кечкенә кузга җан өөргәдер? Әллә дәшмәү хәерле булырмы? Бетәшкән, тик җөе калган яраны нигә кабат ярсытырга?! Бала чактагы шикелле үкенечләремне тузанлы юлга кара борчак итеп сибеп кенә бетерә дә, җәзадан койма артына посып котыла да алмыйм. Вакыты да башка, үзем дә бүтән. Хаталар да, яра-җәзалар да үзем белән...

Кабаттан төпсез гөмбәз — күккә багам. Анда йолдызлар күпкә сирәгәйгән. Иң яктылары гына калган. Күрәсең, таң каршылау бәхете бәгъзеләренә генә, иң яктыларына язгандыр. Ә андыйлары, төнне көнгә ялгаганнары сирәк, бик сирәк. Кеше дә бит шулай: истәлекләрнең иң изгеләрен йә иң үкенечлеләрен генә гомер ахырынача саклый.

...Тәрәзә төбендә исле гөл. Ул таң каршылый.

ТУГАЙ ТУЛЫ БӘПЕМБӘ*

Әтием Гыйбадулла улы Хизбулла Мөхәммәтколовның якты рухына багышлыйм.

Аяк очымда өсләренә ак халат, кулларына перчатка кигән бер агай һәм ике апай тора. Барысының да йөзләре җитди. Күзләрен генә калдырып, авыз-борыннарына маска кигәннәр. Сөйләшмиләр, тик күзләре белән генә аңлашалар.

Баш очымда торган апайның, киресенчә, сөйләшеп сүзе бетми. Ничәнче класста, ничек укуымнан алып, нәсел-нәсәбемә тиклем төпченә.

Аның сүзчәнлеге миңа җан өргәндәй, хәлнең мөшкеллеге дә онытыла төшә:

— Апай, верандада утырган теге дәү гөлнең исеме ничек ул?

— Бәй, әллә син аны тәү тапкыр күрәсеңме?

Күз алдыма авыл өйләренең тәрәзә төпләрендә үскән яран, тамчы, исле гөлләр килә:

— Юк, мондыен һич очратканым булмады.

Шулчак хирург агайның кашлары язылып китә, күзләреннән җылы нур бөркелә:

— Бүген мин ул гөлдә бер бөре күрдем әле. Син савыгуга, ул, мөгаен, чәчкә атар.

...Эч сызылып авырта, йөрәк суырылып килә. Сикереп торып, хирург агайның кулларыннан тотсам, бу газаплар бетәр сыман. Ләкин ни дә булса эшләргә өлгермим, йокы баса, тән авырая башлый. Тиздән хирург агайлар да, сестралар да, миннән ераклаша барып, ак томан эченә кереп югала...

Берчак дөнья яктырып, кояш кыздырып җибәргән төсле булып китә. Үземне хәтфә тугайда икәнмен дип хис итәм. Күз алдымда тузганак-йолдызчыклар чуарлана. Яныма кызлар җыелып килгән. Алар берөзлексез:

Бәпем, бәпем, бәпембә,
Тугай агай — бәпембә... —

дип такмаклаган уңайга, тузганаклар бөдрә чәчле сары башларын горур күтәреп үрлиләр, үсәләр. Шундый

---

* Бәпембә — тузганак.

нечкәләр, шундый иркәләр — куллар ирексездән йомшак, нәфис сабакларга үреләә... Бераздан тугайда бер бөртек тә тузганак калмый.

Итәкләренә тузганак тутырып алган кызлар, ялантәпиләрен ялтыратып, узышып, авылга таба йөгерә:

— Әти! Бәпембә! Кара әле, күпме бәпембә!..

Әтием, тузганакларны күрергә тырышып, без килгән якка, тугайга карый.

— Юу-ук, анда бетте инде, менә монда алар!

Мин итәгемдәге чәчкәләрне нигез буена сибеп җибәрәм.

— Аһ, нишләдең син, кызым?!

Тузганак дип өзгәннәрем әле генә йомыркадан чыккан сары түшле каз бәбкәләре, имеш. Алар, нәзек алсу тәпиләрен кызганыч тырпайтып, үлеп беткәннәр.

— Кош каргышын алгансың, балам...

— Бәпембә дип өзгән идем...

— Яме барның җаны да бар, кызым!

...Күпме вакыт үткәнен дә, үзем белән ни булганын да хәтерләмим. Бәләкәй генә бүлмәдә берьялгызым ятам. Урам якка бер тәрәзә карый. Урам якка дию ем шул, машиналарның гүләп үткәне ап-ачык ишетелеп тора. Бүлмәнең ишеге ачык, ләкин аннан яктылык төшми. Нигә ул кап-караңгы булып ыржаеп тора? Күрәсең, мин яткан бүлмәгә ниндидер тәрәзәсез бүлмә аша үтә торганнардыр. Сәер, бик сәер. Шушы үзем яткан кечкенә бүлмәне дә, теге караңгысын да кайчандыр күргәнем бар иде түгелме?

Шулчак теге караңгы бүлмәгә яктылык бәреп керә — ишектә озын буйлы, ак халатлы агай күренә. Күзләре бик тә таныш, тик менә...

— Хәлең ничек, сеңлем? Чәчкә күрергә чыгабызмы инде?

Шунда мин бөтенесен дә төшендем. Торырга талпынам, ләкин доктор түшемә кулын салып өлгерә:

— Әлегә сиңа торырга ярамый. Аягыңа баскач, верандага сине үзем алып чыгармын, яме?

Нинди йомшак, ягымлы тавыш, нинди илаһи йөз! Мин аның озын, нечкә бармакларына карыйм, чигәләремне кайнар яшьләр өтә, рәхмәт яшьләре...

Тагы берүзем калам. Башта һаман бер уй: кайда күрдем соң шушы караңгы палатаны, кайда, кайда... Кинәт колагыма әниемнең боек тавышы чалынып киткәндәй була: «Әтиең бәләкәй генә караңгы бүлмәдә җан бир-

де. Район үзәгенә операциягә алып барырга машина юк, диделәр. Ни хәл итәсең инде, тәкъдиренә шулай язылгач. Сугыштан кайткач, бары тугыз ел яшәп калдык. Исән-сау кайтуының куанычы булып син дөньяга килдең. Ир баладай нык-таза булып үссен, диде. Алтыда атка атландырды, тик менә өзәңгене өзә басар чагыңны күрә алмады...»

Чигәләр уттай көйрәп яна башлый, зиһен тарала, баш шаулый, әйтерсең лә урамнан машиналар өзлексез улап, үкереп уза. Машина булмаган... Менә бит алар күпме?

Машиналар үтеп бетүгә, алар калдырып киткән тузан-томан эченнән ярсыган атлар килеп чыга. Тук-тук, дөп-дөп! Тояклар астында җир селкенә, ат җиле аяктан ега...

Торчы, кызым, атлан атка,
Иярле ат янәшәңдә –
Җирдә ятма!

Әтиемнең тавышын ишетеп, сикереп торам, аның солдат киемендә икәнен күргәч, атлылар киткән якка ымлап:

– Сугышмы әллә? – дип пышылдыйм.

– Сугыш түгел, кызым, Сабантуй!

Әтием мине күтәреп өзәңгегә бастыра, хуҗасы кулын селтәүгә, җирән айгыр сикереп чаба башлый. Тәннән салкын тирләр бәреп чыга – мин чытырдап атның ялына ябышам:

– Курка-а-а-ам, атай!

Үз тавышыма үзем сискәнеп уянуга, каршымда әниемнең борчулы йөзен күрәм.

– Куркыныч төш күрдеңме әллә, балам?

– Әтием бит шушында...

– Юкны уйлама, тынычлан.

– Машиналар йөреп тора, ә докторлар шундый әйбәтләр...

– Кешеләр төрле була, кызым. Доктор да бит адәм затыннан.

...Кешеләр төрле була. Өстенә бүрәнә авып барган иптәшен коткарам дип, үзенә үзе әҗәл чакырганда, әтием бу турыда уйладымы икән? Бәлки, бер-берсенең гомеренә үз гомерен ялгаган кешеләргә әҗәлләрдән дәва юктыр? Шулай булмаса, мондый зур җирдә машина табылмас идеме әллә, берсе-бер ярдәм кулын сузмас идеме?

Тагы кыза башладым, эчәсе килә. Су сорыйм дисәм, тавыш чыкмый. Әллә хәл бетә, әллә йокы баса. Үземне түшәккә сеңгәндәй хис итәм.

Кемдер башыма кулын сала, беләгемнән тотып тора:

– Тагын аңын җуйган. Пульс начар. Операция уңышлы үтте – анысына иманым камил. Тәвәккәлләвемә үкенмим. Шунысы гаҗәп: нәрсә борчый аны? Нигә ул туктаусыз атасы белән саташа?

– Әгәр ул-бу хәл була калса, Рәхимҗан Фазылович, җавапны сез бирәсез. Онытмагыз: операция минем рөхсәттән тыш ясалды. Кем белә, болай бераз яшәр дә иде әле...

– Ә мин аның бераз түгел, озак яшәвен теләдем, Хәснә Талиповна.

Хәснә Талиповна! Тукта, димәк... Инде мин боларның ни сөйләшкәннәрен дә аңлый алмыйм, системага яңа шешә куйганнары ишетелә. Нәзек кенә көпшә аша йөрәккә үтә күренмәле сыеклык ага: тып, тып... Тып, тып.

...Кара көзнең озын төне. Төньяктан искән ачулы җил, үз тәкерегенә үзе чәчи-чәчи, караңгы тәрәзәләрне камчылый. Салкын яңгыр тәрәзә яңагы ярыгыннан үтә дә тып-тып идәнгә тама...

– Әни?

– Йокламыйсыңмыни әле?

– Әни, ә нишләп әтиемә операция ясамадылар? Янында врач булды дисең дә...

– Ул операция ясый торганы түгел иде.

– Ә нинди ләре ясый аны?

– Әй, балакай, куй инде. Көне буе ярдәм көтеп, тилмереп ятты мескенкәй. Үзе һаман сезне кайгыртты, кайту белән ике капчык бодайны тегерменгә җибәрергә кушты. Кич хәле авырая башлады. Машина табарга куштылар. Таныш булмаган җирдә кая бара беләсең? Әлеге шикелле коеп яңгыр ява иде. Унлап өйнең капкасын шакыдым, тик бушка гына. Төнге икедә җан да бирде.

– Кем иде ул врач? Исеме ничек иде?!

– Хәснә. Талиповна... Баш врач. Күпләр карап торып үтергәннәре өчен хөкемгә тарттырырга куштылар. Мин әлегә аядым. Тере кеше тереклек итсен, дидем...

– Инде шулай әтиемне бер дә күрмәм микән?!

Тышта тынычлыгын югалткан җил үкси, кара чикмән бөркәнгән дөньяны ачы яшькә манчый...

Иртәгесен әнием мине иртүк өйдән алып чыга. Кая баруыбызны әйтми, мин дә сорамыйм. Авылны чыккач,

төсе качкан иреннәрен ныгытып кысып, зиратка юнәлә. Каберлекнең капкасы төбендә, үтәргәме-юкмы дигәндәй, икеләнеп, каушап калам.

— Үт, балам, үт. Туудан калмаганны, үлемнән калмассың. Һәммәбезгә дә берчак килеп шушында ятасы. Күпләрнең туфрагы читтә язды. Илаһым шуны күрсәтмәсен...

Туфрагы басылып өлгермәгән, кәсләнеп, ярмаланып яткан озынча кабер янында туктыйбыз. Зиһенем бер томалана, бер яктыра: мине һавага чөяр көчле куллар; хикмәтле әкиятләре белән сихерләгән ягымлы тавыш; икмәк, кыр, үлән исе аңкыган җылы куен; яланнардан кайткан чук-чук, тәлгәш-тәлгәш җиләк-күчтәнәчләр; тегер-тегер тәгәрәгән тәгәрмәчләрдә тирбәлә-тирбәлә, алдына башым салган килеш аның Ирәндек тауларыдай озын, югары, ялан һавасыдай иркен, назлы җырларын тыңлап барулар — берсе дә кабат булмаячак. Аларның бөтенесен дә менә шушы чем-кара туфрак баскан. Әнием, бер уч дымлы туфрак алып, күкрәгемә баса — җаныма кабер салкынлыгы үткәреп, кайгымны басарга, оныттырырга итә, күрәсең...

Онытырга. Аны онытып буламыни?! Авырган чакларымда әтиемнең кытыршы учын маңгаемда тою, аның төк баскан йөзен, күлдәй төпсез күзләрен күрү генә дә миңа әллә күпме көч бирә иде...

Кемдер маңгаема учын куя, каты бармаклары белән чигәләремне өткән яшьләрне сөртеп ала. «Әти, әти куллары...» Шул куллар сыйпаган җиргә тып итеп бер тамчы тама:

— Хәснә Талиповна! Ул елый, ул исенә килде!

Хәснә Талиповна! Тагы... Шулчак мин, күңелемне ун ел буе бимазалаган сүзләрне әйтеп калырга дип, тырышып-тырмашып күзләремне ачам. Үзенә төбәлгән карашны сизепме, әллә Рәхимҗан Фазылович эндәшкәнгәме, ак халатлы, калын гәүдәле хатын миңа табан борыла. Шулчак мин ап-ак халатның түш кесәсендә янып торган куш уч зурлык чәчкә күрәм. Теге чәчкә!

...Әйтер сүзләрем таш булып тамагыма утыра, иреннәремне көйдереп, «Баш врач, чәчкәне нигә өздегез?!» дигән пышылдау чыга.

Кып-кызыл чәчкәдән кандай сандал яшьләр тама. Бар дөнья кызылга манчыла...

Шул хәлдән соң урынымны алмаштырдылар. Бу бүлмә яктырак та, иркенрәк тә иде. Янда кешеләр дә бар.

Көн дә иртән Рәхимҗан Фазыловичның палатага килеп кергәнен, чем-кара күзләрен балкытып, «Хәлләр ничек?» дип сораганын көтеп алам. Менә берчак хастаханә белән хушлашыр көн дә җитте.

Әнием белән җитәкләшеп, хастаханә болдырында торабыз.

— Күз нурым, гөлемне коткардың, рәхмәт сиңа, доктор!

Безне озата чыккан яшь табиб Рәхимҗан Фазыловичның йөзе уйчан, боек. Ул нигәдер миннән күзләрен яшерә... Икебез дә читкә карыйбыз һәм... чәчкәсе өзелгән ботакның ятимсерәп, боегып, тәрәзәгә төбәлгәнен күрәбез.

Йомшак кына куллар башымны югары күтәрә.

Күзләр... Айсыз төндәй төпсез, уйчан күзләр. Мин бу күзләрне еллар аша да күрәм. Аларда үземә югалту һәм сагышлар аша килгән олы бер хакыйкать укыйм: «Матурлык яклауга мохтаҗ. Ямьгә битараф кешеләр кеше язмышына да ваемсыз була...»

* * *

Бәпем, бәпем, бәпембә,
Тугай агай — бәпембә...

Тузганаклар үскән тугайда тузганак башлы ике улым куышып йөри. Ачык сары чәчләрендә, көләч йөзләрендә кояш уйный:

Бәпем, бәпем, бәпембә,
Тугай тулы бәпембә!

ЭЧТӘЛЕК

Мөгри-мөгри килә Бөйрәкәй (*Роман*) 5
Илекәй (*Повесть*) 147

Хикәяләр
Асыл ташлы муенса 220
Кызыл башмаклар 229
Умырзая гөлнең гомеркәе 246
Айлы төн 265
Ялгыз бөркет күктә бөтерелә 272
Бал дип үрелгәнем... 297
Исле гөл 301
Тугай тулы бәпембә 314

Литературно-художественное издание

Гарипова Танчулпан Хизбулловна

ОЖЕРЕЛЬЕ ИЗ ДРАГОЦЕННЫХ КАМНЕЙ

Казань. Татарское книжное издательство. 2015

Перевод с башкирского на татарский язык

Әдәби-нәфис басма

Гарипова Таңчулпан Хизбулла кызы

АСЫЛ ТАШЛЫ МУЕНСА

16+ Знак информационной продукции
согласно ФЗ от 29.12.2010 г. № 436—ФЗ

Мөхәррире *Л. Ә. Гыйззәтуллина.* Рәссамы һәм бизәлеш мөхәррире *М. Д. Вазиева.* Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучысы *Ф. Р. Гыйсмәтуллина.* Корректоры *Л. Р. Галимова.* Оригинал-макеттан басарга кул куелды 23.06.2015. Форматы 84×108 ¹/₃₂. Шартлы басма табагы 16,8. Тиражы 2000 д. Заказ О-1799. «Татарстан китап нәшрияты» ДУП. 420111. Казан, Бауман урамы, 19. Тел./факс: (843) 519-45-22. http://tatkniga.ru e-mail: info@tatkniga.ru. «Татмедиа» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы. 420066. Казан, Декабристлар урамы, 2.

60,00

ПРОШ
07 СЕН 2016
Подпись

9 785298 029032